ISSN 0206–4189
Индекс 73210 12+

# КАЗАН УТЛАРЫ

5.2013



# Татарстан Республикасы Президенты
# УКАЗЫ

## *2013 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен бирү турында*

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен карап, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре комиссиясе тәкъдимнәрен кабул итәргә һәм 2013 елда, чыгарма буларак, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге биш Дәүләт бүләген бирергә.

2. Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләрен түбәндәгеләргә бирергә:

1) **Айдаров Ильяс Сәйяр улына** — Г.Тукайга багышланган сәнгать әсәрләре циклы (2005-2012 еллар), Уральск һәм Казан шәһәрләрендәге Г.Тукай музейларында тематик күргәзмәләре өчен;

2) **Бикчурова Нәбирә Миңнәхмәт кызына** (Нәбирә Гыйматдиновага) — «Мәхәббәттә гөнаһ бар» (Татарстан китап нәшрияты, 2008 ел), «Синдә минем хакым бар» (Татарстан китап нәшрияты, 2011 ел) китаплары, «Хатыннар сагышы» (Казан, «Идел-Пресс», 2010 ел) әсәре өчен;

3) **Гайнуллина Алсу Әскәр кызына** — сәхнәдә Г.Хугаевның «Кара чикмән» спектаклендә Буретта, М.Гыйлаҗевнын, Р.Хәмиднен «Курчак туе» спектаклендә Наташа, З.Зәйнуллинның «Арбалы хатыннар» спектаклендә Гайшә образларын иҗат итүе өчен;

4) **Кузьминых София Даниловнага** — Г.Тукай истәлегенә багышланган, күн мозаика техникасын кулланып башкарылган әсәрләр циклы өчен;

5) **Тимербулатов Шамил Харис улына** — «Женский лик Победы» бишенче симфониясе өчен.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә.

3. Әлеге Указ ана кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н.МИҢНЕХАНОВ**

*Казан, Кремль*
*2013 ел, 25 апрель № ПУ-352*

# Казан утлары
# Qazan utlari

2013

5
(1087)

*ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ:*
*«ТАТМЕДИА»*
*ачык акционерлык җәмгыяте*

*БАШ МӨХӘРРИР*
**Равил Габдрахман улы**
**Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Рабит Батулла**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Рәдиф Гаташ**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Айрат Сибагатуллин**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Марат Закир, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Флера Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
*Баш мөхәррир — 562-10-62.*
*Баш мөхәррир урынбасары — 562-10-38.*
*Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге — 562-11-28.*
*Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге — 562-11-53.*
*Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге — 562-11-53.*
*Гамәли хезмәткәрләр — 562-11-28.*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80.*
**Факс** — (843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

**ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР**

Айдар ХӘЛИМ. Чын жинүче кем? *Хикәя.* ....5
Сания ӘХМӘТҖАНОВА. Арча капкасы. *Шигырьләр.* ....37
Рәис САФИН. Садыйкның уянуы. *Бәян.* ....41
Әмир МӘХМҮДОВ. Эзлим дөнья тоткасын. *Шигырьләр.* ....56
Марат ӘМИРХАНОВ. Ир-мамай. *Тарихи бәян.* ....59
Чыңгыз МУСИН. Дөнья иркен — җанда кысанлык. *Шигырьләр.* ....122

**ПУБЛИЦИСТИКА**

Рәис ЗАРИПОВ. Онытылган «Алтын Йолдыз» ияләре. ....128
Нурихан ФӘТТАХ. Балтач районында китап сәүдәсенең торышы. ....132
Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ. Сездә ничек, бездә шулай саталар китапларны. ....136

**ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ**

Фәрит ЯХИН. Шигъри рух тантанасы. ....141

**ФӘН**

Гамир ГАРИФУЛЛИН. Тарих мәйданында сәлҗүк төркиләре. *Фәнни-популяр очерк.* ....148
Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ....163

**ХӘТЕР**

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ. Кырым татарлары фаҗигасе. ....166

«Татар энциклопедиясе» битләреннән. ....175

**КИТАП КҮЗӘТҮ**

Гомәр ДАУТОВ. «Йозак» ачкычы. ....178

**ЮБИЛЕЙЛАР**

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Бәхетсез почмакның иясе. *(Зариф Бәширинең тууына 125 ел)* ....181
Рәйсә МУСАБӘКОВА. Олуг галимне искә алып... *(Абдулла Сайгановның тууына 100 ел)* ....185
Нәҗип Думавиның тууына 130 ел. ....187
Гариф Галиевнең тууына 110 ел. ....188
Мөхәммәт Садриның тууына 100 ел. ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....126
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....191

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: рассказ А.ХАЛИМА «Кто истинный победитель?»; повесть Р.САФИНА «Пробуждение Садыка»; историческая повесть М.АМИРХАНОВА «Мамай»; стихи С.АХМЕТЗЯНОВОЙ, А.МАХМУДОВА, Ч.МУСИНА.

«Публицистика»: Р.ЗАРИПОВ. «Забытые Герои»; Н.ФАТТАХ. «Книготорговля в Балтасинском районе», Р.ШАРАФИЕВ. «А теперь дело обстоит так...».

«Литературная критика»: статья Ф.ЯХИНА о творчестве К.СИБГАТУЛЛИНА и Н.АКМАЛА.

«Наука»: Г.ГАРИФУЛЛИН. «Сельджуки-тюрки в истории»; Ф.ГАРИПОВА. «История наших деревень».

Страницы из «Татарской энциклопедии».

«Память»: Х.ИСМАГИЛОВ. «Трагедия крымских татар».

«Книжное обозрение»: Г.ДАУТОВ. «Ключ к книге «Замок».

«Наши юбиляры»: статьи Р.ЗАЙДУЛЛЫ, посвященная 125-летию со дня рождения З.БАШИРИ и Р.МУСАБЕКОВОЙ, посвященная 100-летию со дня рождения А.САЙГАНОВА.

Из фотоархива журнала.

Дневник общественно-культурной жизни.

На наших обложках: «Парк победы в городе Казани»; писатели из Альметьевского края.

## IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*

«Prose and Poetry»: story by A.HALIM «Who is true winner?»; story by R.SAFIN «Awakening of Sadyk»; historical story by M.AMIRKHANOV «Mamay»; verses by S.AHMETZYANOVA, A.MAHMUDOV, CH.MUSIN.

«Publicism»: R.ZARIPOV. «Forgotten Heroes»; N.FATTAH. «Book selling in Baltasy district», R.SHARAFIEV. «This is the case now».

«Literary criticism»: article by F.YAHIN about creativity of K.SIBGATULLIN and N.AKMAL.

«Science»: G.GARIFULLIN. «Seljuk-Turks in history»; F.GARIPOVA. «History of our villages».

Pages from «Tatar encyclopedia».

«Memory»: H.ISMAGUILOV. «Tragedy of Crimean Tatars».

«Book review»: G.DAUTOV. «Key to the book «Lock».

«Our hero of the anniversary: articles by R.ZAYDULLA dedicated to 125th anniversary of Z.BASHIRA and R.MUSABEKOVA dedicated to 100th anniversary of A.SAYGANOV.

From photo-archived of magazine.

Diary of social-cultural life.

On our covers: «Victory park in Kazan city»; writers from Almetyevsk.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә жыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 30.04.2013, график буенча 30.04.2013.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ С-1024. Тираж 4016.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча Федераль хезмәтендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

«ПИК «Идел-Пресс» ААЖ «ТАТМЕДИА» филиалы типографиясендә басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2013 ел.



Айдар Хәлим

# ЧЫН ҖИҢҮЧЕ КЕМ?

ХИКӘЯ

*Көрәштәшем Сәид Хәнәфи улы Еникеев исталегенә багышлыйм*

## I

Төнлә белән йөрәге чәнчеп уянды Тәлгат. Бер сәбәпсез аны кайчандыр кем алдындадыр үзе кылган, әмма дә ләкин әле булса кичерелмәгән гөнаһ тойгысы биләп алды. Аңа эссе булып китте, аягы белән өстендәге юрганын тибеп очырды.Каян килер бу әрнүле үкенеч? Бер караганда,тормышы ярыйсы гына алга тәгәри, ашарга ризыгы бар, хатыны, бала-чагалары исән-сау, китапларын дәүләт исәбенә чыгарырга ашкынып тормасалар да, хәзер, имеш, цензура бетерелгәч, аның үз өлешенә төшкән кысым, цензура бетерелмәсә дә, — кайчагында чыккан китапларын саткалап, тегеннән өч, моннан биш тиен сорап, аларын да чыгаргалаштырган була. Ул туганнарын, дусларын, таныш-белешләрен, хәтта илле ел элек чыгып киткән авылын, авылдашларын, инде дистә еллар элек дөнья белән хушлашкан, инде каберләрен генә түгел, хәтта ишек алларын да үлән басып киткән күрше-күләннәрен берәмтекләп күз алдына бастыра, алар алдында исәп-хисап тота башлады. Шулчак ул дерт итеп куйды: тукта әле, тукта, иптәшкәем, быел нинди, ничәнче ел соң әле? Нәрсә турында көне-төне сүз куерткан була Рәсәйнең телевидение каналлары? Әйе-әйе, җиңүнең, алар теле белән әйткәндә, Бөек Җиңүебезнең 65 еллыгы бит!.. Чынлап та шулай!..

Үзен төртеп уяткандай уяткан сәбәпнең очына чыга башлавын сизенгән карт язучы, кәефе килеп, сул ягы — йөрәге тарафына борылып ятты һәм, өшегәндәй булып, әле генә тибеп очырган юрганын үзенә тартты. Җиңү бәйрәме елы икән шул!

Әлбәттә, җиңүнең ничегрәк яулануы, кемнәрнең җинеп тә җиңелүче, кемнәрнең җиңелеп тә җиңүчегә чыкканлыгы хакында аның, язучының, үз фикере, үз карашы бар. Бу инде, кем әйтмешли, икенче, сәяси мәсьәлә. Ничек кенә булмасын, сугыш һәм ул алып килгән ятимлек аның канына

Айдар ХӘЛИМ (1942) —*шагыйрь, прозаик, публицист, җәмәгать эшлеклесе; күпсанлы китаплар («Милли шигырьләр», «Убить империю», «Татар вакыты», «Тилергән сирень» һ. б.) авторы. ТР Мәдәният министрлыгы һәм ТР Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби премиясе лауреаты. Чаллыда яши.*

сагыш, әрнеш, мәңгелек югалту булып сеңгән нәрсә. Моны ничек онытасың. Ничек кенә булмасын, ул йөзен бер тапкыр да күрмичә фронтта һәлак булган ата баласы. Җинүче улы. Аның фамилиясен йөрткән нәселеннән уналты ир-егетне алып китте ул, каһәрен. Авылда башка мондый нәсел дә юк. Берьюлы уналты җинүченең энекәше ул!.. Шул сугыш сиерын җигеп сука тарткан анасын,ачлыктан шешенеп үлгән бертуганнарын, күршеләрен вакытыннан алда гүргә кертте ул хәшәрәт. Үткән гасырның сиксәненче елларында, Горбачев янарышы телләрне чишкәч, Чехословакиядә булып,туганнар каберлегендә яткан әтисенең җәсәден яд итте. Әйе, сугыш хакында күп язды ул. Аны хәтта «ятимлек җырчысы» дип тә атадылар.

Әмма язуы җитенкерәмәгән икән шул. Иң кирәген, иң мөһимен, иң йөрәккә төшкәнен язып өлгермәгән икән. Йөрәге чәнчеп уянуының сәбәбе нәкъ менә шул бит! Ул Уфа тарафларының ерак Дим-Өязе буйларында яткан газизләрдән газиз авылының бер очыннан икенче очына кадәр исән яугирләрне санап чыкты. Ике бөртек кенә калганнар!.. Йә Ходa, әллә кайдагы житмеш борылыштан читтәгеләр турында язып та, шул кадерле бөртекләр хакында язмаган бит! Ничек алар читтә калган соң?! Әле, бүген, менә шушы сәгатьтә исәннәр микән алар?! Исән генә торсалар иде!.. Аңа оят булып китте. Авылына хәзер торып йөгердәй булып, юрганын янә дә тибеп очырды.

Тукта, бүген ничәсе соң әле? Егерменче апрель таңы атып килә. Җиңү көненә кадәр унтугыз көн генә калган түгелме? Өлгерерме? Бүген үк кузгалырга кирәк! Хатынынннан ычкына алса, әлбәттә. Йөрәгең начар дип җибәрми торачак. Үзенең чире турында «Гомер иткән хатыным Гөлфия өстеннән берьюлы өч хатынга — Ишемия, Стенокардия, Гипертониягә өйләндем», дип шаяртырга ярата ул. Ярар, үзенең саулыгы гына була күрсен, хатынын ничек тә сындырыр.

Ул исәпли башлады. Ике көн — юлга. Бишәр йөздән мең чакрым. Авылда өч көн булсын ди. Язарга — өч көн. Әмма язмаларын Уфа гәзитләрендә чыгарганда яхшы булыр иде дә бит. Уфаның «Кызыл тан»ын авылда хет берничә кеше алдыра әле. Казаннныкыларны бу якларга бөтенләй дә үткәртмиләр. Алдырырдай кеше табылган хәлдә дә, яздыртмыйлар. Жирле власть тыйган. «Татар тәэсире» көчәя, имеш. Аның үзенең дә Уфа тарафларында хәлләре хөрти бит әле. Кайчандыр башкорт газетасында эшләгән, ул заманның кызыл авызлар теле белән әйткәндә, атаклы публицистның, Башкортстандагы татар-башкорт хәлләре турында Мәскәү матбугатында шаулатканыннан соң, үзенә дә юлны тыйдылар. Менә утыз ел инде аның исеме матбугатта күренми. Бөтенләй тыныч: Бальзакны да, авылдашлары булган язучы Тәлгатне дә белмиләр. Ул гынамы: авылдашлары Уфа хакимиятенең ата дошманы. Юлларда машинасының көпчәкләрен тишеп, аска да очырдылар, Уфа урамнарында ОМОНнан да издерттеләр. Һәр кайткан саен Башкортстанга кереп, шуннан чыгып киткәнче аны «койрык» озатып йөри. Өйрәнгән инде. Ярар, соңгы чорда бик аждаһаланмыйлар. Ярар, бу кайтуында да алай бик бәйләнмәсләр, бәлки. Әмма язганнарын барыбер дә Казанда гына чыгарырга кала. Бер генә санга сыймаслар да әле. Ярар, анысын да хәл итәр. Ә менә, басылып чыккан хәлдә, гәзитләрне авылга ничек җибәрергә? Аларны бит җиңүчеләр үзләре һәм аларның якыннары бәйрәм алдыннан укып өлгерергә тиешләр! Югыйсә, аларның мәгънәсе дә калмый. Ярар, Наполеон әйтмешли, тотынырга кирәк: сугыш ниятне үзе ачыклар. Бер рәте чыкмый калмас әле.

Ул иртән хатыны белән озак кына кинәшләшеп килешкәннән соң, «Ватаным Татарстан» газетасы баш мөхәрриренең дә фатихасын алып, юлга чыкты.

## II

Авылдагы бертуган абыйсы кайтуына куанды, әмма, гадәттәгечә, артык аптырамады: анын өчен бүгенге һава торышы, игеннәр чыгышы энесенең язучы булуына караганда күпкә житдирәк иде. Әмма ул, ни өчен шулай көтмәгәндәрәк кайтып төшүенең сәбәбен белгәннән соң, анын өчен бик мөһим яналык әйтеп салды:

— Сабиржан абзый да авылда бит әле... Хатыны белән кайтканнар. Зөлкарнәйләрнең иске өендә яшәп яталар...

— Кичә сарык суйган идек... — дип өстәде жиңгәсе. — Билдәмәлек жиреннән бер мул гына кисәк ит, бер йомарлам май, катык та кертеп чыккан идем әле. Син дә кайтып төшкәч, аларны да чакырып, мәжлес үткәрми булмас...

Бу яналык әдипне куандырды да, уйландырды да. Менәгаеш!.. Бирим дисә колына — чыгарып куяр юлына, дигәннәре шушы буладыр инде. Сабиржан абзыйлары да фронтовик бит! Авылдагы егерме бишенче елгылардан кырылмый калган бердәнбер солдат!.. Ничек ул аны онытып жибәргән соң? Авылда яшәмәгәнгәдер. Әйе, ул, Сабиржан абзыйсы, сугыштан соңгы ачлыкта бәләкәй арба белән авылдан Сталинабад, хәзерге Дүшәмбе якларына чыгып киткән гаиләсенә турыдан-туры кайтып төшеп, төпләнеп, шул ук Сталинабадта авылларыннан беренче булып югары уку йорты, юридик факультет тәмамлап, шунда ук башлы-күзле булып алганнан соң Уфага кайтып урнашкан һәм үз эше буенча зур гына вазифалар биләп, атказанган юрист дигән исемгә ия булып, бүгенге көнгә кадәр Уфада яшәп ята һәм, сөйләүләренчә, ниндидер юридик оешмада эшләп, хосусый хезмәт тә күрсәткәләп ала, имеш...

Булган кеше ул Сабиржан абзыйсы.Авылдашларына ярдәмен дә кызганмый; әмма, һаман да шул кеше сүзенә ышанганда, буш рәхмәткә түгел. Аннан, адәм баласын гаепләп тә булмый, аеруча адвокат, юрист кебек ак якалы нечкә хезмәт иясен: ни дисәң дә, кесәләре тирән, төпсез, карга баласы кебек, өлеш сорап кына тора... Шунысы хак, ул барча туганнарын, балаларын аякка бастырды, кайсына эш табарга, укырга булышты, фатир белән ярдәм итте, кайсына йорт төзешеп, барысын олы юлга чыгарды. Туган-тумачалары белән генә түгел, үзеннән кечерәк чит ир-ат заты белән мөгамәләдә дә анын иң яраткан сүзе «энекәш» иде.Тәлгатнең анардан бер ярдәм дә күргәне булмады: үзе дә теләмәде, сорап та бармады. Шулай да бер тапкыр, Казанда укыган чагында, үтеп барышлый Уфада туктагач, Сабиржан абзыйсы аны, энекәшен, культурадан артта калмасын дип, кемдер биргән билетка Мәскәүдән килгән бер симфоник оркестр концертына алып барган иде. Тамаша башлангач та ул әле генә районнан тирләп-пошлыгып кайтып кергән аякларын штиблетларыннан чыгарып утырган һәм минем аякларым сезнең борын тишекләрегездән кадерлерәк дигәндәй кыяфәт белән бар тирә-якны әчегән балан исләре белән тутырган иде. Тәлгат бер сүз дә әйтмәде, түзде, анарда, киресенчә, үзен шулай ат абзарындагы кебек хужаларча тота белгән авылдашы өчен горурлык та уянып куйган иде. Кара, нинди иркен ихтыярлы, гасаби холыклы икән бу юрист халкы!.. Шулай да абзыйсы аңа, әле борынлап кына килүче яшь язучыга, югарыдан, ышанмыйчарак карагандай, очрашканда-ниткәндә, аеруча башкалар алдында, ярмасын эре яргандай күренә иде. Шөкер, очраклы вак нәрсәләргә зур игътибар биреп, алар араларны өзмәде — артык якын булмасалар да, ташлашмадылар. Ветеран, туган жиренең патриоты, бер бишектә үскән энекәш-сеңелкәшләре калмаса да, һәркемне бертуган исәпләп, авылын онытмый. Ел саен диярлек кайтып, урыны зиратка күчкән чыбык очы Зөлкарнәйнең иске йортында берәр ай чамасы яшәп ала...

Менә янә дә кайткан икән авылга. Ярар, хуш. Иртәнге сәгать тугызлар иде. Тәлгат артык йобанып тормыйча, эшен аңардан башларга булды. Авылның очтан очка сузылган бердәнбер урамы буйлап барганда ул күзе сукырайган, бакчаларын чүп үлән — әрекмән, кычыткан баскан ихаталарга карамаска тырышты. Караган саен алардан елмаеп,кочагын җәеп, Тәлгатнең күз алдында яшәгән, өйләнешкән, балалар үстергән, бергә печән чапкан, урманнарда бүрәнә-матчалык агачлар аударган, әмма инде барысы да бакыйга киткән авылдашлары килеп чыгар һәм аның күзен чокыр кебек тоелды. Бу аның өчен, авылы дип ут йоткан тупракпәрвәр әдип өчен, дарга менүгә тиң иде. Дөньябызны ничек итеп бу хәлгә җиткерә алдыгыз, дип сорасалар, ни дип җавап бирер? Елга аша чыкканда ул өстендәге таш булып каткан туфрак катламына кадәр изрәп, ашалып, җир-ашы коелып беткән күперне күреп тетрәнде. Ат тоягы гына түгел, озакламый барлы-юклы игенне ташырга дип читләрдән киләчәк йөк машиналарының көпчәкләре дә төшеп китәрлек тишек-тошыклардан аның сөекле Өязесе — шигъриятенең илһамчысы булган туган елгасының хәлсез дулкыннары ашадан-аша күренеп типченә иде. Аны йөрәге кысып алгандай итте. Алтмыш ел элек авылларына нефть эзләргә килгән бораулаучылар салган корыч торбалар да гүя искереп, тузып-таушалып, инде шушы тимерләрнең үзләрен сипләрлек бүрәнәләр, калын такталар сорап, шәрәләнеп калган сыртларын кояшта кыздырып яталар.Ул шушы заманнан заманга изелеп сыгылган торбаларны алыштырырга, күперне төзәтергә чакырып күпме язды, әмма кулыннан килмәде бүген үләм, иртәгә үләм дип чак-чак тын алган күмәк хуҗалыкның. Һич тә арттырмыйча әйткәндә, бар гомерен багышлады ул авылын күтәрү дигән акланмаган бурычка, әмма, нишләсен, бер генә миллиметр да алга җибәрә алмады. Киресенчә, партия-совет хакимияте аны ишәк итеп өстенә менеп атланып, талый-талый соңгы чиккә җиткерде. Менә шулай кайчандыр авыл өстендә янган йолдызлар хәзер күпернең умрау тишекләре аша елгага коелып төшкән иделәр.

Шул ук вакытта авыл, үлгән күренсә дә, кәһәр генә тере иде. Зарланма әле, Тәлгат!.. Куан!.. Әгәр ул тере булмаган булса, Сабирҗан кардәшебез дә, син дә, язучы иптәш, монда кайтмаган булыр идегез. Күперне төзәтә алмасак та, дулкыннары җимерек күпер аша булса да күренеп типченгән күперләр аша кайтабыз бит әле авылга, дип уйлады ул. Авыл исән, аның тын алышын тоярга һәм моны тою, ишетү өчен иң элек күкрәгенә кислород мендәре куеп тыңларга кирәк. Исән булмаса, син авылдагы исәннәр турында әсәр язарга кайта алган булыр идеңме? Исән генә түгел, алар безгә, читтә йөреп азган-тузганнарга, җимерек күпер тишекләре аша карап та илһам-көч бирә. Авылның бүгенге, читтән бик каушаган-таушалган күренгән кешеләре дә безгә, кайтып күренеп китүчеләргә караганда сау-сәламәтрәк түгел микән? Алар Тәлгаткә үрнәк булып күренде. Аларга барып җитешкәнче, көрешкәнче, сорашканчы исән генә була күрсеннәр иде! — дип уйлады ул.

Уйланып, кибет янына килеп җиткәнен сизми дә, абайламый да калган. Ишеген әле генә ачкан, төн йокысы күзләреннән генә түгел, түшеннән дә төшеп бетмәгән кибетче хатыннан — теге аны танымады, башка авыл хатыныдыр, күрәсең, — шүрлекләрендә нәрсә бар, шуның белән күчтәнәч юнәтеп, ул нәкъ кибет каршындагы зәңгәр тәрәзә капкачлы йортка юнәлде.

Ишек эчтән элдерелгән иде.

— Кем анда?

Тәлгат исемен атады. Ишек келәсе гармун басмагына баскан тавыш чыгарып ачылды. Яңа исемне ишетү белән югалып калган, беренче күз сирпүеннән табак битле булып шәйләнгән хатын, ачык күкрәген уч төпләре

белән каплагандай итеп, йөгереп кереп китте. Тәлгат унайсызланып куйды. Бөек Жиңү бәйрәме дигән булып, аксак-туксак килеш туксанга житеп барган жиңүчеләрне тан тишегеннән борчып йөрергә аның ни хакы бар соң?!

Ул капшанып кына дигәндәй балачактан таныш иске ишек тупсасы аша эчкә үтте. Алгы якка ишеге урынына эленгән керле чаршау аша эчтән бүселеп йокы һәм торгынлык исе чыга иде.

— Әйдә, энекәш!.. Мин — хәзер!.. Тутыя, чәеңне юнәт!..

Илтифатлы колакка эчке яктан карт-коры ир-атның мышный-мышный, ашык-пошык чалбар тарткалаганы ишетелде. Тәлгат, кучтәнәчләрен өстәл өстенә куеп, кире тупса төбенә килде, күптән күрмәгән Сабиржан абзыйсын каршыларга әзерләнде. Менә бөрмәләнеп җыерылган чаршау тартылып ачылды һәм аннан авылдашының сабый чактан таныш, күңелгә бик тә якын гәүдәсе — кып итеп торган кыска, базык буй-сыны, тулы, итләч кызыл бите, татар морзаларына хас зыялы йөзе күренде. Әле көн яктылыгы кереп өлгермәгән алгы якта, тупса төбендә басып торган Тәлгатне күрмәгән Сабиржан дивардан капшанып, электр басмагын эзләде:

— Тутыя, яктылык бир, пон-нимаешь!..

Ниһаять, абзыйсының инде сүлпән карт күз карашлары әле һаман төн сөрмәсе йөзгән һавада бераз аешкандай итте, ул ишек төбендә басып торган гәүдәне шәйләп, Тәлгаткә, ә Тәлгат үз чиратында Сабиржанга таба атлады.

— Исәнме, энекәш!.. Исән-сау гына йөрүме? Кайттыкмы?

Алар иңнәреннән кагышып кочаклаштылар. Мондый очракларда була торган кыскача хәл-әхвәл белешкән арада Тәлгат Сабиржан абзыйсына кайтып төшүенең төп максаты — Жиңүнең 65 еллыгы уңаеннан ике исән-сау фронтовик авылдашы, шул исәптән, аның бәхетенә, өченчегә авылына кайтып төшкән Сабиржан абзасы турында язарга дигән уе барлыгын хәбәр итеп өлгерде.

— Тутыя, Ильич яктысын бир, дим, пон-нимаешь!..

Ул арада шул ук җыерылган чаршауны җилләндереп, эчке яктан өстендә җилкән кадәр халат өстерәп, тутырган тавык кебек тулышкан Тутыя җиңгәсе килеп чыкты. Ул черт итеп басмакка басты. Бүлмәгә ниһаять Сабиржан абзыйсы көткән Ильич яктысы да керде.

— Менә шулай!.. Света!.. Побольше света!.. — дип кеткелдәде почмактагы калай юынгычны доңгыр-доңгыр китереп битен-башын сыпырып маташкан Сабиржан. Аннан өстәп куйды. — Да, этот самый... Ленин әйткән шулай дип!.. Мин түгел!..

Тәлгатнең бу хатынны беренче күрүе иде. Сабиржанның элекке хатынын аерып яшьрәккә өйләнгәнлеген ишеткән иде. Ул аптырап калды. Хатыннар кавеменең ирләренең кабыргасыннан шуларга охшап яратыла дигәннәрен ишеткәне булса да, моңа кадәр хатынының иренә, иренең хатынына бу кадәр дә суеп каплагандай охшау очрагының шаһиты булганы юк иде. Яхшы тәрбиядә, затлы ризык белән тукланып яшәгәнлеге әллә кайлардан кычкырып торган шул ук алсу түгәрәк йөз, шул ук кызгылт табак бит, шул ук шешенке күз кабаклары эченнән дөньяга бер хәйлә белән йөгерешеп караган коңгырт сәйлән күзләр. Әгәр Сабиржан абзыйның пеләш башына бүрек кидереп, ике колагына ике алка таксаң, ул әһ дигәнче Тутыяга, Тутыясы исә, колаклы бүрек кидерсәң, шундук Сабиржанына әвереләчәк иде. Ул арада булмый, электр чәйнүге урынында кыбырдый башлагач, хатынкай аларны өстәл янына чакырды, чынаякка суык чәй агызып, өстенә шыбырдатып кайнаган су агызды да, чынаякларын алар каршына этәреп тә куйды:

— Әйдәгез, булганыннан житешегез әле... Сөтем бетеп киткән икән.

Авыл кибетендә сатып алырга сөт тә, юньле азык та юк. Йорттан-йортка йөреп, кешеләрдән ит теләнеп казан да асасым килми. Итен-мазарын тапсаң, бозлыгы юк...

«Бозлык» дигән сүз Тәлгатнең борчулы күнелен күтәреп җибәрде. «Халык иҗаты үлемсез шул, — дип нәтиҗә ясады ул. — Холодильник та, суыткыч та түгел, бозлык. Бердәнбер дөрес төрки атама».

Монда килер алдыннан гына тамак туклыгы иткән Тәлгат, ашыйсы килмәсә дә, кешенең нәфсесе күздән чыга дигәндәй, өстәлне күздән кичерде. Әмма анда авызы-борыны бикле шикәр савытыннан һәм туралмыйча куелган ике баш кыярдан башка нәрсә юк иде. Ул вакытны сузып әче вьетнам чәен уртлаган булып утырды. Шунысы кызык, Сабирҗан абзыйсының Тәлгатнең аның хакында язарга теләге булуы, хәтта шуның өчен биш йөз чакрымдагы Чаллыдан махсус кайтып төшүе турында хәбәренә бернинди дә тәэсире булмады.Сүзне нидән башларга белмичә утырган Тәлгатнең хәлен җиңеләйтеп, ул өстәлдән энекәше алып килгән күчтәнәч төргәген алды, туй бавырсагы шикелле юантык, буынтыклы бармаклары белән сүтте, аннан ашыкмыйча гына булган ризыкларны өстәлгә чыгарып салды:

— Менә, бар бит!.. Булганны нигә өстәлгә куймаска!..

Ул чәен авызын чупылдата-чупылдата алдындагы печенье-вафлиләр белән эчкән арада Тәлгат бая әйткән теләген янадан кабатлады:

— Сабирҗан абзый, кыен булмаса, син үзең үткән фронт юлларын хәтереңә төшерсәң, мин бераз теркәштергәләп утырган булыр идем...

— Теркәштергәләп, дисең инде? Аны кайда чыгармакчы буласың соң? — диде теге бар нәрсәдән хәбәрдар күзләрен тажырайтып. — Уфадамы? Казандамы?

— Уфада булмас кебек... Үзең беләсең минем хәлне. Казанда тырыштырып карармын дип уйлыйм.

— Шулайдыр шул... — диде Сабирҗан абзыйсы сузып. Аннан кеткелдәгәндәй итеп өстәп куйды. — Сиңа бит Уфа ябык!.. Безгә ни... Казандагы каз ите дә яраган... Гәзитен китереп житкерә алсан...

— Чыгуын чыкса, ничек тә житкерергә тырышырбыз инде... — диде Тәлгат. — Анда проблема булмас кебек. Миңа юлны япсалар да, Уфа—Казан арасын япканнары юк бит әле...

— Анысы ук булмас булуын... Фидирәл цинтр бирмәс... Яра-а-ар, алай булгач. Аллага тапшырдык. — Ул шыгырдап урыныннан күтәрелде. — Ваянный истәлекләр хатын-кыз тынлый торган нәрсә түгел. Киттек теге якка. Урындыгынны ал...

Алар урындыкларын күтәреп, эчке бүлмәгә үттеләр. Кеше яшәмәгәч, бу почмаклары жылынып өлгермәгән вакытлы куышта юньләп жыештырылып өлгермәгән никель башлы иске караваттан һәм өсте маршал Жуков, Еременко, Батов кебек полководецларның хәрби истәлекләре белән тулган өстәлдән башка бернәрсә юк иде.

Утырыштылар. Тәлгат блокнотын өстәлгә салды да абзыйсына текәлде. Абзыйсы исә озын итеп кикереп, тук кыяфәт белән аңа текәлгән иде. Тәлгат сүзен нидән башларга белмичәрәк, югалып калгандай булды, вәләкин үзен тиз кулга алып:

— Менә, Сабирҗан абзый, син сугышларны үтеп, исән калгансың. Ватан сугышындагы батырлыкларың өчен сиңа заманы өчен бик сирәк «Дан»орденын да биргәннәр...— дип өлгермәде, абзыйсы аны:

— Орденны аны, энекәш, батырлык өчен алып булмый. Очрагы гына туры килмәсә... — дип, чак һушыннан яздырмады. Һәм аңа авызын да ачарга бирмичә, сөйләп китте. — Син миннән, ничек исән калдың, дип

сора. Сугышта үлү түгел, исән калу вакыйга. Мин сиңа теге «Дан» ордены тарихын да сөйләрмен. Аңа кадәр барып житә алсак, пон-нимаешь... Мин сиңа ничек итеп безне, унжиде яше дә тулып житмәгән малайларны, кышкы ыжгыр суыкта, чабаталарда ваянкаматтан кулларыбызга мылтык урынына түмәр күтәртеп ике йөз чакрымдагы Алкин лагерьларена алып киткәннәрен, юлда ничә малаебызның ачлык-ялангачлыктан, туңып, юл буенда коммунизм маягы булып ятып калганнарын да сөйләп тормыйм, ярыймы? Кемгә кызык ул? Билгеле нәрсә! Әмма берәүгә билгеле булып та икенче берәүләргә билгеле түгел. Менә бу маршалларга!..— Ул өстәлдәге мемуарларга төртеп күрсәтте. — Берлинны көндәше Рокоссовский түгел, үзе һәм... пон-нимаешь, Беренче май бәйрәменә кулга төшерү хакына сугыш азагында безнең кебек ярты миллионны суга салган атаклы башкисәр маршал Жуковлар бу хакта язмыйлар!.. Канэчкечләр!.. «Света, побольше света!..» Ленин әйткән. Мин түгел. Сугыш ул, энекәш, сөйли алмый торган нәрсә. Сөйләп булса, аны башламаслар да иде. И-их, күпме кырылды малайлар ачлыктан ул Алкин лагерьләрендә!.. Исләремә төшсә!.. Орден-наградларын ыргытып бәрәсем килә!..

Тәлгат тыштан караганда бик сабыр, тотанаклы Сабиржан абзыйсының болай тәэсирләнәчәген көтмәгән иде. Ул инде шуның белән дә канәгать иде.

— Кыш. Куып китерделәр... — дип дәвам итте Сабиржан, бу хакта сорамасалар да. —Ачлыктан шешенеп, туңып үлгәннәр өстеннән салдырып алынган киемнәргә киендерделәр. Абзарда салам өстендә йоклыйбыз. Рәткә басу белән «Запевай!» Кая ди анда жырлау?! Чак басып торабыз. Жырласак та, «Бетсен патша, янсын тәхет, безгә сугыш кирәкми!..» дип «Көзге ачы жилләрдә»не жырлый алмый идек бит инде... Үзең беләсең заманын. Яткан урыныбызда ук бәдрәфебез, шушында тышка чыгабыз, сиябез, пон-нимаешь... Әмма эчемнән генә «Тукта, жырлатырмын әле мин сезне» дип тешемне кысып куя идем...

Капчыгымда үзем ясаган ике пар чабата бар иде, шуларны икмәккә алыштырып җан асрыйм. Кызыл Армия!.. Тузган чабаталарым авызларын чалшайтып, елыйлар.. Киндерәләрен авылга җибәрермен дип капчыгыма салам... Хет иннек-кершән буят, җибәртмиләр. Шундый матурлар, мескенкәйләр. Чит-ят якларда ташлама, дип елыйлар кебек. Күпме түзәргә мөмкин?! Казармаларны җылытырга дип урманга әрдәнә артыннан килгәч, качып-посып,туң агач кәүсәсе өстендә химически каләм белән Оборона комитетына, иптәш Сталинның исеменә жалу яздым мин... Ышанасыңмы?! Бармакларымны туңдырып...

— Тутыя абыстай, чәй керт әле! Сугыш искә төшү белән тамагым кипте! — дип кычкырды ул алгы якка хатынын беренче тапкыр ни өчендер «абыстай» дип атап. —Курыкмадым андый хатны язарга. Ни өчен мин, гомумән, үлемнән астына шыр җибәргән кеше, моны язарга курыкмадым? Мин, юрист, әле генә килеп аңладым: мин сугыш кына тудыра ала торган хәвеф режимында яшәгән булганмын. Фашисттан килә торган тышкы үлемнән куркып, Сталиннан килә торган эчке үлемнән курыкмаганмын. Аның булуында шикләнмәгәнмен дә! Мин бу эшне үзем кебек башкаларга зыян китермичә эшләргә тиешлегемне аңлый идем. Әгәр кулыңнан килсә, хәтта үз язмышыңны куркыныч астына куеп та, аларга ярдәм итү теләгеннән чыгып аңлаганмын, күрәсең. Моны ни өчен мин генә эшләргә тиеш булганмын? Чөнки мин яңа җыелган новобранецлар арасында чагыштырмача белемле, укымышлы кеше идем. Зыялы, димәк!.. Җиде класс белемле әләкче!.. Ул чактагы татарның җиде классы — бүгенге академия!

Әйе, пон-нимаешь, әгәр кемдер мин ватан өчен ике дә уйламыйча

жанымны бирәм, илем генә исән булсын, мин үзем исән булмасам да бәхетле, мин барыбер һәйкәл бөркете булып илемә кайтачакмын. фәлән-төгән дип авыз суын корыта икән, ышанма — сафсата бу. Ике генә түгел, мең кат уйландыра! Яшисе килә! Үлемне хәйлә белән алдыйсы килә!.. Шушы халәт шушы режим шартларында йөрәккә төен булып төйнәлә һәм ничек кенә булса да исән калу ягын чамаларга боера. Һәркемдә бар бу тойгы. Гомер бер генә бит!.. Югалган ил дә бер килеп кайта, гомер генә кайтмый, туган!..

Сабирҗан абзыйның хистән борын тишекләре йомшарды. Ул тирә-ягында борын сөртер чүпрәк эзләде. Теге яктан ишелеп кереп, алдына чәй куйган хатынына кырыс кына:

— Кунакның авызы юк мени? Кунакка да!..

— Мин, бәй, сорамагач...

— Сез, хатын-кызлар, гел сораганны гына бирергә яратасыз... Борын сөртергә тастымал да керт...

Мондый тотанаксызлык өчен Тәлгаткә уңайсыз булып китте. Тутыя җиңги авызына бер кашык тоз капкандай шым гына теге якка шылды.

— Белем коткарды мине. Гомерем буе. Бүгенге университет безнең замандагы җиде класс белемен бирәлми, дип әйткән идемме? Әйе, бирәлми. Нәрсә, бүгенге укытучылар наданмы? Анысы да бардыр, әмма заман, режим икенче...Кешеләр икенче... Минем теге туң түмәр өстендә язылган әләк хатын тикшерергә Кремльдән Ворошилов үзе килде. Ул лагерь начальнигын строй каршында атып үтереп китте...

Тәлгатнең бу хакта зурдан кубып укыганы булмаса да, халык авызыннан күп тапкырлар ишеткәне бар иде. Кара, шундый куркыныч заманнарда бу тарихи шау-шуны куптаручы кеше аларның авылдашлары, җитмәсә, Сабирҗан абзасы икән ләбаса!.. Менә ни өчен кайтарткан икән Аллаһы Тәгалә аны авылына!..

— Хатны кем язганын белсәләр, мине дә бәдрәф артына алып барып атачаклар иде... — дип дәвам итте Сабирҗан. — Әмма лагерь начальнигын атып кына яшь солдатларны чалгы белән чапкан үлемнән үзен юкка чыгара алмады Ставка вәкиле. Чөнки ул халыкның таракан кебек кырылу сәбәбен белергә теләмәде. Бу аның хәленнән дә килми иде. Мине дә үтерә алмады. «Жить в обществе и быть свободным от общества невозможно» дип кем әйткән? Шул ук Ленин, энекәш. Без түгел. Җиргә яхшылык китерәм дип иң зур золым китергән идеалист. Әйе, мин бу очракта Сталин-Ворошиловлардан акыллырак, хәйләкәррәк Кремльдә яши идем... Хәйлә!.. Нинди даһи шигырь!.. Солдатны хәйлә коткара!..Татар хәйләкәр булырга тиеш!..Мин ул чакта нибары бер метр илле сантиметрлы татар малае, даими укып торуның үлемнән исән калуда бердәнбер чара икәнлеген аңлаган идем. Лагерьдә контрразведка нык иснәнә башлады. Хатны язучы мин икәнен белсәләр, штрафбат белән генә чикләнерләр иде микән? Әйе, энекәш, әле башланып кына килгән бу иттурагычта бары тик берәр ярыкка укырга ычкынып кына исән калып була иде!..

Әйе, уку коткарды. Үлүе бик җиңел, яшәве генә авыр, аһ, авыр!.. Нәкъ менә синең бүгенге хәлең кебек. Кеше сөйләгән хакны язуы авыр, үзең уйлап чыгарган ялганны язуы җиңел, шулаймы? Сезнең заман язучылары ничектер, мин белмим... Ә менә безнең заманныкылар, гафу ит, кызлыгы алынмый сазаган кызларны хәтерләтә иделәр... Әйе, башыма җиткәнче, миңа Алкин лагерьләреннән ычкынырга кирәк иде. Эскадрон командиры ябрәй Якобсонга ике әчмуха чәй, ике әчмуха тәмәке төртеп, ат ветеринарларының дүрт айлык тизләтелгән курсларына укырга китүгә ирештем. Көне-сәгате үлемгә торганда дүрт ай буена «тиз-тиз укып» үлмичә

тору яхшырак бит инде... Жиде класс коткарды!.. Ашау чагыштырмача яхшы, ятар урын актан, жылы, снаряд-бомба шартламый, окоп казыйсы юк... Аннан, малай... — Абзыйсы, хатыны юк микән дигәндәй, тирә-ягына каранып алды. — Саранскида укыдым мин. Мукшы кызлары кебек юмарт кызлар юк ул!.. Татар кызлары кебек саран да, метек тә түгел...

Шуны гына көткәндәй, жингисе ана да чәй һәм абзыйсына танау корытырганиндидер чуар чүпрәк кисәге дә кертте. Форсаттан файдаланган Тәлгат:

— Кара әле, ябрәй кадәр ябрәй дә атлы гаскәрдә хезмәт иткән диген, ә? — дип куйды сөйләшүнең көтелмәгәндә шундый кызыклы юлдан кереп китүенә куанып. — Нинди яхшы ябрәй!.. Үзе ябрәй, үзе ат өстендә!..

— Ябрәйнең яхшысы булмый. Хәйләкәре генә була. Жинелүчеләр ягында да, жиңүчеләр арасында да. Атта булмаса да, атта ул. Төшкәне дә юк. Гел ат өстендә булырга анардан өйрәнергә кирәк. Бу бит пушка өстерәү дә, танк двигателен күтәрү дә түгел... Сузылганнан сузыла барган сугышны үземчә сузу өчен мин, кайда мөмкин, шунда укырга атлыгып тордым.Бер очрактан икенче очракка. Сугыш, гомумән дә, очраклылыклардан тора. Ул ихтыйатлы адәм баласын буш калдырмый. Өлешсез итми. Ветфельдшерлар мәктәбен тәмамлагач, беренче тапкыр утка кердем һәм беренче тапкыр яраландым. Брянский юнәлешендә булды бу хәл. Безнең яхшы гына башланган һөҗүмебез тыгылып калды һәм һөҗүмебез фашистлар белән кул сугышына әйләнеп, без янадан чигендек. Мин беренче тапкыр үземнең өстемә килгән фашистның тилергән күзләрен күрдем. Кулларындагы пычаклы автоматыннан түгел, шушы шашкан кан белән тулышкан күзләреннән курыктым мин... Әйе, энекәш, курыктым. Минем үземнең күзләрем ана, бәлки, тагын да тилерәк күренгәндер. Әнә, ул килә... Минем иреннәрем үзләреннән-үзләре әти-әни мәрхүмнәрем өйрәткән бисмилланы кабатлый иде...Бисмиллаһ иррахман иррахим... Менә мин бруствердан күтәреләм... Әлхәмделиллаһи раббил галәмин!.. Калганын мин юньләп хәтерләмим дә. Сугышта кеше икенче кешене үзен хәтерләмичә...хәтерсез килеш үтерә икән... Хәтере булган кеше кеше үтерәлми!.. Әллә шушы бисмиллаһ, әллә мин үземне-үзем коткардым...

— Димәк, син намаз укыйсың, Сабиржан абзый?! — диде күптән түгел намазга баскан һәм авылдашы сөйләгән яналыктан куанычын яшерә алмаган Тәлгат.

— Ю-у-ук... — диде абзыйсы әлләни аптырамаган кыяфәттә. — Укымыйм!.. Мин дингә, Аллаһ барлыкка ышанам. Әмма мин атеист, понимаешь... Тик нишлисең, шушы кул сугышында фашист мине түгел, мин фашистны үтердем, энекәш... Үтермәсәм, ул мине үтергән була иде!.. Берне түгел, икене!. Минем белән әллә нәрсә булды. Яшәү хакына мин тилергән жанварга әверелгән идем. Курку дигән нәрсә бер китсә китә ул. Мин, авылдан чыккан китап корты, бүген кеше үтердем!.. Мин, Ибраһим мулла һәм Сәлимә абыстайның улы!.. Кеше ышанырлыкмы?! Трофейга бихисап корал тапшырдым. Ул заманда фашистның бер трофей автоматы өчен түшкә «Кызыл Йолдыз» кадыйлар иде. Үлү өчен күп акыл кирәкми. Ә менә исән калу өчен — кирәк. Бу алышта мин шушы иң гади хакыйкатьне аңладым. Куркуымнан кеше үтерүемне батырлык дип атап, мине орденга тәкъдим иттеләр. Әмма алмадым мин ул орденны. Әллә бирмәделәр, әллә килеп житмәде тагын. Ярый әле бирмәделәр. Мин бу каннан кул юып кына үлгәнче дә котыла алмам, күрәсең.

Ә син Бөек Жиңү дисең. Сугыш минем эш түгел иде... Мин сугышка каршы акыллы китап укып кына көрәшә ала идем. Минем күзем кысык — күпне күрә, колак зур — күпне ишетә иде. Брянский урманнарында

күпмедер бет ашатып ятканнан соң, форсатын китереп чыгарып, тагын да дүрт айлык телеграфистлар мәктәбенә укуга ычкына алдым мин. Ишеткәнең бармы Морзе аппаратын? Пип-пип. Бармакларың аппаратта эшлиме, анысы мөһим түгел, бу аппарат синең гомереңә янамасын гына. Аны тәмамлагач, тудыйм-судыйм, тагын укырга юл ачылды бит, малай! Бу юлы бөтенләй дә армия аристократиясе хезмәте — поварлыкка киттем мин. Әдәбиятта пешекче диләр иде бугай. Әмма минем борчак пешмәде, кыскасы, казан асты кыздырырга туры килмәде. Бик теләсәм дә. Вакансия булмады. Армия казанының төбе генә кара, асты алтын аның. Моңа Сталинга хат язып кына ирешеп булмый.

Сугышны мин Алкин лагерьләрендә түмәр күтәреп башлап, автоматчик булып тәмамладым. Ха-ха-ха!.. — Сабирҗан абзыйсы буылып көлде. Аның белән бергә, шартына китереп, Тәлгат тә кеткелдәгәндәй булды.

— Әмма казанның ярдәме тимичә калмады. Шулай бер тапкыр, Балтыйк буе фронтында, Каунаска җитәрәк, алҗыткыч сугышлардан соң, безне резервка чыгардылар. Җәяүле марштабыз. Үтереп арытты. Йокы аяк өсте генә. Безнең арттан атлы обоз — поход кухнясы бара. Хуҗасы дус кеше. Ыслакбаштан чуаш малае. Вәчли-петчә. Курсларда бергә укыдык. Минем көмеш портсигарым бар иде. Взвод командирыма шуны төрттем, «чуток кына мырлап алырга рөхсәт итегез», — мин әйтәм. Рөхсәт итте теге. Нишләсен, кеше күзе сугышта да май сорый. Вәчли мине буш поход казанына яшерде. Чишенми-нитми кереп яттым. Ничә сәгать йоклаганмындыр, Вәчли-петчә уята: «Бстабай, земляк, Каунас взят!» Колакларымны йомарлыйм һәм әле генә ишеткәндәй итәм: бәй, обоз тәгәрмәчләре Балтыйк буеның йомры таш түшәлгән юлларында доңгыр-доңгыр килә ләбаса! Бу кадәр тавышка колакларым тонмыйча ничек йоклаганмын?

Минем өчен сугыш Калининградта тәмамланды да инде. Кунерсдорф дигән авыл өчен барган сугышта яраланып, госпитальгә эләктем. Берлинга барып җитми калдым. Фашист миннән менә шулай котылды. Әтү мин американнарга өлеш тә калдырмый идем... — Ул күзен кысып тагын көлемсерәде. — Мин, бәлки, шул Берлинга барып җитмәвем аркасында гына үземә дигән соңгы фашист ядрәсеннән котылганмындыр да? Менә бу истәлекләрнең авторлары... — Ул тагын өстәлендә чәчелеп яткан китапларга ымлады. — Җиңү хакына солдат гомере белән исәпләшмиләр. Аларга җиңү — сәяси капитал. Кеше гомере капитал түгел. Ничек әле? «Если враг не сдается, его уничтожают». Кем әйткән моны? Сталин. Мин түгел.

— Максим Горький, — дип кыстырды Тәлгат.

— Ярар. Пущай, шулай булсын. Один чурт шулар җырчысы. Үзенә күрә, сина сөйләгәннәрдән чыгып бәяләгәндә, мин сина татарның Василий Теркины булып чыгам түгелме? Аһ, син әле шулай итәргә җыенасыңмы? Ул чакта мин сине шулай итәм!.. Алар мине укытып чыгара тордылар, мин аларга яна уку төрләре уйлап чыгара тордым. Чынлап та, үз тәҗрибәмнән беләм: фаҗигане көлке аша үткәрсәң, гомер озыная. Безнең борынгы бабайлар безгә шуны сеңдерә алганнар. Ә менә сезгә, сездән соңгыларга, без шушы серне сеңдерә алдыкмы? Юк. Шаярта белми сездән соң килгән буын. Менә шулай, энекәш. Сугышны аны сөйлисе дә килми. Сине үлемгә куып кертәләр дә, сугыш арбасы астында тапталып үлсәң дә, батырларча үлде, дип өенә — гаиләнә, балаларыңа үлем хәбәре салалар. Үлемнән геройлык ясау... Шушы да булдымы егетлек?! Ул «герой»ның гәүдәсе еш кына җирләнмичә дә кала, козгыннарга азык!.. Җә, көлке түгелме? Нинди батырлык?.. Безнең татар өчен бигрәк тә... Ни-нәрсә хакына һәлак булдык? Ил өчен дияр иден — илен, җир өчен дияр иден — җирең, җыр өчен дияр иден — җырың юк. Бар алар, тик инде синеке түгел. Тартып алынган.

Күп укып, мин менә шуларны аңлаган идем инде. Сугыш башында качапоса Алкиндагы хәлләр турында Сталинга хат язуым да, сугыштан соң юриспруденция буенча китүем дә шул аңлы булуыма бәйле иде.

Ул туктап тын алды. Касәсендәге салкын чәйне уртлады.

— Монда рәхәт!.. Тыныч!.. Авылда үлемсез мин. Бер ел чамасы шәһәрдә яшәп, үләр хәлгә житеп, монда кайтам да, моннан үлемсез булып китәм... Сиңа монда минем хакта батырлык кылган дип язарлык кәтрә хәбәр дә юк. Бер караганда, мин гади «шкурник». Шулаймы?

— Түгел, — диде Тәлгат. — Син сугышның гади бер игенчесе...

— Әйттең тагын!.. Ә бит эчтән үзең мине «шкурник» дип утырасың, шулаймы? Ярар. Һәр буын үз язмышын шулай үзенчә үтә... Ягъни үз гомерем турында гына кайгыртканмын. Әйе, яшермим. Мин үз гомерем турында кайгырттым. Чөнки ул миңа Ходайдан, атам-анамнан бирелгән иң кыйммәтле байлык иде... Мин — закон сагында торган юрист. Закон да миңа кеше гомерен саклау бурычын төшергән. — Ул аягын аякка куеп утырды. Яшьләнгән шомырт кара күзләре белән Тәлгаткә текәлде. — Әйдә, энекәш, язма. Герой дип бер тапкыр язмасалар да, сиксән бишкә килеп життем бит әле...

— Юк, язам, Сабиржан абзыкай!.. — диде Тәлгат, абзыйсы ачкан яңалыклардан бераз шомга калып. Ул аңа сугышны мондый яссылыкта сөйләгән беренче кеше иде. — Бик кызык бит бу!.. Яңача караш!..

— Яңача карашка үзенчә кара. Галәттә, яңа караш өчен безнең Рәсәйдә башка сугалар. Бәлки, яңача карашка искечә карарсың. Синең дә гомерең озын булыр, пон-нимаешь... Язмасаң, үпкә юк. Язсаң, басып чыгарсалар, үзеңә шифа...

— Син теге орден алган батырлыгың турында тәки сөйләмәдең бит әле. Сүзеннең башында, аңа барып житә алсак, дигән идең. Менә килеп тә життек...

— Әй, шулай бит әле. Батырлык дип... Батырлык та түгел инде ул. Минем үземә, кем әйтмешли, шаян холкыма бик тә япьтәш килгән бер мәзәк хәл инде ул. Синең ышанмавың да... Син ышансаң, башкаларның ышанмавы мөмкин. Ул шунысы белән кызык: миңа Брянский фронтында чынлап та батырлык дип исәпләнерлек гамәл өчен орден бирмәсәләр, бу юлы батырлыкка якын да килмәгән бер көлке хәл өчен «Дан» ордены белән чәпәделәр. Йомшак жиргә. Әйе, чынлап!.. Ярар, тыңла. Безнең рота Кунерсдорф авылын бер омтылыш белән ала алды. Сугышта бер операция икенчесенә һич кенә дә охшамый. Бу юлы безнең һөҗүм өчен сайланган сәгать тә, артиллерия әзерлеге дә, яшерен рекогносцировка чаралары да бик уңышлы оештырылган булып чыкты. Дошман өчен бу шул кадәр дә көтелмәгән һөҗүм иде ки, алар аңнарына килгәнче авыл безнең кулга күчкән иде инде. Безнең яктан нибары ике генә корбан булды. Утызлап немец әсирлеккә төште. Менә шул уңыштан соң без командование исеменнән бераз булса да исерергә тиеш идек. Төшке аш вакытында кеше башына икешәр йөз грамм шнапс бирделәр. Минем тышка чыгасым килде. Авырдан, каһәрен. Аны-моны уйламыйча, үзем белән хәтта корал да алмыйча — имеш, жиңүче! — янәшәдәге урманга киттем. Кәеф шәп. Вакыты-мөмкинлеге булганда тәһарәт тә алгалаган мөселман кешесе, жиң астыма сулы савыт та яшереп, куерак урынга кереп утырдым. Эшемне бетереп, тордым. Чалбар каешларымны эләктергәндә... карасам... инәкәй генәм!.. Күзем шар булды: мине өчесе өч яктан уратып алып, каршымда, кулларын күтәреп, әзмәвердәй өч немец басып тора. Куркышымнан яңадан утырыр хәлдә идем. Тукта, Сибгатуллин, дим һәм бар көчемә:

— Һенде hoh!.. — дип кычкырып җибәрәм. Тавышым шундый да көр чыкты, әллә минеке түгелме дип куркуга да төштем.

Нәрсә «һенде-hoh»лап торырга, алар үзләре әллә кайчан һенде-hoh бит инде. Хәзер, сугыш Берлинга җитеп килгәндә, һәм инде бүгенге җинелүдән соң, аларга акыл керә башлаган гади немец балаларына, җир йөзендә иң кадерле нәрсә иде? Гомер иде! Аларга хәтта совет әсирлегендәге гомер дә кадерле гомер иде!.. — Абзыйсының күнеле йомшарды. Ул караваt башына элгән чүпрәген алып, яшен сөртте. — Миңа кирәк гомер аларга да кирәк иде!. Берни булмагандай, өчесенең дә автоматларын җирдән күтәрдем, икесен иңемә асып, берсен күкрәгемә алып, миннән герой ясаячак дошманнарымны карурман сукмагы буйлап командованиегә китереп тапшырдым. Син сораган «Дан» орденының тарихы шундый. Тиешле орден бирелмичә калса, тиешле булмаганы миңа тәһарәт алганда күктән төште...

Ул карашын бер ноктага текәп бераз уйланып торды.

— Һаман да язам дип утырасыңмы?

— Әйе.

— Ярар. Аның өчен берәр биреләчәк наградаңнан буш калмасаң... Хәзер кемгә барасың соң?

— Авылда, беләсең, синнән башка ике фронтовик калган инде. Башта Сафуан абзый, аннан Закирҗан абзыйга барырга иде исәп... Өйдә булсалар...

— Өйдә булмый кая китсеннәр. Сәлам әйт. Бик яхшы кеше ул Сафуан абзый. Заманында нык кына салса да, хәзер намазлыгыннан төшми. Ә менә минем намазлыкка күтәрелгәнем юк... Һәркемнең Аллаһ белән үз исәп-хисабы бар. Сафуан абзый Башкорт атлы дивизиясендә хезмәт итте. Аның хакында авыл халкында, имеш, кулына үзе атып кайткан, дигән сүз йөреде. Гайбәт ул. Безнең авылда минем ише хәйләкәрләр бар, әмма сатлыклар юк. Өязе суын эчеп үскән кеше түбән җанлы булалмый. Ә менә Закирҗан абзый ул сугышның чын кара сукачысы... Дөрес, бераз ерткычрак. Авыл түрәсе — бригадир булды бит... Өлкән лейтенант. Ишетми, колагына мамык тыгып бар...

Тәлгатнең абзыйсына тагын берәр мөһим, җан өзгеч сорау бирәсе килеп китте. Әмма ул сорау аның башына һич кенә дә килми иде...

—Сабирҗан абзый!.. — дип кычкырып җибәрде ул кинәт, алтын тапкандай. — Синең телең бик матур... Сайрап торган әдәби тел. Бик укымышлы да булгансың... Син яшь чагында шигырь язмадыңмы?

— Юк... Аллага шөкер!.. Шагыйрьләр акылга җинел халык бит алар... — дип киерелеп көлде Сабирҗан. — Үсмер чакта күзе төшкән кызына шигырь язмаган бер мин генә калдым бугай. Мин аларга шигырь багышлап вакланмадым, яраттым гына... Теләсәм дә, язмый, нык тора идем. Язган булсам, бәлки, Кадыйр Даян абзыйлардан ким шагыйрь дә булмаган булыр идем. Нигә кирәк ул шигырь? Шигырь кешенең эчен актарып чыгара. Аның белән баеп та, хәйләкәр булып та булмый...

Абзыйсы аны озатып калырга дип ишек алдына чыккач, Тәлгатнең фотоаппараты барлыгы исенә төште.

— Чәкетеп алыйм әле, Сабирҗан абзый!..

— Пжалысты!.. Анысы гына була ул... — диде дә, нидер исенә төшкәндәй, кире борылып, өенә кереп китте. — Тукта!..

Һәм башына мәчет картлары кия торган ак җинел кәпәч — кәләпүш киеп чыкты.

— Шулай яхшырак булыр!.. Кәләпүш кешегә нур өсти!..

Бу Тәлгаткә дә ошады. Ул аны җилкапкага куллары-аякләре белән таянган килеш төшереп алды.

## III

Урам буйлап Сафуан абзыйларга барганда ул туктаусыз Сабиржан абзый турында уйланды. Кара, нинди серле хәлләр!.. Ярый әле кайткан!.. Кайчан белгән булыр иде бу кадәр серләрне? Сугыш ул — хәвеф режимы, анда исән калу өчен көрәштә һәр чара үзен аклый, тик үз иптәшләренә генә зыян салма, диме? Ул, язучы буларак, үзендә бер сирәк тойгы тойды: Сабиржан абзасының кылган гамәлләрендә, бер караганда, без сөйләп, язып өйрәнгән батырлык та юк кебек, әмма яшәү батырлыгының сере бар, матурлык, юк, яшәү матурлыгының сере бар иде... Авылдан чыккан ике йөз ир заты сугышта кырылган, шуларга өстәп, имгәнеп кайткан ике йөзләп ир заты авылда вафат булган, Сабиржан абзый күкрәк киергән батыр да түгел, куак артына качкан куркак та түгел, әмма исән иде!.. Йомырка кебек түгәрәк сугыш ветераны иде!..

Боргалана-боргалана авылның аргы очына барып чыккан Өязе күперенә житәрәк, туктап, бераз уйланып, һушын җыеп торды. Авылның бу очы — икенче, Тәлгатләр очы исә беренче бригад санала иде. Ике очта да колхозга куып кертелгән халыктан тартып алынган буралардан корыштырылган иркен ат сарайлары иде... Менә бу урында икенче бригадның ат сарае, анда йөз дә илле баш елкы малын караучы Сафуан абзыйсы, сабый чакларыннан хәтердә калуынча, ул үткән саен кое сиртмәсенең суы агып торган тишек бидрәсен донгыр-донгыр китереп атларын эчерә торган иде... Ул колхоз таралганчы диярлек шул бер эшендә — ат карауда булды. Шунысы кызык: өч ат караучының да исемнәре Сафуан, аларны тик кушаматлары белән генә аералар иде: Шытыр Сафуан, Йомыйк Сафуан һәм Әндри Сафуан. Халык аларны кызык итеп сөйли торган иде. Шулай бер мәлне ат абзарында күрше авылдан килгән салым инспекторы: «Сездә Сафуаннар буа буарлык. Син кайсысы буласың?» дип сорагач, йомшак күнелле, чебенне дә рәнжетмәс Йомыйк Сафуан «Әйе, бездә күп алар, мин Йомыйгы булам инде, Йомыйгы» дип алдында биеп торгач, инспектор буыла-буыла көлеп, түләтәсе салымын түләтергә онытып китеп барган, имеш. Халык сөйләсә сөйли инде ул. Әйе, икесе мәрхүм инде. Кая ди сугыш яугирләре генә, хәтта ат сарайларыннан да, коедан да эз дә калмаган. Халыкның күз яшендә ничек көчләп оештырылган булса, колхоз шундый ук күз яшендә таралды да бетте. Таланган малда мантып буламы? СССРың, Рәсәен кара!.. Ил таланып, тел таланып, кием-салым таланып, хәтта җырлары да таланып ясалган!.. И-и, бу үткән гомерләр!.., Бер Әндри Сафуаны гына исән. Ике ай гына элек 102 яше тулган икән. Менә ул аның белән очрашырга бара. Сафуан абзый Тәлгатнең әтисеннән бер яшькә зуррак, алар бергә авыл мәдрәсәсендә укыган. Әтисенең һәлак булганына инде 66 ел, ә менә аның балачак дусты, култык астына түмәр кыстырып мәдрәсәгә барган шәриктәше Сафуан, Аллага шөкер, исән-сау!

## IV

Ул жил капканы бавыннан ычкындырып, тавышсыз-тынсыз гына эчкә үтте. Әйе, иртә килгән язлардан соң ишек алларында күпереп үскән бәбкә үләненә җәелгән чүпрәк паласта аякларын суза биреп, сары кавынга охшаган карт утыра. Сафуан абзый танавы астыннан нииндидер мөнәҗәт сүзләре мыгырдый-мыгырдый, кулындагы таягы белән паласын, чебенкигәвен кугандай, каккалый-суккалый, янәшәсендә генә сары йомарлам шикелле тәгәрәшеп, бипелдәшә-бипелдәшә үләндә чемченгән бәпкәләрен саклап утыра иде. Якынрак килгәч, ул хәлсез карт бала кучләрне яба торган кечкенә, искергән-муртайган түмәр умартаны хәтерләтеп куйды. Тәлгат аның борын төбенә килеп туктады. Нәкъ менә шушы бәбкәләре арасында

чәкетеп алды ул аны сурәткә. Кыска буйлы, какча, өстенә ыргытып, табырдагы елкы малын тотып ала торган корык агачы кебек кипшенгән гәүдәле, гадәтенчә, мыегын мыек, сакалын сакал дип атап булмаган, кырынса да, кырынмаган булып күренгән Сафуан абзый аны шәйләмәде дә кебек. Инде бернichә ел күрмәгән йөз дә ике яшьлек авылдашын ул сагышлы сагыну белән күзеннән кичерде. Шулай да биредә һич кенә дә үләргә җыенган кеше юк иде. Куанычыннан күзенә яшь тиртте. Мондый аксакалларыбыз булганда авыл үлә диме?! Ярый әле кайткан! Мондый сирәк манзараны кайчан күрер иде? Малның исен-косын да оныткан иске абзар, тәртәләре шул абзар лапасына күтәреп куелган иске фурман, елак яшел үлән һәм яшь балавыздан йөгереп чыккан сары бәбкәләр!.. Һәм Бөек Җиңү көненә алтмыш биш ел тула дигән көннәрдә бәбкәләрен өсләренә дошман самолетларына охшап —әмма гүелдәп түгел, ә шым гына!— килгән тилгән-мазардан саклап утырган фронтовик-ветеран... Инде тәмам күзгә-күз диярлек якынайгач, шырт сакаллы Сафуан абзый үзенең кояшта пешенгән, куырылган йөзе, яктылыктан кеше күрмәс дәрәҗәдә кысылган күзләре, танау һәм колак тишекләре белән эре күзәнәкле орлык бәрәңгесен хәтерләтте. Ул иске һәм яңа, таныш һәм таныш та түгел иде...

— Исән генәме, Сафуан абзый!

— Исән генә... Менәтерәк... Кыш үтермә, җәй үтер, ач үтермә, тук үтер, дип яшәп яткан булам әле ... — Карт күзен тагын да кыса төшеп, тавыш килгән якка карады. — Кем буласың соң әле син?

Авылдашы шушы яшендә дә һаман да шул шаян Сафуан булып калган иде.Тәлгат үз исемен атады.

— Ә-ә-ә, синмени әле, Тәлгат улым, — диде карт, җанланып китеп, кулындагы таягын паласына ыргытты һәм тирәсендә чөкердәшкән бәбкәләр арасыннан үзе дә бер картайган бөркет сымак талпынып, ач бүредәй, тирә-ягына ике тапкыр әйләнеп карап, ике кулын сузды. — Әйдә, күрешик, булмаса...Мә, бер йөз яшьлек юньле кул тот. Кайткан дигәннәр иде шул. Гаиләләр, бала-чагалар исән-саулармы? Йөргән-яшәгән җирләр бәрәкәттәме? Нинди эшләр җимереп йөрисең? Китаплар язылламы? Үзенә Казаннарда кадер-хөрмәт бармы? — дип, сорауларын тезеп китте.

Тәлгат бу сорауларга булдыра алганча тулы җавап биргәннән соң кайтуының сәбәбен аңлатты.

— Җиңүче дип аны... Моңа кадәр үзебезне җиңүчегә санап йөри идек тә... Соңгы вакытта кемнең җиңүче икәнен онытып киттек бугай... Җиңелүчеләр җиңүче булып безнең көрсигә утырды түгелме? Юк, хуҗалык маясында германнардан күпкә артка калуыбызны... безгә дигән кәнтрибүтсине ябрэйләргә генә түләп ятуларын әйтмим. Анысы вак мәсьәлә. Монда мәсьәләнең эреләре тулып ята!.. Татар авылы корыды. Хуҗалар аны коммун башлары белән сыерларын ужымга кертеп корыттылар. Балтыйк буеннан салам белән килгән корт тәмам шашты, мәлгунь. Кармавыч белән әрекмән генә калды... Безнең кәнститутси кая булды икән? Чучканың да кәнститутсисе бар бит әле... — Авылның болай да гадәттән тыш шаян, хикмәтле, тапкыр, бай телле, матур күңелле, әйтергә кирәк, шаукымлы кешесе, йөз яшь тулып узуына карамастан, үзенең Аллаһтан төшкән сыйфатларына хыянәт итмичә, акылының энҗеле каймаларын, хәтеренфигылен кәтрә дә югалтмыйча, шулай саф килеш саклаган аксакалы, мондый сөйләшүгә аерым бер сусау белән сусаган тере җан иясе, шундук сүзендә чишелеп китте. — Ходай Тәгалә миңа өч тапкыр өйләнергә, унике бала үстерергә, менә шушы куллар белән өч йорт-җир бетерергә насыйп итте. Әмма туган нигездә төпчекне дә калдыра алмагач, мин нинди җиңүче булыйм ди? Бабайлар нигезе бит төпчекләр белән сакланып килгән.Ә безнең

төпчекләр нигез җимерүче булып чыкты. Кем гаепле? Үзебез! Мин аларны нигезгә, чишмәгә тарттым, безнеке булмаган влач, безнеке булмаган мәктәп аларны миннән, нигездән, чишмәдән мәйданга-шайтанга тартты. Күбесе бүген шәһәрдә трай тибәләр... Элегрәк хет мал суйганда кайталар иде. Хәзер, мал да суймагач, кайтучы да юк. Авылдагылары төшереп алалар да, капка төбендә казык булып басып, эш юклыктан зарланалар. Нинди эш?! Син бит эш өстендә — җирдә басып торасын. Мал үстер, әнә акланнарда үләнне чабарга кеше юк. Иген үстер, яланнар чәчелмичә ята... Нәкъ сәвит чучкасы кебек, режимлы ашап, тиз симердек. Син, тел падишаһы, «взять, взятка» дигән сүзнең татарның «үҗәт»еннән алынганын, шәт, беләсеңдер. Вжять!.. Вжять яво!.. Авылда ике малаем бар, әмма киленнәрнең биатай белән яшисе килми!.. Вжять яво!.. Бичәм биш ел элек вафат булды. Кызым белән яшәп ятам...

Тәлгат сиздермичә генә әңгәмәдәшенең йөзенә, аннан күзләренә игътибар итте. Ул аларда ярылып яткан каршылык күрде: битенең тиресе никадәр картайган, авыз читләре, бугаз тирәләре никадәр ләшперәеп җыерчыкланган, өсте-өстенә менеп, тирән-тирән буразналар белән ергаланган булса, күзләре шулкадәр яшь һәм милли очкынлы иде. «Моның күзләре минекеләрдән яшьрәктер, мөгаен. Әллә саклык кассасында саклаган инде... — дип уйлап алды Тәлгат. — Аның 66 ел элек һәлак булган атасыннан бер яшькә картрак булган кешенең күзе шулкадәр дә нурлы һәм гайрәтле булуы мөмкинме? Булса, сере нидә? Язмасында шуның серен ача алмасмы?»

Әмма аңа бу сергә бик авыр булган сугыш темасы аша барасы иде шул. Тик карт, сорау бирерлек тә ара калдырмыйча, әле һаман үзенекен сөйли иде. Аны башланган сүз юнәлешенә якынайту теләгендә картның гомере буе ат каравын, хәзер инде авылда колхоз белән бергә ат сарайларының да җимерелеп бетүен искә алуга, ул, кайчандыр шушы үзе эшләгән тарафларга күз ташлап:

— Исемә төшермә!.. Явыз кеше мин!.. Сугыш явыз иткән кеше!.. Тыныч тормышта үз кулларым белән йөзләгән колын кабул итеп, фронтта үз кулларым белән үләлми яткан йөзләгән яралы атны чалып ташлаган... атып үтергән явыз кеше!.. Адәм үлемен күрү авыр, ат үлеме монардан да авыррак!.. Син күрсәң иде яралы ат күзендәге сагышны!.. Эскрипкә инде, малайгынам!.. Ишледән Сукыр Сәгыйть тальян уйный диярсең! Хәзер күккә карарга тартынам. Аннан йолдызлар миңа үзем чалган ат күзләре белән карыйлардыр кебек... Колхозның абзарлары гына түгел, барлык мал-туары да дөньяга ат күзләре белән карый иде. Ат тартты татар нужасын, ат... Ат аның йөкчесе генә түгел, гайрәт канатчысы!.. Колхоз дигән үләт татарга урыс-мукшыга караганда авыргарак төште. Чөнки без, мал-туар сөйгән күчмә халык, патша заманында да маллы булдык. «Үземә дә бер күкәй, сәвиткә дә бер күкәй, көн дә күкәй салалмыйча асылынамын, түтәй» дигән тавык җырын хәтерлисеңдер. Сарай-келәтләр халыктан ничек талап алынсалар, шулай таралып, җимерелеп тә төштеләр. Гөнаһка килгән нәрсә шалтырап коела. Утызынчы еллар башында мәчеттән ясалган клуб сәхнәсен Ибраһим абзыйның урыс капкасыннан әтмәлләгәннәр иде. Хәзер мәчет юк, клуб бар, анда сәхнә дә бар, биергә кеше генә юк. Менә ничек Аллаһ җәзалый!.. Күпме йокысыз төннәр үткәрдем мин ат дворының кайры тунында? Тун дигәннән. Мин фронтка үз тунымда киттем. Гаскәр биргән тунны кимәдем... Сугыштан соң, саламсыз да калган көннәрдә мин атларымны райкомнан килгән коры салам түгел, ялан баланы белән тукландырдым. Ашата белсәң, ат ялан гына түгел, балан да ашый!.. Малга сукма, үзенә сук!.. Мин укыган кеше түгел, бар укыганым әтиең белән бергә ике еллык авыл мәдрәсәсе. Миллионның күпме икәнен белмим... Акча саный белгәч, житкән!.. — Ул

кеткелдәп көлеп җибәрде. — Әмма атларыма син әйткән тишек бидрә белән миллион бидрә су эчергәнемне беләм. Кеше ничек шулай аңлы була икән? Кызык бит, ә? Мин бит укымаган, әмма миллионның күпме икәнлеген беләм, аңлыйм диген, ә?!..

— Сугыш турында... — дип искә төшерде язучы, картның күп сөйләүдән хәле бетеп китүеннән шикләнеп.

Колакка сак, үз хәленә караганда тизрәк кунакның хәлен алырлык карт аны шундук бүлде:

—Син миңа мина сугыш турында сөйләргә кушасың. Минем сугыш турында һич кенә дә сөйлисем килми. Нишләптер барысы да гел генә сугыш турында сөйләргә кушалар. Бу хакта телевизор сөйләгәне дә баштин ашкан бит инде. Жыларга да, жырларга да кушмыйлар. Ә бит жылый идек! Ничек кенә!.. Жырлый идек!.. Печәннән кайтканда!.. Ничек кенә жырлый идек!. Жыр дигәннән. Аны бит, көең булмаса, сугыш кушса да жырлап булмый, каһәрең. Көйне белү генә житми. Шулай, сугышка алынгач, карантин үткәндә, егылганчы стройда... нигә бәреп екмыйлар икән, ичмасам, дигән хәлгә житкәнче торганда... аяклар туңган, ач карында тегермән ташлары әйләнә... Агач кашыкларыбыз нәзек чылбыр белән гимнәстүрке каешларына бәйләнгән-бәйләнүен, ашарга гына юк!.. Әрмия кәтәлүге ачы кәбестәдән арынмый. Туң аякларның жылап булса да жылынасы килә, ә монда сиңа тиле шикелле авыз тутырып жырларга кушалар. Кая урысча жыр, таң саен әжәл көтәбез. Менә шушы сарылы-яшелле бәбкәләр кебек жыен татар-башкорт балалары кайсы боерыкның уңга, кайсының сулга икәнен дә аешмый. Беркем жырламый. Мина килә командир, авызыма кердәй булып:

— Жырла!.. Нигә жырламыйсың? — ди. — Шо ыстоииш как истукан?

— Жырлыйм бит, иптәш командир! — дим. — Кычкырып жырлыйм!..

— Жырлыйсың жырламый ни!.. Авызынны гына ачып ябасын!..

— Жырлар идем, өйдә биш балам ач утыра! — дим аны-моны уйламыйча.

— Ышту за разговорчики! — ди бу. — Биш балаң өчен жырла!.. Ике нәрәт за непослушанье!..

Мин сугышны ике нәрәт, биш патрон белән башладым. Воронеж янында кердем мин ана беренче тапкыр. Сугыш яланыннан таш багана булып каткан үле солдатларыбызны жирләмичә ташлап киттек бит без!.. Гөнаһын кая куярмын, ахирәттә Аллаһы Тәгаләгә ни дип жавап бирермен?! Шунысы, сугыш яланында, өстенә ыжгырып дошман килгәндә, башына беренче булып бисмилла килә. Нигә шулай икән? Бездән бит бисмилланы куганнар иде! Ә ул килә!.. Бисмилланы белмим дип әйтмичә йөргән бисмилласызлардан да бисмиллаһ әйттерә бу сугыш. Һөжүмдә халык никадәр күмәк булса, кеше үзен шулкадәр ялгыз тоя... Ул үз кальбендәге Аллаһ белән генә сөйләшә. Бернинди командирны, генерал-маршалларны танымый. Аңа Аллаһы Тәгалә генә генерал. Аллаһ белән кеше арасындагы бер арадашчы калмый. Штат кыскартыла!.. Мин шуның серенә төшенә алмадым, туганым... Кеше затының үлем каршындагы ялгызлыгын аңлыйм мин... Әмма монда нииндидер икенче сер дә бар кебек... Менә сиңа кечкенә бер тарих. Без Воронеждан ерак булмаган бер хуторны өч тапкыр алып, өч тапкыр бирдек. Исеме, ялгышмасам, Старица бугай. Безнең атлы эскадронны, югарыдагы командирларның нииндидер бер тилесе, пехотага һәм тупчыларга ярдәмгә дип, снаряд ташырга тараттылар. Кавалерия аты колхоз малы, йөк ташый торган ат түгел ләбаса, алар кылыч-айкаш, чабыш атлары... Чабыш аты йөкне тартмый, прусты тарта алмый, мескенкәй. Шулай булса да, тәртәгә үзем дә жигелеп, алгы сызыкка аның белән биш йөк снаряд китерә алдым.

Хәлдән тайды, күзе тилерде, кан белән пошкыра башлады, бахыр... Шулай тимер юл астындагы күпергә килеп керәм дигәндә дошман самолетлары килеп чыгып, бомбага тота башламасынмы!.. Их, кая безнен үзебезнен Өязе — Дим буйларыннан килгән йөк атларыбыз? Туктады бит Доннан килгән нәзек билле Лүдечкәм!.. Ни алга, ни артка!.. Сикереп төшеп, камытка килеп сарылдым: «Ложись, малкай!» Анлый!.. Ышанасынмы, Дон буеннан килгән өйрәтелгән казачи атлар үзләрен мондый заданиегә җибәргән генераллардан акыллыраклар, — ятты, малкаем!.. Нәрсә булса булыр дидем дә, күпер астына кермәдем, атым белән янәшәдән жиргә сендем... Күзгә-күз, колакка-колак. Ат күзендә мин үлем түгел, мон күрдем. Мин шушында инде ничәнче тапкыр сугышның никадәр мәгънәсез, имансыз һәм каһәрле бер гыйлләт икәнлегенә инандым. Ул мина да, минем миллион тишек төпле бидрәмә дә кирәкми иде. Мин аны, Гитлер башлаганмы, әллә Сталинмы — аермадым: ул минем өчен берәүнен икенчедән өстенлеге өчен үтерү ярышы булып, аны күрә алмас нәфрәттә кайнадым. Тирә-ягымда фью-фью килеп ядрәләр сызгырыша, бомбалар шартлый, ә минем телемдә әллә нинди сүзләр, мин белмәгән-ишетмәгән авазлар кайнаша иде. Нәрсә бу? Без бит, бер карасаң, Дон ярларыннан килгән атым белән икәү үлем каршындабыз... Телемнең сүз ирке белән нәрсәдер сөйлисе, кулымның гамәл ирке белән нәрсәдер язасы килә: әмма сөйли дә, яза да белмим! Укымаганмын!.. Житмәсә, өстебездә күкләрне умырып-умырып, самолетлар котыра.. Кинәт кенә дөнья тынып калды. Телләрем кабатлый:

Мең дә тугыз йөз дә кырык бердә афәт килде
Гитлер белән бергә,
Коточкыч фетнә башланды бездә,
Канлы яшьләр түгелде жиргә.
Сугыш бөек дибез, бу — хаксызлык.
Адәм жанын алу затсызлык.
Телəге барда бетәр бу оятсызлык,
Кабил белән Һабил булу — кансызлык...

Башымны күтәреп карыйм: дәжжаллар киткән. Ни-нәрсә булды соң бу? Ат белән янәшәдә ятканда минем күнелемә беренче тапкыр шигырь килгән икән бит!.. Менә Аллаһының рәхмәте нинди була. Үзем укымышсыз булсам да, укымышлы бабаларым стройда җырлатмый, әмма үлеп ятканда шигырь җибәрә. Әйе, хак, мина, искечә дә, яңача да укый-яза белмәгән кешегә, нәселемнән, ата-анамнан шигырь иңгән!.. Әт-тә-тә ул шигырь дигәнең аңлаган кешегә!.. Күп нәрсәләрне оныттым бу су буеннан да озын гомеремдә, әмма шушы шигырьне генә онытмый хәтер. Моның сере нәрсәдә? Укуда гынамы? Син, укыган, әйт!.. Снарядларны пазитсигә китереп житкерергә насыйп итмәде. Якында мина шартлап, атым да, үзем дә яраланып, аңнарыбызны җуйганбыз...

Карт тагын берничә сугыш истәлеге сөйләп алды. Бер караганда, Тәлгатнең язарлык маясы тупланган иде. Аңа инде хәзер китәргә дә була иде кебек. Әмма аны балачактан ук ишеткән, әмма әле дә булса ачыкланмаган, сер булып калган бер сорау борчый иде. «Сораргамы, юкмы? — дип бораулады аның миен бу фикер. — Кабер якасында торган карт яугирне үпкәләтмәсме?» «Сора, сора, — диде аңа икенче тавыш. — Кешенең маңгаена язылган язмышы кәгазьгә дә язылырга, башкаларга сер булып калмаска тиеш. Бу хакта әле булса туктамый бит әшәке телләр. Имеш, кулына үзе аттырып кайткан да, бүген утыз мең пинсә ала... Әгәр ниндидер ачыклык кертсә, бәлки, карт солдатны вафаты алдыннан булса да гайбәттән коткарыр иде...»

Әллә кагылмаскамы? Ничек булган,шулай калсын. Юк, әдипнең эчендә теге икенче тавыш бу теманы туган авыл халкының намусы, әдәбе — хакыйкать каршында күтәрелүен тели иде. Һәм ул — ни булса да булыр! — аңа ярдәм итү — авыл халкын гайбәт гөнаһыннан коткару ниятендә бу хакта сорарга булды.

— Сафуан абзый... — диде ул, яхшы ишетсен өчен тавышын күтәрә төшеп. — Сиңа, бәлки, мондый нечкә сорауны беркемнең дә биргәне булмагандыр. Гафу үтенәм, әлбәттә. — Тәлгатнең йөрәге еш тибәргә тотынды. — Әгәр кирәкми дисәң, икебезнең арада гына... Язмамда аңа кагылмам да. Әмма дус бар, дошман бар дигәндәй...Сөйлисең килмәсә, сөйләмә. Әмма мин, сезнең язучыгыз, бу сорауны хәтта син аңа җавап бирмәгән очракта да бирмичә калалмыйм. Минем сезне гомерегез азагында яклыйсым, аклыйсым килә.. Бу нахактан син күпме кыйналдың!.. Шул хакта аңлатыбрак китсәң...

— Аклама син мине!.. Минем моңа мохтаҗлыгым юк!.. — дип кычкырып җибәрде аксакал. — Син теге самострел мәсьәләсен әйтәсең инде?.. — Ул карашын бер ноктага текәп, уйланып калды һәм көлемсерәде. Аннан, бая ташлаган таягын кулы белән паласын каккалап алды да, сорауга туры җавап бирүдән читләшеп, сүзен дәвам итте. — Мине исән калу бәхетемнән көнләгән дошманнарым сүзе бит ул... Кем әле минем гомеремнең азагын билгели?! Анда кемнең алдан барачагын хәтта сезнең ише язучылар да билгели алмый! Бер Аллаһ кына!.. Мине акларга да кирәкми!.. — Ул тирә-якка ачулы караш ыргыткандай булды. — Мин үзем дастуен!.. — Карт гүя ки бу сораудан үзендә өстәмә көч тойган иде.

— Шулай, карантин үткәннән соң, безгә кызылармис кенәгәләре тараттылар... Әй, тукта әле! Синең ул замандагы әрмис кенәгәсен күргәнең дә юктыр әле... Сабира!.. Сабира, дим!..

Әтисенең һәр авазын тишек колак белән тыңлаган кызы болдырга йөгереп чыкты.

— Менә Тәлгат абзаңа минем кызылармис кенәгәсен чыгар әле!.. Шунда спут[1] башында гынадыр!.. Ваянкамат килсә дип шунда гына куйган идем...

Шушы кадәр гомер яшәгән аксакалның саф хәтеренә әдип тагын бер мәртәбә таң калды. Ул Өязе буенда берәр мәңгелек тамыр табып чәйнәгән мәллә?

— Әйе, тараттылар... — дип, карт фикерен искә төшереп, дәвам итә башлап өлгермәде, Сабира 1941 елдан сакланган хәрби билетны әтисенең кулына китереп тә тоттырды. — Төчедән булса да коймагынны җиткер!.. Чәеңне янарт!.. Баздан бал алып чык!..

Язучының уч төпләре пешкәндәй булды. Әйе, яугирләр турында күпме язып, аның сугыш башлангандагы гади солдат кенәгәсен күргәне һәм кулында тотып караганы юк иде. Әйе, оешып карайган кан кебек кара-кызыл төстәге, учка сыярлык дәрәҗәдә кечкенә, сугышларны, җил-давылларны үткән катыргы үзе дә җил кебек юкадан-юка, хәтер кебек сабырдан-сабыр, гайре энциклопедияләрдән мәгълүматлырак китап иде.

— Менәтерәк, укы! — диде карт солдат. — Нигә тынып калдың? Укый беләсеңдер ич!..

Тәлгат аңына килеп, аның үзе турында белешмәләрен укыштыра башлады.

— Сибгатуллин Сафуан Галимәрдән улы... Татар. Грамотасыз...

Абзыйсы аны шундук:

— Безнең ише вак-төяк турындагыларын укып торма! Безне болай да беләләр. Маршал Жуков түгел! — дип бүлдерде һәм кеткелдәп көлеп тә куйды. — Минем әрмедәге хосусый милкемнең исемлеген укы син!.. Хәзер

[1] Спут (диал.) — мич

мондый дукәмәтне күз алдына да китермиләр. Иләндә малсыз калган татар солдатының плингә төшкәндәге байлыгын барла!..

Тәлгат кенәгәне актарды һәм берничә бит алга китеп зур исемлекне укый башлады:

— Гимнастерка... Размер... Галифе... венгерка... плащ-палатка... лямка... бляшка... ремень... — Тәлгат татарчага тәрҗемә итә башлады. — Эчке ыштан-күлмәк... Бер пар чолгау... Каеш... Бүрек...Агач кашык... Кәтәлук... Инә-жеп...

— Аларын да укып торма. Ат күренмиме анда? Ат? Каклаган каз күренмиме?

Тәлгат картның шаяртуын да исәпкә алмыйча, исемлекне тагын бер кат тикшереп чыкты. Әмма атны табалмады.

— Монда ат күренми...— диде ул аптырап.

— Күренмидер шул... — дип уфырды карт. — Ә мин фронтка үз атым белән киткән идем. Шарты шундый иде. Мин генә түгел. Тагын да сигез сөлектәй... берсен санамаганда жегетебез... Мәрхүмнәр... Ару кешеләр үлеп бетте. Мин генә азакка калдым... Урыннары ожмахта булсын... — Картның күнеле йомшарды, ул озак кына янында чөкердәгән бәпкәләргә карап торды. — Атларыбызны алып, безне яңаларга атландырдылар да бит... Ат бит ул менеп-жигеп йөри торган жан иясе генә түгел. Ат ул — исем, киләчәк афтаритит, машина-өрәкитә дә!.. Шуна күрә кешедән «Атың нинди?» дип сорыйлар. Шул атларыбыз кая булды икән, мәрхүмнәр дип әле булса ут йотам. Ачка үлделәрме? Әллә ит комбинатына озатылдыларммы? Гомерем мал арасында үтеп, мөселман бәндәнең һәм хөкүмәтнең мал сую аермасын беләм. Хөкүмәт ничек суйдыра? Бу хакта аларга сүз әйтәсе булма!.. Ашаганда кашыгыңны тартып алып, маңгаена кундырырлар. Ит комбинатында мал суйганда күсенең башына көрәк белән генә кундыралар да, ул теге баштан колбаса булып килеп тә чыга...

Ул бераз тын алып торгандай итте.

— Ә син сугыш та сугыш дисең... Безгә шул сугыштагы чын жиңүчене табарга кирәк. Һәр сугышның иң авыр бурычы бу. Ул мине биш, мин аны алты тапкыр үтереп кенә жиңү коры жиңү генә әле ул. Жиңүнең мәгънәсе бүтәндә. Аның жимешләрен файдалана белү ул чын жиңү... Мина ваянкаматтан, имеш, үлгәч, һәйкәл куябыз, диләр. Нигә кирәк ул мина? Жиңгәч, сез үзегезне жиңүгә алып чыккан минем атыма һәйкәл куегыз! Жиңүчеләргә тиң итеп тормышны яхшыртыгыз!.. Менә ул чын һәйкәл нинди була... Укымышлы кешеләр Жир шарын бик зу-у-ур диләр. Мина шул зур Жирнең шары атларымның кечкенә күзеннән күренде. Шулай яшәдем мин. Йөз дә ике яшь. Әллә шуна озак яшәдем микән?.. — Картның тавышы нечкәрде, ул ак күлмәгенең жиң очы белән яшьләрен сөртеп алгандай булды. — Минем хактагы теге яманатны да авылыбыздан атсыз калган бер зат чыгарды бит, явыз... Мин ул өйләнәсе кызны тартып алган идем!.. Мин атсыз гына калсам, ул атсыз да, затсыз да, яманатлы да булып калды. Ул мине пычрата-пычрата теле череп үлде. Исемен әйтмим, беләсең. Әйе, тәкъдир дигән нәрсә бар. Тиле ядрә кайда кунарга дип кулынны-биленне сайлап кунмый. Самострел!.. — Карт чак ишетелерлек итеп тирәннән кеткелдәп куды. — Бар, ясарсын!.. Анда ахмаклар утырмый. Трибунал!.. Тик шунысы, кулыма андый самострел ясаганчы мина ярчыгы янбашымны умырып алган иде шул инде... Соравың өчен рәхмәт, улым. Шуның өчен генә дә кайтасың булган. Ә мин бит синнән бу сорауны гомер буе көткән идем... Бирмәдең. Бүген килеп бирдең, нәкәнис... Рәхмәт, яме!.. Мин гомер буе газапландым: теге самострел ядрәсен миңа үз авылдашым жибәрмәде микән дип? Бер тапкыр үзенә дә әйттем. Ыржаеп кына куйды.

Әйе, төрле кеше бар иде... Көлсәң — көл, еласаң — ела. Безнең авылдан Газизҗан бар иде, мәрхүм. Иләс-миләс җегет иде шунда. Фронтка алмадылар. Трудармиясен исәпләмәгәндә, авылдан чыкканы булмады. Ике ел буе авылына хат язмаган. Кайткач, «Нигә язмадың? дип сорагач, «Анда, фронтта, хат кайгысы юк, адресыгызны оныткан идем», — дип җавап биргән бу... Ә кулым яраланып кайту тарихы ул бик гади генә. Оборонда ятабыз. Блиндажыбызның ишегеп бик тар иткәнбез, тәбәнәк тә. Иренгән ике эшләр дип бабайлар юкка гына әйтмәгән шул. Заданиедән исән-сау кайтып кергәндә винтовкам шул тәбәнәк ишеккә эләгеп калды. Кулымны чыгарып көбәкне ычкындырыйм дигәндә генә бар отделение күз алдында адашкан ядрә мине яралап ташлады. Менә бит ул ничек була сугышта, туган, дошман тупсасында йөреп тә тота алмаган ядрә мине үз тупсама исән-сау әйләнеп кайткач килеп тапты.

Тәлгат бу сөйләшүдән бик канәгать иде. Икесе бер авыл кешесе, аның язучысы исемен күтәреп, шушындый матур, күңелле, бай тарихлы кешеләре турында язмый йөргән диген,ә?! Инде бүген өченче, Сафуанның күршесендә генә яшәгән Закирҗан абзыйсы белән дә сөйләшсә, авылда эше дә тәмамлана түгелме соң? Закирҗан белән туганнан туган балалар, җитмәсә, бер фамилия йөреткән күршеләр дә булуын искә төшереп, ул анардан күпкә кечерәк туганнан туган энесе турында сорамакчы булды:

— Закирҗан абзыйлар ни хәлдә икән соң? — диде ул, анда да кирәсе барын әйтми торып. —Исән-сау гына яшәп яталармы?

— Исән-сау булмый кая китсен ул. Абзар арты өлкән лейтнаты. Ай ярым укып кына булырсың тагын лейтнат, — диде Сафуан абзый авылларына хас телдә төрттереп. — Сиксәндә генә алды ул «өлкән» дигәнен. Мин генә һаман рәтәвәй... — Ул гадәтенчә авызын бөреп кенә кеткелдәде. — Туймагач та туймый икән кеше, ә? Һаман ат, сыер асрый. Ишеге төнлә дә шыгырдый. Ә бер сарыгын да корбан чалмый, дуңгыз. Минем корбан чалырга хәлемнән килми. Ә менә абзар артымда, әнә, ике коргаксыган чана, ике арба, келәтемдә алты камыт-дуга кайчан җигәрләр икән дип чым-чыкыр җылап ята. Мәрфугасын үзеннән калдырмыйча урманнан кайтып керми, бугашап...

— Һаман да ишетмидер инде. Колакка каты иде...

— Үзенә дигәндә бик ишетә. «Мә» дигәнне. «Бир» дигәнне — юк. Ашарга дигәндә күзе дә бик яхшы күрә...

— Әле өйдәләр микән соң?

— Нәрсә, аның турында да язасыңмы? Әйдә, яз, яз!..

Әле генә йөз яшьле һәм якты йөзле картның йөзеннән болыт йөгереп үткәндәй булды. Бу кемгәдер зыян китерә торган тарлыктан, хөсетлектән дә, күңел каралыгыннан да түгел, ә бәлки, беркая чыкмыйча авылда картайган кешеләрнең бер-берсенә карата ярымшаян, таләпчән һәм бераз гына кытыгы килеп көнләшүчән мөнәсәбәтенең чагылышы иде.

— Төштән соң, син килер алдыннан гына буш арбасындагы бичәсе белән шалтырап урманга чыгып киткәннәрен күреп калган идем. Әле кайтмадылар шикелле... Газ бар, өендә электр бар, ул һаман утын ташый. Туймаса да туймый икән кеше дигәнең... Бар, белешеп чык...

— Чынлап та...

Тәлгат оеган буыннары белән сызлана биреп, урыныннан күтәрелде. Карт аның буынына төшеп чәй эчәргә кыстады. Әмма Чаллылардан ук вакыты кысылып кайткан Тәлгатнең иркенләп чәй эчеп утыру мөмкинлеге юк иде. Әгәр Закирҗан абзыйсы белән очраша алса, иртәгә иртүк китеп тә баруы мөмкин. Хушлашканда картның хәтерен тикшереп, тагын бер генә сорау бирәсе килде:

— Син хезмәт иткән хәрби частеннен исемен хәтерлисеңме?

Соравы ахмакларча килеп чыкты, әлбәттә.

Ләкин ана ул тәгаен җавап алды:

— Карт көнемдә мина нигә кирәк ул? Исеме шунда, кыекта. Күрерсен...

Тәлгат жил капканы ачып, тау ягына чыкты да Закиржаннар ихатасына таба юнәлде. Бер унайдан Сафуан абзыйсынын янгырларда караеп калтайган өй кыегына күз ташлады. Анда «Бирелә Бөек Ватан сугышы ветераны, Ленин, Кызыл Байрак, икенче дәрәҗә Суворов орденлы Жиденче Бранденбург гвардия кавалерия корпусы рядовое Сафуан Сибгатуллин яши» дип язылган иде.

Кинәт Имәнлек урманнары ягыннан кояшта әлсерәгән жил искәндәй итте. Кояш офыкка тәгәри дә башлаган икән. Ике кеше белән сөйләшеп, көне сизелмичә үтеп тә китте. Хәер, өйдән-өйгә сөйләшеп-сорашып гомере дә үтте бит. Күкрәгендә бер медаль-фәләне дә юк. Күкрәк читлегендәге йөрәктә кеше гомеркәйләре турында нәкъ менә бүген ишеткәндәй дастаннар. Сафуан абзасы да түшен күпертерлек орден-медальләре белән горурланып утырмады. Әмма нинди бәһале гомер узылган, нинди авыр, гыйбрәтле язмыш кичерелгән! Күпме кешеләр белән очрашып, ул бу кадәр дә үзенчәлекле акыллы кешеләрне сирәк очратты. Һәм ул анын авылдашы иде!.. Күнеле күтәрелеп куйды. Ана тагын ни кирәк?

Менә ул Закиржаннын такта капкасын ачып керде. Тыштан ачык яшелгә буялган жыйнак йортнын ихата эче матур, гөлләр кебек ямьле һәм чиста иде. Аны күрү белән су лаканы янында мәшәләнгән ана каз ысылдый-ысылдый муенын сузып анын янына килде. Гүя ул хужаларнын өйдә түгеллеген, әлегә ихатада үзләренен генә хужа икәнлеген хәбәр итә иде. Димәк, бүгенгә насыйп итмәде. Иртәгә иртәрәк килер болай булгач.

Ишектә йозак иде. Тәлгат кире чыккач, капка төбендә торган Сафуан абзыйсына тап булды.

— Синнән сон Зөлхәбирәнен хаждан кайткан улы хәер кертеп чыкты... — дип дәвам итте сүзен бу ару белмәс карт. — Бабай, кечкенә булса да хәер китердем, ди. Картатам белән картинәм рухына дога кылырсын дими, агач авыз. Кечкенә хәер китердем, ди. Хәернен анын зуры-кечесе булмый. Барча бала-чаганнын кылган гамәлләре безнен өскә языла бара... Хажга «съездит итеп» кайталар, ә менә шуны белмиләр. Шевиот кәчтүндә хажга барып кына ожмахка кереп булмый. Мәчет төзеп кенә дә. Мәчет үзе намаз укымый. Намаз укырга кирәк.Һәркайсыбызга!.. Жир йөзендә эшне калдырмый торган бер гамәл бар, ул — намаз. Ят та тор, ят та тор, имән төбе тап-такыр!.. Мангаен күпкәнче укы!.. Нәрсә атлы казак кебек катып калдын? — Ул яшьләрчә анын касыгына төртте. — Әйдә инде, кереп бер чынаяк чәй эчеп чык...

— Юк, өйгә кайтыйм инде!.. Абзыйны юньләп күрергә дә өлгермәдем, — дип тартышкан булды кунак.

— Өлгерерсен әле. Чәй эчми китә диме?! Килешмәгәнне! Анарчы, бәлки, Закиржан да кайтыр. Әйдә-әйдә! — Ул һаман сөйләнә-сөйләнә аны өйгә өстерәде. — Мин аны, сугышны, биш патрон, ике нәрәт белән башладым. Гәзиткә яза калсан, онытма. Мин шушы яшемдә дә эшсез утырмыйм. Хәлем барынча көн саен авыл урамнарын әйләнгәләштерәм. Иман эзлим.Һәр тереклеккә дога кылам. Азынды халык. Мал асрамый, мал асраса, корбанын чалмый. Корбансыз малнын бәрәкәте буламы?

Алар иске сайгакларны шыгырдата-шыгырдата эчкә үттеләр...

## V

Тәлгат иртә белән Закирҗаннарга китте. Ул абзарында, әле берничә көн элек кенә дөньяга килеп, аякланып азапланган бозау аранында нәрсәдер каккалап-суккалап маташа иде. Бераз чиләнеп торган юеш күзле, оч-очлары асылынган кашлы, йөзе белән борынгы кыпчак бабаларыбызны хәтерләткән бу бик тә тыныч, сабыр кеше, гадәтенчә, күрешкәнгә куанмады да, аптырамады да. Аңа арандагы бозау да, аның өчен Чаллыдан кайткан якташ язучы да бер иде. Аның авыз читендәге елмаюга охшаган чырае кеше белән очрашканда да, аерылышканда да, макташканда да, хурлашканда да шулай үзгәрешсез калганын белә Тәлгат. Гүя ул гел киная белән эченнән генә кешедән көлә. Гүя ки башкаларның үзен ишетә алмаганнары өчен. Сугышка кадәр ул андый булмаган. Бомба шартлавыннан авыр җәрәхәт һәм контузия алып, бик каты колакка каткан гвардия өлкән лейтенанты Закирҗан Сибгатуллинны фронт санитары кайтарып китә. Тәлгат яхшы хәтерли, төшереп алган чагында берәрсе аның белән «Кулыңнан килми!» дигән кебегрәк итеп бәхәсләшә калса, шундук янәшәсендә торган берәр атны, корсак астына кереп, иңнәрендә күтәргән бу әзмәвердәй ир сугыштан соң озак еллар бригадир булып эшләде. Аның бригадирлык хезмәтенең иң авыр өлеше өйдән-өйгә эшкә әйтеп йөргәндә булгандыр дип уйлый Тәлгат. Ул кешегә чамадан тыш кычкырып, колак тондырырлык итеп сөйли сөйләвен, ә менә үзе кешене ишетми иде. «Әһә, ярар!» — дип китә дә бара иде. Имеш, аңа барып җитте. Борчылмагыз. Аңлашмаганнарын ым-ишарә аша аңлаша иде халык. Шул ишетмәве аркасында Закирҗан абзыйлар гаиләсе кызык хәлләргә дә калгалый иде. Әйтик, тау буена кичке шәфакъ түшәлгәч, көндезге тузан басылып, кеше авазы, аһәң кислородта чистарынып көч алгач, тау битләвендәге ихатасы мунчасыннан Закирҗан ишек алдындагы хатынына «Мыштырдамый гына ыштан китер!» дип кычкырса, бу боерык аларның үзләренә караганда тизрәк авыл халкына барып ирешә. Димәк, бригадирлары мунчада. Иртәгә аның турында мәзәк әзер. Элегрәк аның колагы ничек кенә кычкырсаң да ишетмәс дәрәҗәдә каты булган. Берничә елдан ачыла төшкән. Халык сөйләвенчә, аның теге серле елмаюы бригадирлык чорларыннан калган, имеш. Күпме сөйләсәгез дә, мин сезне ишетмим, аңламыйм, әмма бар влач миндә,сезнең мине аңлавыгыз миңа бик җиткән, дия иде ул гүя сиңа бу елмаюы белән.

Закирҗан абзыйсы авылдашы Тәлгатне нәкъ шушы елмаю белән каршылады. «Син нишләп йөргән буласың инде аяк астында чуалып?» дигән сымаграк карап торды ул аңа. Тәлгат үзенең килү максатын никадәр аңлатырга теләсә дә, танау астыннан гына мыгырдап маташкан Закирҗан аны аңлап җиткермәде һәм кулындагы чүкечен абзар алдындагы түмәр өстенә ташлап, кулы белән өенә күрсәтте. Гүя аңлашмаудан котылу чарасы өендә генә иде.

— Керик... Хатын...

Әйе, кешелек белән мөнәсәбәтләрдә хатыны Зөлхәбирәдән башка ул берни эшли һәм беркая баралмый. Юк, эшли, киресенчә, күп нәрсәне жиренә җиткереп, хәтта арттырып та эшли, әмма сөйләргә дигәндә аның өчен хатыны гына сөйли иде. Балачактан өйрәнгәненчә, Тәлгат хатынга Зөлхәбирәттәй дип эндәшеп, күрешкәннән соң, үзенең аларга килү максатын, бурычын аңлатты. Аналык бәхетен мулдан татып, балалар үстергән, тараткан, гомере чагыштырмача барлыкта үткән, бигрәк тә соңгы елларда, сугыш ветеранын карап, муллыкта яшәгән, күңел киңлеге, беркатлы самимияте йөзенә бәреп чыккан, иреннән канәгать картайган һәм җитмешләрдән узып, шактый авырайган гәүдәле, чал кергән чәчен ак яулыгы астына җыйнак итеп җыештырган тутасы аны бик тиз аңлады һәм,

утырышырга ымлап, чәйнүген электрга тоташтырды да, хәлиткеч адымнар белән эчке якка кереп китеп, иренен орден-медальләр белән чуарланган кәчтүнен алып чыкты һәм каршыдагы чөйгә элеп куйды:

— Шулай унайлырак... Әллә каян күренеп тора... Сөйләве дә унайлы... Ике генә көн элек мәктәптән килеп киткәннәр иде...

Инде һәр авыл йортында очрата алган кебек, монда да өсте төрле вактөяк аш-су, дөнья кирәк-ярагы чәчелеп яткан өстәл артына утырып өлгергән ирләр, берсе икенчесеннән ниндидер тәкъдим көткәндәй, күзгә-күз текәшеп тынып калганнар иде. Язучы хәрби бүләкләр белән бизәлгән костюмын кешегә күрсәтүдән Закиржанда ниндидер үзгәреш хасил булганлыгын тойды. Күкрәгеннән карт карчыганың «Чаңк!» итеп чаңкылдау аһәне чыккандай, күз чокырлары яшь белән тулгандай булды.

— Закиржан абзый, безнең авылдан чыккан офицерлар күп түгел. Син шуларның берсе. Жиңү бәйрәме алдыннан... — дип сүзен башлап та өлгермәгән Тәлгат, «Тукта, бер тапкыр сөйләнгәнне мәгънәсезгә янадан кабатлау нигә кирәк булды соң әле миңа?» дигәндәй туктап калды да, гүя үзенең Закиржан абзасы белән кыенрак хәлгә тарыганлыгын аңлатырга теләгәндәй, сүзен дәвам итәргә булды. — Менә үзең үткән... сугыш юллары турында сөйли алганча сөйләсәң иде...

— Озак еллар бригадир... Малның чирен күз карашыннан беләм. Кеше брачлары аны китаплар укып та белмиләр. Сыер һәм ат асрыйм. Ике мунчам бар. Янәсында үзем, искесендә хатын керә... Менә шул... — дип, кулы белән ни өчендер хатынына күрсәтеп, Тәлгатнең соравына жавабын тәмамлап та куйды.

«Әллә аның соравын чынлап та ишетеп, аңлап сөйләдеме бу?» — дип куанырга ашыккан Тәлгат асылда ике ут уртасында калган иде. Авылдашы янына килер алдыннан аның нинди халәттә булачагы, үзе үткән фронт юллары турында сөйли алуы-алмавы хакында уйлап та карамаганмы? Ишетмичә дә колхоз эшенә әйдәп йөргән чукрак Закиржан белән менә хәзер кичектермәстән үзе турында сөйләргә тиешле Закиржан арасында жир белән күк аермасы иде!..

Әмма ул чигенә алмый иде.

— Закиржан абзый, син сугышны ничегрәк башладың?

— Нәрсә дисең? Ни дидең?! — Ул елар чиккә житеп, кулын колагына куйды һәм Тәлгаткә якын ук килде. — Әй, шушы сугыш!.. Кеше белән туйганчы сөйләшә алмадым!.. Контузия!..

— Сугышны кайдарак башладың, ул ничегрәк булды? — дип кычкырды, юк, жир ертырдай булып акырды Тәлгат.

— Ә-ә, сугыш турында сөйлисеңмени?!.. Нигә кирәк ул хәзер? — дип үзе дә акырып жибәрде Закиржан, бар дөньяга ишетелерлек итеп. — Сугышканда сугыштык. «Прощай, любими гурыт, уходим зафтры в море...» дип жырлап кердек без Севастопольгә. Хәзер «Ми мирные люди, но наш бранепуез ыстоит на запасном пути...» Тормыш әйбәт, Аллага шөкер. Ел саен елкы чалам. Пинсә мул. Китереп бирәләр. Критикә юк. Балалар килеп-китеп тора...

Һәм ул тагын да хатыны тарафына күрсәтеп, кулын селкеде. Әмма мич арасында булышкан Зөлхәбирәттәй, күрәсең, үз вакытын белеп, сүз арасына керергә ашыкмады. Колак мендәрләре ярылганчы кычкырыша-кычкырыша, Тәлгат аның сугыш алдыннан гына жиденче сыйныф тәмамлавын, шунын нәтижәсендә фронтта кече офицерлар курсына эләгүен, дүрт тапкыр яраланып, Саратовта госпитальдә алты ай буе ярасы да юньләп бәйләнмичә үлекләп ятуын белә алды. Сугыш операцияләре турында сөйләтү мөмкин түгеллеге Тәлгаткә тәмам дә ачык иде. Нишләргә? Шулай турсаеп чыгып китмәс бит инде!..

Ул, очрашу-күрешү өчен ерак юлдан кайткан авылдаш, бер нәтиҗәсез китәлми, китәргә хокукы юк иде. Бүген бик иртәләп килсә дә, бәрәкәттән соңлаган иде. Бу аның сугышны алтмыш биш елдан соң эзәрлекләп йөрегәндә шул ук сугыш алдында чираттагы җинелүе иде. Әмма ничек кенә акланмасын, билләһи газыйм, бу легендар кешеләр бүген исән булсалар, иртәгә исән булмаячаклар бит!.. Ул кечкенә язмалык булса да мәгълүмат тупларга тиеш!..

Гарьлегеннән елыйсы килеп китте. Заманында «гәзит бүресе» исемен йөреткән әдип үзенә хас кыюлык белән урыныннан күтәрелде, медальләр белән ялтырап торган костюм янына килде һәм «Кызыл Йолдыз» орденына күрсәтеп:

— Закирҗан абзый, ике генә сүз!.. — дип янә дә тамагын ертырдай булып кычкырды. — Менә моны ни өчен бирделәр?

Һәм — куркып китте — абзыйсы башын уч төпләренә салган да, үкси-үкси елый иде...

Мич аралыгыннан авыр гәүдәсе белән атылып чыккан Зөлхәбирәсе аңа ярдәмгә Тәлгаткә караганда иртәрәк килеп җитте:

— Закир, Закир... Тынычлан... Тынычлан, җаный!.. — Ул иренең әле һаман бөртек тә коелмаган һәм чалара да башламаган шомырт кара чәчләре көнҗәләсен бармаклары белән тарап сыйпый, иркәли, шунда ук янәшәсендә нишләргә дә белми басып торган Тәлгатне дә юатырга тырыша иде. — Аның шундый өянәге бар, энем, үзе кылган батырлыклар турында сөйли алмый. Наградлар, бигрәк тә бу орден-мазар турында сорашканда шул өянәге кузгала... Борчылма, озакламый үтә ул... Авыл халкы бу хакта белми дә. Хәзер, хәзер, Закир! — Ул мич арасына керде, чынаякка кайнаган су коеп һәм анда ниндидер ак матдә болгатып, иренә китереп бирде. — Эч әле менә шуны, эчеп җибәр әле... Хәзер чәй китерәм. Тәлгат энем, син дә утыр!..

Закирҗан абзый карашын чынаяктан күтәрмичә китерелгән дарулы суны җай гына уртлады. Ара-тирә сөйләнә-сөйләнә Зөлхәбирәттәй өстәлгә чәй тәмләткечләре ташый башлады.

— Бу сугыш барыбызга да күрсәтте инде...

Герман кызы чәчен тарый,
Ал белән үрер әле,
Безгә күрсәткән газапны
Үзе дә күрер әле, —

дип такмаклый идек ул елларда... Закирыма чыкканда миңа уналты гына иде әле. Авылда ирләр юк диярлек, яшьләре... яшел борын гына. «Ике япьле сәнәкне, җыен патсан эреләнде сугыш булу сәбәпле, « —дип җырлый идек. Яраттым да, кызгандым да мин Закирымны!.. Ни дисәң дә, тере ир кисәге иде бит ул!.. Яралардан үлекләгән һәм салкын тиюдән шеш-чобан баскан бу кадерле гәүдәне мин үзебезнең никахыбызга, кыз башым белән, күтәреп диярлек алып килдем. Ике ел диярлек күтәреп йөреттем. Шул хәлендә җитмеш чакрымдагы Әкчиннән генә бер атна өстерәп кайтарганнар бит аны!.. Ә мин, авылдагы чәчби, бу хакта белмәгәнмен дә!.. Белмәгәнмен! Белгән булсам, булачак балаларымның газиз әткәләрен канатларымда күтәреп алып кайткан булыр идем!.. Менә, тынычланды да... — диде ул картына ымлап. — Шулай басыла ул. Яхшы. Утыр, Тәлгат энем. Туган дисән дә була инде. Без бит әниләр ягыннан кардәшләр. Чәенне эч. Сине кунак итеп тә булмады. Менә, вак бәлешләрдән авыз ит әле. Төелгән мал карыныннан житкергән идем... — Ул борылып, Закирының колагына кычкырды. — Чәенне эч!.. Шикәрне күп салма, сиңа ярамый!.. Диабит!.. Ашагыз әле, ашагыз!.. — дип бераз яннарында өтәләнеп алганнан соң,

ул Тәлгатнен каршына ук килеп утырды. — Балык бирсән, бәйләп бир, башын-күзен чәйнәп бир дигәндәй, әйдә, сораштыр, анын батырлыкларын мин сина үзем сөйлим!..

Тәлгат беренче тапкыр мондый хәлгә тарыган иде. Сугыш тарафыннан изелгән, ватылган, хәтта бу хакта сөйли дә алмаган, халыкта «Ат күтәргән Закирҗан» дигән кушамат йөреткән ир, авыз читендәге елмаюын саклап, дымлы күзләрен челт-челт йомгалаштырып, бернәрсә диярлек ишетмичә, ни сөйләргә дә белмичә, әмма барысын да тынлаган-аңлагандай булып оеп утыра, ә менә анын сугыштагы ирлек-егетлек гайрәте турындагы исәп-хисапны хатыны бирә иде. Йомшак күнелле Тәлгатнен күзенә дә яшь бәрде. Анын күзе кәгазьгә төшергән хәрефләрен дә күрми иде...

Әмма озын-озак уйларга форсат юк, сугыш белән тынычлык арасындагы алтмыш биш ел буе сакланып килгән ядкарьләр аны чигенмәслек итеп китереп кыскан иде.

— Зөлхәбирәттәй, менә бу орденны Закирҗан абзыйга нинди батырлыгы өчен биргәннәр? — дип кабатлады ул соравын.

— Ул анын авылга кайткач, артыннан эзләп тапкан соңгы ордены. Безнен Закир башта Черномор флотта мәрәк булган бит ул. Алар дингез карабыннан Киреч дигән коры җиргә десант төшкәннәр... Сиваш дигән бик әшәке тозлы сазлыкны үтеп, пласдармны нык кына яулап алып, баявай әхрәнинийәдә ятканда болар дошман засадысына эләгәләр... — Тәлгат ишеткәннәрнен бер генә авазын да түкми-чәчмичә, ашыгып-ашыгып дәфтәренә терки барды. Гүя жиңгәчәйдән ишеткән «баявай әхрәнинийә»ләр Закирҗан абзыйсынын үзе сөйләгәннәреннән дә кадерлерәк, дөресрәк һәм төгәлрәк иде. — Руталарыннан берничә генә кеше исән кала. Шул исәптән безнен Закир. Рота командиры Захарушкин дигән кеше бик каты яралана. Закир командирын сазлыктан ике тәүлек буе өстерәп-күтәреп, үзебезнекеләр ягына алып чыга һәм госпитальгә тапшыра. Гыннади Фидырычнын безгә сугыштан соң хатлары да килеп торды. Хәзер исән дә түгелдер инде... Авылында ат күтәргәнгә кадәр минем Закирым сугышта Захарушкиннарны күтәреп орден алган!.. Вәт!.. — Кулындагы таба тота торган кисәү агачына таянган Зөлхәбирәттәй аңа төбәлеп укталды: — Йә, тагын нинди сорауларын бар?

Мондый чакларда «тимерне кызуында сугып калырга өйрәнгән «гәзит бүресе» шундук икенче соравын бирде.

— Җавап бирәм. Закирнын жиде класс белеме барлыгын белгәч, аны пихуты әфисәрләре укуына җибәрәләр. Белемле әфисәрләр җитешми, белемсезеннән белемлесе күбрәк кырыла... Шуннан кече лейтнант булып чыккач, аны пихутный бзбут командиры итәләр. «Кече лейтнант» дип кимсетү ул — дөрес түгел. Сугыштагы җиңүләрне шул кече лейтнантлар оештырган бит. Безнен Закир зур, бик зу-у-ур лейтнант булган ул. Үзен уйлап кара, син командир да бул һәм бер үк вакытта марышта барганда туксан килалы Дегтяревски пуләмутне дә иңендә ташы. Кирмәнчәк тирәсендә бик каты сугыш була. Шунда анын бзбуты тоташ бер авылны берүзе фашистлардан азат итә һәм алты нимесне әсир төшерә. Менә шул. Калганын матур итеп үзен сырларсын. Сезнен халык аңа оста бит...

Тәлгат абзыйсына карады. Анын тирләп чыккан маңгаеннан бу күтәрелә, күзләренен яшкелт төймәсе исә мөлдерәмә яшьтә йөзә иде. Ул гүя ки фәрештәләр тынычлыгында оеган да, хатынынын иреннәре кыймылдавында үз хакыйкатен танып, ләззәт кичерә һәм авыз читеннән теге бригадир чактагы чалымнары белән елмая иде.Тәлгат тагын бер орденга игътибар итмәкче булды:

— Ә менә бу... «Бөек Ватан сугышы» орденын...

— Бу инде 1944 ел азагында, яраланып, кәнтүзи алып, шушы колак барабаннарын шартлаткан сугыш өчен. Биләрусия ягында Мәгилүф дигән шәһәр бар. Ай-һай, каты бара анда сугышлар!.. Закир бзботы дошманның передәвенә бәреп керә. Кул сугышлары башланып китә. Менә шул бәрелештә... Ходайга шөкер, тукмак кебек йодрыклары белән... Син аның йодрыкларына кара, йодрыкларына... Әйе, шушы тукмактай йодрыклары белән өч нимесне, эшләпәле кадак кебек, башларына кадәр җиргә сугып кертә. Фрисләрнең башларындагы корыч эшләпәләре генә ялтырап тора икән!... — Зөлхәбирәттәй күнеле килеп, кеткелдәп куйды. — Ходайга шөкер, безнең бәхеткә исән кала... Мин бит анардан алты менә дигән таза бала табып үстердем!... Әйе, сөйләп бетерим...Шул чак аның өстенә генә мина төшә. Үлә дә алмыйча, исән дә калалмыйча, юнәлешен югалтып, сугыш кыры буйлап чабып йөргәндә, нәсилкегә шакарып[2] бәйләп, үзебезнең якка озаталар... Ул башта Мәскәү янындагы Мытиччи, аннан Балакау госпитәлләрендә алты ай дәвалана. Бу орден дә аны шунда килеп таба. Ялалары озак бәйләнми үлек белән саркып яткач, аны шеш баса... Брачлар аякка бастыра алмагач, авылга кайтарырга булалар. Минем карамакка булып чыга инде... Авылда кызлар буа буарлык, ә бу, ялалы булса да, ир-җегет! Житмәсә, әфисәр!.. Мин аны яраттым да куйдым. Барысының күзе тажырайды. Ул да мине сайлады. Мин аны кәҗә сөте, имән кайрысы, клевер чәчкәсе белән кеше иттем дә куйдым. Аны авылга китереп китүче санитар Яүдәкимефкә дә рәхмәт. Барлык дуәкәмәтләрен, наградларын, хәтта алмаш чолгауларына кадәр алып кайткан... Дуәкәмәтләрен карыйсыңмы? — Зөлхәбирәттәй кызлар җинеллеге белән ду китереп түр яктан аның хәрби билетын, орден кенәгәләрен алып та чыкты.

Сөйләнгән, ул ишеткән сүзләр барысы да канлы юллар үткән кенәгәдә теркәлеп, дастанга әверелгән хаклык иде. Запастагы өлкән лейтенант Закирҗан Сибгатуллин. Дүрт орден, алты яра алган. Тәлгат кулындагы белешмәләрдә алтмыш биш — житмеш еллап элек теркәлгән ялалар һәм хәрби бүләкләр исемлеге күршедәге Сафуан абзый кенәгәсендәге сыман, кан куесы булып кызарып яна иделәр... Тәлгатнең моңа кадәрге әңгәмәдәш яугирләре арасында төрлесе, яшерен-батырын түгел, булмаганны да бар итеп, күпертеп сөйләүчеләр, үзләренең кылмаган батырлыкларыннан Гали батыр риваятьләре ясаучылар да очраштыра иде. Биредә киресе: кылынган батырлык турында сөйләр кеше булмаганлыктан, бу җәфаны аның уртак түшәк билгән хатыны алган иде.

Тәлгат бик канәгать иде. Закирҗан абзыйсы аның язучылык тәҗрибәсендә үз батырлыклары турында сөйли алмас дәрәҗәдәге бердәнбер батыр иде. Менә шулай. Өч авылдашы турында житәрлек мәгълүмат тупланды сымак. Булмаганны уйлап чыгарып көчәнәсе түгел, сурәтлисе генә калды. Көче житәр кебек. Әмма аның бу йорттан чыгар алдыннан үзе өчен Зөлхәбирәттәсе түгел, ә йортның хуҗасына бик мөһим тагын да берәр сорау бирәсе, анардан үз тавышы белән нинди булса да җавап аласы килде. Нишләптер, Закирҗан абзыйсына үз тавышы кайткандыр шикелле тоелды. Менә булыр иде вакыйга!.. Ул янә дә авылдашын күздән кичерде. Нинди дә матур, илһамы каш очларына кадәр канатланган кеше иде ул!.. Хатынына карап яшәргән һәм гүя, аның хакына үзе генә булдыра алган жырлар язып, киләчәк гомерләрен озайткандай күренде. Нинди рәк сорау бирергә икән дип уйлап өлгермәде, аның зиһенендә кичә генә очрашкан авылдашлары — соңгы фронтовиклар Сабирҗан, Сафуан абзыйлары пәйда булды һәм язучы чукраклардан да чукрак Закирҗан абзыйсынын уң колагына капланып, әгәр шулай әйтергә яраса, баскыч куеп менгәндәй,

[2] Шакарып (диал.) – каерып.

арада дошман түгел, жил дә үтмәслек урын калдырмыйча сипләнеп, башына килгән беренче фикерне бар көченә кычкырды:

— Закиржан абзый!.. Синең яшь чагында шигырь язганың булмадымы?

Күрәсең, ишетеп житмәгән абзыйсы ияге белән сүзенне «Тагын да кабатла!» дигән ишарә ясады.

Тәлгат соравын тагын да кабатлады.

— Нәрсә дисең? — Җавабында каты кычкырган Закиржан абзый, ярдәм көтеп, аңа түгел, хатынына эндәште. — Нәрсә диден?

— Яшь чагында шигырь язмадыңмы, дип сорый, — диде аның колагына Зөлхәбирәттәй.

Нәрсәдер аңа барып житте һәм нәрсәседер барып та житмәде шикелле. Сугыш дәвам итә иде.

— Юк!.. — диде саңгырау тавыш белән Закиржан абзый. — Белмим. Безнең полкта андый кеше юк иде!..

Хужалар тупсадан озатып калды.Тәлгат аларның икесен йорт нигезенә утыртып, фотога да чәкетеп алды.

— Ат та, сыер да асрыйм... — диде Закиржан абзый хушлашканда, малтуар исе килеп торган каралтыларына ымлап. — Ике мунчам бар... Берсендә хатын, икенчесендә үзем керәм. Мунча керергә кил...

Төшлеккә житеп барган кояш астындагы өянкеләрдән төшкән күләгәләр кыскарганнан-кыскара бара иде...

## VI

Чаллыга кайткач, телефоннан колагын-башын томалап, өч көн буена урыныннан тормыйча, илһамланып, әрнеп һәм ярсып, өч авылдашы турында «Соңгылар» дигән язмасын язды. Ярата ул бу тормыштан алынган реаль хикәяләү жанрын: кешеләре дә тере, үлмәгән-нитмәгән, бер үк вакытта ул очерк кебек чынбарлык сурәт һәм шул ук вакытта чын әдәби әсәр дә...

Ул авыр хезмәттән кайнарланган башы белән язмаларын шундук газетаның баш мөхәррире исеменә электрон хат юллады. Фотоларны интернет аша жибәрү кулымнан килми, шуны булдыра торган берәр адәм табалсам, сонрак аңысын да хәл итәрмен, һәрхәлдә, әле вакыт юк түгел, язмалар укылып, фатиха алынгач, үзем булса да китереп китәрмен, дип тә өстәде. Өч көн буе баш мөхәррирдән хәбәр көтеп, телефон төбендә утырды. Хәбәр булмады. Шалтыратып, белеште: әйтүләренә караганда, язмалары электрон почтага килмәгән, ә баш мөхәррирләре Чуаштан якларында йөреп ята икән...Язма барган булырга тиеш. Татар газеталарында әлегә яхшы интернетчылар юк диярлек шул. Булганнары иренчәк, килгән почтаны актарып карарга да теләмиләр. Билгесезлек аның йокысын алды. Түземе калмыйча, язмасының принтердан алынган язма һәм электрон күчермәсен дә, инде ясатып өлгергән фотоларын да алып, сәгать дүрттәге таң автобусы белән Казанга йөз төбәп юлга чыкты. Чынлап та, юньле-рәтле итеп карагач, жибәргән язмалары башлы-күзле булды: килүен килгән, әмма мөхәррир әле булса кайтмаган иде. Бүлек мөдире язмаларны укып ошатты. Алар икәүләп баш мөхәррире кесә телефонынннан чыктылар. Ул ике көннән кайтачагын хәбәр итте. Көтми чарасы юк иде. Кунакханәләр бик тә кыйммәт, сусыз кран, утсыз бүлмә өчен биш кат тиреңне туныйлар; ул, карт язучы, Казанга килгән саен кунар урын эзләп жәфалана; пенсия акчасы юл йөрергә дә такы-токы гына житеп торганга, чарадан-бичара булса да, әлләни уфтанмыйча көтәргә булды... Дөрес, аның Казанда ачык йөзле, өстәле мул колхоз базарын хәтерләткән, башыннан, үзенеке кебек, чәчен шуып төшәр дәрәҗәдә пеләш язучы дусты Көнзаман Шәйхи аны һәрчак

кабул итәргә әзер, әмма аны килгән саен борчырга кальбендә батырлык та, җәтлек тә җитешми иде...

Баш мөхәррир аны җылы каршылады.Язмаларны укып чыккан, яраткан. Ул гынамы, татар журналистикасында гына түгел, ә бәлки барлык әдәбиятыбызда сугыш, сугыштагы батырлык дигән сәяси-фәлсәфи категориягә карата яңача караш ачылу мөмкинлеген әйтеп, һәм, моннан тыш, иң куанычлысы шул, аларның апрельнең соңгы һәм май башындагы өч санда басылачагына ышандырды.

Чаллысына ул канатланып кайтты. Чыккан хәлдә, гәзитләрне туган авылына, халкына, язмаларның каһарманнарына ничек җиткерер? Инде моның өчен дә кайтып йөреп булмый бит инде! Автобуста ук төрле планнар корды: ул гәзитнең өч санын язма геройларына өч данәдә... юк, бертуган абзыйсын, авыл хакимиятен, район хакимен дә кушып, алтышар, юк, кирәге чыгуы ихтимал дип, тугызар данәдә күбәйтәчәк һәм Чаллы-Эстәрлетамак автобусы шоферына берәр йөз сум төртеп, биреп җибәрәчәк. Шофер аларны, Әкчин борылышына берәр кеше килеп торса, кулдан-кулга тапшырачак. Ә кем каршылар автобусны Әкчин борылышында? Нигә аптырыйсың юкка, дип бүлде аны икенче тавыш. Абыйсының улы, Шәүкәт энекәше каршылар. Шулай шул!.. Машинасы бар. Әгәр ул, әле генә операциядән чыккан кеше, чирләп-нитеп китсә? Ул очракта авыл биләмәсе рәисе Мансур да килеп ала ала. Район үзәгеннән болай да кайтып кергәне юк. Ә район үзәге Миякә аларның авылы белән Әкчин арасындагы кап урталыкта.

Тора-бара авылдашларын куандыру тойгысы аны тагын да кинрәк офыкларга чыгарды. Нигә аңа гәзитләрне алтышар данәдә генә күбәйтергә? Үз авылдашлары турындагы язмаларны барлык халык укырга тиеш түгелмени? Авыл биләмәсенә кергән биш авыл, шул исәптән Өязебаш, Дубровка чуашлары? Чуашлар талантлы, тырыш халык, чуашча, урысча гына түгел, татарча да сыдырып салалар!.. Йөзәрдән өч сан — өч йөз данә житәрме? Житәр. Хәттин ашкан. Кулдан-кулга йөртеп укысалар, кадерлерәк тә булыр Әгәр ул Казан типографиясе белән алдан сөйләшеп, һәр санны йөзәр данә артыграк бастырса, өч йөз данә гәзитне Чаллыга алып кайта алырмы? Алыр. Җае чыгар, борчылма. Чаллыга кайткач, шул ук автобус йөртүчесе белән сөйләшә дә, бер-ике йөзлек чумарасын биреп, Әкчингә сала да җибәрә. Калганы — уйланылганча.

Эшне озакка сузмыйча, баш мөхәрриргә шалтыратты. Ул җаваплылыкны үз өстенә алып, һәр санны йөзәр данә арттырып бастыру турында нәшрият җитәкчесе белән сөйләшәчәген, әмма бу гамәлнең буш булмаячагын, гәзитнең һәр данәсе иң очсыз дигәндә икешәр сумга төшәчәген җиткерде. Тәлгат түләү хакында сүзсез килеште: ат аунаган җирдә төк калмый булмый. Хәзер инде авыл тарафлары белән килешәсе калды.Энекәшенең кәефе иләс-миләс иде. Артык ашкынып торуы сизелмәде. Авыл биләмәсе рәисе дә чамадан тыш сак кабул итте аның хәбәрен. Бу аңлашыла да. Түрәнең олысы-кечесендә, алар уйлавынча, «урындагы җитәкчелек белән алдан киңәшмичә кайтып киткән язучы» га карата салкынлык тоелырга тиеш. «Ярар, мин гәзитләрне алып та кайттым ди. Аны йорттан-йортка кем таратып чыгар?» «Хат ташучылар, — дип җавап бирде Тәлгат. — Авылга килгән почта белән бергә таратып чыгарлар...» «Һмм... — дип мыгырданды рәис. — Һмм...» Һәм шушы «һмм»нан ары китмәде.

Иртәгә гәзитнең беренче саны чыга дигән кичтә теге «һмм»нарның мәгънәсенә төшенү белән шыбыр тиргә батты: алар дөрес фикер йөртә бит!.. Ана бу эшкә авыл биләмәсе рәисен дә, хат ташучыны да, хәтта эшсез утырган энесен дә кыстырырга ярамый икән бит! Ул бу хакта ничек онытып җибәргән?! Утыз елга якын элек Уфа татарларын көчләп башкорт

итеп яздыруның серләрен ачып салган һәм жирле житәкчелекнең кара дошманы итеп игълан ителгән Тәлгат әгәр дә аларны бу эшкә жиксә, рәис белән хат ташучы эшсез, эшсез энекәше тешсез йә машинасыз, балалары мәктәпсез, гәзитне укыган кешеләр утсыз, газсыз, утын-печәнсез калачаклар икән бит!..

Нишләргә? Әмма конвейер хәрәкәткә жибәрелгән — гәзитнең башлам саны басылган иде инде. Артка юл юк, ул бары тик алга гына иде.Аннан, Ватан өчен канын койган сиксән-туксан, хәтта йөз яшьлек аксакаллар турында язганы өчен, бәлки, үч алып маташмаслар? Анарда бу кадәр хокуксызлыгы, үзен уратып алган дөньяның бу кадәр тупаслыгы, кешелексез ваклыгы өчен ачу да уянып куйгандай итте: тарихта булган объектив вакыйганы сурәтләгәне өчен адәм баласын күпме таптарга мөмкин? Аның язучы буларак, теләсә нинди проблеманы күтәрергә хокукы бар лабаса — сүз иреге!.. Анысы шулаен шулай, ә менә бу очракта ничек хәл итәргә? Гәзитләрне авылдагы абыйсына жибәрергә кирәк, ул аларны мәктәпкә алып барып, балаларга бирер,балалар булдыра алганчы йорттан йортка таратырлар!

Ана рәхәт булып китте. Менә мәсьәлә хәл дә ителде сымак. Дүртенче май иртәсендә, һаман да шул таңдагы, сәгать дүрттәге автобус белән Казанга юлга чыкты. Гәзитнең Закиржан абзый турындагы әле үзе күреп тә өлгермәгән соңгы саны күз алдыннан китмәде. Ничегрәк чыкты икән? Кайсы биттә? Кыскартмаганнармы? Ничекләр яратып язды бит ул аларны. Алдагы ике санын кат-кат укыды. Яратып язылган язмаларын гына шулай кат-кат укый ул.

Нәшриятта барысы да тәртиптә иде. Өч санда чыккан өч йөз данә гәзит өчен тиешен түләп, баш мөхәрриргә рәхмәт әйтергә кергәч, ул аны чак-чак күтәрерлек йөге белән үзе үк автовокзалга китереп, озатып та калды. Бар бит яхшы кешеләр!..

Шул ук көнне кичен Чаллысына кайтып та житте. Иртәгә үк бу газиз йөкне автобус белән жибәреп, аны каршыласын һәм әтисенә илтеп тапшырсын өчен һаман да шул энесе Шәүкәт белән яңадан сөйләшмәкче булды. Әмма шул ук көнне кайтып керүе белән фатирында телефон шалтырады.

— Исәнме, Тәлгат абзый!.. — диде телефондагы аваз. — Кәмил әле бу. Миякәдән...

Бу аның әнисенең бертуган абзыйсының улы — туганнан туган энесе иде. Ул нишләптер үзенең исемен бервакытта да Камил түгел, Кәмил дип бозып әйттерергә тырышты. Бабасына өченче хатынлыкка килгән, айнык чагы сирәк мишәр хатыны шулай нечкәртеп әйтергә өйрәттеме — Тәлгат өчен бусы вак мәсьәлә иде...

— Исәнме, туган!.. Син ничек бу якларга килеп чыктың? Нигә безгә куна килмәдең?

— Минем Чаллыда служак яши. День рождениесенә килдем... — Бик дулкынланган Камил шундук сорауларын тезеп китте. — Син үзең ничек соң? Кайтырга жыенмыйсыңмы? Теге материалың язылдымы, чыктымы?

— Син бу хакта каян беләсең? — диде соңгы вакытта Камилнең Чаллыга «день рождения»ләргә еш йөри башлавына һәм моңа кадәр туган санап үзенә ябешеп барган егетнең Чаллыга килгәч, кереп тормыйча, шалтыратып кына чикләнүенә аптыраган Тәлгат. Уйлавынча, Миякә мәктәбендә физкультура укыткан кеше аның газетада язмалары чыгуын бөтенләй дә белмәскә тиеш иде.

— Земля слухами полна!.. — диде ул. — Бу хакта бөтен район сөйли...

— Чаллыга еш йөри башладың... Үзең кермисең дә...

— Вакыт юк бит.
— Монда килергә вакыт тапкач... Син машина беләнме?
— Әйе.
— Кайчан китәсең?
— Иртәгә иртән. Әйдә, алып кайтам.
— Юк. Һич кенә дә кайтып йөрерлек җаем юк. Минем сиңа бер үтенеч бар иде...
— Ниндирәк?
— Авылыбызның соңгы фронтовиклары турындагы шул гәзитләрне авылга — абыйга кайтарып тапшырсаң иде. Алар белән нишләргә кирәген мин аңа шалтыратып әйтермен...
— О-о-о!.. Ярар!..— дип кычкырып җибәрде Камил куанычыннан. — Эшлибез аны!.. Иртәгә иртән кереп алырмын...
Иртәгәсен, Тәлгат күзен тырнап ачып та өлгермәде, кысык күзләре һәм йомыкый йөзе, кечкенә башы белән йомранны хәтерләткән Камил килеп тә житте. Ул ничектер таркау һәм каудар кыйлана иде. Күпме генә кыстасалар да чәй эчәргә дә кереп тормады. Төргәкне машинасына салды да, китеп тә барды.

Ике көн үтүгә Тәлгат абыйсына элемтәгә чыкты. Аның сөйләшүе бик салкын, гүя сүз авылдашлары турында түгел, ә Һималай тарафларындагы «кар кешеләре» турында бара иде. Камил гәзитләрне китермәгән. Инде сигезенче май житте. Гәзитләр һаман да юк иде. Камилнең кесә телефоны да, өй телефоны да өнсез иде.

Тәмам аптыраган һәм хәвефкә төшкән, йокысын җуйган Тәлгат, әллә абыйсы да шаярта микән дип, эшнең очын табу нияте белән авылына карап юлга чыкты. Әмма гәзитләр авылга чынлап та килеп ирешмәгән иде. Тугызынчы май иртәсендә ул Сафуан һәм Закирҗан абзыйларына атап алынган күчтәнәчләре һәм алып кайткан гәзит күчермәләрен тапшырып куандырды да, нишләргә дә белмичә, аягы тарткан тарафка юнәлде. Бу авыл зираты иде. Мондый чакларда әнисенең каберенә барып, дога кылырга, аның рухы белән киңәшергә ярата ул. Биредә карттасы — әнисенең атасы Галирахман, ике бертуган абыйлары Хәбибрахман белән Лотфрахман, апасы Хәмдиянең җәсәдләре янәшә яталар. Тәлгат ел саен диярлек кайтып, әнисенең күркәм тотылган кабер өстен караштыру белән беррәттән аның туганнары — Тәлгатнең әби-бабаларының ташландык каберлекләрен чүп-чардан, тамыр-томырдан арындырып китә. Арындырмый хәле юк, чөнки нәкъ менә шушы Камил кебек туганнан туганнар — аларның балалары ата-аналарының каберләре өстенә сәрби-сирень кебек тиз үсеп, үтә дә азып үрчи торган куаклар утыртканнар да, башкача килеп тә күренмәгәннәр. Менә ничә ел шуларны арчып хәлләрдән тая Тәлгат. Тәмам җәфалады аны сирень чытырманы. Тазартканнан соң бер ел да үтми, килсә, тагын урман баскан. Кереп тә булмый. Бигрәк тә Камилнең әтисе Лотфрахман каберендә хөкем сөрә иде мондый тәртипсезлек. Чардуганы кеше керә алмаслык биек итеп металл чыбыктан ясалган. Аңа баскыч куеп кына керергә мөмкин. Житмәсә, куаклык эченнән зират иясенең калай тактасы да күренми, анда бернинди исем-җисем дә күренми... Нәрсә генә эшләмәде Тәлгат бу котырган куаклардан котылу өчен. Тамырларына крәчин дә, колорад кортына каршы дару да, хәтта кашыклап кер агарта торган ак хлор да салып карады. Юк, корыта алмый икән ясалма химия тере табигатьне. Берәү булса, үз балалары бар, шушында яшәп ятып, килсеннәр дә тазартсыннар дип кул гына селтәр иде. Әмма ул алай булдыра алмый, беренчедән, иң якын карындашлар, икенчедән, нәкъ әнә шул карындашларның ташландык каберләре аркасында әнисенең гөл кебек яктырып утырган каберенең тышкы көе китә, рәвеше

ямьсезләнә. Янәшәдәге дүрт кабернен аеруча чыгырдан чыгып ташландык хәлгә килгәне һаман да шул Камилнен әтисе Лотфрахманныкы иде. «Син бүген Миякәгә барма. Шушы каберләрне тәртипкә китер», — диде ана жир астыннан кадерле аһән.

Бу — анасынын ана багышлап кылынган догасыннан сон килгән тавышы иде.

Тәлгат кире өенә кайтып, өстендәгесен эш киемнәренә алыштырды да, кулына балта-көрәк, кечкенә баскыч алып янә дә зиратка килде һәм карангы төшкәнче шунда булды. Ул тәүдә баскычын куеп, Лотфрахман бабасынын каберенә төште, жаен табып, чытыр-чатырны кискәләп-чапкалап, биек чардуган читлеге аша ыргытты һәм зират ихатасыннан тышка сөйрәп чыгарып, бер ат йөге чамасыдай итеп өеп куйды. Балалары, оныклары исән-сау яшәп яткан хәлдә дә кабер өсләрендәге калайларына исемнәре дә язылмаган әби-бабаларына Чаллыга кайткач яна каберташлар эшләтергә кирәк дигән фикергә килде ул. Нишләсә дә күнелен ике генә уй өйкәде: шушында, борын төбендә генә яшәгән Камилнен хет елына бер тапкыр туган авылына — атасынын каберенә килергә вакыты юкмы да, ул теге гәзитләрне кая тыккан?..

Иртәгесен Миякәгә карап юлга чыкты. Ана кичектергесез рәвештә Камилне табарга кирәк иде. Һәм ул аны тапты. Хатыны Надежда Николаевна, табак битле бүрәт кызы, аны, иренен туганнан туган абыйсын, тупсасыннан эчкә чакырып та тормыйча, теләр-теләмәс кенә:

— Сезгә нигә кирәк ул? — дип, сорауга сорау белән каршылады. — Анын эше муеннан!.. Көн дә «Бердәм Россия» җыелышлары... Кичә дә сон гына кайтты... Хәзер мунчада!..

Килене белән нибары икенче тапкыр очрашуы иде. Өйдә, ишек аша, гадәттәгечә, хатын-кыз игътибары булмаган эт-баш, сыер-аяк хәлендәге тәртипсезлек шәйләнде. Беренче очрашу аларнын үзләрендәге мәжлестә булды. Бу таш мангайлы, лакан кадәр кин, түгәрәк йөзле, дала кызы икәнлеге әллә кайлардан кычкырып торган хатын ике сәгать буе үзенен бүрәт түгел, ә маржа булуын расларга тырышып тостлар тотты.

«Бердәм Россия» бу-парларыннан, күрәсен, иртәнге сәгатьтә мунчада арынырга булган Камил артыннан ул бакча почмагында томанланып утырган бура ягына китте. Мунча әле бетерелмәгән, тирә-ягында өем-өем төзелеш кирәк-ярагы аунап ята иде. Мондый халәттә кешене борчу матур булмаса да, вакыты кысан булу һәм тизрәк беләсе килү сәбәпле, Тәлгат болай да ачык ишекне шакырга мәжбүр иде.

Менә ишек ачылды, аннан бүселеп, ничектер арканланып, ишелеп чыккан бу эченнән Камилнен жепшегән озын борыны, кечкенә башы, кара сәйлән кебек тәгәрәп торган күзләре, чынлап та юеш йомранны хәтерләткән елак йөзе күренде. Аны гүя электр шаукымы сукты. Күз тирәләре тартышты, ул, әллә куркышыннан, әллә шәрәлегеннән тартынып, бөрешә, үзеннән-үзе качарга теләгәндәй, урынында бөтерелде һәм агасы янына керә күрмәсен дигәндәй ишеген кыса төшеп, көрмәкләнгән тел белән эндәште:

— Нәрсә, абзый кеше? Сина миннән ни кирәк?

— Теге гәзитләр... — диде ачуын чак тыйган Тәлгат. — Теге гәзитләрне кая куйдын?!

— Син аларны милициядән сора, абзый кеше... Башкортстан ягына чыккач та, мине туктаттылар һәм багажникны ачып, алып калдылар... — дип лепердәде Камил ишеккә ябешкән юеш усак яфрагы шикелле. — Менә шул. Милициядән белеш...

Лотфрахман бабасының авыл зиратындагы кабер чүбе бу мунча ишегә аша тажраеп карап торган «Бердәм Рәсәй» чүбеннән күпкә аграк, сафрак һәм мәгънәлерәк иде.

— Сөйләмә юкны! — дип кычкырды Тәлгат. — Хөкем карары булмый торып, бер генә милиционерның да шәхси милекне кулга алырга хокукы юк. Син милицияне бу кадәре ахмак дип белдеңме? — Һәм үзе дә сизмәстән, ишек аша сузылып, «Кәмил»не бугазыннан тартып китерде һәм мунча эченә этәреп җибәрде. — Моннан соң без синең белән туган түгелбез!.. Хәсис!..

Һәм мунча ишеген шарт ябып, ихатадан чыгып китте. Әгәр аның авылдашлары — җитмеш биш яшьлек Сабирҗан абзыйсы кеше намусын яклап хөкемнән, сиксән яшьлек Закирҗан абзый мал асрыйм, дип урманнан, йөз дә ике яшьлек Сафуан абзыйсы иман эзләп авыл урамнарыннан кайтып кермәгән булса, бу авылдашы — аның иң якын кан-кардәше — «Бердәм Россия»нең шаулы-парлы мәҗлесләреннән кайтып керми иде... «Гәзитләрне урман эчендә яндырган бу», дип уйлап алды Тәлгат. Шунда ук икенче фикер каршы төште: «Юк, яндырмаган. Район җитәкчелегенә кертеп тапшырган. Ул аларның боерыгын үтәгән». Әгәр дә Тәлгат Камилнең нибары ике айдан соң физкультура укытучысы башы белән ике меңгә якын бала укыган урта мәктәпнең директоры итеп билгеләнәчәген белсә, бәлки, монда килеп тә, бу сасы мунчага шакып та азапланмаган булыр иде.

Ә бит ул аның газизә әнисенең газиз бертуган абыйсы — Ватан сугышында һаман да шул изелеп-яраланып булса да җиңеп кайткан Лотфрахманның газиз угылы иде. Ул авылында тәрбияләнеп, туган телендә укыса, мондый булмаган булыр иде, дип уфырды ул. Әмма ул үз туган телендә дә, чит телдә дә тиешле белем-тәрбия алмаган, лавкада сатучы булган анасы, урманчы атасы артыннан бер урыннан икенче урынга күченеп йөреп, нә авыл, нә шәһәр мохитын сеңдермәгән, ниһаять, район үзәгендә төпләнеп, ниндидер сыйныфсыз «ыслушши»[3]ларның иркәби балалары белән бер сыйныфта укып, бозылып-шукланып, шулай ике арада – бер турыда эленеп торып, әдәпсез, ихтыяри такы-токыда калган бер мескин зат иде.

Тәлгат капкадан урамга чыкты.

Аның башын хәзер бер генә сорау изә иде: «Җинүче кем?»

[3] Служащий (рус) – хезмәткәр.



## Сания Әхмәтҗанова

# АРЧА КАПКАСЫ

*«Казан ханлыгы чорында шәһәр агач дивар белән уратып алынган, аның машлары, капкалары булган... Арча капкасы — Арча кырына һәм Арча шәһәренә илтә торган юлга каршы урнашканга күрә шулай аталган булса кирәк...»*
М.Худяков. «Казан ханлыгы тарихы буенча очерклар».

***

**Бармы минем ачып керер капкам,**
**Кем капкасын кагыйм, җан тарыкса?**
**Бүре булып улый төнге хәтер,**
**Арча гөмбәзендә Ай калыкса.**

**Уяумы син, Вөҗдан атлы сакчым,**
**Йорт-утарым кайда? Кайда ханнар?!**
**Кирмән диварында бәргәләнә**
**Шәүлә булып гүя өрәк-җаннар...**

**Үткәнемне эзләп килдем монда,**
**Чик куярга нәүмиз шикләремә;**
**Ачып керәм Вакыт капуларын,**
**Тылсым-ачкыч табып бикләренә.**

**Чыңгызыйлар каны тамган җирдә**
**Бар дәхелем — икърар итә алам!**
**Үз капкамнан кереп нигеземә,**
**Үз йортымда солтан булып калам.**

**...Урман — колак, кыр — күз ... мәңгелек сер...**
**Ниләр күрдең, сөйлә, Арча кыры!**
**Ни ишеттең, Урман, әйт, яшермә, —**
**Хакыйкатькә өмет баглыйм бары.**
**Ачылыгыз, Вакыт капулары!**

Сания ӘХМӘТҖАНОВА — *шагыйрә; «Оч ирекккә, җырым», «Пар алма», «Гәрәбә» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

## Низамлы нигез

*(Ханлыкның шанлы вакыты)*

**Сак астында Хан капкасы, тыныч йоклый башкаласы...**
**Арча юлы ныгытмалы, Арча кыры — ил кальгасы.**

**Бу — ханлыкның шанлы чагы, Мөхәммәдле[1] — данлы чагы,**
**Йорт-утарның таянычы — ганимәтле Арча ягы.**

**Гади халык һәм затлысы, җәяүлесе һәм атлысы... —**
**Башкалага киң ачыла — Арчаның бар үз капусы.**

**Хан капкасы — янәшәдә, төп капка һәм «көндәше» дә;**
**Бәла-каза килә калса, теләктәше-иңдәше дә.**

**Хан капкасын кагучылар — аксөякләр, карачылар[2],**
**Җилнең кайдан искәнен дә ирештереп торучылар.**

**...Ханнар килә, ханнар китә ... яу артыннан яулар үтә;**
**Бер вариска мәдех[3] бетсә, башкасына чират җитә.**

**Бу — ханлыкның кан агышы, Ватан-йортның җан кагышы,**
**Капкаларның иңнәренә иңен куйган ил язмышы.**

**Ныгыт, Казан, диварларың, тирән булсын су-урларың,**
**Урман — колак, кыр күз булса, җир астыннан тап юлларың.**

**Арча кыры — япан кырдыр, далага хас өне бардыр:**
**«Хан сараен уяу сакла: илбаскынга дөнья тардыр!»**

**Казанымның туар таңы ил күзенә багып тора,**
**Идел-йортның капкаларын хәтәр җилләр кагып тора.**

## Һәлакәткә бер адым

*(1552 елның 9 нчы мартында булган түнтәрелеш)*

**«Ишетегез патша биргән соң фәрманны:**
**Шаһгалинең сүнеп бара көч-дәрманы;**
**Ханлык күчә бүгенгедән мәскәүләргә,**
**Билгеләнә рус калгае[4] хан урынына».**

**Түрә-кара таралырга әмер ала,**
**Хан сарае каршылыксыз бушап кала;**
**Төп капкадан наместникның мал-мөлкәте**
**Эчкә уза... Телсез шаһит — Казан-кала...**

**Иртәгесен атау кичеп, үзән аша**
**Мәскәүлеләр башкалага якынлаша.**
**Безнең өч бәк, алданрак барып җитеп,**
**Хан капкасын бикләп куя: ни тамаша!**

---

[1] Мөхәммәдле — Олуг Мөхәммәд варислары күз алдында тотыла.
[2] Карачылар — диван әгъзалары, хан киңәшчеләре, әмирләр.
[3] Мәдех — мактау, зурлау.
[4] Калгай — наместник, югары дәүләт хокуклары булган кеше.

Капка төбен «саклый» калгай көн буена,
Зөяләргә ятак була төн куены.
Казанлылар шартнамәне үтәрләр, дип,
Чынга алмый Мәскәү ягы бу «уен»ны.

Ялгышмы бу, хак адыммы — кем әйтала?
Бер көн, бер төн бар капкалар өнсез кала.
Биктә — Арча капкасы да... Мәскәүләргә
Үз-үзенә ышанганлык аяк чала.

Өч фидаи түнтәрелеш юлын сайлый —
Беркавымга ханлык шулай ирек яулый;
Ихтыярый буйсындыру чынга ашмый,
Ядегәргә хан тәхетен насыйп әйли.

...Ханлык өчен уй-исәпле көннәр җитә,
Хан гаскәре яу башларга әмер көтә...
Тояклардан ут чәчрәтеп җилгән чапкын
Кыямәтнең якынлыгын хәбәр итә.

Элеккечә җырлап тормый капкалар да,
Сыкрап куя ачсалар да, япсалар да;
Сизенгәндәй фаҗиганең яу чыкканын,
Сагаялар, таңгы җилләр каксалар да.

Кол Шәрифнең мәчетендә кичке азан,
Идел-йортның язмышына ниләр язган?
Кынылардан яшьнәп чыга булат кылыч,
Йә үлемгә, йә җиңүгә бара Казан...

## Канлы рәшә

*(Арча шәһәренә кыргын яу. Һәлакәт)*

Төтен сулап ята хәрабәләр,
Бирешмәскә кирмән җан тырмаша;
Соңгы кугәнендә, аягүрә,
Соңгы капка иңрәп ыңгыраша.

Утлы дәһшәт. Кем ышаныр, әрнеп,
Идел-йортның исән каласына...
Баш иелгән илдә башкаладан
Өмет күчә Арча кальгасына.

Инде бетте... дигәч, кабат калка,
Сөңгеләрдә әле дәрман калган.
Ханлык байрагына иң соңыннан
Газиз ягым — Арча каны тамган.

Дошман таптый җирең, аннан — динең...
Үрелер ул Телең капкасына!
Җиңелгәнне җәлләп аяганны
Тарих белми: кайтып, мең кат сына!

**Телне җуйсак, Сим-Сим көче генә**
**Ача алмас Хәтер капкаларын.**
**Ничек аңлатырбыз бу Җиһанга**
**Татар дигән шанлы милләт барын?!**

*******

**Күмерләнгән имән баганалар —**
**Ут телләре барын ялмап алган.**
**Арча капкасының итәгенә**
**Яраланган бер эт башын салган.**

**Текә маңгай — бүре чалымнары,**
**Адәм акыллары — күзләрендә.**
**Тояк тавышлары тупырдамый**
**Сынган дага калган эзләрендә.**

**Бәгыреннән елый карт алабай,**
**Сизә хуҗасының кайтмасын да...**
**Гаярь шаһбаз инде ат кешнәтмәс**
**Көл ителгән Арча капкасында.**

## 460 елдан соң хакыйкать

**Гасырларны гасыр алмаштыра,**
**Хакыйкатьнең көле җилдә туза...**
**Бүз бүредән туган нәселемнең**
**Тәхетенә бүген кемнәр хуҗа?**

**Мин — бәйсезлек көрәшенә чыккан**
**Күңел ханлыгымның бер яугире!**
**Өзәңгегә басып җилеп керер**
**Үз капкамны эзләп килдем бире.**

**Ата-бабасының каберен тапмый**
**Зар-интизар булган үксез кебек,**
**Арча капкасының урынын эзлим,**
**Дивар ташларына күзем тегеп.**

**Мәңгелектән тагын, өмет сирпеп,**
**Башкаламның җиләс таңы ата;**
**Богылтауның[5] Кояш чыгышында**
**Бөгәрләнеп, ап-ак көчек ята...**

**Атлы дәвер... Бәхилләшү аһы —**
**Күкнең Айлы-көмеш дагасында.**
**Пышылдады шул мәл мосафир җил:**
**«Иман яңарт азан догасында...»**

**Арча капкасының киерелеп**
**Ачылганын күрдем менә шунда...**

[5] Богылтау — Казан кирмәне урнашкан түбә-җир



Рәис
Сафин

# САДЫЙКНЫҢ УЯНУЫ

БӘЯН

Аның кайтуы авыл халкын кайгы-хәсрәттән беркадәр арындырып җибәргәндәй итте. Сугыш елларының барлык эреле-ваклы мәшәкатьләрен, авыр колхоз эшен үз иңнәрендә күтәреп барган яшь кызларның да уяныр-уянмас халәттәге җаннары сискәнеп, иләс күңелләре күтәрелеп китте. Йөрәк түрләрендә, сизелер-сизелмәс кенә итеп, әле үзләре генә белә торган ул берәүгә уянган яшьлек хисләрен бөреләндереп, күңел түтәлләрендә мәхәббәт гөлләре шыттырды. Дәһшәтле сугыш кырларында ятып калган, хәбәрсез югалган батыр ир-егетләрнең дә сөйгән ярлары: бәлкем ул да әле исәндер дигән өмет чаткылары белән яши башлады. Татлы хыялларын яшьнәтеп җибәрде. Тәкъдир үзенең алай ук кырыс, рәхимсез түгеллеген тормыш барышы белән исбатлап, елмайгандай итте. Чөнки монарчы фронттан кайтканнарның йә аягы киселгән, йә кулы өзелгән, йә башка әгъзалары яраланып, яраксызга әйләнгән булса, Садыйк исә, бу каһәр суккан сугышны үз аягында тәмамлап, җиңүче булып кайтты. Аның яшь, тыгыз, мускуллары калкып торган түгәрәк гәүдәсенә үлчәп теккәндәй киемнәре, һәрчак чиста итеп юылган, пөхтә итеп үтүкләнгән гимнастеркасының күкрәк турысына тезеп тагылган Кызыл Байрак, Дан орденнары, Европа илләренең баш калаларын фашист илбасарларыннан азат иткәндә күрсәткән батырлыклары өчен бирелгән медальләре күз явын алырлык итеп чистартылган булып, һәрчак ялык-йолык килеп, кызларны гына түгел, башкаларны да һуштан яздырып торыр иделәр. Садыйк кичен клубка төшкән көнне халык рәхәтләнеп күңел ачты, бөтен борчу-мәшәкатьләрен оныткандай итеп көлде, ихластан җәелеп елмайды.

Юк, Садыйк көлкеле мәзәк сөйләп көлдерергә, авыз ерырга, һич югы дөньяларын оныттырып елмаерга мәҗбүр итмәде. Ул бары тик кичке уеннарны башлап җибәрде, ана җан өрде, кич буе кыздырып торды, ашкынулы дәрте башкаларга күчеп, аларны сихерләде сыман. Үсмерләрнең дә Садыйк абыйлары кебек орденлы-медальле буласылары, аның кебек оста итеп, такмак әйтә-әйтә бииселәре килде. Ә Садыйк абыйлары яшьләр уратып алган түгәрәкне әйләнеп чыга да, уртага басып, үзе белән сугыш гарасатларын кичкән, ничәшәр тапкыр үлем тырнагыннан тере калып чыккан күрше егете — дусты Йосыфка күз кысып ала. Ә Йосыф исә, бертуган кебек

Рәис САФИН (1935) — *шагыйрь һәм прозаик; «Йөрәк парчалары», «Бабайлар чуагы», «Күзгә аҗаган»» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

канкардәшенә әйләнгән Садыйкның ишарәсен сүзсез дә аңлап, Берлинны яулап алганда күрсәткән батырлыклары өчен маршал Конев бүләк итеп биргән нимес аккордеонын кулына алып, пуля тигәннән кәкрәебрәк калган муенын бер якка кыйшайта төшеп, халкыбызның сихри бию көйләреннән тезмә сызып җибәрә. Татарның тылсымлы-сихри моңнарына яраклаштырып, махсус эшләтелгән шул ак аккордеонның телләренә Йосыф кагылуга, түгәрәк эчендә ярсулы ярыш башлана. Монда инде тукмак та түзеп тора алмас иде. Шушы ялкынлы мизгелләрне генә көткән Садыйк, йөгәннән ычкынган кырыкмыш дуамал тай сыман, түгәрәк буйлап йөзеп китә. Юк, ул йөзеп кенә калмый, кулларын як-якка җәеп канатлы ат булып оча! Бу вакытта аның солдат каешы белән биленнән кысып бәйләнгән җыйнак, ыспай гәүдәсе үзеннән-үзе һавада эленеп тора сыман. Менә ул түгәрәк уртасында өермәдәй зыр-зыр килеп әйләнә, очып-очынып бии башлый. Ул арада Садыйк чүгә-тора, «хоппа-хоппа!» диеп, кулларын як-якка җәя-җыя сулыш күнегүләре ясап ала. Аннан түгәрәктәге кызларның берәрсе алдына килеп, ялтырап торган хром итекләренең очы белән клуб идәнен чәбәкләргә керешә, кызны биергә чакыра. Аңа кушылып биергә чыккан кызлар никадәр генә горурлык хисе кичереп, минем кем белән биегәнемне күрәсезме, дигәндәй итеп, янып-пешеп тырышсалар да, уфылдашып түгәрәк читенә чыга торалар. Ә Садыйк бии. Шатлана-шатлана, дәртләнә-дәртләнә, ару-талуны белмичә бии! Чөнки ул хыялында гына йөрткән бу бәхетле кичләрне өч ел буе окоп базларында өши-туңа, өзелеп сагына-сагышлана күрәшеп алды.

Туган җиренә исән-сау кайтып күренәсе, авылдашларын бүгенгедәй шатландырасы, аларның елмаюлы көләч йөзләрен бик-бик күрәсе килде аның. Мәхшәргә тиң сугыш елларында шушы әкияти сыман саналган минутларны якынайту, чынбарлыкка ашыру өчен ул да, бөтен халык белән бер сафта торып, үзен аямыйча сугышты, яраларын төзәтеп, янәдән дә янә яу кырына ыргылды. Тиңдәше булмаган шушы бәхетле көннәр килсен өчен миллионлаган кешеләр үзләрен корбан итте, сугыш кырларында ятып калды, концлагерьларның тәмуг мичләрендә янды. Алар барысы да бүгенгедәй бәхетле-шатлыклы кичәләр кабатланып торсын өчен утлы-ялкынлы еллар кичерде.

...Садыйк түгәрәкнең уртасына басып, хром итекләрен тыпырдата-тыпырдата бии, такмак әйтә:

Без Берлинга барып җиттек,  
Җиңү байрагын элдек.  
Күрмәгәннәрне дә күрдек,  
Белмәгәннәрне белдек.

Туган якта рәхәт икән,  
Һай, барина-барина,  
Егет-кызлар ярәшсеннәр  
Хак яраткан ярына.

Халык, сокланып, егеткә гөр килеп кул чаба. «Афәрин!» дип, алкышларга күмә.

Твардовскийның мәшһүр Василий Тёркинын хәтерләткән Садыйкка гашыйк булмаган, аның дәртле кочагына керергә теләмәгән, кайнар мәхәббәтенең ләззәтен татырга хыялланмаган берәр кыз бар микән?! Басынкы холыклы Кадернисаның да йөрәген жилкетә, парә-парә китерә иде ул. Садыйкның төс-битен, кыяфәтен, аның төз гәүдәсен, сихри елмаюлы күз карашларын бер генә тапкыр булса да, читтән генә булса да күрергә өметләнеп килгән Кадерниса йөрәгендә егет ут ягып, күнелен кайнатты.

Анын да Садыйк абыйсына кушыласы, янәшәсендә бөгелә-сыгыла, очына-очына биегән түбән оч кызларыннан да уздырып биисе килә, һай, килә иде! Алар кебек бии белмәгәненә үкенде. Кайчак, кеше-кара күрмәгәндә, абзарга чыгып, теге чытлыкланучы кызлар кебек, итәкләрен селти-селти аяк очларында әйләнергә дә маташып карады. Кулларын гәүдәсе белән тигезләнеп килгән билләренә куеп, никадәр генә чүгеп-чүгеп алырга тырышып маташса да, лап итеп арт ягына утырудан ары китә алмады. Анын күз яшьләренә чыланган тырышлыклары әле аяклары чалынып китеп, әле башы әйләнгәндәй булып тәмамланды. Ләкин биергә өйрәнү теләге кызның күнеленә береккән иде. Ул барыбер биергә өйрәнәчәкмен дип үз-үзенә сүз бирде. «Аюны да биергә өйрәтәләр. Мин бит аю түгел югыйсә» диде кыз, ныклы нияткә килеп. Иң мөһиме — теләк булу кирәк. «Теләге булган адәмемне теләгенә ирештерермен» дигән Аллаһы Тәгалә дә...

Садыйк абыйлары кемгә гашыйк булыр, кемне яратыр, кемне ышанычлы тормыш юлдашы итеп сайлап алыр, кемне бәхетле итәр кебек уйлар һәр кызның күнеленә тынгылык бирмәүче шашкын уй-хисләр Кадернисаны көннән-көн ныграк бимазалады, төн йокыларын качырды. Анын да шушы, күктәге торна дәрәҗәсендәге бәхетнең иясе буласы килде, шул турыда хыялланды.

Мондый татлы уй-хыяллар кызларның кайберләрен алыштырып куйгандай итте. Алар бер-берләреннән көнләшә-көнләшә, яшерен генә ярыштылар, үзләрен тыйнак, күркәм холыклы булырга мәҗбүр иттеләр.

Кызларның мондый гамьле үзгәрешләре егетләрне дә читләтеп үтмәде. Алар да Садыйк абыйларында булган күркәм сыйфатларны үзләренә ияртергә тырышты. Камыт бавын кысып бәйли алмаган берәүләр, тәмәке тартуларын ташлап, кыш буе түбә саламы гына ашаганнан күтәрәмгә чыккан, сука тарта алмаган мескеннәрне сигездән үргән каеш чыбыркы белән каезламый, тәртә белән сөякле сыртларына ормый башладылар. Кызлар күнелен яулап алу өчен катлы-катлы итеп сүгенергә түгел, ә бәлки тәмле тел белән, яхшы эш-гамәлләр кылып, кирәк чакта горур, кирәк чакта кече күңелле була белүнең кадерен аңладылар. Хәтта сугыштан кайткан кайбер буйдаклар да, тол хатыннар янына йөрүләреннән тыйлыгып, берәм-берәм гаилә корып җибәрде. Ә Садыйк исә бригадир итеп билгеләнгән көннән җиң сызганып эшкә кереште. Халык телендә: «анын фәлән җире яраланган булган икән, шуна күрә хатын-кызларга гаме юк икән» дигән ачы гайбәт сүзләре авылның бер очыннан икенче очына йөрсә дә, бу авыз чайкауларга әллә ни исе китмичә алны-ялны сүтмичә эшләвен белде. Ләкин, җилсез яфрак селкенми дигәндәй...

***

Ул елны Җир-Ана үзенең коткаручыларын котлап, аларга бүләгем булсын дигәндәй итеп, мул уныш үстерде. Анын шушы юмарт бүләге өчен мең рәхмәтләр әйтеп, югалтуларсыз җыеп алырга, келәт-амбарларга коры килеш салып куярга кирәк иде. Садыйк бу изге эшкә сугышта һөҗүмгә баргандай әзерләнде. Көнен-төнен кырда булды, алтын көлтәләр ташытты. Ындыр табагында туктаусыз тырылдап эшләп торган тракторга киң тасма аша тоташтырылган молотилка-суктыргыч исә, сугыш кырындагы легендар Катюша кебек сызгыру-улау тавышлары чыгара-чыгара, транспортер тасмасында килгән көлтәләрне бер яктан суыртып-йотып ала, икенче яктан, буш саламны чөя торды. Тасма янында борын-битләрен катлы-катлы яулык белән каплап бәйләгән хатын-кызлар, һәрчак өермәдәй тузан эчендә булып, берәүләре көлтәләрнең билбауларын чишеп, берәүләре аларны көлтә сугу машинасының авызына тутырды. Бу җаваплы эшкә саулыгы-сәламәтлеге

булган, көчле-гайрәтле кешеләрне куя иделәр. Тукмагыч авызына чишелгән көлтәләрне тотырып торучының сизгерлеге дә үтә мөһим. Ул кеше көлтә тукмау машинасының ни рәвештә эшләвенә карап, көлтәләрне нинди күләмдә, нинди рәвештә тотырырга кирәклеген белергә тиеш. Шушы эшнең белгече, сизеп-тоеп эшләүнең остасы — Кадерниса иде. Ул булганда көлтә тукмау машинасын трактор белән тоташтырган шкив каешы да өзелми, һындыр машинасы да һәрчак гөр килеп торыр иде. Сылу, чибәр кызлар көлтә сугу машинасыннан чыккан гәрәбәдәй бөртекләрне агач көрәк белән җилдә җилгәртеп, саламын эскерт салучыларга әзерләп тора.

Ул көнне эш иртәдән үк үз җаена килә алмый интектерде. Төне буе җилдавыл кубарып яуган көзге янгыр кешеләрне генә түгел, хәтта техниканы да үшәнләндергән, алар да янгырдан суынып, бөрешеп калгандай иделәр. Әлегә кадәр карусыз гына эшләп торган трактор да кабынып китә алмый тенкәгә тиде. Ул да ах-ух килеп, төчкерде, кәҗәләнде. Кабынып китсә дә, кинәт туктап калды. Инде җай гына эшләп китте дигәндә, көлтә сугу машинасы барабанына чи көлтә тыгылып, кырык ямаулы транспортер тасмасы бер урында ышкылып торды-торды да, ямаулы урыны бүселеп чыгудан өзелеп үк китте. Садыйк янә тасмага кушып ялгар өчен каеш эзләп, әле анда, әле монда йөгерде. Тик булган запас каешларның барысы да ямаулыкка китеп беткән булып чыкты. Ниһаять, утлы-ялкынлы сугыш елларын үзе белән уртаклашкан каешын билennән салып бирергә мәҗбүр булды. Аннары колхоз механигы булып эшләүче танкист дусты Йосыф, эшне җайга салып җибәргәнче ял итеп алырга диеп, эскерт итәгенә барып утырды.

Ул үзен кәефсез хис итте. Аны сагышлы моңсулык басты. Әллә көннең сүрәнлеге, әллә эшнең вакытында башланып китә алмавыннан... Нәрсә генә булмасын, Садыйкның күнеле әрнүле иде. Җаны сулык-сулык килеп үрсәләнде. Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, соңгы елларда тормышының аергысыз бер билгесенә әверелгән каешыннан да колак какты... Ул күзен йомып, чуалчык уйларга талды. Күз алдыннан бер-бер артлы соңгы еллары йөгереп үтте. Бу араларда дәртләнеп яшәп йөргән Садыйк шомлы, борчулымәшәкатьле яшәешкә килеп төртелде. Ул җанын рәнҗетүчеләрне битәрләп утырганда, янында салам кыштырдавын тоеп, унга борылып карады. Анда салам учмасы тоткан Кадерниса басып тора иде.

— Нихәлләр, Садыйк абый? — диде кыз кыяр-кыймас кына.

— Исәнме, Кадерниса сенлем. Әллә Йосыф абыең мине чакырырга дип җибәрдеме?

— Юк, мин үзем килдем.

— Алай булса, утыр, ял ит, — диде егет, эскерт төбендәге коры саламнарны кабарта төшеп.

— Рәхмәт. Йосыф абый эшне көйләгәнче утырып торыйм дигән идем шул, әгәр ачуланмасаң.

— Алай димә әле син, Кадерниса сеңлем. Бер гаепсез кешене нишләп мин ачуланыйм ди?

— Рөхсәт итсәң дип әйтүем инде.

— Рөхсәт, бик рөхсәт. Хәтта шатмын да. Сер итеп кенә әйтәм: сине минем яныма ямансу күнелем тартып китерде.

— Нишләп икән?

— Аның моңсу чагы әле. Шул моңсу күнелнең сине күрәсе, синең тавышыңны ишетәсе килде.

— Оялтмачы инде, Садыйк абый. Авылыбызда берсеннән-берсе чибәр кызлар тулып ятканда күңелең мине чакырып ялгышмады микән? — диде кыз, Садыйкка астыртын гына, сынаулы караш ташлап.

— Анысы инде күңел эше, аңа әмер биреп булмый. Әйе, авылыбызда чибәр кызлар күп, Аллага шөкер. Тик... тәкатьсезләре дә аз түгел...

— Өлештән каласылары килмидер.

— Ә син?

— Мин? – дип, уйга калды Кадерниса. Ул ашыкмый гына, һәр сүзен бөртекләп кенә, фикерләп кенә:

— Гашыйк булган кешемне мин өлешләп түгел, ә гомерлеккә житәрлек итеп, бердәнберем итеп яратыр идем. Тик моның өчен ике кешенең дә уйтеләкләре тәңгәл килеп, ихластан акылы һәм хисләре кушылган хыянәтсез мәхәббәте булу кирәктер. Барысын да мәхәббәт хәл итә, — дип оялчан күзен аска төбәп, тезеп китте ул.

Мондый акыллы фикерләрне Кадерниса авызыннан ишетермен дип көтмәгән иде егет. Менә сиңа шыпырт Кадерниса, менә сиңа тактика, менә сиңа стратегия дип уйлады сержант Садыйк... Димәк, бөтен хикмәт мәхәббәтнең икендә дә барлыгында, яисә юклыгында, диген, алайса... Ә соң мәхәббәт дигән могжизалы, серле-сихри вә илаһи көч минем үземдә бармы? Янәшәмдә утырган кыз минем өчен кем ул? Җаныма кадерле кешеме? Әллә соң үзенең сафлыгы, эчкерсез күңеле, самимилеге белән ихтирамымны казанган, хөрмәтемне яулап алган бер кыз гынамы? Алай дисәң, нигә клубка Кадерниса килгән көннәрдә күңелем күтәренке була, дәртем ташып тора? Аны ашкынып көтәм, күзем гел аңда гына була? Менә бит бүген дә ямансу күңелемә Кадерниса кирәк булды. Җаным-тәнем белән аның бирегә килүен теләдем. Нишләп шулай соң бу?! Бәлкем, хыялымдагы билгесез кыз шушы Кадерниса үзедер? Бәлкем, язмыш мине шушы кыз өчен саклап йөрткән, исән-имин туган туфрагыма кайтырга насыйп иткәндер? Кадерниса әйтмешли, акыл һәм хисләрнең берләшеп, мәхәббәткә әверелүен көтәдер, дигән уйлар дулкын-дулкын булып Садыйкның күңел ярларына сугылып узды. Әниемнең дә жае чыккан саен Кадерниса турында сүз катулары юкка түгелдер? Кадерниса да минем тормыш юлдашым булыр өчен, язмышым тарафыннан баекланган бердәнбер кешемдер? Кадерле кешемдер, бәлкем...

Ул арада трактор да берничә мәртәбә пошкырып алды, сездән котылып булмас, ахры, дигәндәй, хутка китеп, тыркылдый башлады. Егет белән кыз да җәһәт кенә урыннарыннан торып, эш урыннарына ашыктылар.

Бу сөйләшү Садыйк белән Кадернисаның икесе өчен дә тәэсирле булды. Унсигез яше тулыр-тулмас сугышка китеп, өч ел буе әле окопта, әле госпитальдә ятып гомер уздырган Садыйкка да һәм аның белән күрешеп сөйләшүне татлы хыялында гына йөрткән Кадернисага да өлгергәнлеккә сынау булды бу. Тик эскерт яныннан үзен һавада очкандай хис итеп киткән кыз егет белән нәрсә турында сөйләшкәнен дә, Садыйкка үзенең ни дип әйткәнен дә хәтерләмәде. Бу хәлләр аңа төшендә күргәндәй генә тоелды. Ләкин ул Садыйк җәйгән саламга утыруын исенә төшереп рәхәтлек кичерде. Чөнки гыйшык утында янган кызның беренче мәртәбә эчтән янып-көеп яраткан кешесе белән сөйләшүе иде шул бу.

Дөрес, сугышка кадәр Садыйк Назирә исемле кыз белән танышып, матур гына йөреп тә киткәннәр иде. Ләкин сугыш аларның тормышларына үз төзәтмәләрен кертте. Берсен фронтка озаттылар, ә икенчесен Уралдагы заводларның берсенә эшкә алып киттеләр. Назирә шунда ир хатыны, балаларының анасы булды.

Садыйк шушы кара кашлы, кара күзле, мөлаем елмая белгән, бер караганда әле сабыйлыктан да чыгып бетмәгән эчкерсез Кадерниса каршында үзе дә сизмәстән сынау тотты. Эш-гамәлләрен күңеленнән аның белән киңәшеп башкарды. Һәм бу сугышта боерык үтәргә өйрәнгән яшь егет өчен табигый хәл иде кебек. Әле чын мәхәббәтнең нинди икәнен татып карамаган булса да,

күнел төрендә йөрткән Кадерниса һаман саен аңа кадерлерәк затка әверелә барды, тынгылык бирмәде. Хәзер клуб тирәсендә дә сирәк күренде егет. Аның Кадерниса белән үзара җылы мөнәсәбәтләре исә кызларның йөрәгендә көнчелек уты кабызды. Берәүләрне шашкын хөсетлек-көнчелекләре хәтта үч алырга котыртты. Кешедәге шушы котсыз теләк берчакны уянып китеп, аның оят-намусын, күркәм сыйфатларын читкә этәреп куя икән шул. Аны хәтәр сукмактан алып китә. Эченә шайтан оялап, аны вәсвәсәли, күнеленә коткы салып, ихтыяр көчен үзенә буйсындыра.

***

...Ул көнне дә, һәрвакыттагыча, ындыр табагында кызу эш кайнады. Инде сентябрь ае бетеп барса да, әле кырларда зур, җәенке корсаклы чүлмәкләргә охшаган кибәннәр хәттин ашкан иде. Ә көннәр кыскарганнан кыскарды, яңгырлар һаман саен ешрак яуды. Колхозчылар бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр баш күтәрми иген суктырды. Механик Йосыф ындыр табагының берничә урынына элгән лампочкаларын генераторга тоташтырып, ут яндырып җибәрде. Көндезге кебек якты булмаса да, күз ияләшә төшкәч, «тозсызны күзсез дә таный» дигәндәй, нәрсәнең нәрсә икәнен күрергә, капшап булса да, эшләргә мөмкин иде. Шушы эңгер-меңгердә Кадерниса транспортердан килгән көлтәләрнең һәрберсен җәеп, тегенди-мондый әйбер булмагае дип аларны бәргәли-суккалый барабанга озатып торган бер мәлне, уч төбендә коточкыч авырту тоеп, кулын тартып алды. Шунда ул уч төбенә урак очы кадалганын күрде. Кызның куркудан ачыргаланып кычкырып җибәрүенә Йосыф уракны аның уч төбеннән тартып алды.

— Кулың бераз канасын. Тәненә төрле чүп-чар ияреп кергән булса, чыксын, — дип, Йосыф букчасыннан йод, марля алырга дип китеп барды. Урак көлтә арасына яшерелгән, сабы салам белән бәйләп беркетелгән иде. Уракның очы кайралган... «Кемнең үчлеге булыр икән бу» — диештеләр колхозчылар. Йосыф та уракны кулына алып, «Ярый әле суктыргычның барабанына кадәр барып җитми калды, юкса бөтен агрегатны эштән чыгарыр иде», диде. Берәүләр бу хәлне кемнеңдер усал шаяруы гына итеп кабул итсә, ә берәүләре исә, совет заманында бик күп гаепсезләргә тагылып, аларны корбан иткән корткычлыкка тиңләп, кичекмәстән милиция органнарына хәбәр итәргә кирәк, диде. Уенмыни? Әгәр урак сугу механизмнарын эштән чыгарып, эш туктап калса, бу үтә хәтәр корткычлык лабаса! Ярый әле мондый аяныч хәл булмый калды. Ләкин ындыр табагындагыларның барысы да (бу кабахәтлекне эшләүчедән башка) шушы яман хәлгә дәррәү килеп ризасызлык белдерде. Гаеплене һичшиксез җавапка тартырга кирәк диделәр.

Йосыф Кадернисаның ярасын ике яктан да йод белән чистартып, марля белән бәйләп куйды. Ул арада ындыр табагының тынып калуына аптырап, пошаманга төшеп, колхоз рәисе Сабирҗан да килеп җитте. Эшнең нинәрсәдә икәнен чамалагач, халыкны көлтә сугу машинасы янына җыйды.

«Гаепле» уракны алып, аның очлы башын як-яктан караштырып, очына бармакларын тидереп куйды ул.

— Моны кемдер кичә-бүген генә игәү белән кайрап очлаган. Менә, игәү эзләре дә бар. Кемнеңдер кемгәдер үче кабынган, — дип Сабир уракны Йосыфка сузды.

— Ярый әле, кызганыч булса да, Кадернисаның уч төбенә эләгеп калган. Юкса агрегатларны чәлпәрәмә китергән буласы икән, — диде Йосыф, уракны башкаларга биреп.

— Бәлкем, күрше авылныкыларның көнче берәрсе урак төрелгән көлтәне безнең ындырга ташлап киткәндер, — диде түбән очның Әминәсе, уракны жентекләп, әйләндерә-әйләндерә карап.

— Бик мөмкин. Бу ыгы-зыгыда кемнең нишләп йөргәнен кем белсен...

— Безнең уракларның барысын да кайрап, тимерчедә тамга салган иделәр, — диде урак куллан-кулга күчеп йөргән арада Әминә, сүзен очлап. Колхоз рәисе сүзен дәвам итте:

— Ул кеше безнең арабызда булса, аның хәле барыбызныкыннан да мөшкелрәк. Шуңа күрә сезнең белән киңәш корып, барыбыз өчен дә гыйбрәт булырлык бу хәлне шушында калдырып, онытыйк. Милиция органнарына хәбәр итмик. Әгәр ул кеше безнең авылдашыбыз булса, монда безнең дә гаеп бар. Без аны тәрбияли белмәгәнбез. Ул мескеннең хәленә хәлдәш була алмаганбыз. Ә ул үзенең уй-теләкләренә ия була алмаган.Борчулары белән берүзе калган, ялгышкан. Әгәр инде милиция органнарына хәбәр итсәк, алар чебеннән фил ясап, көне-төне тикшерә башлаячак. Эштән аерып, берәм-берәм чакырып сорау алулар китәр. Кирәкме безгә бу мәшәкатьләр?

Халык бер мәлгә тын калды.

— Шул гына житмәгәние... — диде кемдер.

— Инде бер тәгаен карарга килгәнбез икән, бу турыда, хәтта үз авылыбыз кешеләре дә белмәсен. Ул сер булып калсын. Килештекме?

— Килештек! — диде халык.

— Барыгызга да рәхмәт. Ә хәзер өйләрегезгә кайтыгыз, ял итегез.

***

Авыл халкының теленә кереп, монарчы әле һаман да сер булып калган һәм инде кыз-кыркынның күңелен жилкетеп-ымсындырып, жаннарына тынычлык бирми, туктаусыз кыбырсытып торган бер сорауга: — Садыйкның ирлеге бармы-юкмы турындагы бәхәсле сүз боткасына, ниһаять, күпмедер ачыклык кереп, билгесезлек пәрдәсенең бер почмагы ачыла башлады сыман. Сентябрь башларында егет житди рәвештә авырып китеп, Казан госпиталенә барып ятарга мәжбүр булды. Снаряд ярчыгы кайтавазы бу юлы да шеш булып, кабат «аваз салган иде». Садыйктан кат-кат анализлар алып, медицина фәненең бу хактагы соңгы казанышларын кулланып, табиблар хәл кадәри барысын да ихлас эшләргә тырыштылар.

Профессор Рәхимжанов та егетне үз канаты астына алып, дәваланунын һәр рәвешен күзәтеп тора. Һәр көнне Садыйк ятагы янында булырга тырыша. Инде өч атна вакыт үтеп, соңгы анализларын тикшереп караганнан соң, Садыйкны бүлмәсенә чакырып, аталарча киңәшләрен бирә.

— Егеткәем, син бик бәхетле кеше икәнсең. Сине әниеннең изге хәер-догалары саклап калгандыр. Өч ел сугышта булып, синең кебек сау-сәламәт кайту бик сирәк кешеләргә тәтеде. Шушы бәхетеннең игелеген күреп, рәхәт яшә. Фронт госпитальләрендә эшләгән табиблар да сине ихластан дөрес дәвалаганнар. Без дә кулыбыздан килгәннең барысын да эшләргә тырыштык. Ата кеше булырыңа шигем юк. Калганы үзеңнән һәм булачак хатыныңның сабырлыгыннан, тәкатьсезләнмәвеннән тора. Ул кыз сине чын күңеленнән яратып, синең нинди икәненне белеп, зур таләпләр куймый гына, түземлелек белән яши белсә, һәм син дә һәртөрле хәмерләрдән тыйлыгып, женес әгъзаңны салкын тиюдән саклап, артык авыр әйберләр күтәрми генә яшәсәң, иншалла, барысы да тәртиптә булыр. Уңышлар телим сиңа, — диде профессор.

Садыйк та, профессорга чиксез рәхмәтен белдереп: «Беренче улыбызны сезнең исемегез белән атап, хөрмәтле кунак итеп, бәби туена чакырачакбыз», — диде.

Шатлыгыннан канатланып авылына кайткан Садыйк, әнисе Фатыйма апа белән сөенечен уртаклашып, бер кат чәйләр эчеп алгач, идарәгә йөгерде.

— Бик вакытлы килдең. Иртәгә ат җигеп, Кадернисаны больниска алып барырсың. Кулын табибларга күрсәтеп кайтырсыз, — диде Сабирҗан, егет белән кызга үзара аңлашырга вакыт җиткәнен тоеп.

— Нәрсә булды аның кулына?

— Үзеннән сорарсың.

Үзеннән сорыйсы булмады. Бу турыда улы Садыйкка әнисе бәйнә-бәйнә сөйләп бирде. Бу мәкерле гамәлне эшләүченең дә исемен атап, халык шул дип әйтә, диде.

— Кем булса да, ул мескен үзе дә аңламыйча авыл халкын мәсхәрәләгән. Әгәр син әйткән кеше булса, бик тә кызганыч, ул каһарман әтисенең хөрмәтле исемен пычраткан, — диде Садыйк әнисенә. Моны көнчелек галәмәте эшләткәнен башына да китермәде егет...

***

Иртән иртүк Садыйк атын Кадернисалар капка төбенә китереп туктатты. Озак та көттерми, шешкән кулын яулык белән бәйләп муенына аскан Кадерниса да чыкты. Ул арбага мул итеп түшәлгән саламның асылынып-салынып торганнарын рәтләп маташкан егеткә:

— Саумы, Садыйк абый, — дип, ягымлы елмайды.

— Саумы, Кадерниса сеңлем. Әйдә, утыр. Әзер булсаң, Аллага тапшырып, кузгалырбыз да.

Кыз арбага утырган арада капка төбенә Кадернисаның әнисе дә чыгып басты.

— Садыйк улым, зинһар, кызымны саклый күр, — дип Бибигайшә авызын яулык чите белән каплады.

— Борчылма. Күз алмамдай итеп саклармын! — диде егет, кызга арбага утырырга булышты.

— Хәерле юл, балалар. Исән-имин йөрегез!

Кадерниса сулык-сулык килеп сызлаган кулын сәламәте белән тотып, йомшак итеп җәелгән салам өстенә менеп утыругa, юлчылар кузгалып китте. Инде атна-ун көн явымнар булмаганлыктан, юллар такыраеп калган. Арба келтерәп кенә бара.

Егет белән кыз бер-берсенә сүз катырга кыюлыклары җитмичә берара тын гына бардылар. Офык читеннән күтәрелеп килгән кояш урыны-урыны белән күк йөзен каплап алган аклы-каралы, төрле кыяфәттәге болытлар арасыннан әле чыга, әле керә, җылы нурларын җир өстенә бөрки. Зират агачлары өсләреннән дәррәү күтәрелгән карга өерләре, соңгы яфракларны җилгә очырып, һавага җәелә. Алар, кученнән аерылып чыккан бал кортлары сыман, тирә-якны берничә тапкыр кар-кар килешеп әйләнгәннән соң, кибән өсләренә ябырыла.

— Җыеп алган күпме ашлыкны югалтабыз, — диде егет, ниһаять, сүз башларга сәбәп табып.

— Аллаһы Тәгалә ризыкны барыбыз өчен дә бирә. Ашлыкның да келәтләргә кергәне генә безнеке. Бәрәкәте булсын...

— Дөрес әйттең. Мин сугыш кырларында исраф булган мал-мөлкәтне үз күзләрем белән күрдем

— Әйтмә инде, Садыйк абый. Уйласаң, акылдан язарлык шул...

Әле кичә генә диңгездәй чайкалып, шаулап иген үскән кырлар инде бушап калган. Бары тик, сәнгать әсәре дәрәҗәсенә җиткереп, зур-зур чүлмәкләр рәвешенә китереп салынган Хөснетдин абзыйның, «Хөсни кибәннәре» дип аталып, тирә-якта дан алган кибәннәре генә утырып калган. Бу да бит яшәү өчен барган көрәшнең бер чагылышы лабаса. Унышы җыеп алынган басу-кырларда ферма көтүләре, авыл халкының каз көтүләре җәелеп, чемченеп

йөри. Әнә, әле сугышка кадәр Чиләбе заводлары эшләп чыгарган тракторын иярләп, тирә-яктагы тынлыкка тормыш шавы индереп, Галимҗан абый җир сөрә. Сука очлары тиеп актарылган урыннардан арба тәгәрмәчләренен дырык-дырык килеп, менә-төшә тәгәрәп барулары Кадернисаның авыру кулын йолкып-йолкып алгандай итә. Кулының сызлавын никадәр Садыйктан яшерергә тырышса да, ул, ыңгырашып, кулын күкрәгенә кыскалый.

— Әллә юлның бозылган урыннарын җәяү генә үтикме соң? — диде кыз. Садыйк атын туктатып, Кадернисага арбадан төшәргә булышты.

— Рәхмәт, Садыйк абый. Мине нәни баладай итеп күтәреп төшерүеңә. Көчле икәнсең. Син яхшы кеше. Тик Ходай беребезне дә кеше кулларына калдырмасын икән.

— Амин, шулай булсын.

— Ә үзең соң? Үзеннең хәлең ничек, Садыйк абый?

— Табиблар яхшы диделәр. Булган вак-төяк авыруларынны Кадерниса туташ дәвалап бетерер, диде профессор.

— И-и, Садыйк абый, бу синең шаяртып әйтүең инде. Мин духтыр түгел ич, — диде кыз егеткә карап.

— «Духтырлар»: «Без — тән дәвалаучылар. Ә сиңа хәзер җан дәвалаучысы кирәк», — диделәр.

— Анысы кем булыр икән соң инде?

— Ул кешенең мин бик тә, бик тә син булуын теләр идем, — диде Садыйк. Ул өмет тулы коңгырт күзләрен тутырып кызга карады.

Кадерниса алдан ук ике арада моңа мөнәсәбәтле сүз булырын сизгән иде. Дөресрәге, ул шуны теләгән иде дә. Ләкин сөйләшү бу кадәр үк тиз булыр дип башына да китермәде. Садыйкның сүзләре бер ялкын булып йөгереп үттеләр.

Садыйк та тын алырга базмый, җаны-тәне хафаланып, үрсәләнгән күңелен тынычландырырга тырышып, һич кенә кирәкмәстән дә, тигез такыр юлдан барган атының дилбегәсен тарткалап, кыбырсыкланып барды. Ул кызның җавабын көтте. Нәрсә дияр? Әзерме ул бергә тормыш юлын үтәргә? Аның аяк астында яткан кайгы-хәсрәтләрен, һәр туар көн китергән борчу-мәшәкатьләрен иңнәренә алып, бер-беренә ышанычлы иптәш булырга, сөеп-яратып яшәр хатын булырга ризамы ул?

Ниһаять, Кадерниса телгә килде.

— Садыйк абый... Каушап калдым әле... Өздереп кенә җавап та бирә алмыйм. Ачуланма инде...

— Рәхмәт, Кадерниса. Бу синең иң дөрес җавабың булды. Үзең ишетеп беләсең, авыл халкы телендә минем турыда төрле сүзләр йөри. Нахагы да, хагы да. Ул сүзләр дә юктан гына барлыкка килмәгән. Уйла. Ахырдан үкенерлек булмасын. Үзең әйтмешли, күңел хисләрең аша, акыл аша үткәреп, төптән уйла.

— Яраткан кеше өчен бу гайбәтләрнең катнашы юк. Мондый сөйкемсез сүзләрне үзләре дә пакь булмаган кешеләр генә сөйләп йөриләр. Ә минем пычранасым килми. Минем өчен син ничек бар — шул бар булганың белән кадерле! — диде кыз.

Кадернисаның ихлас сүзләрен ишеткән Садыйк, корт чаккандай итеп, урыныннан сикереп торды. Ул дәртләнеп кызны беренче мәртәбә кочагына алды. Илаһи сөенү белән:

— Җан кисәккәем, кадерле Кадернисам. Мин сиңа чынлап торып кадерлеме? — дип сорады.

— Кадерле. Чынлап торып бик кадерле, — диде кыз, кыяр-кыймас кына Садыйкка карап. Аның мөлдерәмә сагышлы да, ялкынлы да күзләреннән мәхәббәт ташкыны ага иде сыман.

***

Хирург, Кадернисаның кабартма булып шешкән кулын бармак очлары белән баскалап карый-карый:

— Бу тәмам өлгереп җиткән икән, бик вакытлы килгәнсең, — диде. Аннан янәшәсендә басып торган шәфкать туташына кызны операциягә әзерләргә кушты. Ике укол кадаганнан соң, пәрдә артындагы кулын нишләткәннәрен күрмәде дә, белмәде дә кыз. Инде уч төбен ярып, яраны төрле чүп-чардан арындырып, бәйләп куйгач:

— Хәлең ничек, башың әйләнмиме? — дип сорады табиб.

— Юк, әйләнми. Авызым гына кипте, — диде.

— Суны берәр сәгатьтән эчәрсең, ярыймы? — Менә сина Вишневский мае. Шуның белән иртә-кич кулыңны майларсың, — дип, кечерәк кенә пыяла савыт бирде. Аннан соң, коридор ишеген ачып:

— Егет, ал гүзәлкәеңне, — дип, Садыйкка эндәште. — Берәр сәгать утырып ял итсен, — дип тә өстәде.

Юлның бер өлешен сүзсез генә: Кадерниса Садыйк үзе белән алып килгән чишмә суын эчкәләп, Садыйк исә, кызны борчыйсы килмичә — икесе дә үз уй-хыялларына чумып, тын гына бардылар.

Ара-тирә бер-берсенә текәлгән күзләр генә серләште. Бу аларның сынаулы да, сораулы да карашларының беренче мәртәбә сөешеп очрашулары иде. Садыйк гомерендә беренче мәртәбә өмет белән тулы гашыйк кешенең күзендәге иксез-чиксез ялкынлы мәхәббәт дәрьясын күрде. Ул үзе дә сизмәстән шушы тылсымлы дәрьяга чумгандай булды. Ниндидер мизгелләр арасында аның җанын моңарчы белмәгән ләззәтле хис-тойгылар кочып алды. Күңеленең яшерен кыллары тибрәнеп, бөтен тәненә сихри рәхәтлек җәелде.Бәгырендә ут-ялкын дөрләгәндәй булып китте. Ул сак кына, беленер-беленмәс тибрәнгәләп алган кызның кулын үзенең күкрәге турысына китереп куйды.

— Сизәсеңме?

— Сизәм, — диде кыз, егетнең йөрәк тибешеннән бар вөҗүденә көч-сихәт агылганын тоеп.

***

Ул елны көз искиткеч матур килде. Октябрь башларында халык гозерен ишеткәндәй итеп, берничә тәүлек вакыты-вакыты коеп та яуган яңгырлардан соң, күк йөзе катлам-катлам болытлардан арынып, көн аязып китте. Һәркөн иртән офыкларны алсу төскә манып, ялтырап кояш чыкты. Аның барча тереклеккә җан өрүче кодрәтле нурлары әле дә үзләренең сихри сулышларын бөркеп, бөтен дөньяны назлап иркәли. Бар табигать шушы илаһи рәхәтлеккә чумып, Аллаһыга чиксез рәхмәтләрен әйтә-әйтә зекер итә, көч җыя, зәмһәрир кышкы салкыннарны каршы алырга әзерләнә. Көзге уҗымнар да шаулап-гөрләп, кояшның көләч нурларына тартыла, тамыр ныгыта. Кыр бакчаларыннан бәрәңгеләрен алып бетерергә өлгермәгәннәр җир-ананың куенында тагы да үсеп, ярмаланып киткән йодрыктай бәрәңгеләрен киптереп, базларына салып куйдылар. Каралты-кураларының ватыкларын төзәтеп, бәрәңге бакчаларын казып, алма-чия, җиләк-җимеш агачларын кышка әзерләп кую хәстәрен күрделәр. Ындыр табагында да эш туктап тормады. Басу-кырлардагы чүмәлә-кибәннәр берәм-берәм кими барсалар да, эшләр бу рәвешчә дәвам иткәндә, сугуны яна елга кадәр сузу мөмкинлеге бар иде. Шуңа күрә бу бик тә җитди көнүзәк мәсьәлә колхозчыларның гомуми җыелышында каралды. Халык бертавыштан эшне иртәнге алтыдан кичке унбергә кадәр оештырырга кирәк дип карар кабул итте. Ындыр табагының як-якларын

саламнан үреп ясалган чыпта-каплавычлар белән төреп куйдылар. Йосыф кыр эшләреннән бушаган тракторны да генераторга тоташтырып, эш урыннарына ялт итеп янып торган лампочкалар элеп чыкты. Суктыргычка тоташтырылган трактор ватылып туктый-нитә калса дип ындыр табагында өстәмә трактор кизү торды. Авыл халкы быелгы мул уңышка шатланасөенә иген суктырды.

Кадернисаның да уч төбендәге ярасы төзәлеп, ул үзенең эш урынына килеп басты. Садыйк та, иртәнге нәрәдтән соң бер кат вак-төяк эшләрен бетереп, күрәсе кешеләрен күреп, йомышларын йомышлап бетергәннән соң, ындыр табагында булып, аның туктаусыз эшен тәэмин итеп торды. Вакыт-вакыт килеп, транспортёрда шуышкан көлтәләрне капшап-тикшереп киткәләде. «Бер авызың пешкәч, өреп эчәсең» дигәндәй, Кадерниса да каты брезент бияләйләр киеп эшләде. Сугылган саламнарны да эскертләргә салмыйча сыер фермасы буендагы бушлыкка ташып өйделәр. Бер өлеше белән шунда ук башак болгатып, сыерларга ашаттылар. Шушы эшләрнең барысы да Садыйк житәкчелегендә башкарылды, барына да ул жаваплы булды. Колхоз рәисе Сабиржан да ындыр табагыннан эзен суытмады. Әледән-әле килеп, үзе дә, сынар кулына агач көрәк алып, элеваторга китәсе ашлыкны капчыкларга тутырышты. Ындырда эшләүчеләр өчен дип пешерелгән ризыкларның тәмен авылдашлары белән бер табынга утырып бүлеште. Бер килүендә ул, Йосыфны читкә дәшеп, акрын гына:

— Теге, бәлале урак хужасының тавышы-тыны юкмы? — дип сорады, хәйләле елмаеп.

— Юк. Хәер, аны эзләп маташасы да юктыр. Сугышка кадәр балта осталары бригадиры булган Габдулла абый кызы Галимәдә генә әтисенең эш коралларын кайрау өчен дип тоткан игәве бар...

— Мин дә уйлаган идем аны... Сиңа бик зур үтенечем бар.

— Әйт, Сабир абый.

— Яу кырында башларын салган фронтовиклар исеменнән һәм үз исемемнән үтенеп сорыйм: безнең әлегә дәлилсез бу уйларыбызны зинһар өчен берәү дә белмәсен. Хәтта жан дустың Садыйк та белмәсен. Онытыйк без аны. Авылдашларның бер-берләренә шикләнеп, кырын караулары бер дә файдага түгел. Дус булып, тату яшик. Ата-бабаның: «Бердәм булыгыз, бердәмлектә — көч!» диеп, әманәт итеп, васыять итеп әйтеп калдырганнарын онытмыйк. Сөйләштек, килештекме?

— Килештек. Миннән бернинди дә сүз чыкмас!

— Ышанам. Егет сүзе бер була, — диде Сабиржан, Йосыфның кулын кысып.

***

— Батырларча сугышып, «Кызыл Байрак» ордены кавалеры булган, яу кырында ятып калган Габдулланың гаиләсенә ничек ярдәм итәргә, — дип сорады Сабир үз-үзеннән. Кызы Галимәнең көлтә арасына очлы урак яшереп куюын ничек аңларга мөмкин? Ә бәлкем, бу яман шуклык бөтенләй дә Габдулланың бердәнбер кызы Галимә эше түгелдер? Бәлкем, мин ялгышамдыр? Әлбәттә, ялгышам! — Шушы уйлар белән Сабир идарәгә кайтып керде. Ул турыдан-туры авыл Советы рәисе Ибраһим бүлмәсенең ишеген какты.

— Рәхим ит, Сабир туган, — дип, елмаеп каршы алды аны Ибраһим, сул аягына аксый-аксый, өстәле артыннан чыгып. Әйе, Габдулла һәлак булган сугышта Ибраһим да каты яраланган иде шул. Дошман самолетлары аның да сул аягының сөякләрен пулялар белән тишеп-чәрдәкләп, җилкәсен дә яралап, тәненә ярчыклар сибеп китә. Ярый әле, полк санитарлары

якында гына булып, вакытында ярдәм итәләр. Үзләре үк госпитальгә илтеп тапшырдылар.

— Эшеңнән бүлдем, ахры?

— Борчылма. Ул көндәлек исәп-хисап эше.

— Сиңа килүемнең сәбәбе шул: Габдулла абый Сафиуллин гаиләсенә ярдәм итәсе иде бит!

— Авыл Советының мөмкинлекләре зурдан түгеллеген үзең беләсең. Тик шулай да, туктаусыз район җитәкчелегенә йөри торгач, тукый торгач, сыерлары булмау сәбәпле, дустым Габдулланың гаиләсен ит, сөт, май салымнарыннан азат итә алдык.

— Бу бик саллы ярдәм булган икән бит.

— Үзебез дә шатландык инде. Аннан соң, үзең беләсең, колхоз исәбеннән ел саен кыш буена җитәрлек утын кайтартыла, хайваннары саламнан, тавыклары көрпәдән өзелми. Быел балта осталары каралты-кураларын төзәтеп куйды. Үзем дә инде кулдан килгәннең барын да эшләргә тырышам.

— Рәхмәт, Ибраһим абый. Быел менә яхшы гына иген уңышы җыеп алдык. Шуны суктырып бетерү алдында торабыз. Эшләрне тәмамлап, ашлык бүлгәндә, колхоз идарәсе Габдулла абый гаиләсенә дә үз өлешен кертер, иншалла. Рәхимә апа үзе дә, балалары да тырышып эшлиләр. Алар да өлешнең зурысына лаек кешеләр.

— Кызы Галимә киләсе елга унынчы классны тәмамлый инде, боерган булса.

— Бик вакытлы искә төшердең әле. Мин дә синең белән Галимә турында сөйләшмәкче идем. Әллә дим колхозчыларның февраль аенда узачак исәп-хисап җыелышында, ул кызны колхоз исәбеннән үзе теләгән институтта укыту турында карар кабул итикме?

— Һай, игелекле гамәл булыр иде бу! Рәхимә дә, Галимә дә шатланып бетә алмаслар иде.

— Алай булгач, сөйләштек. Син аларның күңел кылларын чиртеп кара әле. Укытучылар белән дә киңәшеп, аларның да фикерләрен белү кирәктер? Кызның нәрсәгә сәләтле икәнен дә әйтерләр, институтын да тәкъдим итәрләр.

— Матур уй-фикерләрең өчен рәхмәт. Мин шушы көннәрдә үк бу мәсьәләләрне ачыклармын...

Ләкин Сабирҗанны туктаусыз мең төрле шомлы-шөбһәле уйлар борчыды. Алар аның башында иртә дә, кич тә өермә булып бөтерелде. Җавапсыз сораулар туа торды, борчулы йөрәгенә кадала торды.

Нинди максат белән, кемне йә булмаса ни-нәрсәне күздә тотып көлтә арасына яшерде икән бу кеше очлы уракны?

***

Ноябрь ахырларына таба игеннәрне суктыру ахырына якынлашты. Яңа яуган җепшек кардан шыгырт-шыгырт атлап, яшьләр кичен клубка җыела. Кино күрсәтүче килмәгән, авылның үзешчәннәре концерт күрсәтмәгән, театр куймаган кичләрдә клубта гадәти тормыш кайный. Бер өлеше яшьләр домино суга, шашка-шахмат уйный. Ә бер ишләре җыр-биюләрдә, төрле түгәрәк уеннарында катнаша. Садыйк түгәрәк уртасында сирәк күренсә дә, Йосыф аккордеонын сайраткан, Садыйк аяк очлары белән клуб идәнен чәбәкләгән көннәрдә, клуб халкы җанланып китә. Дәртле биюләр, моңлы җырлар йөрәкләрне җилкендерә. Андый кичләрдә клуб халык белән шыгрым тулы була. Кадерниса, һәрвакыттагыча, клуб уртасындагы уеннарны читтән генә, түгәрәк читендә торып кына, тын

гына күзәтә. Ул эчтән янып сөйгән егете Садыйкны күнел күзе белән дә күрүенә шатлана, күнеленнән аның белән мактана. Сабыр гына клубтагы уеннарның беткәнен, Садыйкның озата кайтуын көтә. Менә бүген дә егет белән кыз бөтен дөньяны акка төреп яуган ябалак кар бөртекләренә сокланып, татлы уй-тойгылары тәэсиреннән рәхәтлек кичереп, авылның тын урамыннан, кулларын кулга тотышып, киләчәккә карап атлыйлар. Ничек булыр ул киләчәк?..

***

Вакыт кичкә авыша төшкәч, Садыйкның әнисе Фатыйма апа, кунакмазар килә калса дип саклап торган такта чәен, улы Садыйк алып кайткан затлы баш яулыгын назлап кына тотып, үз жаена пөхтәләп кенә әнисеннән калган оренбур шәленә төргәннән соң, нечкә тал чыбыгыннан үргән нәни кәрҗингә иплəп кенә күчтәнәчләрен салып, югары очтагы ахирәт дусты Бибигайшә янына юл тотты. Ул ашыкмый гына, вак-вак атлап, ял итә-итә барды. Соңгы вакытта бугазындагы зәхмәтле чире көчәеп, ипи, бәрәңге кебек ризыклар үтми башлаган иде инде. Катык-сөт кебек сыек тәгамнәрне дә авырлык белән йота алуы сәбәпле, күзгә күренеп ябыгып калды ул. Аз гына тегене-моны эшләсә дә, бераз йөргәләп алса да, хәле бетә, күз аллары карангыланып, башы әйләнә башлый. Әле үзе кырык биш яшьтә генә булса да, санаулы гына көннәре калып барганын жаны-тәне белән сизеп, үзе исән чакта йортка килен төшереп, Садыйкны башлы-күзле итеп калдырасы килде аның. Кичә Садыйк Кадернисага өйләнергә нияте барын, кыз да риза икәнен әйткәч, сырхауларын да онытып, дәртләнеп китте. Кадерниса туган көннән алып Фатыйма бу кызны килене итәсе килеп хыялланды. Ахирәт дусты Бибигайшә белән бергәләп караштыр-багышты, аңа күз-колак булып, һәр адымын күзәтеп торды. Бу ике хатын балаларының бергә кушылып, бәхетле гаилә корып жибәрүләре турында әледән-әле сүз куертып ала иделәр. Ахирәт дуслар егет белән кызның бер-берләрен сөешеп өйләнешүләрен бик тә тели иделәр шул. Ә инде кичә улы Садыйк аларның теләкләре тормышка ашу ихтималы барлыгын да әйткәч, Фатыйманың башы түшәмгә тиярдәй булды.

Бибигайшә ахирәт дусты Фатыйманың киләсен күнеле сизеп, аны ашсуын хәстәрләп каршы алды.

— Әйдә, әйдә, түрдән уз. Сагынып та беткән идем үзеннә. Һәр көнне кичен синең янына барып кайтырмын дип үз-үземә сүз бирәм югыйсә. Тик барып житеп кенә булмады. Хәлләрең ничек соң? Азрак сырхаулап тора дип ишеткән идем, — диде хуҗабикә, дустын түргә уздырып.

— Үзең күрәсең, — диде Фатыйма, ябыгып, боегып калган тәненә күрсәтеп, — хәлем әлләни мактанырлык түгел, ахирәткәем, — дип, күчтәнәчләрен бирде.

— И-и, ахирәткәем, бу кадәр зурлап килмәсәң дә ярар иде кана.

— Садыйгым фронттан алып кайткан баш яулыгын сиңа бирәсем килде. Төсем итеп бөркәнерсең.

— Алай ук димә әле син. Әле үз йөзеннә күреп яшәргә язсын. Ходайның рәхмәте киң аның. Менә терә үзең дә терелеп китәрсең, боерган булса...

— Шулай булсын иде дә бит... Тик минем бу тамак чире — әҗәл чире шул. Аннан исән калулары икеле, дускаем. Шуңа күрә дә, үзем исән чакта кавыштырып каласы иде бит балаларны, — диде Фатыйма, карлыккан тавыш белән кырых-кырых йөткергәләп ала-ала.

— Кадерниса кичә кичен кайткач, Садыйкның тәкъдим ясаганын әйтте. Аллаһы Тәгаләнең балаларыбыз күнеленә салган мәхәббәте бәрәкәтле

булсын инде. Мин шат, мин бик шөкер, ахирәткәем. Тигезлектә яшәп гомер итсеннәр.

— Шулай гына була күрсен. Еллар тыныч булып, тәүфыйклы балалар үстерергә насыйп булсын. Ә гомер дигәнең — ул искән җил кебек уза да китә икән.

— Әйтмә дә инде. Әле кайчан гына үзебез дә мәш килеп, кияүгә чыгып йөргән идек югыйсә. Әйтерсең, кичә генә кебек, — дип Бибигайшә табын әзерләргә керешге. — Ә бүген инде балаларыбызны башлы-күзле итәргә дә вакыт җиткән. Уйласаң, исең китәрлек инде, ахирәткәем.

— Вакыт туктап тормый шул. Безнең әни әйтәдерие: «Вакытның аты җигелгән» диеп. Ул бара да бара шул. Тик без күргән михнәтләрне, кайгы-хәсрәтләрне, борчу-мәшәкатьләрне, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ачлык-ялангачлыкларны балаларыбызның балаларына да күрергә язмасын иде инде.

— Шулай гына була күрсен лә, — диде Бибигайшә, дустының алдына пары бөркелеп торган чәйле чынаяк куеп. — Әйдә, хәзинәдә барын капкала әле. Менә, яна гына аерткан сөзмәне авыз итеп кара.

— Үтми шул. Бик ашар идем дә бит. Менә монда — тамак төбемдәге бер төер җибәрми, — дип, бугазына төртеп күрсәтте Фатыйма. — Тамагыңнан үткәндә ашап кал дип әйтәдерие әнием, мәрхүмә. Дөрес әйткән икән, җан кисәккәем.

Ахирәтләр сөйләшеп, җай гына чәйләрен капкалап утырган арада, Кадерниса да эштән кайтып керде. Кыз кунак белән оялып кына исәнләшеп, почмак якка узды. Тик озак та үтми, аны бергәләп чәй эчәргә дәшеп алдылар. Сүзне Фатыйма башлады:

— Кадерниса кызым, — диде ул, карлыккан тавыш белән тирән итеп сулыш алырга тырышып. — Садыйк улыма кияүгә чыгарга ризалык бирүең өчен рәхмәт. Аллаһы Тәгалә сезгә бәхетле-шатлыклы, хәерле озын гомер әйләсен. Мәхәббәтегез гомерегез буена сүнмәсен, күңелләрегез сүрелмәсен. Бер-берегезгә ышанычлы терәк булып, сәламәт балалар табыгыз. Аларны тәүфыйклы, намуслы итеп тәрбияләгез. Үзегезне дә, башкаларны да хөрмәт итеп, бер сүздә булып яшәгез. Бездән сезгә хәер-фатыйха. Әби-бабаның әманәтле васыятьләрен мин сезгә тапшырам.

— Изге хәер-фатыйхаң өчен рәхмәт, Фатыйма апа. Аллаһы Тәгалә сиңа да ике дөнья рәхәтен бирсен! — диде Кадерниса.

— Барча теләкләребез дә фәрештәләрнең амин дигән сәгатьләренә туры килеп, тормышка ашар иншалла, ахирәткәем, — дип сүзгә кушылды Бибигайшә.

***

Колхоз рәисе Сабир туйны зурдан кубып, клубта үткәрү ягында иде. Әмма Фатыйма аңа каршы төшәргә җөрьәт итте.

— Кояш кадәр кояш та ошамый кайбер кешеләргә, — диде ул. — Авылның да төрле кешесе бар. Берәүләргә ошаган туй мәҗлесе икенче берәүләргә ошамаска мөмкин. Шуна күрә, һәртөрле гайбәт, яла ягу, нахак сүзләрсез генә хәләл мал, хәләл ризык хисабына үткәрү дөрес булыр. Чөнки туй — изге мәҗлес.

Туй кунакларын егет белән кызның колхозда эшләү көннәренә тигән бодай онынннан җәелгән, вак кына итеп туралган токмач салып пешерелгән аш белән, ит шулпасы белән һәм мәҗлес хөрмәтенә чалынган сарыкларның итләрен савытларга салып та, бәрәңге боткасына кушып та сыйладылар. Ә чәй табынын таба ризыклары бизәде. Әле ил халкының шәһәрләрдә яшәп, завод-фабрикаларда эшләүче өлеше икмәк

карточкалары аша гына жан асрап яткан, ә инде авыл жирләрендә яшәүчеләре хөкүмәттән бернинди дә ярдәм күрмәгән, киресенчә, авыл халкын төрледән-төрле салымнар белән кычкыртып талаган бу чорда Садыйк белән Кадернисаның туй табыны шактый мул иде. Рәхмәт колхоз рәисе Сабирга.

Туйда тукмак уйнамады. Мәжлесе нәкъ менә Фатыйма кодагый әйткәнчә булып, Сабир карамагында үтте. Һәр якнын да хөрмәтле кешеләре сүз кушып, яшьләргә саулык-сәламәтлек, бәхетле-шатлыклы гомер, тәртипле-тәүфыйклы балалар үстерегез, дип теләделәр. Кадернисаның ындырда бергә эшләгән иптәш кызлары да туйда булып, Йосыф абыйларынын аккордеонына кушылып, яраткан көй-моннарын янгыраттылар, дәртле биюләре белән мәжлес халкының күнелләрен күтәреп жибәрделәр. Инде озак вакытлар туй күрмәгән халык тәмам жанланды, барысынын да күнелләре күтәрелеп китте. Тәнәфесләрнең берсендә колхоз рәисе мыштым гына Йосыф янәшәсенә килеп:

— Киләсе туй – синеке. Әзерләнә башла, — диде.

Мондый тәкъдимне һич көтмәгән егет бераз тынсыз торгач:

— Туй итү өчен аның кәләшен табарга кирәк бит әле, — диде.

— Кәләшне еракка барып эзләп йөрисе юк. Әнә алар, берсеннән-берсе чибәрләр. Күнеленә ошаганын, жанын, теләгәнен сайла да ал.

— Әйтик...

— Әйтик, Габдулла абыйның Галимәсе синең өчен туып, буй житкереп килә шикелле?.. Ни диярсең? Бу чибәр тутый кошны тотып калмасаң, очып китүе дә бар. Уйла, уйла, егеткәем, — дип Йосыфка хәйләкәр күз кысты да, – «Урак» белән «Чүкеч»не үзебезчә – татарча берләштерергә кирәк, — дип уйлады Сабиржан.

Туй дәвам итте. Садыйк кияүне кат-кат чакырып биеттеләр. Ул, ниһаять Кадернисаны уртага алып чыгып, такмак әйтеп, бии-бии хәләле тирәсендә әйләнә башлады:

Мәхәббәт татлы булса да,
Алма түгел ашарга.
Гомерлеккә сөйдем сине —
Мөмкин түгел ташларга!

...Алар дүрт малай, ике кыз табып-багып үстерделәр. Гомерләре буе «берданберем булырсың» дигән сүзләренә тугры калып, Кадерниса биергә өйрәнә алмаса да, үрнәк гаилә булып гомер иттеләр.



Әмир
Мәхмүдов

# ЭЗЛИМ ДӨНЬЯ ТОТКАСЫН

## Хыял

**Яшьлек иленә кайталсак,**
**Шомырт күзләреңә карап**
**Чәчләрең тарар идем.**
**Йолдызлы күктән**
**ялварып**
**Тик Бәхет сорар идем.**
**Йолдызлы күкләргә**
**Табынып**
**Тормышны җайлар идек.**
**Бүген булса,**
**Мәхәббәтнең**
**Тик үзен сайлар идек.**
**Алтыннан**
**Кыйммәт Бәхетне**
**Һичшиксез**
**табар идек!**

## Китәбез...

*(вариант)*

**«Китмибез!» – дип, бөек Тукай язган...**
**Китми мөмкин түгел, китәбез!**
**Чиксез далаларны без яңадан**
**Азат халык булып үтәрбез.**

**Мәңгелеккә киткән бөек Тукай...**
**Китәбез шул, туган, китәбез!**
**Коллык богауларын өздек, бугай...**
**Канатлы ат сыман – күктә без!**

Әмир МӘХМҮДОВ (1947) – *шагыйрь, филология фәннәре докторы. «Матурлык тантанасы», «Мәңгелек моң», «Әмир иле» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Татарлыкка гына китәбез без...
Китмәсләр дип өмет итмәгез!
Беркайчан да кире кайтмабыз без...
Кара җаннар, безне көтмәгез!

## Белмим, нәрсә карадык?

Чуер ташларны санадык,
Тын чишмәгә карадык.
Көмеш чишмә
Яннарында
Озын, кара чәчләреңне
Икәү бергә тарадык.
Бәхетне генә югалттык...
Белмим, нәрсә карадык?

## Эзлим дөнья токтасын...

Тормышыңдагы бушлыктан
Сине кемнәр коткарсын?
Котылырга чара эзлим,
Эзлим дөнья токтасын.

## Мин

Янасыларын да яндым,
Авасын да аудым мин.
Ташлары тәгәрәсә дә,
Җимерелмәс таудыр мин.

Авасыларын, аудым да,
Кара җанга – яудыр мин.
Яратырдайлар яратты,
Шуңа күрә саудыр мин.

Дилбегәсен бер бушатып
Җыя белгән җандыр мин.
Байлыгым күп,
ул – серләрем,
Беркемгә дә калдырмыйм.

## Ялгышлар

Зирекле күлен сагынган
Кайтып җиткән аккошлар.
Тормышымда – ялгышлар,
Бу җаным кайда кышлар?

## Кайгылы төсләр эчендә...

Пешмәгән әле алмалар,
Коелып
Тезелгәннәр.
Кайгылы төсләр эчендә
Шатлыклы
Сиземләү бар!

## Файдалы...

**Сайландың син,**
**Тормыш юлларында**
**Чәнечкеле гөл дә**
**Сайладың.**
**Көл калды шул**
**Гүзәл тормышыңнан,**
**Гөлләр өчен**
**Көл дә файдалы.**

## Сизми алар...

**Күңелләре нинди икән?**
**Ишекләре – каралар.**
**Кия белмәгән бәндәләр**
**Ак күлмәкне каралар,**
**Болгана бәндә, югала,**
**Югалган шул чамалар.**
**Еларга кирәк булганда**
**Нинди кызык табалар?**
**Мәкерлек бар...**
**Сизми алар,**
**Шатланып**
**Кул чабалар.**

---

## Хөрмәтле укучыларыбыз һәм авторларыбыз!

**Журналыбыз белән даими танышып баручылар белә булыр: бездә «Казан утлары» архивыннан» дигән рубрика бар. Бу сәхифә байтак еллар гамәлдә булса да, элегрәк елларда материаллар сирәгрәк чыга иде. Соңгы вакытта «архив» активлашты, журналның һәр санында диярлек татар тарихыннан иҗтимагый әһәмияткә ия булган фотосурәтләр басылып килә. Теләгебез—алга таба да рубриканы кызыклырак һәм мәгънәлерәк итү. Бу эшне уңышлы дәвам итү өчен сезнең дә булышлык кирәк. Сезгә мөрәҗәгать-гозеребез шул: үзегезнең шәхси, гаилә альбомнарында яки оешма-учреждение архивларында сакланган кызыклы, тарихи-иҗтимагый кыйммәте булган (әдәбият һәм сәнгатебезнең мәшһүр шәхесләре, истәлекле мәдәни вакыйгаларга караган күренешләр, Казан һәм Татарстан тарихын яктырткан сурәтләр һ.б.) фоторәсемнәрне безгә юлласагыз икән! Шул рәсем турында аңлатма-комментарийларның булуы да шарт, әлбәттә. Без аларны журналда файдаланганнан соң, кире иясләренә кайтара алыр идек.**

**Әйдәгез, кадерле укучылар, мөхтәрәм милләттәшләр, кайдадыр киштә-шкафларда, альбом-папкаларда ябылып яткан истәлекле ядкярләрне яктыга чыгарыйк, халкыбызның рухи елъязмасы сәхифәләре булып киләчәк буыннарга хезмәт итсен алар! Сездән кызыклы фотоматериаллар көтәбез.**



Марат Әмирханов

# ИР–МАМАЙ

ТАРИХИ БӘЯН

*Татар дигән исем йөртәбез без –*
*Татар каны ага тамырда.*
Нури Арсланов

## Тәү кыйсса

— Ай-һай-ваем, коткарыгыз сана...

Тутакайлар көзге чебеннәрдәй янә ятакны сарып алды. Мул сынлы күн[1] хатын да йөгереп кенә шул тарафка сулы ләгәннәрен ташыды.

— Ай-ваем ла...

Кендек әбисе калын иреннәрен очлайтып, әйтә-әйтә инде таушалып беткән җөмләләрен кабатлады:

— Тәтә-бикә, иләктәй җәел, куздай бөреш, тәтә-бикә...

Бикәнең кан качкан йөзе җөй өслегедәй тартышып куйды, нидер әйтмәкче итенсә дә сүзләре чыкмады, бары яшь тәрәлгән күзләре генә сыкранып ачынды.

— Җеп өзәрлек тә хәле калмаган ич бичаракайның, котылулары ташка үлчим...

— Май кап!

Кендек әбисе булышчысын чеметеп алды.

Тулгак бу юлы да нәтиҗәсез тәгәлләнде. Бикәнең гәүдәсе сыгылган кер шикелле бөрешеп катты.

Тышта давыл котырына иде. Киез тирмә тәгәрмәчтәй түгәрәк алкачаңгырасы һәм дә сырт кабыргаларын, түбәсен күтәреп торучы бөгемле агачлары-ниләре белән йөзтүбән кубарга житешеп чайкала.

Ишек сакчысы пошаманда. Ана да гомерендә бик күп гарасатларга тап булырга туры килгәне бар, әмма мондый да хәвефлесенә беренче мәртәбә юлыгуы иде. Күр, ничек тузына, бер-бер йөзьяшәр аждаһаның күк сәгате суккандыр, мөгаен. Жир-ана көчле шул ул, аның кочагыннан ансат кына котыла алмыйсың.

[1] Күн хатын — хезмәтче хатын.

Марат ӘМИРХАНОВ (1933) — *прозаик; «Таш һәйкәл», «Тәкъдир», «И кылган догам минем», «Дөя муены» h.б. китаплар авторы. Журнал укучыларына ул тарихи темага язылган «Үрбәт ханәкә гыйшкы», «Гәүһәршад», «Әлвидаг» романнары белән таныш. Казанда яши.*

— Бәгыремә тия, нинди шау-шу соң анда? — дип өзгәләнеп сорады бикә.

— Сәмум, — диде кендек әбисе, — һич тына белмәде.

Гарәбстан чүлләрендә котырган чын сәмумның гомере югыйсә кыска үзе — бер карыш кояш юлы. Гадәттә ул капылт кына бетеп тә куя иде. Кагыйдәне албасты бутады булса кирәк. Ни-нәрсәгә ишарә бу, һич анламассың. Әнә, бикә дә инде өченче тәүлек баласын таба алмыйча азаплана, мескенем.

Тутыя бикәнең икенче йөге. Тәүгесе җинел булган икән. Монысы көмәнгә узуга ук бугазыннан эләктереп алды шул. Әүвәл аш сайланды. Ризык мул анысы, сайланасың килә икән, сайлан. Әмма ул төшкә дә кермәстәйләрне таптыра. Балачакта дус кызлары белән баш яулыгын җәтмә итеп, сай суда балык тотып уйныйлар иде алар. Балык дисәң исең китәр, чәнти бармактан да кайтышрак көсләр шунда.

Көннәрдән бер көнне күңеле шул балыкларны үтереп сорапмы-сорый гына бит, һич тәкатенә куймый. Элек авыз итеп караган булса икән?! Инеше дә ташу вакытында гына яши, хәзер җәй уртасы, чиллә.

Күңеле барыбер туган-үскән ягының вак балыгын авыз итмичә хушланмады.

Ярый, бусысының сәбәбе дә бар ди, атан дөянең мәшкәсе гүпчем дә акылга сыя торган нәмәстәкәй түгел ләбаса.

Нәфесе котырудан чарасы калмагач, Тутыя серен килендәшенә чиште. Судан шайтанынны да чыгарырдай тәвәккәл һәм кыю зат анын килендәше. Ни-нәрсә кыландыргандыр да, нинди юллар тапкандыр, өйләдән соң ул әлеге ризыкны өстәлөнә куйды.

— Туймасбикә, мә, пешкәнен ашап кара инде алайса, — диде күзләрен уйнатып, — башка сорыйсы итмә, әле дә оялуымнан үлә яздым.

Ходайның рәхмәте, шуннан соң талымлавы да үзеннән-үзе сүнде. Анын урынына, бирән тамакка әверелде. Ни туры килә, шуны соса башлады. Берсендә ярты сарык түшкәсен ялт иттереп куя язды. Алып куймасалар, ихтимал, кисәген дә калдырмаган булыр иде.

— Аллам сакласын, җә ярылырсың, — диде гасәбә хатын, — хуҗабыз да өнәмәс.

Кыят төмәнбаш исә яшь бичәнең аш-суга ятуын үзенчә гөманлый иде.

— Коры үләндә дым булмас, коры сөяктә май булмас, малай тибенә корсакта, малай, баһадир! — дип авызын гына ера.

Төмәнбашның малай теләве һич тә гаҗәп түгел иде. Әлегәчә анын варисы юк. Дүрт хатынынын дүртесе дә кыз алып кайтты. Өмете акланмагач, берсен аерып җибәреп, нәселлерәк җефет сайларга мәҗбүр булды. Ни кызганыч, анысы да беренчегә чәчби бүләк итте.

Тутыя бикәнең ирен бәхеткә чумдырасы, үзенә багланган ышанычны бик тә аклыйсы килә иде, билгеле. Сыналган йола дип җәмәгате янына бүрек киеп ята иде. Каенанасын тез буыннары тотмас хәлгә житкәнче көнгә берничә мәртәбә йөгенеп сәламләр иде. Каенанасы исә: «Йөгенә-йөгенә йөкле бул, буазла да сөтле бул», — дип сәламен кайтара иде. Бу да ир бала табуга хөсне ният иде.

Тутыя бикә муенына камыт житмәстәй түгәрәкләнеп, ит бүкәненә әверелде. Тулгагы бугазына тыгылганчы күшәвен белде.

Ата-бабадан килгән йола баланы далада табуны хуп күрә. Кыят бәк тә хатынын үз биләмәсендәге ялан кырга, ыру тиягенә озатты. Анда алдан ук берничә тирмә күтәреп куйганнар иде инде.

Тутыяга урынны кузалак арбага көйләделәр. Чөнки ат менәрлек хәлдә

түгел иде. Шулай да яраткан тимгел чуар толпары Сонаны, затлы дирбиясен кигезеп, тәртә башына бәйләтте. Ул аны килен булып төшкәндә кырыкмыш тай килеш үзе белән алып килгән иде. Әле дә туган җир төсе итеп саклый, үзеннән калдырмый.

Арбакашны бәк тәгаенләде.

— Колагына ныклап тамыз, — дип кисәтте сәфәр алдыннан, — бикәнең корсагында минем улым ята, әгәр аның белән бер-бер хәл була икән, ат койрыгына тагачакмын.

Арбакаш күлмәкчән туган иде, күрәсең, шушы хәвефле юлда бикәне эченә каты да төшермичә китереп җиткерде, исән-имин туганай туталар кулына тапшырды.

Тутыя бикәнең хәле төнгә авышкач авырлашты. Тулгак арты тулгак, ә карыны һаман бушамый. Кендек әбисе куллары белән булышып та карый, ләкин бикәнең көчен май ураган сеңер-тамырлар йота иде, ахры, тартышуы аналыкка җиткәнче сүнә дә бетә. Күз төпләре кара янып чыкты, иреннәре күмкүк, маңгаеннан туктаусыз тир саркый, корытырга гына өлгер.

— Бикәгә абыстай китертсәң, бәлки, догасының ярдәме тияр иде, — диде шаһиттута.

— Алдарак чарасын күрергә иде дә бит, — диде кендек әбисе, — кем уйлаган, хәзер соң инде, гарасат барча юлларны япты.

— Ай-ваем...

— Менә шулай, менә шулай, көчән бикә, көчән!

— Ай-ваем...

Кечкенә генә бер мизгел арасында Тутыяның баш очыннан фәрештә канат җилпеп узды. Тәненә шундук әүвәлге көче кайтты.

Һәм шунда ук, сәмум зилзиләсен басып, бала тавышы яңгырады.

— Үә-үә-үә...

Кендек әбисе сабыйны кулына алып, артын чәбәкли-чәбәкли оран салды:

— Ул туды, илгә ту[2] туды!

Туталар шау-гөр килеп балага ябырылды, һәммәсенең ана учы белән кагылып аласы, көч-куәт өстисе килә иде. Нарасый әле мондый игътибарга күнмәгән, ризасызлыгын белдерә.

— Үә-үә-үә...

— Сабыр, углан, сабыр, хәзер эт күлмәге кигезермен, кырык көннән салдырырмын, кырык кашык су белән коендырырмын, — дип сөйләнә-сөйләнә кендек әбисе үз шөгыленә керешә.

— Бикәнең җаны күккә ашкан түгелме соң, корткалар, тавыш-тыны ишетелми, — дип шөбһәсен белдерде шаһиттута.

Сабый белән булышып, анасын бөтенләй исләреннән дә чыгарганнар икән ләбаса, таң калдылар: ничек инде шушындый шатлык вә куаныч ташып торган чакта дөнья куймак кирәк?

— Әҗәлгә мәҗәл юк, — диде кендек әбисе тыныч кына, — бикә үз вазифасын җиренә җиткереп башкарды, мөхтәрәм түмәнбашны варислы итте, нәселнең хәзер мирас иясе бар.

«Бер бала бер атага җитә туар,
Бер бала бер атадан үтә туар,
Бер бала бар өстеннән кире карый китә туар», — диде кардәш туганай һәм битен сыйпап куйды.

— Гарасат узды!

Шыгавылның бу хәбәре өй эчендәгеләрне мәшәкатьле чынбарлыкка кайтарды, ыгы-зыгы купты.

[2] Ту — әләм, каһарманлык билгесе мәгънәсендә.

Тутыяны шул ук көнне ыру зиратында җирләделәр. Ә ике көннән ире Кыят бәкне давылбаз[3] кагып, далбай[4] кычкыртып каршы алдылар. Табын мул иде. Дәстәрханда табак-табак ит өелеп тора, чатакларда борынны кычыттырып сары бал чемерди...

Кендек әбисе ак биләүгә биләгән нарасыйны атасының таза һәм көчле беләкләренә салды.

— Менә, мырза, тустыган күзле йөгерек колының, кайнар кочагына кыс, җилегенә тизрәк май тулсын, азамат ир-егет булып җитешсен!

— Авызына зәмзәм, кортка, — диде бәхетле ата, — сөенеч ялына ун дөя, рәхәтен күр!

— Бәрәкалла, мырза, юмартлыгың үзеңә бише белән кайтсын.

— Аналыкны туган-тумача арасыннан сайлыйсы иде, — дип, кардәш туганай да сүзен кыстырды.

Кыят бу тыгылуны ошатмады.

— Кемне сайларга икәнен мин үзем бик яхшы беләм, — диде ачу белән, — бу бәхетле көнемдә ашыма төкермәсәң дә бик ярар иде.

— Анасының васыятен генә исенә төшерүем...

— Тутыя бикә хәзерендә гап-гади бер мәет, җиһан белән тереләр идарә итә, кардәш туганай.

Мәҗлес табыны җанланганнан-җанлана барды, сары бал да йөрешен бермә-бер арттырды, сүзләр көррәк чыга башлады.

— Бәйрәм килде, бәйрәм килде, яшәсен яшь хуҗабыз! — дип оран салды угланнарның берсе, — мактау төмәнбашыбызга, салават!

— Рәхмәт, хак, бүген бездә зур бәйрәм, — диде Кыят мырза, — ыруыбызга лаеклы варис өстәлде.

— Исем-аты да әзер, — дип күтәреп алды кендек әбисе, — бала тугач та чатырга иң әүвәл сак эте аяк басты. Этсак[5] бик күркәм яңгырый.

— Сөбханалла!

— Туктале, тукта, кортка, буташтырма, — диде мырза ризалашмыйча, — мин аңа каһарманлыклары белән дан кичкән иң дәрәҗәле татар исеме әзерләдем. Улым Мамай булыр.

Мамай мырза каршында тез чүгегез!

Бу — 1330 елның август ае ахыры иде.

## Алтыннан суккан Ак Урда

*Сарай дигән каласы,*
*Сиксән күчә арасы.*

«Идегәй» дастаны

Мәет искәрмәстән калтырап китте. Шул ук мизгелдә кәфен эченнән чукмарга охшаш зур саргылт йодрык килеп чыкты...

Җеназа өннән тайды. Баядан бирле үләксә өметеннән күк төбендә асылынып торган козгыннар да тавышсыз-тынсыз гына офык күләгәсенә кереп постылар.

— Терелде!

Кешеләрне тастарчының шом сеңгән шушы шөбһәле сүзе уятып җибәрде. Башланды этеш-төртеш, мәйдан су сипкәндәй бушап та бетте. Кабер янында карачкы сыман бердәнбер сын гына тырпаеп калды.

— Бу нинди әкәмәт? — дип телгә килде кәфен иясе.

[3] Давылбаз — барабан.

[4] Далбай — быргы.

[5] Этсак — XIII гасыр сәяхәтчесе Ибне Баттута язып калдырганча, төркиләр (татарлар), гарәпләр шикелле үк, балага исемне теге яки бу тәгаен очрак тәэсирендә кушканнар. Мәсәлән, мәшһүр Үзбәк ханның бердәнбер яраткан кызы Эткөчек исемле булган. Чөнки кыз туута чатырга беренче булып эт көчеге килеп кергән. Әлеге эпизодта да шуңа охшаш вакыйга сурәтләнә.

— Әссаламугаләйкүм, бәк, ошбу җиһандагы гамәлләренә нокта куелмаган икән әле, бакыйда озак тотмадылар, — дип, жорлана-жорлана карачкы аңа торып утырырга булышты.

— Ни сөйлисең син, тинтәк, нинди бакый?

— Мин дә шулай дим ич инде, бәк, бакыйга иртәрәк дим, әҗәл җитми үлмәк юк, дим.

Кемсәнең хөлләсе сәләмә, башмаклары таушалган, сакал-мыегына пәке тими, күрәсең, маймун йөзендә куз күмердәй күзләре генә елтырап-елтырап ала.

— Әй, дәр-бәдәр,[6] син кем?

— Әүвәл сәлам кайтару фарыз, бәк, — диде кемсә шул ук кәшакәш[7] фасылда, — шикләнмә, коралым юк, орыш корырга килмәдем. Аннан китереп, хәл-хәләтенә игътибар итәр идең...

Мамай үзен күздән кичерде. Илаһи кадир, акылга сыймастай хәл ич бу. Җә, Раббым!

— Менә, Аллаһыны да исенә төшердең, — дип, кемсә җанланып китте, — ә мин Юзекәй атлы булырмын, Хозыр Ильяс хөкемендәге мосафир.

— Вә-ә-га-а-ләйкүмәссәлам, Юзекәй мосафир, инде аңлатып бир, ниткән манзара бу?

— Чебен башына бәхет кунса, сәмер кош сәламгә килә ди...

Мамай кабаланып, хәнҗәренә үрелмәк итте...

— Дөнья беркем өчен дә дәвамлы түгел, Рәсүлуллаһ та анда мәңгелек түгел иде, — дип, мосафир кулын күкрәгенә куйды, — кизәнгәнсең икән инде, сук, үкенечкә калмасын, әнә, кылыч-хәнҗәрләрең баш очында.

Мамайның бәбәкләре әйләнмә шар кебек шул тарафка тәгәрәде. Чыннан да, сәкегә охшаш корылма өстендә ул үзенең шишәген, көбәсен, алтын сурәтле калканын, булат кылычын һәм башка сугыш ярагларын[8] абайлап алды. Шунда ук рәт-рәт ат дирбияләре тезелешкән: асыл ташлар белән бизәлгән ияр, көмештән коелган өзәңгеләр, укалы ябынча, сүс бугалак, хәтта дум-думбакны да онытмаганнар. Сары бал чатагы, тустыганнар аерым урында.

— Күбәләгең дә монда.

Мәгълүм ки, Кытай татарлары үлеп терелүгә ышанганнар. Шуңа күрә мәетне кием-салым, ашамлык, корал һәм дә бәгъзе кирәк-яраклар белән күмгәннәр. Күренекле углан[9]нарны исә җир куенына яраткан атына атландырып индергәннәр.

Күрәсең, мине дә ерак ата-бабаларым йоласына туры китереп җирләүне мәгъкуль күргәннәр.

Тукта-тукта, нинди йола, нинди җеназа? Ни сөйли бу йолкыш?

Ул янә җеназа әшья-әсбабларына[10] күз төшерде. Алар барысы да анык иде. Мәет тә ул үзе...

Мамай үз тавышына буылып, кычкырып җибәрде:

— Жу-у-у-к!

Шыбыр тиргә баткан, йөрәге талкына, тәне яна... Ә үзенең бар булган кальбен бернинди сүзгә дә сыймый торган шатлык хисе биләп алды: төш кенә ич бу, йокы зилзиләсе, саташу. Төшкә ни кермәс?

Тәкъвалыгы чамалы гына булса да, ул аз-маз дини гореф-гадәтләрдән дә хәбәрдәр иде. Әле дә җен-пәриләрдән фәкать сүгенү белән генә арынырга мөмкин дигән фараз күңеленә килде. Бу мосафир дигәне, шиксез, адәм кыяфәтенә кергән аздыргыч шайтан. Төштә дә аңа урын юк!

---

[6] Дәр-бәдәр — хәерче
[7] Кәшакәш — бәхәсле
[8] Яраг — корал
[9] Углан — гаскәр башлыгы.
[10] Әшья-әсбаб — җиһаз, кирәк-ярак.

— Иблис, ыштанынны салдырып артынны каезлаганны көтәсеңме — ычкын моннан!

Ана хәзер ничек тә онытылырга кирәк. Ул күзен йомып, хәтер җебен теземгә салды.

Алар кузгалганда Алтын Таш[11] уянмаган иде, йокысызлыктан әлсерәгән ясавыллар гына күзоч карап, озатып калды.

Кояшны далада чыгардылар. Дала угыз сөтедәй аксыл-саргылт төстә иде.

— Көн аяз, бәк, җинел корбаг[12] ны гына күтәрик, — диде йомышчы мырза. Ул шулай, соңыннан сүз булмасынга, вак-төяк белән дә бимазалый иде. Сүксәң дә юк, сүкмәсәң дә — юк. Үзе дә аңа ияреп, болай да мәгълүм хакыйкатьне кабатлады.

— Сабаны[13] җиргә күмегез, кымыз салкын торсын, — дип кисәтте.

Атларның тезгенен иярә тарттырып бәйләп, тир катырырга җибәрделәр. Актачы[14] ярдәмгә омтылган иде дә, аны читкә этәреп үз толпарын үзе тагаенләде. Иң элек ияр каешларын чишеп, тирлегеннән арындырып, аннан ябынчасын бөркәндерде дә, йөгәнен җинел нуктага алыштырды.

— Бар, Елдырым, аякларынны яза тор, үзем дәшеп алырмын!

Елдырымны колын килеш ана Бирдебәк хан бүләк итте. Биясе алтын бәрабәренә гарәп чүленнән кайтартылган иде. Колынкай тиз арада чала бурлы тай булып җитеште. Койрыгы дүрт чалуга тиң иде, кыскартырга туры килде. Карап торуга әлләни күркәм түгел, Искәндәр җиһангирның Буцефалы шикелле үгез башлы, тукмак гәүдәле. Әмма аяклары күл камышыдай зифа, озын. Күкрәге киң. Төнге елдырым сыман ялт итеп кенә кала, шәүләсен дә абайламыйсың. Шуңа күрә Елдырым дигән исем кушты да инде. Янә дә үзендә кеше акыллары бар, һәр нәрсәне аңлый.

Бүген аның шәхси күнегү көне. Ул аны бик төгәл саклый, кул астындагылардан да шундый ук җаваплылык таләп итә. Чөнки заман үзгәрә, заман белән бергә орыш кануннары үзгәрә, чарлана бара. Элек, әйтик, яу кара болыт сыман ябырылып килә иде дә, дошманын таптап-изеп китә иде. Хәзер исә яуны тоткарлауның бик күп алымнары бар. Моның өчен кайвакыт яшерен канау казу да җитә. Мизгел эчендә атлар аксак-туксак имгәккә әверелә. Ә атсыз яугир җиңү яулый алмый. Шуңа күрә шәхси осталык зарур. Осталык исә күнегү аша чарлана.

— Коланнар[15] шушы тирәдә генә утлап йөри, кузгатырга кешеләр җибәримме? — дип сорады актачы мырза.

— Кабаланма, — диде ул, — әүвәл йомык күздән ук атышып мәргәнле уйнап алабыз, әйт, садакларны[16] китерсеннәр.

Җепкә аскан калын киез җәймәнең баш-башыннан тотып,ике кушчы[17] кырык тугыз атлам ераклыкка барып басты. Ук җәрәхәтләнмәсенгә йөзләренә калкан яптылар. Сәрпи ук[18] атканда андый чатаклыклар да булгалый.

Вазифаи кагыйдә тәртибендә ату сызыгына йөзбашы Кәмал мырза килеп басты. Бурыч — бер ук белән киез рәвешендәге шартлы дошман затның сулышын өзү.

Киез укны йотты. Шулай да:

— Син кара йөрәкне яраладың гына, — дип ризасызлыгын белдерде Мамай, — яралы ерткыч икеләтә куркынычрак.

[11] Алтын Таш — хан бистәсе.
[12] Корбаг — чатыр.
[13] Саба — күн кымыз капчыгы.
[14] Актачы — атлар башлыгы.
[15] Колан — кыргый ат
[16] Садак — ук-җәя савыты
[17] Кушчы — хезмәткәр
[18] Сәрпи ук — ерак очучы ук

— Бәк, тагын бер мөмкинлек бир, монысында тач дөмектерәм!

Мырзаның сәрпие янә чыжылдады.

— Мактыйм, сүзендә тордың, — диде ул, — инде минем күзне бәйләгез.

Мамай сулышын кысып, җәя җебен күкрәгенә тартып китерде дә, капылт кына ычкындырып та җибәрде. Ук караш иярмәс тизлек белән очты. Тынын кайтарганда сәрпи киезнең нәкъ уртасында чайкалып тора иде инде.

— Афәрин, бәк!

Мамай — даланың күркәле мәргәне. Аның хакында егерме адымнан чебен күзен тишкән дип сөйлиләр. Хакмы-түгелме, әмма Чыңгызханның икенче канаты саналган Бодончар нәселеннән шытым алган Кыят вәкилләре осталык җәһәтеннән телгә кергән затлар. Мисал өчен, Исатай яугирны нәкъ менә шушы һөнәре тәхет даирәсенә якынайта да инде. Бервакыт ул Үзбәк ханның бик тә ымсындыргыч дала уенында катнаша.

— Кем дә кем бердәнбер ук белән мин очырткан кошны атып төшерсә, шул мәргәнгә кызымны бирәчәкмен, — дип белдерә Үзбәк-ата.

Мәшһүр ханның кияве булырга теләүчеләр бихисап. Барысы да төрле орышларда яу тоткан мәртәбәле яугирлар. Тик ханның биремен үтәү җиңелләрдән түгел. Чөнки кош кызның йодрыгы кадәр генә, үзе җилдәй житез. Күренүгә, күздән дә югала. Шуңа тиң рәвештә дәгъвачеләр дә бер-бер артлы исемлектән коела бара. Чират Исатайга житкәндә ул инде ялгызы гына торып кала.

— Иса углан, бөтен өмет синдә, Эткөчегемне утыртып калдырма, күрсәт егетлегеңне, — дип елмая да, хан кошын күккә томыра.

Исатайның күзе үткен, кулында төз колаклы йөгерек аткыюч угы...

Һәм шул ук мизгелдә кошчык таш сыман җиргә мәтәлә.

Хан кияүеннән бик уңа. Исатай гурген тора-бара гаскәрбаш, бәкләрбәге сыйфатында гамәли хакимият дилгебәсен үз кулына ала. Бу чорда дәүләт акылга сыймастай кискен үзгәртеп коруларга дучар була. Олыслар башында торучы Жучи токымы шаһзадәләре билгеләп куелган идарәчеләр белән алыштырыла. Исатай үзе Күк Урда тәхетенә утыра. Алай гынамы, улы Жир-Котлыкны варисы дип игълан итә. Шулай итеп, Алтын Урданың көнчыгыш канатында кануни буыннар алмашы шактый вакытка киселеп тора. Башкала буларак, Күк Урданың төп шәһәре Үргәнеч Сарайдан һич калышмый. Фәкать аларның икесендә генә дүрт манаралы мәчет эшли.

— Тәүге ыргымда Тарлан Бүзгә атланырмын, ахры, йөгәнләгез, — диде ул, тамак ялгап алганнан соң, — хәбәр салыгыз, өерне кыздыра башласыннар.

Бәк күнегүләрне фәкать кыргый атлар белән генә уздыра. Алар куркусыз, бузалы, үҗәт. Ансат кына буйсындыра алмыйсың. Шуңа күрә муеннарына аркан салу өчен жиде кат тир түгәргә, еландай бөтерелергә туры килә. Хәер, орыш үзе дә табышмак ич ул. Хәзерлегең нисбәтендә дошманыңнан элеккечә бер генә түгел, биш баш өстен торганда гына мул ганиматкә, бай улҗага өметләнә аласың.

Мамай үкчәләре белән генә атына кагылып алды да ургылып урыныннан купты. Гәүдәсе үзеннән-үзе очарга талпынган бөркет рәвешенә керде, корыгы[19] җил унаена ятты...

Мангаена тир бәреп чыкканда, ул ике пырдымсыз йөгерек тайны элмәкләп өлгергән иде инде. Ә алда Алаяк белән сынашу. Елдырым, шөкер, ял итте, тыны житәр, шәт.

Алаяк — өернең яңа әйдәүчесе. Елкылдап торган чем-кара айгыр. Бәкәлләре генә ак. Шул бәкәлләре хакына Алаяк кушаматы тактылар

[19] Корык — элмәкле озын таяк.

да инде үзенә. Кешнәп тә җибәрсә, бөтен дала ашкынулы моң белән тула.

Мәгәр чосның чосы, шул сәбәпле, күнегү мәйданын өч яктан ур белән урап алырга мәҗбүр булдылар.

Мамайның моннан алдагы әйдәүче айгырны берничә тапкыр бугазлаганы бар иде инде. Тик аның уны үткән, җитезлеге чамалы иде. Алаякның исә яшь чагы, бузалы чагы. Тибешергә маһир, тешләре дә үткен. Кыскасы, лаеклы көндәш.

— Елдырым, тезген тоттырма, — дип, ул атының ялыннан сыйпап куйды. — Әллү!

Елдырым томырылып, өер эченә ерып керде. Коланнар моны көтмәгәннәр иде, күрәсең, колаклары шәмдәй турайды. Шунда ук айгыр аваз салды:

— И-и-ха-ха-ха...

Өер урыныннан кузгалды. Елдырым да адымнарын ешайтты.

Ул бу юлы корыгын бугалакка алыштырган иде. Бугалак җинелрәк тә, унайлырак та.

Алаякка якын килү бик авыр, өер ирек бирми, аркылы төшә. Хәйлә зарур. Хәйлә дигәне дә алдан ук тәгаенләнгән иде. Әнә, ур артында гына посып торган атчабарлар калкып та чыктылар.

Алаяк бер генә мизгелгә эзен югалтты. Өерне туздыру өчен шушы мизгел дә җитте. Ыгы-зыгы башланды.

Мамай бугалагын очырды. Ләкин элмәк айгырның муенына эленмәде, сыртын гына сыпырып узды.

Бугалакны җыеп алган арада, Алаяк шактый читләшергә өлгергән иде инде. Шулай да, ул әле өер эчендә, өметкә әле урын бар.

Елдырым Алаякны эзәрлекләвен белә. Ара бер якыная, бер ерагая. әмма форсат та кулдан ычкына бара. Әнә, көтү акрынлап теземгә салына башлады. Айгырның гына башка басуын көтәләр. Ул үзе дә шуңа омтыла. Әгәр өерне ерып чыга икән — бетте, хушлашырга гына кала.

— Елдырым, аркылы төш, Алаякны ычкындырабыз!

Чыннан да, өербаш аралык тапты, аны турыга куып җитү мөмкин түгел иде инде.

Елдырым хуҗасын анлады, бер җаен китереп, әлегә аралыкка аркылы ятты. Шунда ук булгалак та элмәген җәйде...

— Эләкте бит, эләкте!

Әмма хөр толпар күрәләтә чит тезгенгә керә димени? Менә ул бөтен гайрәтен җыеп, арт аякларына басты да, гәүдәсен йомгак урынына алга ыргытты.

Ыргым шул кадәр дә көчле булды ки, Мамай үз бугалагына уралып җиргә мәтәлеп төшкәнен сизми дә калды...

Хәтер жебе шушында өзелде. Айгырның калтырчадай бәргәли-бәргәли дала буйлап өстерәп алып киткәне дә, яугирларның аңсыз хәлдә ур төбеннән табып алуларын да, женаза хәлләрен дә ул инде белми иде.

Далада мәетнең кадере юк. Мамай исә хан кияве, гурген, дәүләти даирәдә ханнан кала икенче баскычта торучы зур түрә. Шуларга өстәп, Бирдебәк ханның яшьлек дусты, сенлесе Толымбикә ханәкәнен яраткан ире.

Бирдебәк үзе катнашмаса да, җеназаны тамашалы итеп оештырырга боерды.

Гүргә индерергә генә өлгерә алмыйча калдылар, җаны тәненә кайтты.

Мамай өзелгән уй-тасвирларын ялгау нияте белән башын эшләтмәк итте, ләкин башы суы түгелгән чүлмәк сыйфатында иде, күзе белән күк гөмбәзен айкап алды — алары да ботак тишеге, һични күренми. Күнелендә төер булып укмашкан фәкать бер генә сорау: «Өнме бу, төшме?»

Ул әлеге сорауны мосафирга да юллады:

— Өнме бу, төшме?

— Өн, — диде мосафир, — бик хикмәтле өн!

— Нишләп мин берүзем, кая яугирларым?

— Әнә, бак, — диде Юзекәй мыскыллы көлемсерәү белән, — бүре каршындагы сарыклар шикелле куркышып катканнар...

***

Мамайның үлеп-терелүе Сарай[20]ны аяктан екты. Дус бар, дошман бар дигәндәй, һәрвакыттагыча, гөманнар да хәттин ашты. Бәгъзеләр бу хәлне бәкнең мәкерле гамәле дип бәяләсә, икенчеләре хәйләгә юрады. Шуклыкка аударучылар да бар иде.

Бирдебәк хан сөенде генә, чөнки аның Мамайдан да турылыклы һәм булдыклы ярдәмчесе юк. Шулай да, иң эчкерсез куаныч кичергән зат бәкнең хәләл җефете Толымбикә ханәкә иде.

— Тәңрем хәйриямә күрә мәрхәмәтен күрсәтә, иншаллаһ, бәхетле көннәремнең сынҗыры[21] өзелмәс, мәхәббәтем шытымнар бирер, — дип мулдан хәер-сәдака өләштерде.

Ханәкә юмартлыгы, ярдәмчеллеге белән дан тота. Аның үз мәктәбе бар. Анда югары катлам балалары белән бергә, аталары орыш кырында һәлак булган яугирларның уллары да бер тиен түләмичә белем ала, хәрби һөнәр үзләштерә. Хәтта чит мәмләкәтләрдән дә киләләр. Хәзерендә атасы Җанибәк хан олуг дәрәҗәсе биргән Мәскәү кенәзе Иоанн IIнең улы Дмитрийны үз канаты астына алды.

Коры курадай юка гәүдәле, ак чырайлы, зур зәңгәр күзле бу шаһзадәне улы Мансур кебек үк ярата ханәкә. Яшьтәшләр, тугызны гына тутырып киләләр әле. Икесе дә чыраш, тәвәккәл. Дмитрий татар телендә иркен сөйләшә, өч-дүрт айда телнең асылына төшенде. Мансурга алты яшендә Литвадан мөгаллим соратып алганнар иде, урысчаны су кебек эчә.

— Галиҗәнап Толымбикә, мин сезгә гомер бакый бурычлымын, — диде Дмитрий, иртән мәктәпкә җыенганда, — бәхиллэтә алсам гына ярар иде.

— Галиҗәнап түгел, — дип малайның кылгандай аксыл чәченнән сыйпады Толымбикә, — мин бит ханбикә түгел, хан кызы, ягъни дә ханәкә.

— Сез дөньяда иң бөек шәхес.

— Иң бөек шәхес — Байду[22]хан, — дип сүзгә кушылды Мансур, — аннан соң — атаем Мамай бәк!

— Толымбикә галиҗәнап барысыннан да өстен!

Дмитрий сүзләрен тез чүгеп куәтләде.

— Мансур хак, шаһзадә, — диде ханәкә, — бөеклек кыз-хатыннар дәрәҗәсе түгел, без барыбыз да Байду хан дәүләтендә яшибез.

— Мөхтәрәм Мамай углан кебек мәшһүр атчабар булу ай-һай сирәкләргә генә тәти шул ул, — диде Дмитрий дусты белән ризалыгын белдереп.

Ханәкә бу әңгәмәнең эчтәлеген бәккә дә җиткерде.

— Туганда кыек туганны тубыкка салсаң да тураймас, — диде Мамай, ерактанрак суктырып, — ул урыс чебешеннән, белмим, рәт чыгар микән?

— Алай өздереп сөйләшмә, бәк, — диде Толымбикә, — белүемчә, Мәскәү тәхетенә дәгъва итүче варислар арасында ул чебеш, — ничек өйрәтәсең бит — хикмәт шунда. Аннан китереп, кечкенә дә, төш кенә дигән әйтем дә бар.

[20] Сарай — Алтын Урданың башкаласы. Бу исемдә ике шәһәр була: Сарай — Бату (Сарай әл-Мәхрүс); Сарай — Бәркә (Сарай әл-Җәдид). Мамай чорында башкала әл-Җәдидтә (яңа) була инде.

[21] Сынҗыр — чылбыр.

[22] Байду — Батый.

— Син чичәнне җинеп буламы соң, — дип, Мамай хатынын кочагына кертте, — телең белән Улакчы урынына Алтын Урда тәхетен тоткан мәшһүр Баракчин хатынны да аягыңа мөсәххәр итәр[23] иден, шәт.

— Баракчин хатын хәләле Байду хан мирасы хакына башын салган, ә минем улымның атасы белән озак еллар ишкә-иш яшисем килә, — дип, Толымбикә иренә тагын да ныграк сырыша төште, — теге вакытта даладагы фаҗигаң белән бик куркыттың бит, Мамучым.

— И, мысыгым[24]...

Бәк хатынын чаршау эченә алып кереп китте.

***

Толымбикә анышмый торды. Чөнки аның бүлмәсенә ике-өч кат сакны үтеп керергә кирәк. Әле аларны исән-имин үткән очракта да йомышчы идарәбаш иләгеннән сыгыла. Соңгы сүз, әлбәттә, үзендә.

Ә бу сакал-мыек баскан сәләмә киемле бер карышлы адәмне әйтерсең лә ачык тәрәзәдән җил очыртып кертеп ташлады.

— Әссәламугаләйкүм, ханәкә, Ходай хәерле гомерләр насыйп итсен!

— Хәзер сакны дәшәм! — диде ул, сәламне игътибарга алмыйча.

— Тибәгәннең алдыннан, кабаганның артыннан үтәргә куша мәкаль, — диде йомышчы — сезнекен аңламассың, кайсы тарафыгыздан үтәргә дә аптыраш, Мамай бәк башны чабып өзү белән яный, син сак илә куркытасың...

— Син кем? — дип өзеп салды Толымбикә.

— Һөҗүмче. Мамай бәкне ат өстеннән бәреп төшерүче. Атым — Юзекәй, шөгылем — мосафирлык.

— Син? — дип гаҗәпкә калды Толымбикә, — ачуым килмәгәе, көләгә генә ич син.

— Бу — сакчыларыгыз фаразы.

— Бүлмәмә ничек үтеп керден?

Юзекәй якасы эченнән бер нәни генә төен суырып чыгарды да, аны чишеп, учына нидер салды.

— Бу минем бөтием, миңа шул юл ача, мине шул саклый.

— Чәч бөртегеме?

— Таныдың, Ходайның рәхмәте, зирәклегең миңа мәгълүм иде, ышанычымны акладың, — диде Юзекәй, — шуңа күрә Мамайны узып, синең катыңна кердем дә инде. Чәч бөртегенә килгәндә, бу Мөхәммәд пәйгамбәрнең вафаты алдыннан Хаҗ тамашасында диндарларга тараткан чәченең бер нөсхәсе. Изге нөсхә. Аңлагандырсың, мин Хозыр Ильяс үрнәгендәге зат.

— Безнең якларга ничек килеп чыгасы иттең?

— Менә шушы хакта синең белән гәпләшергә телим дә инде, ханәкә. Мәгълүм ки, ирен Мамай бәкне Раббебез үлгәннән соң терелтеп аякка бастырды. Мин бу могҗизаи гамәлнең шаһиты. Мамай хәзер Күкләр кешесе. Күкләр аңа зур өмет баглый. Бу дәүләти мәнфәгатьләр белән дә, дини тәгълимат белән дә бәйле. Мамай Адәм галәйһиссәламнан килүче Илаһи Ислам әгъзасы. Ул Җир дине, Мөхәммәд галәйһиссәлам дине, Шәригатьтән (хәлбуки, Шәригатьнең максаты — кеше кальбен Илаһи Исламга якынайту) өстен.

— Мосафир, син сәер сүзләр сөйлисең, — дип борчылуын сиздерде Толымбикә, — мин...

— Бүлдермә, — диде мосафир, — Мамайга ошбу Илаһи ачыш соңрак киләчәк. Ә син алдан белеп тор, минем ярдәмчем бул.

[23] Мөсәххәр итәр — баш идерү.
[24] Мысыгым — пескәй.

Бүлмәгә Мамай үзе килеп керде.

— Бу жинаятьче ни-нәрсә эшли монда? — дип мосафирга карап бакты.

— Ялгышма, бәк, мин синең дустың, — диде Юзекәй, сүзләрен бастырып кына, — Раббе очраштырды безне. Колагыңа киртлә, дөньялыкта мин синең дусың да, дошманың да. Без инде бер жептә. Хәзергә хуш. Вә илайһи торжагун.

***

Мамай Толымбикәнең агае Бирдебәк шаһзадә белән аралашып үсте. Атасы Кыят углан Җанибәк ханның ышанычлысы иде. Ул җансакчыларны сайлап алу, тикшерү хокукына ия иде. Хан даирәсендә әвәләнү зур дәрәҗә. Шуның белән бергә, сарай тормышы искиткеч четерекле, анда чонгыллар, киреакмалар, упкыннар, әйләнмә-бөтерчекләр бихисап, ялгыш адым ясыйсың икән, беттең — сиңа кул сузучы табылмаячак. Чөнки ханнарның үз башлары да бик еш тәгәри ул мохиттә.

Балачак, шөкер, бу мәкерләрдән азат. Хәтта сарай балалары да һәр тарафка куелган «ярамый» киртәләрен урап узу җаен таба. Менә бүген дә булачак угланнар хәрби күнекмә сылтавы белән Әтил култыгына ат йөздерергә килделәр.

Көн аяз, күктә бер болыт әсәре юк, кояш көлтә-көлтә нурларын бернинди тоткарлыксыз чәчә бирә. Эссе. Малайларга шул гына кирәк тә. Су май кебек. Җанга шифа бирә, тәннәрне иркәли. Рәхәтнең рәхәте.

— Атлан атыңа, әйдә, тирәнгәрәк керәбез, — дип, Бирдебәк бахбаеның сыртына үрмәләде.

Мамай да ыргылмак иткән иде, әмма су читендә арлы-бирле үрсәләнгән Толымбикәне күргәч, атын ташлап шунда ашыкты.

— Шаһинә, нишләп йөрисең монда ялгызың?

— Су кеерәсем килә, — диде кызчык тулы иреннәрен турсайтып, — күлмәгемне саалдыг...

— Ни сөйлисең шаһинә, малайлар алдында чишенергә кара халык затыннанмы әллә син? — дип, Мамай Толымбикәне оялтмакчы булды.

Кызчык аның сүзләрен колагына да элмәде, бер-бер артлы башмакларын читкә очырды.

— Шаһинә, шаһинә дим, кыланма!

Мамай башмакларны җыеп алганда иркә пескәй тез тинентен суга кергән иде инде.

— Ярамый, шаһинә, чык тизрәк!

Толымбикә телен генә чыгарып күрсәтте.

— Мамуч!

Мамайның йөзе чалшаеп чыкты. Бу кызчык кушамат тага лабаса! Ишетсәләрме, теле көтек дип тормаслар. Ә угланнар арасында кушамат түбәнсетү, санламау билгесе булып кабул ителә.

Шаһинә авызыннан бу ватык сүз инде икенче тапкыр чыга бит. Сарайда чаклары иде әле, Мамайның мөгаллименнән кайтып килеше. Кырымга генуялылар килеп урнашкач, Урдада итальян телен өйрәнү ихтыяҗы туды. Шул сәбәпле югары катлам балалары өчен махсус мәктәп ачтылар.

Бакчада ул Толымбикәгә тап булды. Авызы-борыны салынган, күзендә яшь.

— Шаһинәгә ни булды? — дип шөбһәләнеп сорады ул тәтә-тәрбиячедән.

— Мысыкаебыз агач башына менеп китте, һич төшерә алмыйбыз, — диде борчулы гасәбә, — шаһинә шуңа көйсезләнә.

Мамай яфраклар арасыннан ап-ак песи баласын шәйләп алды. Ботактан-ботакка куна-куна чыр-чу килүче сары түшле песнәкләрне аңдып, мөкиббәнгә калган.

— Хәзер, юкка шыншыма.

Мамай кәүсә буйлап өскә үрмәләде.

Кулына ак йомгакны тоттыргач: «Мамуч әйбәт», — дип сөйләнә-сөйләнә кызчык пескәенең борыныннан үбеп алды.

— Мамай, — дип төзәтте аны углан.

Шаһинә күз очлары белән генә көлемсерәп, башын чайкады.

— Мамуч, түгел Мамай.

— Ә син мысык.

— Мамуч, Мамуч, Мамуч...

...Һәм менә тагын Мамуч.

Ул арада тыны-көне беткән тәтә-тәрбияче килеп җитте дә, шаһинәне судан күтәреп алды. Шунда ук сукмакта Тайдула ханбикәнең суна үрдәкнекедәй аумакайлы гәүдәсе күренде.

Мәшһүр Үзбәк ханның тол бичәсе күп санлы оныклары арасыннан Толымбикәне ярата иде. Ул кызчыкны үз тәрбиясенә алды. Күп вакытын ана сарыф итә. Әнә ич, аякларым сырхау дип тормаган, оныкчасы артыннан чыккан.

— Факизә гасәбә, бүгеннән аш-су чатырына күчәсең, шаһинәгә яңа карауч алам, — дип, авызыннан ут чәчте.

Тайдула ханбикә ире исән вакытта хәләле белән рәттән торып, казна эшләре белән шөгыльләнде, абруйлы дәүләт эшлеклесе булып танылды. Ул мөһимнәрдән мөһим саналган сәүдә өлкәсен, аның да дингез аша башкарыла торган тышкы сәүдәне үз кулына алды. Үзбәк хан караб[25] салымын бөртегенә кадәр хатыны исеменә яздыра иде. Шуңа күрә ханбикә халыкара багланышларны бөтен чаралар ярдәмендә үстерергә тырышты. Акча уйнаган җирдә каршылыклар да, аңлашылмаучылыклар да адым саен чыгып кын тора бит ул.

1359 елның 4 март көнендә оныгы Бирдебәк ханлыгы вакытында Венеция Дожы[26] Джовани Дольфинга юллаган хаты һәм акча язуы әле дә хәтерендә.

Уйламаганда-көтмәгәндә, венецияleләр Константинополь янында Урда сәүдәгәрләренә һөҗүм иттеләр. Бераздан Кипрдан кайтып килүче Бачман сәүдәгәр шул хәлгә тап булды. Беренче очракта тауар 748,8 килограмм көмеш белән бәһаләнсә, икенчесендә 93,6 килограмм тәшкил итә иде.

Бирдебәк хан мәсьәләнең төбенә төшеп тормастан, бөтен чыгымнарны венецияleләр өстенә аударды. Ә гаеп атта да, тәртәдә дә. Җентекләп тикшергәннән соң ханбикә шундый нәтиҗәгә килде. Һәм Венеция сәүдәгәрләренә 102,96 килограмм көмеш акчаларын кире кайтарып бирдертте. Гаделлек җинде. Нәтиҗәдә сәүдә элеккегә караганда да җанланыбрак китте.

Тайдула Урдадагы төрле диннәрнең үзара тату яшәвен кайгыртуга да күп көч салды. Рим католик чиркәве башлыгы гына дистәгә якын рәхмәт хаты язды. Дуслык шулкадәр тирәнгә керде ки, Папа Бенедикт XII хәтта ханбикәне католиклар сафына өндәүгә ишарә итүдән дә тартынмады. Менә 1340 елның 17 август белән имзаланган мөрәҗәгате:

«Сезнең күңелегезгә әлеге хисләрне салган Ходайга рәхмәтебез дә, шул ук вакытта, шатлыгыбыз да чиксез, дәхи дә Сез аларны барча игелекләрнең чыганагы булган Аллаһыга таянып башкарасыз. Ошбу күркәм гамәлләрне Аллаһы чын хаклыкны тоеп һәм кабул итеп, ягъни дә Христосны кабул

[25] Караб — татар сүзе (урысчасы – корабль), шуңа күрә «а» хәрефе белән язылырга тиеш. «О» белән язганда татарча ул «кыраб» кебегрәк укыла (ред.).
[26] Дож — башлык.

итеп, хәзерге көрексез вә дәвамсыз яшәештән соң мәңгелек тормыштагы шатлыклардан мәхрүм калмасын дип кальбебезгә индерә. Шул сәбәпле, Сез, мөхтәрәм Галиҗәнап, Ходай кушуы белән, хак католик диненә бирелү аша мактаулы эшләрегезне дәвам иттерерсез дип ышанам».

Әйе, дөньялар үзгәрде. Папа Григорий-Х татарларга каршы тәре походлары оештыру уйлары белән яна, Җучи Олысының 1276 елдагы Польшага уңышлы һөҗүме бу ниятләргә гомерлек киртә куйды. Понтификлар инде рәхмәт хатлары юллый.

Хәзерендә ханбикәнең мәшәкатьләре бөтенләй башка. Ул дәрәҗәле ыруның остабикәсенә, баш тәрбиячесенә әверелде.

Әлеге көннән соң ул үзе дә, оныкчасы да күздән югалды. Хәбәрдар адәмнәр, иң ерак җәйләүгә күченеп китте, дип сөйләде. Мамай моңа сөенде генә, чөнки кушамат кешегә чыкканчы онытылды.

Шул рәвешле уникe җәй, уникe кыш алышынды. Мамай бу вакыт эчендә дәрәҗәле углан булып җитеште, аны хәрби җитәкчеләр рәтендә Ту киңәш[27] җыеннарына да чакыра башладылар.

Атае Кыят шатланып туя алмый. Озынча буйлы, ныкча гәүдәле, кырыс кыяфәтле, көчле куллы, әвәрәдәй җитез хәрәкәтле улы, шөкер, ике тамчы су кебек үзенә охшаган. Яшь чагында ул үзе дә тиңдәшсез атчабар, оста мәргән иде. Аның кылыч вә сөңге уйнатуын тамаша кылырга бөтен дала җыелы иде. Хәзер улы бәйге тота.

Янә җәй чыкты. Җанибәк хан түәге күк күкрәүдән соң ук бәйрәм думдумбагы кактырды. Шунда ук тирә-якка атчабар мөнадиләр[28] чыгып китте. Дала тынлыгында көр тавышлы өндәмә-авазлар янгырады:

— Тыңлагыз, тыңлагыз:
Ай-ялгызның сердәше,
Уйчыларның уйдашы,
Гашыйкларның моңдашы,
Юлчыларның юлдашы.

Тыңлагыз, тыңлагыз, Җанибәк хан күктә яна ай урагы калкып чыккан төнне алыштырган көннән башлап, атна дәвамында, бәйрәм-бәйге игълан итә. Быелгы елда ул гүзәлләрнең гүзәле Толымбикә шаһинәнең бәлигълык биннәфәсенә багышлана. Хан затлы угланнарны «Кыз тоту» чабышкысына көтеп кала. Колакларыгызны торгызыгыз, ишетмәдек димәгез!

Мамай углан башка елларда ким дигәндә өч-дүрт бәйгедә катнаша иде. Бер мәртәбәдә дә бүләксез калганы булмады. Монысында фәкать «Кыз тоту» чабышкысында гына көчен сынарга карар итте. Ыру-нәселе, дәүләти вә җәмгыяви дәрәҗәсе туры килә, ник читтә калырга? Дөрес, дәгъвачеләрнең күпчелеге төрле олыслардан килгән ханзадәләр. Шаһинәнең кулына өмет итәләр булыр, мөгаен. Мамайда ул кайгы юк. Күптән түгел атасы Кырым әмиренең Җәмилә исемле кызын димләвен белдерде.

Сөймәгә бирсәң, сылу бир ди. Егет тә хәләленең сылу булуын тели иде, әлбәттә. Шуңа күрә атаена кызны күргәч кенә ризалагын бирәчәген әйтте.

— Үкенмәссең, — диде Кыят бәк, — кәләшең анаең сынары, атлылар атыннан төшеп, җәяүлеләр ятып карарлык дөнья чибәре.

Бәйге җыены бәк мәдхиясенең дөреслеккә туры килү-килмәвен белү өчен бик уңайлы форсат иде. Тик ни сәбәпледер, әмирнең тирмәне буш торды. Хакимнәрнең кәҗәләре сөзешкән вакыты иде булса кирәк, җыенга килмәделәр.

[27] Ту киңәш — хәрби шура.
[28] Мөнади –хәбәрче.

Мамай шаһинә белән очрашуны ашкынулы күңел белән көтеп алды. Нигәдер йөрәге ярсый, әле болай да үткен хәнҗәрен ташка ышкый башлый, әле җәясенең җебен тарттырырга керешә. Ахыр чиктә җеп тә түзмәде, башка җәя көйләргә туры килде.

Инде барысы да рәтләнде дигәндә генә, күзе аягындагы итегенә төште. Җә, алла, мәсхәрә ләбаса! Карт дөя картасыдай куырылып каткан шушы итекләрне киеп бәйгегә басмакчы. Оят! Шаһинә моны үзен мыскыллау дип кабул итәчәк ич. Һәм дөрес эшләячәк. Хурлыклы төстә бәйгедән читләштерсәләр дә һични әйтә алмыйсың. Хан да тузынчак.

Ул ашыга-кабалана итекләрен салып читкә бәрде дә:

— Нәмә, ангыраланып торасың, яналарын китер! — дип, кушчы яугирга төкрек чәчте.

Тегесе җилкәсен җыерып куйды, чөнки бу көмеш дагалы сәхтиян итекләрне углан кичә генә соратып алган иде.

Бәйге алдыннан егет солтаннарын шаһинә чатырына дәштеләр. Чатыр сөттәй ап-ак киез өйдән гыйбарәт иде. Иркен, чиста, пөхтә. Эче келәм, тышы келәм. Колакларны дала елгасыдай салмак кына аккан кубыз моңы иркәли. Әкияти дөнья.

Ярышташларны шаһинәнең агасы Бирдебәк шаһзадә каршы алды.

— Рәхим итеп узыгыз, кымызыбыздан авыз итегез, — диде ул иелгән башлар өстеннән.

Аякчы[29] мөлдерәмә тулы зур көмеш касәне саф башында торучыга китереп тоттырды. Касә йөрешкә керде.

— Инде биннәфеснең хуҗабикәсе белән танышыгыз, — диде Бирдебәк, — далабызның йолдызы Толымбикә ханәкә!

Өй эчен шаулатып чалгы[30] кактылар. Шунда түр чаршау ачылып китте... Һәм дә каршыда тутый коштай таранган, аккоштаен ясанган, Сона коштай сыланган Толымбикә сылу пәйда булды.

Мамай аң күәсен җуйды. Юк, бу шаһинә түгел, күктән ингән Зөһрә йолдыз! Ул белгәндә эченнән энә үтәрлек тез буе арык кызчык кына иде ич Толымбикә. Ни чырае, ни гәүдәсе дигәндәй... Ә бу? Кара инде, хур кызларың бер якта торсын. Нәкъ дастандагыча, кашларына карасаң, күктән пәйда булгандай, буйларына карасаң, нурдан пәйда булгандай...

— Хәерле узышлар насыйп булсын үзегезгә, угланнар, эчкерсез сәламемне кабул итегез, — диде Толымбикә авыз суларын китерердәй йомшак тавышы белән. Аннан шук кына өстәде, — белегез, минем сезгә тоттырырга исәбем юк.

Ул тагын нидер әйтте, ләкин Мамай аларны ишетмәде.

Шулай әсәрләнеп торганда Бирдебәк килеп җилкәсенә кулын салды да: «Кара аны, сеңелне читләргә тоттырма», — дип кисәтте.

Мамай шунда гына исенә килде.

— Бу Күбәләкнең тынына бәйле...

Бирдебәк дустының изүеннән эләктереп алды да:

— Син нәрсә, шул килмешәкләрдән өркеп калдыңмы әллә? — дип, дердер селкетеп бакты. — Атаң тапкан әмир бытбылдыгын да онyт!

— Сөткә кан тамызып ант эчкән кәләшем түгел, — диде Мамай.

— Шулай булгач соң, күрсәт егетлегеңне.

Бәйге чабарларын бер рәткә тезеп бастырдылар. Мамай Себер ханзадәсе Шәйбани белән туры килде. Камыт аяклы, төптәй нык гәүдәле, зур башлы бу углан оста җайдак булса кирәк. Күр, атына сеңеп беткән, әйтерсең лә икесе

[29] Аякчы –касә өләшүче.

[30] Чалгы — кагышлы музыка коралы.

бер анадан туган. Телгә дә саран. Башкалар шапырыныпмы-шапырына, ә монын авызыннан бер генә җөмлә сытылып чыкты.

— Хәрәмләшүче үзенә үпкәләсен!

— Тезгеннәрне кысарга!

Шунда ук калкулык өстеннән күктәге әкияти сагым[31] манзарасыдай ак атта ак сыбай[32] туташ кул болгады.

Ай күрде, кояш алды, икенче мизгелдә юкка да чыкты.

— Кузгалыгыз!

Ярыш исен сизеп кыбырсына башлаган атлар, ниһаять, ирек алды, артларында тузан өермәсе генә бөтерелеп калды. Җайдакларга да җан керде.

— Һер-р-р-р...

— Һи-һи-һи-һи-и-и...

— Һоп-һоп-һо-о-оп...

Өч-дүрт кучә[33]* арасы тигез бардылар. Чабышкы көнче бит ул, берсенең дә калышасы килми. Тик көч-куәт төрлесенең төрле шул.

Җайдаклар тибенгеләрен ничек кенә еш кулланмасыннар, тора-бара өер башта камыр кебек сузылды, аннан бөтенләй бүлгәләнеп бетте. Иң алда — Мамай белән Шәйбани. Тик бу җиңү дигән сүз түгел әле. Иң соңлап килүче ярышчыга да бәхет елмаерга мөмкин. Барысы да кызның ниятенә, хәйләсенә бәйле. Ул атын теләсә-кайсы тарафка юнәлтә ала лабаса!

Әнә бит, чаптырып барган җиреннән атын кисәк кенә бермә-бер борды да, үзе үк ярышчыларның каршысына килә башлады.

Мамайның йөрәге күкрәк читлеген ватып чыгардай булып тибенә. Тәне ләззәтле кайнар дулкын белән тулышты. Хәзер, менә хәзер шаһинә толпарының тезгененнән эләктереп алачак. Кулларым көчле, шаһинә ычкына алмассын...

Шәйбани да буй бөгә торганнардан шул, Мамай авыз суын корытып ләззәт кичергән арада, бер җәя арасы ыргылып алга да чыкты, җай килүен аңдып кына барган төлке.

— Мокыт, кая тыгыласың? — дип акырды Мамай.

Толымбикә атын капылт уңга каерды, дәгъвачеләр чак маңгайга-маңгай чәкешмәделәр. Хәйләсе шул булган икән чибәркәйнең.

Аһ...

Үзәннәргә, калкулык итәкләренә, сукмак буйларына сибелгән атлы-җәяле вә җәяүле меңнәрчә тамашачы бер авыздан аһ итте.

Толымбикә аучыларын күрәләтә мыскыл итә иде. Инде чират икенче төркемгә житте. Ул бу икене ызгыш мәйданында калдырды да, төп төркем ягына ыргылды. Һәм төркемне яшендәй тизлек белән урталай ерып, аркылыга кисеп тә чыкты.

Күренеп тора, шаһинә тамаша кора. Аның үзен куркыныч астына куеп кыланчыклануы бәйгегә кискенлек, дәрт, комарлы һәвәслек өсти иде.

Хан белән шулай килешенгән иде, күрәсең. Югыйсә кызына утарындагы иң бәһале толпарын тоттырмас иде. Исеме дә җисеменә туры килә — Зилзилә!

Йөгеректә сын булмый. Зилзиләнең дә бер артык-портык җире юк. Шуңа күрә җилдәй житез, ташкындай өлгер.

Төркем янә тәүге рәвешенә керде. Ләкин бу юлы әйдәүче Шәйбани иде инде.

---

[31] Сагым — мираж.
[32] Сыбай — атчабар.
[33] Кучә — урам.

Мамайга ханзадә күләгәсенә тагылудан башка юл калмады.

— Һер-р-р-р...

— Һи-һи-һи-һи-и-и-и...

— Һоп-һоп-һо-о-о-п...

Толымбикә тезгенен кыса төште. Килгән кызудан атын тыя алмыйча, Шәйбани аны узып ук китте. Мамай кыз белән икәүдән-икәү калды. Моннан да уңайлы мизгелнең булуы мөмкин түгел иде. Күңелен ашкындырып, колагына инде күптән онытылган тылсымлы сүз дә килеп сыланды.

— Мамуч...

Мамайның дәрте тулып ашты. Тик озакка гына бармады, Шәйбани хатасын төзәтеп тә өлгерде. Көндәшенең кулы җитешкәләгәнче камчысы еландай боргаланып, кызның тезгенено уралып та куйды.

Дала купты. Атлар, дөяләр, кешеләр барысы бергә хәрәкәткә килде. Баш киемнәре һавага оча, кычкырыш, бакырыш. Чын пәри туе.

— Афәрин, Шәйбани!

— Җинүчегә дан!

Мамай бу шатлыклы авазларны ишетмәс өчен колакларын башлыгы белән томалады да, ярыш кырын ташлап китте. Эче-тышы ут, тәне калтырый. Ул вәгъдәсендә тормады, Бирдебәк шаһзадәгә җавап тотарлыгы юк. Мондый очракта бердәнбер юл — үз хәнҗәреңә яту...

Ихтимал, ниятен башкарган да булыр иде, ялан очында җайдак төркеме күренде. Алар туп-туры аңа таба килә иде.

— Углан, сине хан чатырында көтәләр, — диде йомышчы мырза килә-килешкә, — безнең арттан ияр!

Җанибәк ханның кәефе күтәренке иде.

— Тәүге булып яу башладың, башладың да ташладың, — дип, елмаеп каршы алды ул Мамайны, — дистәдән артык алыптай егет кәмәше чырадай бер көнәкә кызны тота алмасын әле. Хурга калдыгыз бит, сезне хәзер ничек орышка чыгармак кирәк? Ха-ха-ха...

Хан аякчы мырза кулыннан кымыз касәсен алды.

— Бер юлга кичерәм мин сез булдыксызларны, — диде хан, шаяртуын дәвам итеп, — чөнки дә хикмәт сездә түгел, хикмәт асыл затым, кызым Толымбикә шаһинәдә! Менә нинди ак ефәкле хәзинәгә ия безнең Алтыннан суккан Ак урдабыз. Шул хөрмәткә тулгау[34] көтәм.

Сарай субрасы[35] җыру башлады, яшелле-зәңгәрле тавышлары белән аны угланнар күтәреп алды:

Күзекәй сылу кыз –
Йә синеке, йә минеке!
Бакса җанны эреткән,
Әйтсә авыру тереткән,
Әш булсын түремез,
Түрә хөкем күрәмез,
Ексаң, ата, синеке,
Егалмасаң, күзекәй –
Сылу кыз ул минеке!

Хан кымызын бер-ике йотым эчте дә саркытын[36] Шәйбанига сузды. Хан саркыты — ханның бәһасез дәрәҗәдәге олы хөрмәт билгесе. Ә бу бик тә мәгънәле йола. Димәк, Җанибәк хан Иртыш арты олысы белән якылашуны

[34] Тулгау — теземле җыр.
[35] Субра — җырчы.
[36] Саркыт — касәдә калган эчемлек.

мәгъкуль күрә. Шәйбани ханзадә рәхмәт сүзендә үз ниятләренең асылын турыдан-туры ачып салды.

— И, Ак урданың бөек ханы, атаем Шәйбани хан синең белән туганлашуны зур дәрәҗәгә саный, — диде. Үзенең шатлыгы эченә сыймый, шәт, кәҗә бәтиедәй сикергәләп тә китәр иде.

— Иншаллаһ, ниятләребез тормышка ашар, — диде Җанибәк.

Күр инде, Толымбикә шушы албастының куенына керер микәнни, дип Бирдебәк тә ачынып куйды. Мона ирек бирергә ярамый.

Бирдебәк уйларын очлап бетермәде, атае бүлде.

— Улым, ярышчыларга шаһиненең йөлделәрен[37] тапшыр, — диде шул ук күтәренке халәттә, — үзе ахирәтләре белән күңел ача булыр, рөхсәтем бар.

Кыз тоту бәйгесендә катнашкан һәркем ярыш ядкәре сыйфатында затлы дирбия алды. Шунда ук уртага сары бал чапчагын өстерәп чыгардылар. Мамайның гына тугарылып ирек ачу гаме юк иде. Шуна күрә ханнан җибәрүен үтенде.

— Хак, тамашага күз-колак кирәк, — диде Җанибәк, — артык узынып китмәсеннәр, алда әле башланмаган алты көн.

Кунаклар җәйләүләргә таралышып беткәннең икенче көнендә үк Мамайны өйләдән соң Бирдебәк шаһзадә катына чакырдылар. Исәп-хисап тотаргадыр, мөгаен, дип гөманлады ул үзе. Бәйрәм тыныч узды кебек, яланнан нибары өч яралы табып алдылар. Өчесенең дә, газаплы үлемгә дучар итеп, умырткаларын сындырганнар. Башка вакытта үчле үлемнәр дистәдән артып китә иде.

Шаһзадә бүлмәсендә ялгызы гына иде. Чакыруы да дәүләт эше белән бәйле түгелдер, мөгаен. Өстәвенә, иреннәре дә майланган. Күрәсең, бал бөйрәгенә[38]* төшкән.

— Кая олагып йөрисең син? — дип шелтәле караш ташлады ул угланга. Ә үзенең ачуы юк. Киресенчә, килеш-килбәтеннән ниндидер серлелек бөркелеп тора иде.

Бирдебәкне усал дип әйтеп булмый. Шыпырт. Шулай да күңелендәген ачып салырга ашыкмый. Маңгаена чапырыш яткан озынча кысык күзләреннән һичнәрсә укый алмыйсың, алар пәрдәле. Хан уллары гомумән күп сөйләшми, чөнки тәхет өчен дәгъва кылу үтә дә зур саклык таләп итә. Ашыгыч әйтелгән ялгыш сүзнең мәслигенә киртә салуы да бар. Тәхеткә иң якын торучылардан әлегә Бирдебәккә өстенлек бирелә.

Ләкин вәзгыять үзгәрүчән. Шуна күрә шаһзадә үз тирәсенә һәрвакыт таянырдай ышанычлы угланнар тупларга тырыша.

— Гаскәрем янында мин, шаһзадә, әле унлыкбашлар белән утчагыр[39] коралына мөнәсәбәтле күнегү-өйрәнүләр уздырдым, — диде Мамай, сорауны җаваплап, — утчагырны алманнар уңышлы куллана, урыслар да кулларына төшергән дигән хәбәр йөри.

— Бик хуп, — диде Бирдебәк, — шулай да хәзерендә миңа синең киләчәгең күбрәк борчый.

Мамай нидер әйтмәк булып авызын ачкан иде, сүзе тамагына утырды, чөнки ишек уемында Толымбикәнең күркәм сыны күренде.

— Алпамыштай ир булгансың, Мамай углан, таныpлык та түгел, — диде ул, агасы янындагы кәнәфигә утырган арада, — кияү егете булырга да өлгергәнсең икән, ничек диләр әле:

[37] Йөлде — ярышта катнашу билгесе.
[38] Бөйрәк — бөер.
[39] Утчагыр — туп.

Жиренә күрә колыны,
Суына күрә еланы;
Кызына күрә кияве,
Өенә күрә иләге...

— Син шаһинә үзең дә алтын егач, тутый кошка әверелгәнсен, — диде Мамай, төртмә сүзләрне ишетмәмешкә салышты.

— Менә, менә, тутый кошыбыз даланы бик сагынып кайткан, йөртеп кайтыр иден, — диде Бирдебәк, уенын-чынын бергә кушып, — яугирларыңа үзем күз-колак булырмын. Бер-ике көннән дөнья бетмәс.

Мамай шаһинәгә күз йөгертеп алды. Кыз керфекләрен түбән чәнчеп, мәгънәле көлемсерәүдә иде, янәсе, карап карыйк, нинди егет икәнсең.

— Ярәшүле кызның тирмәдә генә утырырга тиешлеге миңа мәгълүм, — дип инде Мамай чеметеп алды.

— Әлегә бернинди ярәшү дә юк, — дип кистерде Бирдебәк кырыс кына, — җыенгыз!

Бу әмер иде инде.

— Шәхсән үзем дә сезгә иярер идем, хан сәфәрдә, — диде Бирдебәк акланганда́й.

Сынарга тели, ахры, атасы юк вакытта көчли-көчли далага чыгарып җибәрмәс иде, дип уйлап куйды Мамай, ялган җимгә ябырылырга язмасын.

— Даланың иң күркәм җиренә алып бар мине, — диде Толымбикә юлга чыккач, — сагынып сөйләрлек булсын.

— Даланың иң күркәм җире — дала үзе инде ул, — диде Мамай.

— Бу да дала бит инде, нигәдер күркәмлеге күренми, — диде Толымбикә.

— Күрә белсән, далада барысы да бар, шаһинә, бизгәнсең генәдер.

Чынында да, жентекләбрәк карасаң, игътибарны җәлеп итәрдәй күренешләр бар икән үзе. Әнә зирек кайрысы төнәтмәсенә манып алгандай кызгылт-сары төскә кергән кояш бишегенә төшәргә җыена. Офык сызыгында киртәгә эленгән кер шикелле үтәли эссе белән тулы дулкын дәрьясы тибрәлә. Тын. Ара-тирә генә чәч селкетерлек урын җил искәләп куя. Ком өемен кузгатырга шул да житә, күрәсен, тиктомалдан ишелеп-ишелеп китәләр.

Толымбикә чыркылдап көлеп җибәрде.

— Кара әле, кара!

Каршыда гына корыган агач тамырына охшаган килбәтсез вәхши зат ком астыннан сынын күрсәтеп-күрсәтеп ала: судагы кебек бер калка, бер бата. Гәүдәсе башыннан гына гыйбарәт, аяклары тырпаеп каткан.

— Кәлтә, — диде Мамай, — ауга чыккан.

— Хәшәрәт.

— Күр, тагын берсе азык эзли.

Бусы елан иде. Әкәмәт. Турыга түгел, аркылыга шуыша.

— Китик без бу чалыш дөньядан, углан, — дип Толымбикә тезгененә үрелде, — бәлки, шаһинәнең күнеленә ятышлы башка җунлерәк урын табарсың?

— Бар андый урын, — диде Мамай, — сәхрә уртасындагы Йомры күл, кичкә барып та житәрбез!

Алдан кычкырган күкенең башы ярылган ди, әйтеп кенә булмый шул әле ул. Уйламаганда, Мамайның Кубәләгә кырын басып аягын сындырмасынмы. Җаны кебек күргән аты иде. Бик кайгырды. Ләкин шаһинә алдында җебеп төшәргә ярыймы соң? Шуңа күрә бөтен түземлеген җыеп, сакчы яугирына:

— Хәл-хәлен хәнҗәр белән тәгаенләгез! — дип әмер бирде.

Шаһинәнең йөзе буйлап ике бөртек яшь тәгәрәде.

— Йоласы шулай, далада яралы ат каза гына китерә, — диде Мамай, кызны да, үзен дә юаткандай.

Толымбикә төнне чатырда үткәрде. Башкаларны, гадәттәгечә, йолдызлар җемелдәшеп йоклатты.

Йомры күл янына икенче көнне төш вакытында гына килеп сыендылар. Коры кура белән капланган ялангач дала куенына гүя биниһая зур көмеш казан иңдереп куйганнар. Чит-читләренә хәтта куаклар да үсмәгән, җем-җем җәйрәп ята.

— Искиткеч манзара, — дип хәйран калды Толымбикә, — Азак дәрьяга тартым.

— Ошбу кырыс гүзәллек фәкать далада гына була ала, — диде Мамай, — Азак ул бүтәнчә гүзәл.

Өттергеч кызудан соң Йомры күлнең сихәте зәмзәм суына тиң иде. Шаһинә рәхәтләнеп коенды. Башкаларга чәчләрен чылату белән генә чикләнергә туры килсә дә, алар да риза-бәхил иде. Чөнки күл янында барыбер җиләс, һавасы саф. Көн үткәне сизелми дә калды.

Толымбикә Мамайны кичке ашка үзе янына, чатырга чакырды.

Мамай иптәшкә ярдәмчесен дә алып керде. Ник дисәң, исеме чыккан кыз белән икәүдән-икәү генә утырып тәгамләү гореф-гадәткә туры килми. Ләкин шаһинә үзенчә хәл итте.

— Углан, яугиреңнең урыны гомум табын янында, кагыйдәне бозмавыңны үтенәм, — диде.

— Мөхтәрәм шаһинә, минем синең исемеңә тузан бөртеге кадәр дә кер төшерәсем килми, — диде Мамай, яугир чыгып киткәч.

— Сүз әле ул вәгъдә түгел, углан, — дип, Толымбикә аны җентекле күз иләге аша үткәрде, — агаем Бирдебәк сиңа аңлашылырлык әйтте булса кирәк. Ә ул — булачак хан!

— Бүгенге ханны берәү дә уза алмый, шаһинә, хәтта ки булачак тәхет иясе дә, — дип, Мамай киреләнүендә булды.

Толымбикәнең күзләренә ризасызлык кунды.

— Углан, вазифаңа кереш!

Мамай касәләргә кымыз агызды, ит табагын, ризык-ашамлыкларны ихлас кайгыртучанлык белән шаһинә тарафынарак шудырып бетерде.

Шаһинә күз алдында үзгәрде дә куйды. Кыз-хатын шулай инде ул, кояш кебек. Кояшны капларга да, ачарга да бияләй кадәре генә болыт кисәге дә җитә ич.

Кыз самими елмаю белән керфекләрен кагып алды. Бу минутта ул яклауга мохтаҗ йомшак затны хәтерләтә иде.

Мамайга да тынычлык килде. Ләкин озакка түгел, шаһинә аны янә утка салды.

— Углан, синең гашыйк булганың бармы? — дип сорады.

Мамайның кулындагы касәсе чайпалып китте дә, кымызы киеменә чәчрәде. Ул аны сизмәде, ә Толымбикәнең йөзеннән серле дулкын сызылып узды.

— Углан, танырга батырчылыгың җитмиме әллә?

Мамай яшертен генә кызга сирпелгән иде дә, тотылды, чөнки Толымбикә дә аңа текәлгән иде. Чем-кара кашлары астындагы асыл таштай шаян кара күзләреннән нинди дер исерткеч нурлар бөркелә, түз генә.

— Җә, углан...

— Мин сиңа гашыйк, — диде егет, ниһаять, үзенекенә охшамаган калтыраулы ят тавыш белән.

Әйтте дә, кабалана-кабалана акланырга да кереште.

— Борчылма, шаһинә, бу тиң гыйшык түгел, батырчылыгын җитмиме әллә, дип сораганга гына серемне ачтым, кичер... Миңа, мөгаен, чыгып китү хәерлерәктер, шаһинә...

Толымбикә утырган килеш кенә keләм буйлап егет янына шуышты...

Тыннары кысылганчы үбештеләр...

Шулай да бераздан Мамай кыздан читләшергә көч тапты. Нәфес — баш бәрабәре!

— Шаһинә, ярамый, шаһинә... Хан бу гамәлебезне хупламаячак, шаһинә...

Толымбикә җинелчә ыңгырашу белән егетнең түш астына керде.

— Мамучым...

— Мысыгым...

***

Гашыйклар даладан бер атта меңгәш[40] булып кайттылар: Толымбикә алда, Мамай артта.

Ә иртән иртүк ханнан чакыру килде. Их, тавыш-гауга чыккалаганчы атаем белән сөйләшергә өлгерми калдым, чагарга житешкәннәр дә икән инде дип ачынып куйды углан. Ашыкканнар. Хәер, монын хәзер бер әһәмияте дә юк инде, вәгъдә — иман. Мәхәббәтен ул сөткә канын тамызып дәлилләде: «Әнтә бәдрүн син, шаһинәм; әнтә нурун фәүка нур»[41]

Хан килүгә кабул итте. Көткән иде, ахры, янында йомышчылар да күренми, даирәсе белән генә. Тәхетендә башын кырын салып, мәрткә киткәндәй оеп утыра. Йөзе дә боек. Һич тә тоткан урыныннан өзә торган усал хаким димәссең. Мамай аптырабрак калды. Ул җәнҗал көткән иде ләбаса. Алай гынамы, Жанибәк тәхетеннән төшеп, читтәге кәнәфигә урнашты, гомер булмаганны, кул изәве белән аңа да урын күрсәтте.

Мамай тезләнеп, ханның җилән чабуын үпте, әмма утырмады.

— Сиңа мөһим биремем бар, углан, — диде хан, туп-туры карап, — игътибар белән тыңла.

Мамай җилкәсеннән бабил ташы төшкәндәй җиңеләеп китте: шөкер, белми икән әле.

— Баш өсте, хан галиҗәнаплары, һәрвакыттагыча биремеңне үтәргә әзер!

— Син Мәскәү чиркәве эшләреннән хәбәрдар, углан, көн тәртибенә шул гамәленне янарту мәсьәләсе килеп басты бит әле, — диде Жанибәк аталарча йомшаклык белән, — сиңа ышанычым зур.

Ни гажәп, ханның ышанычын ул, абруй кундырып килүче яшь углан, хәрби казанышлары бәрабәреннән битәр, илчелеккә кагылышлы очраклы эшчәнлеге белән яулаган иде.

Ул болай булды. Мәскәү хакиме Иоаннның вафатыннан соң Жанибәк олуг кенәз дәрәҗәсен шактый озак көттереп, интектергәннән соң, бишенче тапкыр килүендә, ниһаять, Иван Калитаның өлкән улы Симеонга багышларга хәл кылды, ярлыгын тапшырды.

Митрополит Феагност белән Жанибәк аерым сөйләште. Ник дисәң, аны урыс чиркәвенең биниһая зур байлыгы, дөресрәге, шул байлыктан Урдага бернинди өлеш чыгармавы борчый иде.

Ханның ризасызлыгы җәһәтеннән Феагност ихтирам белән башын иеп әйтте:

— Урыс православие чиркәве мөхтәрәм Үзбәк хан галиҗәнапларына һәрвакыт хәерхаһ булып, изге догаларын житкереп торды, — диде,

[40] Меңгәш — бер атка ике кеше атлану.

[41] Әнтә бәдрүн — тулган ай; Әнтә нурун фәүка нур — нур өстендәге нур.

— нәкъ менә сезнен кин күнелле атакаегыз чиркәү вә монастырьларны салым түләүдән азат итте, урыны оҗмахтадыр, шәт. Шунын аркасында православие җинел сулыш белән яши башлады. Үзегез шаһит, хан Урда башкаласы Сарайда да православие храмы корырга шәрәфле фатихасын бирде. Тәкъвә халык бик рәхмәтле. Бу килүемдә дә анда сезнен исәнлеккә гыйбадәт үткәрдем.

Ханнын авызы капланды һәм тәүге әнгәмә митрополит файдасына тәгәлләнде.

— Бу карт төлкедән әйбер алганчы тавыктан сөт саварсын, — дип башын чайкап торды Җанибәк. Аннары диван биләргә кырыс караш ташлады.

— Сез нинди кинәш бирәсез?

Җавап белән бирәү дә атылып чыгарга ашыкмады. Үзара төркәләшеп тә алдылар. Бераздан арада өлкәнрәгенен мичкәдәй юан гәүдәсе талпынгандай итенде. Җайсызрак кузгалды, ахры, башта исе таралды, шуннан сон гына сүзе чыкты.

— Мөхтәрәм хан, Үзбәк ханнын ярлыгын гамәлдән чыгарырга да була ич, — диде.

Хан чыраен сытты.

— Бүлмәне сасытуын җитмәгән, тузга язмастай кинәшләрен белән саруымны кайнатасын, — диде ул, — акылын түкәнгән, фаразан. Атаем, бөек Үзбәк ханнын ярлыгын гамәлдән алырга башыма тай типкәнме әллә?

Җанибәк һич көтмәгәндә ясавыллар башлыгы Мамай түмәнгә мөрәҗәгать итте.

— Углан, син белекле яугирем, фикер куәнне дә бәһаләсем килә, рәхим ит, тынлыйм, — диде.

— Хөрмәтле галиҗәнап, — диде Мамай яшьләргә хас каударлык белән, — илчелек вазифасында хәйлә дә, куркыту да, җәнҗал да бер үк дәрәҗәдә зарур дип саныйм.

— Ягъни мәсәлән...

— Мина калса, ярлыкны үзгәртү ихтималы турында ялган хәбәр таратырга гына кирәк, митрополит бу җимгә һичшиксез алданачак.

— Башын йомры, углан.

Дөрестән дә, хәбәр бик тиз таралып өлгерде. Митрополит куркуга төште. Үзбәк хан ярлыгы үзгәргән очракта чиркәү бик күп малыннан коры калачак. Шуна күрә тиз генә Урда казнасына 600 тәнкә көмеш акча тапшырды. Бу бөтен Рәсәйнен[42] еллык салым керемен тин иде.

Мамайнын абруе да шул бәрабәргә артты.

Җанибәк тагын йомыш куша. Ә хан йомышы — дәрәҗәле йомыш.

— Кичекмәстән Мәскәүгә чыгып китәсен, олуг кенәзгә минем ярлыгымны тапшырасын, — диде хан, сүзләрен тактага кадак каккандай шыпылдатып (ул инде элекке халәтенә кергән иде), — изге Алексей дигән руханины үзен белән ияртеп алып кайтасын, вакытын тар, яна ай туганда Сарайда булган бул!

Ханнын ярлыгында түбәндәгеләр язылган иде: «Олуг кенәз Иоанн Московскийга! Безнен ишетүебезчә, Күкләр баш попыгызнын догаларына хәерхаһ икән. Минем анаем Тайдула ханбикәгә Тәнредән саулык сорар өчен аны монда җибәр!»

Мамай ханбикәнен сырхавыннан хәбәрдар иде. Толымбикәнен

[42] Рәсәй (Русия) — романда сурәтләнгән вакыйгалар чорында Русия исемле рәсми дәүләт булмый әле, ул сонрак, XIV гасыр ахырында оеша. Әмма «Русия төбәге», «Русия җирләре» сүз тезмәсе телдә IX-X гасырлардан бирле йөри. Дәүләте юк, исеме бар. Бу җирләрдә аерым рус кенәзлекләре мөстәкыйль рәвештә көн күрә, үзара аралашып яшиләр. Бер үк православие динен тоткан, тамырларында славян каны аккан, бер телдә сөйләшкән бу халыкларны гомумиләштерү зарурлыгы чыкканда «Русия» термины кулланылган. Бу нәкъ шул очрак.

тәрбиячесе, яраткан дәү әнисе, ыру корткасына булышу хакына ул, әлбәттә, бөтен көчен салачак.

Юл газабын гүр газабына тиңләгән әйтемне сәфәр тулысынча раслады. Каулауга чыдаша алмыйча менә дигән дүрт аргамак кына аяк сузды, ике яугир урыс кырында ятып калды. Ләкин хан биремен үтәү-үтәмәүгә бернинди югалтулар да сәбәп була алмый. Үз башың бәрабәренәме, башка корбаннар бәрабәренәме — ул үтәлергә тиеш!

Алексей атакай да бик четерекле, тискәре адәм икән. Үзе маймылдай йөнтәс: калак сөягеннән дә түбәнрәк салынып төшкән озын бакыр чәч, күкрәктәй җәенке куе сакал, күзләре дә, авыз-борыны да төк астында, тавышы гына гөрелдәп ишетелә. Ә тавышы күркәм. Еланны өненнән кузгатырлык мең төсмерле тавыш. Татарчаны да әйбәт кенә сукалый. «Мин әһле дин кешесе, түгел хәрби зат», — дип, ат менүдән баш тартты бу. Сүз дә юк, далгушасы[43] затлы, атлары шәпле. Тик әлеге көйгә Мәскәүдән Сарайга кайтып житү өчен ике яңа ай тудырырлык вакыт сарыф итәргә кирәк булыр иде. Ай-ваеына карамыйча, атакайны атка атландырдылар.

Башта меңгәш белән, тора-бара үзе генә. Соңыннан: «Атчабарның үз һиммәте бар икән, углан, йөрәкне тынычландыра, тынны көйли», — дип хәтта рәхмәтен дә җиткерде.

Атакай икенче көнне үк Сарай чиркәвендә Тайдула ханбикәгә атап гыйбадәт үткәрде. Шуннан соң гына ханбикәнең үзе белән очрашты. Икәүдән-икәү генә калып, гәпләшеп утырдылар.

— Ходай догаларыма һәрвакыт хәерхаһ булды, — диде ул, — бу юлы да ким-хур итмәс, кабул итәренә ышанычым зур. Сырхавыңның сәбәбен исә атналык гыйбадәтләремнән соң ирештерермен.

Атакай сүзендә торды, нәкъ бер атнадан хөкемен дә җиткерде.

— Ханбикә, җир йөзендәге күпчелек сырхауларың да чыганагы — бозым, — диде, — бу Иблис токымының шайтани гамәле. Сиңа да бозым салганнар. Мин хәзер догаларым булышлыгында кальбеңнән шул кара бозымны куу белән шөгыльләнәчәкмен. Моңа да бер атна вакыт кирәк булыр.

— Калганына түзәр дә идем әле, баш түнүе, арт чүмечемнең кысуы яман, — диде Тайдула, — бөтен ышаныч синдә, атакай.

Алексей рухани булу өстенә, дәва хәлләре белән дә кызыксына иде: үләннәр җыя, төнәтмәләр ясый, тәҗрибәләр үткәрә.

Тайдуланың чирен дә бер күз сирпеп карау белән тәгаенләде ул. Алсуланып торган итләч битенә, куяннныкы шикелле кып-кызыл күзләренә, мул гәүдәсенә караганда, бозым ханбикәнең канын куерткаңга охшый. Ихтимал, оеш-оеш каткан урыннары да бардыр. Шул сәбәпле, шартларга җитешкән тамырларда кан начар йөри. Баш түнү, баш авырту — шуның бәласе.

Ошбу шартларда гарәпләрдән килгән хиҗама, ягъни дә кан алдыру дога-өшкерүләргә ярдәм генә итә. Атакай ханбикәнең аркасына мөгез куеп, әшәке канын авызы белән суырып чыгарды.

Тайдуланың хәле күз алдында яхшырды. Шуннан соң ханбикә гомере бу православиегә табынып яшәде, Урыс чиркәвенә күп яхшылыклар кылды.

Алексей атакай Сарайда иде әле. Бер көнне Мамай янына Бирдебәк шаһзадә килеп керде. Кәефе шәп иде.

— Ханга яучы җибәр, эш пеште, — диде.

Тиздән Толымбикә Мамай куенына керде.

[43] Далгуша — җинел арба, карандас.

***

Бирдебәкнең үле гәүдәсен бәдрәфтән табып алдылар. Табигый хажәте вакытында аркасына хәнҗәр батырганнар иде. Бәдрәф ханның бердәнбер сак белән йөрми торган урыны булып, һөҗүмне әлеге форсаттан бик оста файдаланганнар иде.

Тәхеткә утыру белән Бирдебәкнең ишле туган-тумачасы берьюлы аның кан дошманына әверелде. Җанибәк ханның унике улыннан һәммәсе фәкать үзен генә хан дәрәҗәсенә лаек дип саный иде. Төрле анадан туган бу шаһзадәләр хәтта аталарының васыятен дә танырга теләмәде.

Җанибәк үзе Әзәриләр[44] илендә сырхауланды. Ә ул анда мәшһүр Әл-Бәдиги кази үтенече буенча йөгәненнән ычкынган Мәлик Әшраф хакимне акылга утырту мәсләгендә барып чыккан иде. Әшраф аны гаскәрен күтәреп каршы алды. Ләкин көч-куәте чамалы булып, тәүге орышта ук әсир төште. Хан аның гөнаһларын гафу кылырга да уйлаган иде, тик халык ирек бирмәде, җәзага тартуын таләп иттеләр.

Икенче төркем Харәзи аша үтеп, Хөрәсән өлкәсенә аяк басты. Моңа, билгеле, Хулагуидлар[45] дәүләтенең таркалуы да ярдәм иткәндер, мөгаен.

Тик ничек кенә булмасын, җучиларның күптәнге хыялы тормышка ашты — Көньяк Кавказ, ниһаять, алар кулына керде, Бөек ефәк юлына борын төрттеләр.

Бу Үзбәк ханның кулыннан да килмәгән иде. Хәлбуки, ул тәхеткә утыруга багышланган тантанада ук рәсми төстә ислам динен кабул итүе турында белдереп, мәмлүкләр солтаны Әл-Мәлик ан-Насыйрга ике идарәче йорт арасында нәсели никах килешүе төзергә тәкъдим ясаган иде. Солтан тәкъдимне хупласа да, Үзбәкнең өметләре акланмады. Мисыр Көньяк Кавказ өчен хулагуидлар белән барган орышта Үзбәк ханга булышлык күрсәтмәде. Гаскәре чигенергә мәҗбүр булды.

Бу вакытта, ни кызганыч, Бату хан нигез салып, бөтен Аурупаны дер селкетеп торган бөек дәүләт — Алтын Урданы Урта дингез акваториясеннән кысрыклый башлаганнар иде инде. Балканга түл жыярга өлгергән Госманлы төрек күз салды. Дарданелл бугазын кулына төшерү исә — Сарайның иң якын икътисади фикердәшләреннән саналган Мисыр һәм Италия белән бәйләнешен күпкә катлауландырды.

Җанибәккә җиңүче сыйфатында бик күп ганимәт тиеш иде. Бу байлыкны дүрт йөз дөягә төяп Сарайга озаттылар.

Эшләре көйләнгәч, өлкән улы Бирдебәкне Әзәридә калдырып, хан кайтырга чыкты. Ләкин ерак китә алмады, чума чире бәреп екты. Шунда ул ашыгыч рәвештә Бирдебәкне чакыртып алды да, васыятен җиткерде.

Дошманлык шуннан соң башланды. Бирдебәк үзе дә усалланды, чын җәлладка әверелде. Аның әмере белән турыдан-туры тәхеткә дәгъва итәргә хакы булган барча туганнары да юк ителде. Моны ул якын ярдәмчесе, рәхимсез Тулыбәй бәк кулы белән башкарды. Тик ыру агачының ботаклары күп, аларны кырып-кискәләп бетерү мөмкин түгел. Бирдебәкнең гомерен нәкъ менә шул яшь шытым вәкилләре өзде дә инде.

Мамайның язмышы да кыл өстендә калды. Дөрес, Бирдебәк аны үчлек гамәлләрендә катнаштырмады, хатыны Толымбикә ханәкә юл куймады

[44] Әзәри — Әзәрбайҗан.

[45] Хулагуидлар дәүләте — хәзерге Иран, Ирак һ.б. илләр мәйданын биләгән Монгол илһаннары дәүләте.

булса кирәк. Ул асылда дәүләтнең идарә системасына кагылышлы эшләр, халыкара мөнәсәбәтләрне көйләү белән шөгыльләнде. Әйтик, Кырымда төпләнгән генуялеләр белән сөйләшүләр шактый киеренке барды. Ташламалар ясарга, ирекле сәүдә чикләрен киңәйтергә, мул төбәкләрдән саналган Судак өлкәсенең базар капкаларын ачарга туры килде. Чөнки алардан казнага күп акча кирә.

Тайдула ханбикә үзе бер төен. Терелткәннәре өчен, рәхмәт йөзеннән, урыс чиркәвенә ташлама арты ташлама ясаттыра. Каршы килә алмыйсың. Шуңа күрә бүре дә тук булсын, сарык та исән калсын дисәң, бер җиңнән ике кул чыгарып эшләргә туры килә.

Болар инде узгандагы эшләр. Хәзерендә Мамай дәүләт эшләреннән читләштерелде, түмәнбашы булып кына калды.

Нишләргә, кая барып төртелергә, башыңны кем җилкәсенә салырга? Шушы мазалы көннәрнең берсендә аның каршында күктән төшкәндәй Юзекәй мосафир калкып чыкты.

— Бере тукмак, бере чөй, берен ал да берен төй, — диде ул гадәттәгечә ерактан суктырып. — Әллә көлүе, әллә мыскыл итүе, һич аңламассың.

— Бүз көясе булма әле, зинһар, — диде Мамай, — болай да суккаланган чак.

Кул тимәгән сакал-мыегы эченнән Юзекәйнең кызгылт иреннәре күренеп китте.

— Менә-менә, ат яхшы да җил каршы дип зарлана торган чак түгел, углан, — диде мосафир, — ниһаять, синең бүреләреңнең улар вакыты җитте. Күреп торасың, дәүләт тә, гаскәр дә башсыз калды.

— Хак, мосафир, Жучи токымыннан турыдан-туры лаек кануни шаһзадәләр калмады диярлек... Әмма дә ләкин...

— Бернинди «әмма-ләкин»нәр була алмый, углан, — дип ялгап китте Юзекәй, — Раббе Байду хан бөртекләп җыйган Алтын Урданы саклап калу өчен сиңа форсат бирә. Шуңа терелттеләр дә ич инде. Бу — синең изге бурычың!

— Байду хан хакы — Тәңре хакы, — диде Мамай, — аның өчен каным белән ант итәргә әзер.

Ул кулын хәнҗәр очы белән сыдырып алды да, иреннәрен саркып чыккан канга тигезде.

Мамай шул көнне гаиләсен, Үзбәк хан ыруының тәхеткә дәгъва итәрдәй чыбык очы вәкилләрен алып, Кырым тарафына чыгып китте. Шөкер, аның Кырым әмире дигән дәрәҗәле аты бар иде әле.

Кузгалыр алдыннан Толымбикә ханәкә мәктәбендә белем эстәүче Мәскәү кенәзе Дмитрийны чакыртып китерде.

Дмитрийның йөзе йодрыкка сыярлык булып кына калса да, элеккечә тетрәп торган тере малай иде. Кирә-керешкә:

— Мөхтәрәм бәк, мин укуымны Мансур углан белән бергә дәвам итәргә телим, зинһар өчен үзегездән калдырмагыз, — дип, мөрәҗәгатен юллады. Иреннәре мелт-мелт килә, күзләре мөлдерәмә...

Толымбикә аны кочаклап алды да колагына: «Дмитрий, кенәзләргә йомшарырга ярамый», — дип пышылдады.

Малай төз курадай тураеп катты.

— Кенәз, мин сине исән-сау килеш Мәскәүгә озатырга бурычлымын, — диде Мамай, — мәктәп вакытлыча ябыла, кайчан эшли башлар, әлегә билгесез.

— Мөхтәрәм бәк, мәктәп ачылуга хәбәр салырсыз дип ышанам, — диде Дмитрий рәсми рәвештә, — сезгә бик рәхмәтлемен. Хушыгыз!

Кенәз дөп-дөп басып бүлмәдән чыгып китте.

***

Офык артыннан йөзен ачкан кояш нурлары кочагында Чируле күл зәңгәрсу-яшькелт төс белән балкый иде, әйтерсең лә, көмеш кысага кигертелгән биниһая зур зәбәрҗәт. Бу — табигатьнең гөнаһсыз кыз баладай саф-чиста, асыл мизгеле. Шуңа күрәдер, ахры, аучылар да гамәлләренә керешергә кыймыйчарак торалар, тавыш-тынсыз гына илаһи гүзәллекне күзәтәләр.

— Базарлаучы юк әле монда, мырза, — дип, башта Мамай телгә килде, —берән-сәрән кайнашкан чүрәкәйләргә лачын очыртып, ай-һай, ни майтарырсыз икән?

Бу сүзләр Мансурга юнәлтелгән иде. Малай түземсезләнеп атасына бакты. Йөрәге леп-леп, очып китәрдәй булып талпына. Шулай булмыйча, бүген тәүге тапкыр чын сунарчы сыйфатында ауга чыгуы лабаса. Атасы, ниһаять, улын кул астына кертте. Аллаһы боерса, бер-ике елдан углан дәрәҗәсен дә рәсмиләштерер. Аннан соң инде тулы хокуклы яугир булып, яуларга йөриячәк.

— Атаем, давылбаз сугарга кирәк, — диде Мансур белдекле кыяфәттә, — сунарлар әле уянмагандыр.

Мамай ирен читләре белән генә елмаеп куйды да, сүзсез генә сунарбигә ым какты. Шул ук мизгелдә иртәнге тынлыкны ярып, күн барабан авазлары яңгырады. Бу гади авазлар гына түгел, кош-кортларны чакыру, бергә җыю ысулы. Сыналган алым.

Чыннан да, күп тә үтми Иярле тау ышыгыннан төркем-төркем булып күгәл өере күтәрелде. Алар шул кадәр ишле иде ки, бер мәлгә хәтта кояшны да күләгәдә калдырдылар.

Мансурның ияр башындагы лачыны тураеп катты. Күзләре гүя чакма ташыннан бөркелгән очкын, уттай яна,канатлары тырпайган. Һөҗүм алдыннан гына була торган кан котырыгы, орыш ләззәте, җиңү омтылышы кайный иде гәүдәсендә.

— Түз, Әҗеган, түз, — диде Мансур авыз эченнән генә. Ул үзе дә көчхәл белән генә тыелып тора лабаса. Аның да каны ургый, җаны үрсәләнә. Ә әмер юк та юк. Өер инде әнә үтеп бара, күлгә төшмәскә уйладылар, ахры, куркынычны сизеп алганнардыр, мөгаен. Аһ, ни котә бу сунар-би, китәләр бит, китәләр...

Мансур нидер әйтмәкче итеп авызын ачмак иткән иде дә, сүзе теш арасында кысылып калды. Чөнки өер искәрмәстән яңгырдай шыбыршыбыр күлгә коелды.

Яшь аучы соңыннан гына белде, кошлар әүвәл төшәсе җирләрен җентекләп тикшерәләр икән, шуннан ары гына утыралар. Янә бер хакыйкать, тәүге дулкынга һөҗүм ясарга ярамый, таралышып кына бетәчәкләр. Башта төшсеннәр, тынычлансыннар. Аннан далбай сугып, кирәклеләрен генә кузгатасың.

Шулай эшләделәр дә. Сунар-би[46] ау оештыруның чын остасы булуын тагын бер мәртәбә дәлилләде. Ул күбрәк Мансур янында кайнашты.

Кошлар куанышып туюга, далбайчылар эшкә кереште. Аларның бурычы — төркемне бүлгәләп күккә күтәрү.

— Углан, әзер тор, мин аваз салуга, Әҗеганны чөярсең, — диде мырза, күккә терәлгән халәттә.

Төркем күл өслегеннән чыгуга, тавышы да яңгырады.

— Чөй!

Әҗеган атасының бүләге. Бүрек чамасындагы кап-кара лачын. Күрер

[46] Сунар-би — кош авын оештыручы сунарчы түрә.

күзгә әлләни бәрелеп тормый, әмма ифрат дәрәҗәдә житез, очканда күренми дә кала, уктан да уздырыр, шәт. Кош авы өчен ясаган да куйган. Томшыгы да нык, эләктерсә, котылырмын димә.

— Әжеганның иң шәпле чагы, бозып харап итмәсәң, сиңа бик күп шатлыклы мизгелләр китерер әле ул, — диде атасы.

Бозу дигәне уенчык урынына ярату, даими тук тоту, кирәк-кирәкмәскә дә терсәккә утырту дигәнне аңлата иде. Лачын бервакытта да ерткычлыгын җуярга тиеш түгел.

Күгәл[47] төркеме чуртаннан өреккән көс көтүе шикелле кисәк кенә читкә сибелде, әмма рәвешен югалтмады, тыгызлана гына төште. Арада бу капылт үзгәрешкә өлгерә алмыйча калганнары да бар иде, әлбәттә. Менә болары инде лачыннар табышы.

Әжеган чатырдай җәенке канатларын еш-еш җилпештереп, бер сулышта тизлек алды да, атылган таштай күккә ыргылды.. Мансур да, ярдәмчеләре дә тезгеннәрен бушаттылар. Лачынны күздән ычкындырырга ярамый, Әжеган шоңкар түгел, корбанын һавада тотмый, җиргә бәреп төшерә.

Алар аны үләне коры ергамак янында шәйләп алдылар. Кармактай кәкре, бездәй очлы тырнаклары астында симез үрдәк тыпырчына иде.

— Котлыйм, мырза, ирдә дәүләт үскәндә карга салса да каз алыр, ирдән дәүләт китәрдә лачын салса да аз алыр, дигән бабаларыбыз, иншаллаһ, әйбәт чирканчык алдың, атаең Мамай бәк шикелле ау остасы да, яу токтасы да булырсың, — диде сунар-би, — хәзерендә үзеңә үзең әмерче, теләгәнең эшлә.

— Мин синнән риза-бәхилмен, — диде Мансур атасының сүзләре белән. Аның бик тә атаена ошыйсы килә иде.

— Әжеган ярсуына чыдаша алмый, мырза, чөй тизрәк, — дип киңәш бирде кулдаш углан, — үз белдегенә кузгалмасын.

Лачын дөрестән дә ияр башында тапталыпмы-таптала иде, кая басарга урын тапмый.

— Һоп, Әжеган!

Мамай бәк үзе кошчылар төркеменнән аерылып, тау ягынарак авышуны мәслихәт күрде. Ул җәнлек-җанвар аулауны өстенрәк күрә.

Бигрәк тә колан авына мөкиббән. Ә коланнар — далада. Әлеге ауны исә махсус улы Мансур өчен оештырды. Уникe яше белән бара ич инде, чын-чынлап углан камыты кияр вакыты житеп килә.

— Атасы болан тотмаганның баласы колан тотмас, — диде ул Мансурның җилкәсеннән кагып, — мине дүрт аяклылар көтә, күкне тулаем сиңа калдырам, өйләдән соң очрашырбыз.

— Бәк, бүген Мансур углан хакына тау кәҗәләре белән генә канәгатьләнергә туры килер, — дип кисәтте ау башлыгы, — баштук та шулай килешенгән идек.

— Беләм, исемдә, — диде Мамай дустанә кыяфәттә, — лачыным ияр башында, Акбүз атым астымда. Кузгалдык!

Тау кәҗәләре таш-кыялар кочагында яши. Аларга бу патшалыкта куркыныч янамый. Тик анда су юк. Тәүлеккә бер мәртәбә елга буена төшәргә туры килә. Дошманнары шунда сагалап торалар да инде. Аз гына ялгышлык җибәрденме, кемгәдер азык буласың көн кебек ачык. Бу аларның үзләренә дә мәгълүм, билгеле, шуңа күрә колаклар тору: ал да, арт та, уң да, сул да — игътибар үзәгендә.

Кешеләр барыбер хәйләкәррәк, уклары җитмәсә, кош җибәрәләр.

— Кәҗәләр төшә, — дип хәбәр китерде андучы җайдак, — куаклыкка ышыкланыгыз, вакытлы-вакытсыз абайламасыннар.

[47] Күгәл — кыр үрдәгенең бер төре.

Мамай озын куньчлы күн бияләйләрен киеп, шоңкар лачынын терсәгенә кундырды.

— Төкле Аяк, әзерлән!

Шоңкар бу мизгелне иртәдән бирле көтә инде. Көтмичә теге, ачка тук булып йөреп кара әле син. Ау көнне ичмасам авызыңнан кире килгәнче тыгынасың.

Озак та тормый сукмакта кәҗәләр төркеме пәйда булды. Яугирлар шикелле тезелешкәннәр. Иң алда — кәкре мөгезле тәкә, көтү хуҗасы. Күр, ничек ялт-йолт карана.

Лачыннар кәҗәләргә бик сирәк һөҗүм итә, чөнки алар гәүдәгә калын, көчләр нисбәте тигез түгел. Шуна күрә ата кәҗәнең Төкле Аякка исе китмәде, беткәнмени далада тычкан-күсе ише вак-төяк җәнлек аулаучы козгын дип уйлады, ахры. Күрәсең, өйрәтелгән лачыннарга тап булганы юк иде әле.

Төкле Аяк канатларын җәйгән хәлдә көтү өстеннән очып узды да, һич көтмәгәндә җәядән ычкынган ук тизлеге белән саф уртасындагы бүлтерек бәтигә ташланды...

Көтү су кебек сибелде. Шуннан бер төркем җайдакчы чигенү юлын томалау өчен тау сукмагын бүлеп тә алды, икенчесе бүлтерекне тәләкәгә элеп, тиресен салдырды. Бүлтерек ите бәкнең иң яраткан ризыгы.

Мамай шоңкарын янә күккә чөйде. Тәүге уңышы белән әсәрләнгән Төкле Аякның җаны-тәне йөгәнсез нәфес белән тулышкан иде инде. Алга ерткычлык гайрәте бәреп чыкты. Бу юлы сайланып та тормады, күзенә беренче булып чалынган кәҗә өстенә кунды.

Кәҗәнең дә яшисе килә, әнә, ничек үрсәләнә. Сикергәли-сикергәли, ниһаять, лачынны читкә дә бәрде. Чын-чынлап тарткалаш башлады, кәҗә өчен бу җан бәрабәре. Аңа ничек тә дошманына сыртын бирмәскә кирәк. Шөкер, көче бар, җитезлеге дә таман. Әлегә кара кошны үзенә якын җибәрми.

Бәргәләнә-суккалана торгач, алар зур гына бер таш кыяга килеп төртелделәр. Төкле Аяк өчен бу көтелмәгән форсат иде. Һәм ул аннан файдаланмак итеп, күккә күтәрелде дә һөҗүмгә әзерләнде.

Менә хәзер... Кәҗә хәленең котылгысызлыгын төшенеп алгандыр, мөгаен, шул ук мизгелдә түбәнгә сикерде.

Төкле Аяк корбанын очкан төшкә эләктереп алды. Ә чокыр төбенә алар бергә мәтәлеп төштеләр.

Мамай лачыны белән тау чибәре арасындагы аяусыз бәргәләшүне атыннан төшеп күзәтеп торды.

Ак киек, йөгерекмен дип мактанма,
Алдыңда казулы торган үр бар.
Ак шоңкар, очкырмын дип мактанма,
Алдыңда җәюле торган түр бар.

Көтмәгәндә Мамайның күзле Юзекәй мосафир күзе белән очрашты. Шул ук тишеп үтәрдәй үткен вә зиһен катыш мыскыллы караш. Тәне чымырдап китте.

— Әйе, бу мин, төмәнбаш, — диде Юзекәй, гадәттәгечә иярен таягына салган хәлдә, — узганында ахирәт күлмәгеннән арындырган идем, бу юлы имгәнмәсен дип ашыктым...

— Сәләмә кәбәмә ямаулык, — дип мыгырданды Мамай.

— Шоңкарың дәртле күренә, канатын канга тигезмәс, — диде Юзекәй аны ишетмәмешкә салышып, — ә хуҗасы, әйтерсең лә әтәлге, итәк пычратырга маһир.

Мамай кынысыннан хәнҗәрен тартып чыгарды.

— Бирермен мин сиңа әтәлгенне, туганыңа үкенерлек итәрмен.

— Теге вакытта да кисәттем ич, түмәнбаш, мин кем белән исәп-хисап ясарга өлгерерсең әле, төп бурычың — Тәңре ышанычын аклау.

— Мин акламыйммы?

— Тайдула ханбикәгә кул сузу аклаумы? — дип сораугa сорау белән карап бакты мосафир.

Мамай сыгылып төште. Ике-өч ел үтсә дә ошбу ярадан әле һаман кан саркып тора иде. Бу аның хәсрәте дә, үкенече дә, хурлыгы да иде. Саклый алмады ул мәшһүр Үзбәк ханның тол бичәсен, җаны кебек күргән хатыны Толымбикәнең карт анасын, аналык-тәрбиячесен, ниһаять, үзенең иң дәрәҗәле әбекәен. Болары шәхси мөнбәрдән караганда. Ханбикә дәүләти зат, җәмгыятьнең пакьлек символы, рухи терәге иде. Алласын югалткан йөгәнсез Хызра хан шушы илаһи йолдызга кул күтәрергә җөрьәт итте, тәхетенә яныйлар, имеш.

Бу хәбәрне ишеткәч, Толымбикә исе китеп ауды, атна-ун көн керфекләрен дә селкетә алмады мескенем, көч-хәл белән аякка бастырдылар.

— Мин ул тинтәк ханның гомерен өзәргә бурычлы, фатиханны бир, — дип, хатынының тезенә башын салды Мамай. Фатихасыз булмый, чөнки алар бер ыру кешеләре.

— Үч тоту, кан кою шәрәфле ханбикәнең абруена кара тап иде, бәк, — диде Толымбикә, — борчылма, ул кадерсез бәндә умырткасын үзе казыган базында сындырачак әле.

Ханәкәнең сүзе рас килде. Озак та үтми, Хызра ханны үз улы Тимерхуҗа кылыч йөзлегеннән үткәрде. Тәхет чире йогышлы шул.

Юзекәйнең соравы шушы кайгылы вакыйгага ишарә иде.

— Гафиллек бәласе, — диде Мамай телгә килеп.

— Тәңре сиңа Дәүләт дигән кешнәү айгыр белән идарә итү форсаты бирде, ә син читтән күзәтүчегә әйләндең.

— Мин Үзбәк ханның тәхеткә килгән оныгы Килдебәк ханга теләктәшлек итәм, — дип акланды Мамай.

— Барыбер шоңкар түгелсең, шоңкар аулаган кошын һавада тота.

— Шуннан?

— Шуннан шул, бәк, томшыгың тома.

Мамайның йөзе кара янып чыкты, нидер әйтергә теләде, ләкин сүзләре ачулык йоткылыгында сыланып калды.

— Ыһ...

Аның ачу угы монысында Килдебәк ханга юнәлдерелгән иде. Чөнки ул аны читкә тибеп, бәкләр бәге вазифасын Баһрун ыруы вәкиле Тулыбай мырзага тапшырды.

— Соңгы фасылда, әнәтрәк, бер оягa өч козгын кунды, — дип ярасына тоз тамызуын дәвам итте Юзекәй, — Байду хан бу мыскылга чыдаша алмыйча ләхетен җимермәсә ярый инде.

Бу тәхет буталышына төрттерү иде.

— Житте!

— Оягa үз лачыныңны утырт әүвәл, шуннан соң булыр «житте».

...Үзән сукмагында чаптырып килүче атлылар күренде. Шоңкарга да җан керде, шулай булмыйча, корбанын саклау озаккарак китте бит, кан исе тәмам азындырды, кәҗәне ботарлаудан чак-чак тыелып тора.

— Бәк, ут булдың да, су булдың, эзли-эзли аптырап беттек, — диде сунар-би, — ә табыш шәп, котлыйм, болан кадәре кәҗә.

Мамайның күзләре мосафирны эзләде, тик аннан җилләр искән иде инде. Саташам ахры дип борчылып куйды ул. Мәрткә китү бәласе инде.

Юзекәй дигәннәре дә хыялый шәүлә генә булса кирәк. Алайса, ни өчен сүзләре нәкъ эзенә төшә соң? Соңгы ике-өч елда ул «жигелсәң — мичәү, йөгерсәң — чәчәү, әкрен барсаң — калу, абынсаң — баш-күз еру» кебегрәк икеле-микеле кыйблага таяныбрак яшәде. Хак югыйсә ир-егеткә уңышны фәкать тәвәккәллек илә дуамаллык кына китерә.

— Мансур мырзаның да табышы мул, — диде сунар-би, хужасының уйларын бүлеп.

— Ниткән мырза, нидәй табыш?

— Бүгенге ауның каһарманы улың Мансур мырза.

Бу сүзләр Мамайны чынбарлыкка кайтарды.

— Төкле Аяк, урыныңа!

Шоңкар шундук хужасының ияр кашына килеп кунды.

— Кузгалдык!

Корбаг-чатыр корылган, учаклар тергезелгән. Бәк учагы янында берничә пешекче кайнаша. Өчаякка эленгән бүлтерек кәжә түшкәсен туктаусыз әйләндергәлиләр. Көйдерүдән шикләнәләр, курәсең, чөнки түмәнбашы бик талымлы, ана ярау мең бәла.

Башка учакларга да куз төшкән. Авыздан сулар китереп, борынга ит исе, төтен исе бәреп керә.

Мансур мырза лачынын тугрыга куандырды инде. Хәзер түземсезләнеп атаен көтә. Бәк ни әйтер, улының тәүге авына нинди бәя бирер? Үзе исә каңгатьнең аръягында, авызы колагына житкән, әнә никадәр үрдәк! Их, Дмитрий күрсен иде бу галәмәтне.

Мамай килгән тизлектә атыннан сикереп төште дә улы янына ашыкты. Дөресен әйткәндә, ул мондый нәтиҗәне көтмәгән иде, икеләнебрәк:

— Болар үзеңнеке генәме? — дип сорады.

— Үземнеке генә, атаем, бер суна үрдәк тә бар әле, анысын пешерергә алдылар.

— Котлыйм, улым, иншаллаһ, яуларың да ганимәтле булыр.

Йоласына туры китереп, пешкән сунаны китерделәр. Яшь аучы тәүге табышын бөтен кеше алдында ашап бетерергә тиеш. Мансур монысында да сынатмады.

— Ит — адәмнең корычы, булдырдың, — дип хуплады улын бәк, — ә хәзер сары бал эчеп куй, үрдәк су ярата.

Аучылар көлешеп алды.

Бу Мансурның үз гомерендә беренче мәртәбә хәмергә ирен тигезүе иде. Чырае сытылды.

— Чын угланга бик күп сынаулар аша узарга туры килә, — диде Мамай, — хәмер шуларның иң куркынычы, тәүге касәдән үк нәфесенә акылыңны баш итеп куй.

— Барысы да син кушканча булыр, атаем, — диде Мансур, батыраеп китеп, — бер үтенечем дә бар...

— Әйт, нинди үтенеч ул?

— Дустым кенәз Дмитрийны сагындым, атаем, чакыртасы иде, бик...

— Вакыты ул түгел, — дип бүлде улын ата кеше коры гына.

Үтенечемне хәмергә бәйләде, ахры, атаем дип чын борчуга төште Мансур. Их, акыл сынавын үтә алмады, тубырлы алашадай тигез жирдә абынды. Ул, әлбәттә, хак хәлне белми иде. Юзекәй бәккә ифрат та авыр гаеп ташлады ич, баскан жирендә үлән корысын, эчкән жирендә су кипсен, диде.

Табында Мамай онытылды, сары бал киеренкелекне үзенә йомды. Гәп ау хәлләренә күчте.

— Субра, яшь мырзага тулгау фарыз, минем исемнән әйт, — диде Мамай.

Субра әзер иде инде. Башта кубыз аваз бирде, аннан жыр-такмак яңгырады:

Катим Тайдай юмартсың,
Арсландай адусың,
Камзәдәй палвансың,
Галинең гали улысың,
Арслансың, мырза улым.
Садагың алтын, угың алтын,
Чамыргап әйткән сүзең алтын,
Саф азамат мырза улым.
Йәмәннән кеше жыйсам,
Уртага агач тексәм,
Мин тугыз күрек бассам,
Сине дәрәжәгә чиксәм,
Саф алтынсың, мырза улым.

— Тарлан Бүзне китерегез! — диде Мамай, тулгау тәгалләнүгә.

Чатыр авызында бакыр йонлы сөлектәй гүзәл толпар күренде. Табын бер хәрәкәттә урыныннан купты. Дастаннарга тиң толпар алдында утырып торып була ди мени. Аһ иттеләр.

Мамай елгырның нуктасыннан тотып алды да Мансурга мөрәжәгать итте:

— Тактайлаган бычкактай табаны яссы йирән ат, киләпләгән йибәктәй ялы булды йирән ат, озын чәчле кыздай койрыгы озын йирән ат, галәмне узып йөлте алган үгечем юктай йирән ат бирәем сиңа мырза зат.

— Афәрин, бәк!

Мансур бүләк атының муенына сарылды.

Мамай дәвамлады:

— Байду хан йорты түрәсез калды. Алтыннан суккан Ак Урда тәхетенә без мәшһүр Үзбәк хан ыруыннан үз карышкыбызны тәгаенләргә бурычлы. Сарай безне көтә. Ант эчәбез!

Кылыч очлары беләкләргә кадалды, иреннәргә кан буялды.

— Ант!

***

Мамай кичләтеп кенә бичәсе янына керде. Хатыны кече кызлары Айтулы белән мәшгуль иде. Үчти-үчти сикертә, сөя, иркәли.

— Өяр идем, төяр идем, бодай камырын ясар идем, — дип көлде ата кеше.

— Бик өяр идем дә, бик төяр идем дә, арпа камырыдай таралып баруларыннан куркам шул, — диде Толымбикә шул ук шаярту дулкынында.

— Менә монысы дөрес түгел, мысыгым, — диде Мамай бармак янап, — әле син миңа малайлар алып кайтырга тиеш, Мансурыбыз буй житеп килә.

Толымбикә кызчыгын нәнәсенә бирде дә, ире алдына килеп утырды. Тегесе аны кочагына кысты. Өйләнешүләренә дистә ел вакыт үтеп китсә дә, аларның гыйшкы сүрелүне белми, элеккечә дөрли иде әле.

— Шул ният белән кердеңме, мамучым...

Ханәкә мысыктай мыр-мыр килеп, кайнар тыны белән иренең йөзен өттерде, куллары шыпырт кына изү эченә шуды...

Дөньялары онытылды.

Чәй табынында да сүз шул хакта барды. Толымбикә нигәдер кайтып-кайтып әлеге сүзне куертты.

— Мамуч, минем сиңа бер риваять сөйлисем килә, тынла әле, — диде.

— Бик рәхәтләнеп.

— Берничә кеше зарланышып утыралар икән. Берәве авыр сулап: «Әйе, заманалар авыр, бала-чага күп, чыгымнар зураеп китте, житешеп булмый», — дигән.

— Баласы бала, чага дигәнең ни соң ул? — дип сораган әңгәмәдәше.

Яннарында бала-чагадан күп җәфа күргән адәм дә бар икән, әйткән:

— Шул балалар арасында чага торганы була, шунысын чага дип әйтәләр, — дигән.

— Бу нигә ишарә инде, ханәкә? — дип, Мамай хатынына текәлде.

Толымбикә чынаягын читкәрәк этеп куйды да, житди төскә кереп:

— Чагалар безнең арада да бар ич, бәк, — диде, — үзең күреп торасың, тәхеткә хәзер атай үтереп менеш, чиратларын көтеп ала алмыйлар.

— Хак, ханәкә. Тик бу минем угланнарга кагылмый, без бит турыдан-туры тәхеткә дәгъва итә алмыйбыз, ыруыбыз бүтән.

Азга гына тынлык урнашты. Күрше бүлмәдән нәнәнең көйли-көйли бала йоклатканы аермачык ишетелеп торды:

Әлли-бәлли, бәү-бәү,
Атай барда атай баш,
Атай юкта ана баш,
Анай юкта түтә баш,
Түтә юкта үзем баш,
Әлли-бәлли, бәү-бәү...

Ата белән ана бер-берсенә карап елмаештылар.

Мамай нидер әйтмәкче иткән иде дә ханәкә алданрак житеште.

— Бәк, кичә ауда Сарай тәхете буш дигән сүз ычкындыргансың икән...

Монысында инде Мамай Толымбикәгә җөмләсен төгәлләргә ирек бирмәде.

— Ханәкә, мин менә нәкъ шул хакта сөйләшергә дип кергән идем, — диде.

— Сагынуыма түзә алмадым дигән була тагын, алдакчы...

Толымбикә иренә яны беләнрәк борылып утырды. Мамай хатасын төзәтергә ашыкты.

— Мысыгым, синең мәхәббәт угың йөрәгемнең иң түренә ничек кадалган булса, әле дә шул урында тора, — дип, хатынының кулларыннан алды, — дөнья шөгыльләре аңа һич тә комачау итми.

— Беләм, — диде Толымбикә, — сынавым гына, җә, әйт, нинди сүзең бар?

Гәпкә керешкәнче Мамай нанә катына колак салды, тавыш-фәлән ишетелмәде, бәләкәч йокыга киткән иде инде, күрәсең.

— «Сарай тәхете буш тора» дигән тәгъбирнең асылы шунда, ханбикә, — дип йөрәнә-йөрәнә шәрехләргә кереште, — Алтын Урданы[48] саклап калыйк дисәк, без Сарайдагы зилзиләле хәлләргә төкереп, алардан бәйсез үз дәүләтчелегебезне булдырырга тиешбез. Алтын Ташка бүген Килдебәк хужа, иртәгә Мөрид шаһзадәнең дилбегәне үз кулына алуы ихтимал. Шымчыларым ханга һөҗүм әзерләнүен житкерде. Кыскасы, андагы

[48] Алтын Урда — 1243 елда Монголия империясе кочагында Бату хан тарафыннан оештырыла. Тора-бара тулы мөстәкыйльлеккә ирешкән бу бөек Татар дәүләте тарихи географиядә «Жучи Олысы», «Олуг Улус», «Дәшти Кыпчак», «Урда» исемнәре белән йөртелә. Алтын сыйфатнамәсе ханның Алтын чатырына, Алтын сараена мөнәсәбәттә кулланылган. Термин буларак, «Алтын Урда» дәүләте таралып, ике йөз ел үткәч, XVI гасыр азагында гыйльми әйләнешкә керә башлый. Укучыларны бутамас өчен, әсәрдә дәүләт атамасы «Алтын Урда» дип кенә алынды.

ызгыш-талаш безнең Сарайга әйләнеп кайтуыбызның көнен якынайтачак кына.

— Сөбханалла, бәк, ә тәхетенә кемне тәгаенлисең?

— Агаен Бирдебәк ханның кияве Абдуллаһ кулай булыр сыман тоела, — диде Мамай йөрүеннән тукталып, — Чыңгыз нәселеннән, үзе яшь. Кануни яктан тел-теш тигезерлек түгел. Монысы — иң кыйммәтлесе.

Толымбикәнең чынаягындагы чәе чайпалып, ашъяулыкны таплады.

— Шул хөрәсәннеме?

— Аның бүреге генә кирәк, бүрек астындагы мие безнеке булачак.

— Хәйләкәр син, Мамуч, — дип бармак янады Толымбикә, —кыюлыгың миңа бик тә ошый, башкисәрлегең дә.

— Адәм тормышында шундый бер хикмәтле чик бар, — диде Мамай, — әгәр аны атлап чыгасың икән, артка юл ябыла, чигенә алмыйсың. Сине бернинди киртәләр дә тота алмый. Әхлак та, дин дә, башкасы да. Тәхет кан бәрабәренә яши. Тәхет — көчлеләр бәйгесе. Һәм ошбу язмышка, ул ничек кенә тәгаенләнмәсен, берәүнең дә үпкәләргә хакы юк. Чөнки бу язмышны син үз теләгең белән сайлыйсың. Хәзер мин шул халәттә.

— Ошбу көрәштә мин синең ышанычлы терәгең!

## Дәвер, Кыят дәвере

*Ил булганга — ил булды,*
*Яу булганга –яу булды.*
«Идегәй» дастаны

Ут биетеп яшәргә күнеккән кыбырсык вә үҗәт Мамай белән чагыштырганда, ике генә дистәне тутырган Абдуллаһ бер гафил гыйбад затны хәтерләтә иде. Акрын, дәшмеш. Янмый, көйми. Яшәеше генә түгел, йөз-чырае, килеш-килбәте дә торгынлык сазына көйләнгән иде. Шуңа күрә тәхет тәкъдимен дә сүрән генә кабул итте. Хатыны Көнәкә исә, киресенчә, күтәреп алды.

— Миңа да ханбикә хөрмәтләре күрергә язган икән, — дип, шатлыгыннан Толымбикәне үбәргә тотынды, — рәхмәт сөекле каеначкаем, яхшылыгыңа — яхшылык, Аллаһы боерса.

— Рәхмәтенә рәхмәт, сенелкәем, — диде Толымбикә, хис һөҗүменнән арынып, — иреннән әкүл ясагансың бит, кәеф-сафа гына корып ятасыз, ахры, кара инде киявебезгә, кукәй рәвешенә кергән ләбаса, тотар җире дә калмаган, мимылдаган тәки.

— Мөхтәрәм ханәкәләр, дәүләти тәкъдимне гаилә-ыру кысаларына яба күрмәгез берүк, — дип кисәтте Мамай, — әкүлгә килгәндә исә, ханның мәшәкатьләре баштан ашкан, корсак та үзеннән-үзе шиңәр. Абдуллаһ, хан бүреге киюгә, дәүләте буйлап эш сәяхәтенә чыгып китәчәк...

— Мин йөрүне яратмыйм, — диде Абдуллаһ.

— Ярату-яратмаулар белән хушлашырга туры килер, — диде Мамай көлемсерәбрәк, — халык үзенең хакимен күреп белергә тели. Аеруча Кара диңгез буе, Азак тирәләрендәге чикләрне ныгыту сорала. Казан Болгарына соңрак үзем барырмын. Анда хәлләр катлаулы, мөстәкыйльлек даулыйлар, аерылып чыкмак булалар дип ишеттем. Салымны кайда да фәкать Урдага, ягъни безгә генә түләргә тиешләр.

Эшне тиз тоттылар. Икенче көнне үк Мамай корылтай җыйды. Монда да үгезне мөгезеннән алды. Чөнки барысы да алдан килешенгән иде инде. Кыска гына кереш нотыктан соң Толымбикәгә мөрәҗәгать итте.

— Ханбикә, синең сүзең кануни көчкә ия. Безнең, ягъни дә Кырым

әмирлегә тәкъдименә карата фикерләренне белдерсән иде, — диде. Һәм өстәде: «Каләмче һәр сүзенне кәгазьгә теркәп, мөһер сугачак».

Толымбикә тып-тып басып, әмир кәнәфиенә барып утырды. Гәүдәсе орчыктай туры, йөзе тәкәббер. Шул кыяфәттә башта җыелышучыларга күз йөртеп чыкты. Аннан соң вәкарь белән генә мәмләкәтнең давыллы язмышына зилзилә өстәячәк белдерүен җиткерде:

— Мин мәшһүр Үзбәк ханның оныгы, мөхтәрәм Җанибәк ханның Толымбикә атлы кызы, ханәкә, бөек кардәшебез Байду хан нигез салган Алтын Урда дәүләтен саклап калу һәм ныгыту мәнфәгатьләрендә аек акыл вә дә зур җаваплылык белән каһарман Җучи нәселе вәкиле Абдуллаһ шаһзадәне хан дип игълан итәм.

Зал дәррәү торып басты.

— Афәрин!

— Мәрхәбә!

Абдуллаһка хан бүреге кигезделәр. Ул, үз чиратында, Мамай мырзаны бәкләрбәге вазифасына билгеләде, рәхмәт белдерде.

Мәҗлесләр үткәреп тормадылар, тәхет нотыгы да булмады. Чөнки моның өчен тәхет зарур. Ә ул Сарайда. Башта әле бу каланы алырга кирәк.

— Калган рәсми җыеннарны Алтын Ташта, Хан бистәсендә үткәрербез, — диде Мамай, — анынча да башкарасы эшләребез хәтдин ашкан. Иң беренче кичектергесез бурыч — Абдуллаһ хан исеменнән акча сугу. Үз акча тамгасы булмаган хан — ялган хан ул, аны бер чит мәмләкәт тә танымаячак. Янә дә баглалышлар. Казна. Мин үзем шәхсән беренче вакытта шул эшләр белән шөгыльләнәчәкмен.

Бу җәһәттән аның төп терәге балачак каласы Каффа иде. Төгәлрәге, Каффадагы Генуя сәүдәгәрләр үзәге. Көнчыгыш вә Көнбатыш кыйтгаларының дингез юлы сәүдәсе алар кулыннан уза. Каффа портына көн саен дөньяның төрле почмакларыннан килгән караблар туктый. Тауар әйләнеше бик зур. Казнага да шактый акча керә.

Италиялеләр, хәл бүгенге тотрыклы рәвешенә кергәнче, канга шактый тоз сиптеләр. Башбаштаклык җучиларның көндәше Хулагу белән Кавказ арты җирләре өчен тарткалашу чорыннан ук башланды. Генуялылар моннан бик оста файдаланды, илханнар белән якынлашты. Венециялеләр үз чиратында Җучи дәүләтен сайлады. Үзара да тату яшәмәделәр, коралга ябышкан чаклары да булгалады. Әйтик, шундый бер бәрелеш нәтиҗәсендә бөтен мәшрикъта зур абруй казанган Венеция сәүдәгәре һәм дипломаты Марко Поло генуялыларга әсир төште. Бу көрексез хәлнең файдасы да булды. Марко үзенең күргәннәрен зиндандашларына сөйләде. Бу сөйләгәннәрне синьор Рустичано язып алды. «Дөньяның төрлелеге турындагы китаплар» исемле күренекле басма менә шул рәвешле туды.

Каффа хәзерендә генуялыларга арендага бирелде. Өлкә алар юрисдикциясендә, алар кануны нигезендә яши. Консулны да Генуя шәһәре дожы[49] билгели.

Мамай монда еш була. Консул — синьор Антоний белән дустанә яшиләр. Ул аңа олылап, Дож дип мөрәҗәгать итә, хәлбуки бу Генуя шәһәр — җөмһүрияте хакименең рәсми атама-дәрәҗәсе. Ә Антоний өчен ул синьор Манчетти, гурген, мырза-әмир.

Бүген исә «синьор Манчетти, гурген, мырза-би» дип сәламләде. Мамайның колагы сак, бу үзгәрешне шундук абайлап алды.

— Мин барысыннан да хәбәрдар, — диде Антоний аның сораулы карашына җавап итеп, — котлыйм. Ул италикларга хас хислелек белән әңгәмәдәшен күтәреп, бала уйнаткандай идән уртасында бөтерелеп алды.

[49] Дож — башлык.

— Яңа хөкүмәт төзү бик зур сәяси вакыйга, синьор Манчетти, гурген, мырза-би, аны билгеләп үтмәсәк, хата кылырбыз.

Көләч йөзле, нәфис буй-сынлы чибәр туташ алтынсу төсендәге затлы шәрабны бокалларга агызды.

— Абдуллаһ-Мамай дәүләтенең гомере шушы йөз еллык шәрабныкы шикелле озын булсын, — дип, тост тәкъдим итте Антоний.

Бүлмәгә саф бәллүр чыңы таралды.

— Бүген сиңа, синьор Манчетти, гурген, мырза-би, иң гүзәл туташыбыз синьоритта Чечилия кадер-хөрмәт күрсәтер, — диде Антоний тигез ак тешләрен ялтыратып, — риза-бәхил калырсың, сүз бирәм.

Синьоритта озын керфекләрен идәнгә чәнчеп кенә елмайды да, җиңелчә генә тез чүгеп куйды. Шәрә изүеннән оядан баш тәрткән кош балаларыдай күкрәк алмалары күренеп китте.

Кунакның җаны-тәне шәһвәт белән тулды. Моны Антоний да сизде.

— Чибәркәйгә дә чират житәр, — диде туп-турыдан, — хәзер гәпләшеп алыйк, күрәм, йомышларың күп булса кирәк.

Мамай әлеге вәсвәсәле йомшаклыгыннан кыенсынып, башын читкә борды. Антонийның шәрабе аны һәрвакыт шулай кирәк-кирәкмәс жирдән дә дулкынландыра. Йомышы, әлбәттә, күп, шуның өчен килде ләбаса.

Гәпне хужа кеше башлады.

— Бу ике дәүләт безнең мөнәсәбәтләргә тискәре йогынты ясамасмы, дөресен әйткәндә, мин шуннан шикләнәм, — диде. — Үзең беләсең, ике көймәнең койрыгын тоту мөмкин түгел.

Ул инде бөтенләй икенче кеше иде: йөзе жыелган, карашы житди, сүзләре үткен.

— Кырым әмирлегенә моңарчы дәгъваң бар идеме соң? — дип соравын юллады Мамай.

Ул да үз асылына кайткан иде инде.

— Юк, ике яктан да гаһеднамә төгәл үтәлә.

— Киләчәктә тагын да яхшырак булачак, галиҗәнап Дож, икеләнергә урын юк.

— Үзәк дәүләт Сарайда бит, би...

Мамай үзенекен ялгап китте.

— Кырым да Алтын Урда жире, дож, бик тиздән Бәркә хан нигез салган Сарай да безнең кулга төшәчәк. Бу көнне якынайтуга син дә үз өлешеңне кертә аласың.

— Ничек?

— Табигый, әлегә казнабызның төбе такыр, шуңа күрә гаскәр туплауда аерым кыенлыклар килеп туды, — диде Мамай, әңгәмәдәшенә туры карап, — ярдәмеңә өмет итәргә хакым бар дип уйлыйм.

— Күпкә китмәсме?

— Борчылма, Сарай тәхетен алгач, безнең мөмкинлекләр киңәячәк,ташламалар ясарбыз, чыгымың икеләтә кайтыр.

Антоний бокалын учына кысып, тәрәзә янына килеп басты. Озак кына бер-берсен куышып уйнаган иренчәк дулкыннарны күзәтеп торды. Жилбикә ялга талган, күрәсең, яфрак та селкенми.

— Акчаны тавык булып тавык та чүпләми, хикмәт анда түгел, — диде ул әңгәмәдәше янына борылып, — безне барыннан да элек сәүдә мәйданын киңәйтү мәсьәләсе кызыксындыра. Русия базарында ныклап тамыр жәю кулай булыр иде, мәсәлән.

— Русиядә диңгез юк...

— Коры жиргә чыгарга да вакыт житте, би.

— Безне кая куясың?

— Дөнья киң, анда барыбызга да урын житәрлек. Татулык кына булсын.

Мамай ризалыгын белдереп, башын иеп куйды да, гәүдәсен кәнәфинең читенәрәк шуыштырды. Кырын ятып гәпләшүгә күнекмәгән иде ул. Жайлап утыргач:

— Антоний, минем тагын бер мөһим мәсьәлә буенча сөйләшәсем бар иде бит, — диде.

— Монысы хакында, синьор Манчетти, карабта сөйләшербез, күрәсеңме, көне шәп, дингез дымык, синьоритталар әзер, — дип кунагын житәкләп алды хужа. Аннан тукталып кисәк кенә:

— Исемә төшкәндә сорыйм әле, би, жә соңарырмын, акчага үз тамганны да суктырасыңдыр бит? — дип сорады

— Сонардын шул, синьор, — дип көлде Мамай, — Абдуллаһ хан акчасын йөрешкә керттек инде.

— Кызганыч, миндә әнә Мәуберханда сугылган акча бар. Анда Сөргатмыш солтан исеме белән беррәттән Таймур Гөркан әмирнең исеме дә теркәлгән.

— Үз исеменнән акча сугарга дәүләтнең Илбашы гына хаклы. Мин кануни хак гамәлләрне генә таныйм.

— Аңлашылды, ә хәзер киттек, безне караб көтә.

Антоний эленке-салынкылыкны белми. Һәрвакыт хәрәкәттә. Яшәеше дә шуңа көйләнгән.Эшли икән, сытып эшли, ял итә икән, тугарылып ял итә. Ял дигәне дингез, караб, чибәр туташлар, жыр, бию, музыка...

Аларны көлеп-елмаеп гүзәл синьоритталар каршы алды. Араларында Чечилия дә бар.

— Хуш киләсез, синьор әфәнделәр, затлы итальян шәрабеннән авыз итегез, — дип, бокаллар тәкъдим итте ул.

— Йолдызларым, сезнең өчен, — диде Антоний һәм эчеп бетерүгә бокалын идәнгә бәрде.

— Монысы бәхеткә, йолдызларым!

Йолдызлар чырылдашып кул чапты.

Мамай эчтән генә сыкранып куйды. Күренә ки, типтерү давыллы булырга охшый. Һәм ул ким дигәндә ике-өч көнгә сузылачак. Аның исә тугарылып кәеф-сафа эчендә кайнарга чамасы юк, вакыты тар. Шуңа күрә Антоний ныклап торып мәжлес сазлыгына кереп чумганчы йомышын йомышлап калырга кирәк.

Табынга утырыр алдыннан, жаен табып, ул аны ниндидер бер кысан каютага өстерәп диярдәй алып керде. Тегесе моны үзенчә гөманлады, күрәсең, авыз ерды:

— Әйттем ич инде, Чечилия синеке була, дидем! Кыбырсыма!

— Тыңла әле, синьор Антоний, минем сиңа бик тә четерекле бер үтенечем бар.

Ул азга гына тукталып торды. Бу ара аңа хужаның игътибарын жәлеп итү өчен кирәк иде. Һәм дә максатына иреште, Антонийның шук-көләч йөзенә житдилек кайтты.

— Сөйлә соң, көттермә.

— Һәр дәүләтнең абруе чит мәмләкәтләргә бәйле, — дип тәкърарлап китте Мамай, — алар хокукый дип саный икән, дәүләт яши, санамый икән, урының типкедә.

— Иң сөймәгәнем акыл сату, — диде Антоний, — уйнашчы хатын түгелсең, боргаланмыйча гына үтенечеңне әйт.

— Абдуллаһ хан сине Римга илче итеп жибәрергә карар кылды. Синнән дә кулай кеше юк, карышмасаң иде.

Антонийның болай да калку күзләре шар булды.

— Минеме?

— Син генә түгел, бүген-иртәгә илчеләребез Харәземгә, Константинопольгә, Русиягә, Кытайга, Монголиягә чыгып китәчәк. Мин үзем Литва кенәзлегенә ниятләп торам.

Синең вазифаң, синьор консул, Папа белән Абдуллаһ ханның, ягъни Рим белән Урда мөнәсәбәтләрен көйләп җибәрүдән гыйбарәт, — дип шәрехләвен дәвам итте Мамай, — Рим белән Алтын Урда арасында юл һәрвакыт такыр булган. Үзбәк хан чорында исә ул яңа баскычка күтәрелә. Бездә Бенедикт-XIIнең Үзбәк ханга, Тайдула ханбикәгә, тәхет варисы Җанибәк ханзадәгә язган рәхмәт хатлары саклана.

Вәзгыять тамырдан үзгәрде. Шуны колагыңа киртлә: моннан ары Алтын Урда дәүләтенең башкаласы — Урда![50] Ә Сарай ни, диярсең? Сарай — фетнәчеләр үзәге.

***

**Рим.** Антоний папа катына бик авырлык белән генә үтеп керде. Көнгә ике-өч кенә кеше кабул итә икән. Анда да иң танылган, дөнья күләмендә абруй казанган рухани вә дәүләт эшлеклеләрен генә сайлап алалар.

Идарә сәркәтибе Антонийның шәхеснамә билгеләмәләрен бик җентекләп тикшерде, затлы металлдан коелган исемле байза-пластинкасын хәтта тешләп тә карады.

— Әллә беренче тапкыр күрүеңме? — дип сорады Антоний.

— Ишеткәнем бар иде, ә кулыма беренче тапкыр керә, — диде яшь түрә, — мин ошбу вазифамны әле өченче ай гына башкарам.

— Чыңгызхан заманыннан килә торган ышанычнамә.

Сәркәтип көмеш кысага кигертелгән калын китапны озак кына актарды да:

— Абдуллаһ хан безнең исемлектә юк, — диде. — Сарай тәхетендә, белүемчә, Мөрид хан утыра.

— Ә Кырым әмире Мамай бәк?

— Мамай бәк бар, ләкин...

Антоний Алтын Урданың тарихка «Великая замятня» исеме белән кереп калачак егерме елга сузылган канлы чуалышлар чытырманына башын тыкмады, сәүдәгәрләргә хас житезлек белән сәркәтипнең учына алтын тәнкә генә шудырды.

— Мамай бәк шул Абдуллаһ хан инде ул.

Аудиенция залында Антонийны йомышчы кардинал каршына бастырдылар.

Папа үзе биниһая зур тәхетендә мендәргә кунган чебен кебек кенә чүмәшеп утыра. Урбан кардиналның папалык чоры азагына якынлашкан икән инде, диган уй йөгереп узды Антонийның башыннан. Ул баш руханиның кулын үпмәк булып талпынып караган иде дә, кардинал аркылы төште.

— Үтенечегезне житкерегез, вакыт тар.

Антоний Абдуллаһ ханның ярлыгын сузды.

— Понтифик Сарай белән булган мөнәсәбәтләрне дә туктатып торуны кирәк тапты, ә сез әллә нинди билгесез ялган ханны төртәсез, — диде канәгатьсезлек белән, — Римның абруе барсыннан да өстен.

Зур залны яңгыратып, тәхет хуҗасы телгә килде. Антоний дерт итеп китте. Күр, тавышы ничек көр чыга, чебен кебек тоела гына икән.

[50] Урда — Мамай оештырган дәүләтнең күченеп йөрүче башкаласы. Солхат, Судак шәһәрләре утырма башкала ролен үтәгәннәр.

— Әүвәл Ходай каршында күркәм гамәлләре белән католиклар койган канны юсыннар, шунарчы барча аралашуларга да киртә салам!

Сүз Сарай тәхетендә нибары биш кенә ай утырып алган Күлнә хан турында барган икән. Моны Антоний соңыннан гына белде. Хан ике улын да Римда чукындырган, католиклар ягына авышкан. Шунын өчен үзен дә, уллары Иоанн белән Михаилны да канга батырып үтергәннәр.

— Мөхтәрәм понтифик, киртә кору ансат ул, менә юл салып кара син...

Кардиналның күзеннән очкыннар сибелде, авызы: «бәхәсләшмә!» — дип ысылдады. Понтифик, киресенчә, тәвәккәл милләттәшен ошатты, ахры:

— Син, туганкай, юл салучымы әллә? — дип, карап бакты.

— Әйе, мөхтәрәм понтифик, юл салучы. Кырымда Генуялылар үзәге булдырдык. Көнчыгыш белән Көнбатыш дингез сәүдәсен үз кулыбызда тотабыз. Русия, Урал, Сибирия, Каспий төбәкләренә кармак салырга исәп бар. Сәүдә үтеп кергән жирдә дингә дә сукмак ачыла. Без үз миссионерларыбыз белән теләктәшлек итәргә әзер.

— Кардинал, Абдуллаһ хан галиҗәнапларына җавап ярлыгы әзерлә, мин анын хакимлеген таныйм һәм фатихамны бирәм, — дип әмерен юллады понтифик.

***

**Дәмәшкъ.**

Кәмал угланны солтанатта кочак җәеп каршы алдылар.

Хулагилар Дәмәшкъның чит мәмләкәтләр белән мөстәкыйль рәвештә аралашуын өнәп бетермәсәләр дә, Хафиз солтан илче килүне зур абруй сыйфатында кабул итте. Анын әле хакимлек итүенә ярты ел гына иде. Атасы Әсәдулла солтанның вафатыннан соң династия кануны буенча олы агасы Өрестәм шаһзадә тәхеткә утырырга тиеш булса да, ул аны бер караңгы төндә ятагында буып үтерде. Канын чыгармады, чөнки диндәш туганының канын чыгару зур гөнаһ. Үтерү, мәсләгенә карап, ярлыкана, кан чыгару — юк!

Яшь солтан Дәмәшкъ каласының элекке данын кайтару уе белән яна иде. Агасын юлдан алып ташлауны да шуның белән аңлатты. Имеш, Өрестәм шаһзадә Мисырдан читләшеп, тулысынча Богдад кул астына керү мәнфәгатен алга сөргән.

— Безнең жир бик борынгыдан килә, — дип, үтә дә зур горурлык белән тәфсилләде солтан, — Мөхәммәд галәйһиссәламгә Аллаһының изге китабы — Әл-Коръән ингәнче күптән элек мәшһүр Дәмәшкъ патшалыгы бөтен чүл илләрендә дан тоткан. Пәйгамбәребез вафатыннан соң аның ыруы булган Өммәедләр хәлифәте канат җәя. Шам каласы (Дәмәшкъ) — янә баш шәһәр.

— «Сузылган шам кылыч» тәкъбире шул хөрмәткә, алайса, — дип, Кәмал илче дә үз сүзен кыстырып куйды. Югыйсә хужа кеше авыз да ачтырмый, гел үзенекен такылдый. Инде тезмә сүзгә күчте.

Без сугышкан йирләрдә
Сары мәйдан чүл иде,
Сары болак саз иде,
Аргымакның өстендә

Кылыч чабып, ук аткан
Ул җиһангир мән идем.

Кәмал мырза дала кешесе. Эче-тышы хөрлек белән тулышкан, күзе очсыз-кырыйсыз кинлеккә күнеккән. Үз мәмләкәте каласына да аерым зарурлык килеп туганда гына кайта. Анда үзен тышаулы ат кебек хис итә.

Шулай да Хафиз солтан аның шәһри битарафлыгын чатната алды бугай, хәтта бәхәскә дә кереп китте.

— Игътибар ит, мөхтәрәм илче, бу безнең иң изге урыныбыз, — диде солтан бер сәер корылма янында, — монда бөтен тирә-як мөселманнары Аллаһыга гыйбадәт кыла, гөнаһларыннан арына.

— Кыйшайган таш баганалар...

Солтан ярсып китте.

— Таш баганалар, имеш, кыйшайган, имеш. Шуның белән истәлекле дә алар. Бу изге Дәмәшкъ Тәңресе гыйбадәтханәсенең калдыклары. Без аңа кул тидерми кадерләп саклыйбыз. Чөнки ул дәүләтебезнең бөеклек символы, халкыбызның хак мактанычы.

Өммәедләр төзегән мәчеткә кергәч, икеләнү-шөбһәләре бөтенләй таралды.

Керүгә ап-ак читек тоттырдылар. Солтан үрнәгендә Кәмал дә гасәбә егет ярдәмендә аяк киемен алыштырды. Читекләр аңа чак кына иде. Күрәсең, үлчәмне алып, махсус теккәннәр. Ә менә тоткалы капкач беркетелгән көмеш савытны бермәл нишләтергә белмичә кулында әйләндергәләп торды. Солтан аңа дисбесен салды. Ә ул дисбесез икәнлеген белдертмәс өчен читеген рәтләгәндәй итенде.

Мырзаның мондый затлы бинаны беренче күрүе иде, исе-акылы китте. Күзне камаштырып асыл ташлар, алтын-көмештән үрелгән аллы-гөлле бизәкләр җемелдәшә, гүя күктәге йолдызлар диярсең... Биек, якты, хозур, пакь. Бу сихри манзарадан күңелләрне сафландырып ниндидер ашкынулы садә моң сибелә. Моң кальбеңә үтеп керә, җаныңны, рухыңны Аллаһы белән тоташтыра, фани дөнья касәфәтләре онытыла.

Кәмалнең тәкъвалеге сай иде. Шулай да солтан артыннан намазлыкка тезләнде.

— Далада дин тотуы авыррак шул, — диде ул соңыннан, аклангандай.

Солтан ризалашмыйча башын чайкады.

— Тәкъвалек сулаган һава кебек ул, мөхтәрәм илче, аңа бернәрсә дә киртә куя алмый. Аллаһы Тәгалә адәмнәрне фани дөньяга сынау өчен генә җибәргән. Бу катгый сынауны уңышлы үтүнең бердәнбер юлы — исламият, хак динебез.

Өйләдән соң Орыш ярагы бүлмәсен карадылар. Бусагадан атлап керүгә, солтан кылычын кынысыннан суырып чыгарды. Ярагбашның да кулында кылыч иде. Бер-берсенә якын килеп, бар көчкә кылычларын чәкештерделәр, тирә-якка чар ташыннан бөркелгәндәй очкыннар сибелде.

— Күк керсен, кызыл чыксын!

Солтанның өндәмәсенә ярагбаш та шул ук тәкъбир белән җавап бирде.

— Күк керсен, кызыл чыксын!

Бу өндәмә гаскәриләрнең анты икән, ягъни орыш дошманны җиңгәнче, каны чыкканчы барачак.

Сөрьяни булат кылычның даны бөтен җиһанга таралган. Риваять буенча, бу кылыч хаҗәте чыгуга үзеннән-үзе сузыла, кирәк икән, кыскара да икән. Иясен дә хәвеф-хәтәрдән саклый, имеш.

— Кылыч сәлам бирдерә, башың җиргә идерә, — дип җорланды солтан.

Кәмал углан аны ишетмәде дә. Чөнки мөкиббән киткән иде. Мондый затлы орыш ярагларын тагын кайда күрәсең? Ни генә юк: ук-җәя, сөңге-чукмар, суел-хәнҗәр, пәке-пычак, калкан...

Ә кылычлар — бихисап. Турысы да, кәкресе дә, озыны да, кыскасы да, калыны да, нәзеге дә. Кайсылары дуга урынына бөгелә, сынуның ни икәнен дә белми.

Ярагбаш көмеш саплы кылыч тоттырды.

— Углан, урдалыларның ни-нәрсәгә маһир икәнен күрсәт, — дип, табигый зурлыктагы дошмани зат карачкыга ым какты.

Кәмал бер кизәнүдә җилкәсеннән чабып, гәүдәне утын пүләнедәй икегә аерды.

— Афәрин, углан, бу кылыч сиңа бүләгем, — диде солтан, — иртәгә чүлгә чыгып китәбез, чын ир-егет шунда сынала.

Кәмал ихтирам белән башын иде дә әйтте:

— Галиҗәнап, барысы өчен дә бик зур рәхмәтлемен, кызганыч, сәфәр өчен бирелгән вакытым тәгәлләнеп килә, юлга чыгарга рөхсәтеңне бирсәң икән. Абдуллаһ хан синнән вәкаләтле ярлык көтә. Үзегезнең дә илчеләрегезне кадер-хөрмәт илә кабул итәрбез.

— Үз эшен шулай төгәл белгән йомышчыларны мин бик ихтирам итәм, илче, — диде солтан, — ханга ярлыгым иртәнгә әзер булыр.

**Җидесу.**

Дөрмән мырзаны төн пәрдәсе төшкәч, озын юлдан соң хәл алырга дип баш терәгән вакытында әсир иттеләр, ангысаннар төркеме сизми дә калды. Югыйсә өченче тәүлек инде бер җан иясе дә очрамаган иде. Баксаң, әле кичә генә монда Җидесу хакиме киез өен күтәрткән икән. Җәйләү өчен урыны менә дигән, көмеш сулы күле дә җәйрәп ята.

Дөрмән мырза айбалтадан башка корал йөртми. Анысы да исем өченгә генә. Илчегә үлем юк. Ләкин аларга һөҗүм итүчеләрнең фикере бу гомуми хакыйкатькә туры килми иде булса кирәк. Хаким алдына аны богаулы халәтендә китереп бастырдылар.

Хаким фирәзә ташыдай тере күзләрен беленер-беленмәс кенә каш астында уйнатып алды да, тәгамен дәвам итте. Биш бармагына эленгән касәсен сол белән генә авызына китерә дә, өрә-өрә чөмереп куя. Янә өрә, янә чөмерә.

Дөрмән ирексездән өй хуҗасын күз уныннан үткәрде. Көче ташып торган яшь чагы. Азамат ир-егет. Фырт күренә, сакалын кыска итеп кырдырган, ә мыегы, киресенчә, озын, славяннарныкына тартым, очы кайтарылган, бөтерелеп тора.

Хуҗа, ниһаять, буш касәсен табынчыга сузды. Икенчесе ана тастымал тоттырды. Чәй эчкәндәге шикелле ул ашыкмыйча гына озаклап сөртенде. Аннан соң читтәге келәмгә күчеп, суын быгыртата-быгыртата хур-хур суырды.

Хакимебез аксак икән, дип уйлап куйды илче.

— Әй, шымчы, нәмә иснәнеп йөрисең минем биләмәмдә! — дип кычкырды хаким искәрмәстән генә башын күтәреп, — алдашсаң, бел, башыңны үзем чабып өзәм.

— Хаким, түбәнчелек белән гафу үтенәм, белмәвем сәбәпле, сезләргә ничек мөрәҗәгать итәргә дә кыюлыгым җитми, кичерегез, зинһар!

— Каршыңда — Җидесу дәүләтенең әмире мөхтәрәм Тамерлан![51] Тез чүгеп сәламлә! — дип өзде аны төптән юан ярдәмчесе.

— Мин бөек Алтын Урда дәүләтенең әле генә тәхеткә менгән Абдуллаһ ханның илчесе, — диде Дөрмән мырза, — Моголстан ханы Туглак Тимергә ярлык илтешем. Гамәлебез изге, тоткарламасаң иде, хаким.

Ул бу чатан әмирнең, ни кадәр генә эреләнмәсен, баш кеше түгеллеген аңлап алган иде инде.

Тамерлан бирегә үзен җиһангa таныту нияте белән Сәмәркандтан килеп чыккан макир[52] зат иде. Туглак Тимердән олыс сорады, тегесе үтенечне

[51] Тарихи чыганакларда: Тимерлан, Тимерләнк, Шаһ Тимер, Аксак Тимер.

[52] Макир — мәкер.

канәгатьләндерде. Чөнки башкисәр яугирларга мохтажлык кичерә иде. Соныннан үкенде үкенүен, тик соң иде инде. Баксаң, яугир гади яугир гына булмыйча, бөек Чыңгызхан нәселенең чыбык очы да икән ич. Өстәвенә, гурген, Мөшаһәдә атлы хан кызы белән никахлашкан.

Мондыйлар нәфесле була, алар башкаларга буйсынмый, үзләре буйсындыра — дан-дәрәҗә кортлары.

Озак та үтми, әлеге фаразлар акланды да, Туглак Тимергә, әмир мөстәкыйль Җирсу дәүләте төзеп, Моголстаннан аерылып чыкмакчы, имеш, дигән хәбәрләр дә килеп җитте.

Дөрмән илче шушы астыртын чуалыш вакытына туры килгән иде.

— Байсам[53]* да, ярлыгым да түш кесәмә тегелгән, — диде ул, — бөтен кәгазьләр дә тәртиптә.

Юан адәм хәнҗәре белән илченең яшерен кесәсен ертып төшерде.

Тамерлан аның ышаныч язуларына күз дә төшермәде.

— Бу ялган язу-билгеләрең арт сөртергә дә ярамый, — дип төкрекләрен чәчте, — тиздән Алтын Урдагызның көлен күккә очырачакмын!

— Ми-и-и-ңа нишләргә соң? — дип сорады Дөрмән тотлыгы-тотлыга.

— Сине, шымчы, Газраил көтә, — дип каһкаһәле көлү белән көлде әмир, — ярлык иян Туглак Тимерне дә шул язмыш көтә... кәх-кәх-кәх...

Дала бүреләре Дөрмән илченең үләксәсен ырылдаша-ырылдаша ботарладылар.

**Мисыр.**

Тугача мырзаның юлы уңды. Насретдин солтан аны көттермичә үз катына үткәрде.

— Җанибәк ханның вафатыннан соң эзне суыткан идегез, югыйсә Мамай угланны бик охшатып калган идем, әйдүк, рәхим ит, — диде солтан ачык йөз белән, — без бит якын туганнар, каныбыз бер.

— Мин, галиҗәнап, бәкләрбәге Мамай мырза кушуы буенча килдем дә инде, — диде Тугача илче, — ул Абдуллаһ шаһзадәнең куларкасы иде, тәхеткә дә утыртты. Бәкләрбәге сиңа бүләк итеп, өч ау лачыны, алтын йөгәнле, асыл иярле өч аргамак, булат кылыч җибәрде. Йөз кол-әсир юлда. Тиздән монда булырлар.

— Сөбханалла, Ходай бәрәкәтле хакимлек насыйп итсен, без аларның икесенә дә хәерхаһ булырбыз. Шөкер, Ислам дөньясында лаеклы урыныбыз бар, сүзебез үтә.

— Амин, галиҗәнап!

***

— Йолкырга дип барып, йолкынып кайттыгыз, ә?

Юзекәй үз төртмә сүзеннән үзе кеткелдәп алды.

— Хыянәт, — диде Мамай аклангандай.

— Дошман дустан ярала.

— Хак, дәрвиш, дөрес сүзгә җавап юк.

Юзекәйнең бармаклары дисбе төймәседәй эленеп калды. Чөнки бәкнең тәүге тапкыр аның сүзен җөпләве иде. Бу мосафирны тәшвишкә төшерде. Ник дисәң, максаты җәнабен һәрвакыт пычак йөзендә тоту, тынычланырга, битарафлыкта калырга ирек бирмәү. Хәлбуки, төшенкелек тә, канәгатьлек тә асылда бер бизмәндә үлчәнә. Һәр ике сыйфат адәмне нәүмизлеккә, сүлпәнлеккә этәрә, көрәш юлыннан читкә алып ташлый.

— Ирнең ире ком өемен тау итәр, дигән борынгылар, — дип, ирен

[53] Байса — шәхси тамга.

очыннан яраткан әйтемен очырды. Азрак тоелды, күрәсен, үз сүзләрен дә өстисе итте: «Ә син сәбәп эзлисен, үгезгә мөгез авыр түгел».

Һәм мәсләгенә иреште дә.

Мамай сикереп торды да хәнҗәрен буш түмәргә батырды.

— Әй, син, йолкыш, авызынны үлчәп ач, югыйсә...

Юзекәйнен утырган ташында тузан гына бөтерелеп калды.

Бәкләрбәгенен кара көннәре иде. Иң ышанычлылар арасында йөрткән Туктар угланнын хыянәте аны сон дәрәҗәдә ярсытты. Сарай кулга төште дигәндә генә түбәне белән Мөрид хан ягына чыкты, сөнгесен үзен үстергән, кеше иткән җиһангиры тарафына борды. Көчләр нисбәте кискен үзгәрде. Иң аянычы, бу башкаларга тискәре йогынты ясады, шомланып, икеләнеп калдылар.

Мамай башбаштаклык тирәнгә кергәнче тиз генә төмәнен орыш кырыннан чыгарды.

Ышанычы зур иде. Яуга киткәндә Толымбикәне кочагына алды да, колагына пышылдады:

— Мысыгым, тиздән үзебезнен ятагыбызда ауначакбыз, — диде.

— Унышлы сәфәр, Мамучым.

Толымбикәнен балачагы Сарайның Алтын Таш бистәсендә үтте. Шунда ир хатыны булды, балаларын тапты. Алтын Таш ике көннен берендә төшенә керә. Сагынды ул аны. Иренен бу сүзләре шуна күрә аны бик нык җирсендерде, башын да терәмичә кайтуын көтте.

Мамай бер айдан арып-алҗап, җиде төн уртасында кайтып егылды.

— Мысыгым, мин сүземдә тора алмадым, кичер, — диде.

Толымбикәнен эчендәге бәгыре өзелеп төшкәндәй булды, ләкин сиздермәде.

— Борчылма, Мамучым, бу күнелсез очраклык кына, иманым камил, без үз калабызга әйләнеп кайтачакбыз әле.

— Вәгъдә!

— Хан беләме сон? — дип сүзне икенчегә борып җибәрде ханәкә.

— Чапкын җибәрдем.

— Дөрес эшләгәнсен, белеп торсын илне кулда тотунын ничек авыр икәнен.

— Башка яуларда мин аны үзем белән алып өйрәтәчәкмен.

— Әләм сыйфатындамы?

Мамайнын төксе йөзендә җанлану җепләре кыймылдашып куйды.

— Ханәкә, сина бүрек киеп туасы калган.

Толымбикә иренә килеп сарылды.

— Ул вакытта без кавыша алмаган булыр идек, Мамучым, әле ярый Тәнре кыз итеп яраткан...

Яратышулар да, тынычландырырга тырышулар да баш карачынын янган йөрәген вакытлыча гына баса алды.

Туктар углан ана Нугай якларыннан килеп башын орды. Әле мыек чыгарып кына килә иде. Каты куллы, кырыс йөзле бу яшь егетне беренче караштa ук ошатты. Ул шәхси төмәненә нәкъ менә шундый кыргыннарны җыя иде. Хәтта үз илен ни сәбәпле ташлап китүе белән дә кызыксынмады.

Угланга, дөрестән дә, дәгъва белдермәле түгел иде. Ат өстендә үзен иркен тота, кылычны да, айбалтаны да, сөнгене дә бер үк осталык белән уйната. Күз салдымы, котылырмын димә. Кешеләр белән ачылып сөйләшергә яратмый анысы, авызы йозакта. Шулай  бераздан ул аны унбашы итеп билгеләде. Чөнки яуда телдән битәр батырлык зарур. Шәхси үрнәк әллә нинди алтын сүзләрдән дә өстенрәк. Озак та үтми, йөзбашы вазифасын ышанып тапшырды. Егет бу ышанычын да аклады. Шуна күрә Сарайга

һөҗүм әзерләгәндә дә аңа зур өмет баглады. Угланның түбәне алга-артка карамастан, беренче булып калага атылып керергә, Хан сараен алырга тиеш иде. Хан әсир ителгәч, гаскәр инде каршылык күрсәтми.

Барып чыкмады. Үкенечле хәл. Кәкрене кабер генә турайта диюләре хак икән. Үз йортына хыянәт иткән, чит йортка хәерхаһ була димени?

— Бераз җилләнеп кайтыр идең, — диде Толымбикә, — башыңа «яңа» уйлар да килер иде.

Ул үзе дә нindидер кискен бер фикергә килгән иде булса кирәк, сикереп торды да, атылып тышка чыкты. Аны иярләнгән өч аты, җанатар яугирлары көтеп тора иде.

— Салкын Ташка!

Тояклар дөбердәште. Көн дымык иде, тузан болыты шактый вакыт һавада асылынып торды.

Салкын Таш — хәрби үзәк. Анда орыш серләренә төшендерәләр, кылыч, сөңге, айбалта ише сугыш кораллары белән эш итәргә өйрәтәләр, җайдаклык күнегүләре үткәрәләр. Остаханәләрдә көне-төне ут сүнми, чүкеч тавышы тынып тормый. Җәза корбагы да шунда.

Мамай килү унаенда ук тезгенен шул якка тартты.

— Гарәпшаһ угланны чакырыгыз, — диде ул ияреннән сикерер-сикермәс, — тиз!

Анын каршына кәмшек танаулы, чабата колаклы, табак йөзле кәтәнә углан килеп басты. Угланнар даирәсендә Гарәпшаһ әле яңа кеше. Әмма шушы бер ел эчендә телгә кереп өлгерде инде. «Гәүдәгә — кәрлә, батырлыкта — Алып» диләр аның турында. Хәйләкәр, аяусыз. Тумыштан яугир.

— Ни боерасың, бәк?

— Сез Туктар хыянәтче белән якташлар бит, шулаймы?

Мамай хәнҗәр карашын угланга батырды.

— Ишетүемчә, ул Сарысу төбәгеннән, ә мин Харәзем даласыннан, — диде Гарәпшаһ, җилкәсен җыерып, — аңламадым, монда минем нинди гаебем бар соң?

— Бар, бәлкем, сез ике шымчы сүз берләшкәнсездер?

— Нинди сүз берләшү, бәк. Сарай орышында мин катнашмадым, Мокшы урманнарына җибәргән идең, күп бүләкләр...

— Беләм, — дип кисте бәк, — барыбер турылыклыгыңны дәлилләргә туры килер.

— Баш өсте!

— Туктар хыянәтчене тере хәлендә Салкын Ташка алып кайтасың. Ун көн вакыт бирәм. Үтә!

Әзерлек төркеменә ул яшертен генә шәхси шымчыларны да өстәде. Углан алай-болай икеләнеп калган очракта, усал ният турында әйтеп тә торасы түгел, башын борганчы йөрәгенә хәнҗәр кадалачак иде.

Гарәпшаһ яшертен, качып-посып җай эзләп йөрмәде. Атларын әллүргә генә атлатып, көпә-көндез, нindидер бәйсез дуамаллык белән туп-туры Туктар угланның чатыры алдына килеп туктады. Аларны Мөрдинекеләр дип белделәр, күрәсен, тикшереп-төпченеп торучы булмады. Чөнки хан яугирлары гына үзләрен шулай эре вә өстен тота.

Туктар бәк үзе дә гаҗәпләнүен күрсәтмәде.

— Минем арттан килдеңме? — дип кенә сорады. Аннан: «Мамайча бу, нәкъ аныңча», — дип куйды.

— Бу гамәлгә сине нәрсә этәрде соң, барысы да үзең теләгәнчә иде ич, — дип белеште Гарәпшаһ, — һич аңламыйм.

Туктар иреннәрен кысып, уйга батып торды да:

— Бу минем шәхси фаҗигам, — диде һәм кыска гына аңлатмасын да бирде.

Баксаң, Туктар зур ыру иясе, шаһзадә икән, Сарысу олысы хакиме Тугача әмирнең бертуганы. Тугача тәхетен үз улларына мирас итү өчен ошбу дәрәҗәгә хаклы кануни дәгъваче булып саналган бердәнбер энесен көчләп печтергән, ирлек орлыгыннан мәхрүм иткән. Бала юк икән, дәгъваче дә юк.

— Мин сине алып китәргә мәҗбүрмен, — диде Гарәпшаһ, — зинһар, карышма.

— Тиздән Мөрид ханны да ташлап китә идем, — диде углан, — мин бит тәгаен кешегә түгел, хакимлек хакына теләсә-нинди яман гамәлләрдән дә чирканмаучы тәхетерткычларына үч саклыйм. Шулар минем гомерлек дошманнарым. Алда хыянәтләрем күп булачак әле.

Сабак булсын өченгә Туктарны яугирлар алдында, ачык һавада җәзаладылар. Җәзанын иң яманы иде: муенын телеп, саркып торган җәрәхәте эченнән тамырына кыл шудырдылар. Кыл бөгәрләнә, төртелә, кадала. Туктарның авыртудан вакыт-вакыт аңы югалып тора, өзгәләнә-өзгәләнә кычкыргалап та ала. Җәза-бинең тавышы да тоныклана, сүзләре җир астыннан сытылып чыккан кебек кенә ишетелә башлый.

— Антыңны янарт, сатлык җан, антыңны янарт диләр сиңа!

Туктарның теле аркылы килде, теше иренен сытып керде, әмма буш вәгъдә бирмәде.

Бу көтеп алган үч гамәле Мамайга да канәгатьлек китермәде. Толымбикә янына әвене янган кешедәй төшенке күңел белән кайтты. Толымбикәнең исә, киресенчә, түбәсе күктә иде. Хадимәләренең дә үкчәләре җиргә тими, бүлмә буйлап йөгерешәләр.

— Бәк, сиңа былбыл рәхмәтен житкерде, тәрәзәдән очып кереп җилкәмә кунды, — диде куанычыннан кулларын чәбәкли-чәбәкли, — ниятләребезгә юл ачылыр, Алла боерса, бу бит фәрештәләр кушуы буенча эшләнә.

Соңгы көннәрдә ханәкә яралы былбыл баласы белән мәшгуль иде. Бу мескен кошчыкны ул ата мәче авызыннан тартып алды. Аны төрледән-төрле тасвирламалар куллана-куллана йөз мәртәбә генә сөйләмәгәндер. Берсендә әлеге ерткыч мәче корымнан да кара иде. Бераздан эттән дә зуррак утлы җирән җанварга әйләнде. Әле сары түшне котрык песинең иләктәй олы авызыннан йолып алган, әле элмәкле тырнакларыннан хәнҗәр ярдәмендә арындырган.

Ничек кенә тәрбияләмәде Толымбикә былбылны, кемнәрне генә чакырмады, тәки канат кактырды, рәхмәт төшкере, кошчык бер атнадан чырык-чырык килеп, очып та китте. Бүген әнә анасы мәрхәмәтле коткаручыга рәхим-шәфкатен белдергән.

Мамай сүзсез генә ятакка ауды. Толымбикә кул ишарәсе белән генә хадимә туташларны бүлмәдән чыгарып җибәрде дә ире янына утырды:

— Арыгансың, ахры, мин җүләр чәүкәдәй чәрелдим...

— Теге хәрам ага белән буталып беттем, гаепне хакимнәргә аудара, хыянәтен җинаятькә санамый.

Толымбикә иренең җил ашаган кытыршы йөзен сыйпаштыргалап торды да, үз алдына гына сөйләнгәндәй, уйларын шәрехләде.

— Беләсеңме, Мамучым, Ходай бәндәләрне пар итеп яраткан: ир заты, хатын заты. Вазифалары үзгә, ә асыллары уртак. Бу уртаклык барыннан да элек бер-береңә зарурлыкта чагыла. Ир-егет яудан-яуга йөри-йөри кырыслана, кансызлана, үчләнә. Ерткычка әверелүдән аны кыз-хатынның мәхәббәте саклый. Аллаһы Тәгалә кыз-хатынга әнә шундый илаһи көч насыйп иткән. Былбыл-ана да моны исбатлады. Хатын-кыз кочагында ир-

ат камыр хәленә керә, үз асылына кайта. Туктар шаһзадә ошбу бәхеттән мәхрүм ителгән. Аның үче дә хак үч.

Мамай хатынын хупламады да, каршы да төшмәде. Иртәгесен исә туры Салкын Ташка юнәлде.

— Туктар угланны ирекккә чыгар, — диде сакбашка, — аның яшәрлеге барыбер юк инде.

— Углан, качкан...

***

«1363 ел, август аеның 22нче көне. Кенәз Дмитрий Иоаннович Московский хәзрәтләре таң белән күп бүләкләр төяп, Мамай мырзага шәрәфле үтенечләрен житкерергә чыгып китте», — дип теркәп куйды елъязмачы дәфтәр сәхифәсенә. Аннан соң үз алдына, үсмер генә бит әле, сүзе үтәрме икән дип борчылгандай итте.

Атасы Иоанн-II вафат булганда Дмитрий әле тугыз яшьтә генә иде. Аннан алда гына Сарайда Бирдебәк ханны үтерделәр. Шул сәбәпле, ул Толымбикә ханәкә житәкләгән угланнар мәктәбен ташлап китәргә мәжбүр булды.

Мәскәү Дмитрийны тәхет варисы дип саный иде. Ләкин Мөрид хан олуг кенәз дәрәжәсенә Владимир башлыгы Дмитрий Константиновичны лаек дип тапты. Бу дөреслеккә дә туры килә иде. Ник дисән, ошбу кенәз Иван Калита оныгына караганда Ярослав-II икенчегә бер буын якынрак тора иде. Алай да Дмитрий дәрәжә өчен көрәшергә ният итте. Иң әүвәл гаскәр жыеп, көндәшен Владимирдан куып чыгарды. Аннан соң Мөрид хан каршына барып тезләнде. Хан бу юлы яшь кенәзнең үтенечен канәгатьләндерде. Аның үз мәнфәгатьләре: урысларны Мамай мырзага каршы котырту, көчсезләндерү.

Дмитрийга, киресенчә, әлеге вәзгыять күпкә файдалы. Ханнарның ызгышында аның эше юк, ә менә ярлыкларын алу хәлне күпкә жиңеләйтәчәк. Бу — бер. Икенчедән, монысы, мөгаен, иң мөһимедер, кенәз елдан артык Мамай мырза өендә яшәде, улы Мансур белән чын дуслар иде. Ә ханәкәнең йомшак куллары анасыныкына биргесез иде.

Янә дә бер касәфәт, Мөрид хан кулыннан соң килдең дип тәртәгә типмәсме бәк? Икенче яктан алганда, Мөрид ханның ярлыгын санламау булып чыга лабаса бу.

Дмитрий озын юл буе шушы хакта баш ватып барды. Әмма очрашуның тәүге мизгелләре үк бу шик-шөбһәләрне чәлпәрәмә китереп ташлады. Сагынышканнар икән. Туганнар кебек кочаклашып күрештеләр. Беренче атнада ул үзенең олуг кенәз икәнен дә онытты. Мансур белән сөйләшеп-гәпләшеп тә, уйнашып-шаярышып та туймадылар. Даланың матур чагын күргәне булмаган икән. Югыйсә бу кырыс дөньяның һични белән дә алыштыра алмастай үз гүзәллеге бар. Беренче көнне алар ат менеп бил яздылар.

— Әйдә, кояш артыннан барабыз, кайтканда айга эленеп кайтырбыз, — диде Мансур, — без бәләкәй чакта шулай уйный идек.

Көн аяз иде. Офык читендә генә ара-тирә кичәгедән сүнеп бетмәгән эссе дулкыннар кузгалып-кузгалып ала. Күзне тоткарлардай башка һичнәрсә юк. Унга карасаң да дала, сулга карасаң да шул ук күренеш. Атларның йөреше дә сизелми, әйтерсең лә бер урында таптаналар.

Капылт кына каяндыр артын тункайтып, бер куян килеп чыкты һәм бу чиксез манзара үзгәрде дә куйды.

— Тезгененне бушат! — дип кычкырды Мансур.

Чабышкылар алга ыргылды. Куянкай да житез. Табаннары гына ялтырап-ялтырап китә. Тик бу кадәр ишле жайдаклардан котылу бик икеле шул. Ул

моны үзе дә анлый иде булса кирәк, әнә, юл-юнәлешен үзгәртеп, хәйләгә керешмәкче.

— Урап уз да, каршысына төш, — диде Мансур ярдәмче угланга, — мина таба ку.

Хәйлә сонарды, озын колак камалышка эләгүен сизми дә калды. Мансур бара-барышка бугалагын очырды. Ул нәкъ куянның муенына барып уралды.

— Куйдан ким түгел, кара, түшкәсе мимылдап тора, — дип сыйпаштырды Мансур корбанын, — кунак ашына менә дигән.

Дмитрий куянга күз төшерде. Куркынган мескенем, көзге яфрак шикелле дер-дер калтырана. Кызык, куянның күзе кызыл була икән. Әллә коты чыгудан шулай кызарганмы?

— Хәзер тиресен салдырабыз да, таякка асабыз, — дип хәнҗәрен тартып чыгарды Мансур.

Дмитрийнын карашы инде Мансурга күчте. Дусты шактый үзгәргән, кәлтәфи егеткә әйләнеп бара. Йөзе тоныкланган, күзе житдиләнгән, ияге тәкәбберләнгән. Борын астында кара төкләр дә күренгәли башлаган. Тавышы гына утырып житмәгән, яшь әтәчнеке кебек яшелле-зәнгәрле. Атасына тартып, нықча гәүдәле, көчле куллы булырга охшап тора. Шундый ук кыю, шундый ук тәвәккәл.

— Туганым, жибәрик без бу кыска койрыкны, әллә нигә күнелем ятмый, — диде Дмитрий.

— Куянның буен күр дә калжасыннан түнкәрел[54]* дисен инде, алайса. Ихтыярын.

Даланын кылганнар бөресе абага үләне шикелле ай яктысында чәчәген чыгара икән. Күз күреме житмәс дала иксез-чиксез көмеш дәрьяга әверелә. Аяк астындагы килбәтсез коры кура төнлә белән әкияттәге кебек нурлар сибә башлый. Дмитрий бу гүзәллекне мөкиббән китеп күзәтте.

— Рәхмәт, туганым, мина төнге ожмах күрсәттен, — дип, дустынын кулларын кысты.

Урда күчмә башкаласы үзенә бер могжиза. Калада ни булса, монда шул бар. Йөз кешелек киез өй үзе генә ни тора. Ханның барча даирәсе шунда урнашкан. Тәхет залы да. Тирәсендә төрледән-төрле бихисап кярханәләр тезелешеп киткән. Аларда ат, көнкүреш, аш-су дирбияләреннән алып сугыш кирәк-яракларына кадәр ясыйлар. Һәммәсенен короллы сагы бар. Аеруча акча сугу остаханәсенә игътибар зур. Монда коллар эшли. Бөтенесе чылбырга беркетелгән. Дмитрийга да «Урда» тамгасы сугылган тәнкә бүләк иттеләр. Монда күп нәрсәгә өйрәнеп була икән дип күнеленә беркетеп куйды ул шәһәрчек буйлап сәяхәт кылып йөргәндә.

— Бәкләрбәге мөхтәрәм Мамай мырза Урданы Үзбәк хан тәжрибәсенә таянып кордырды, — диде аны озатып йөрүче Диван-би[55], — Мисыр мәмлүкләре дә карап-танышып китте. Ошаттылар. Үзләрендә дә булдырмакчы.

— Үзбәк ханнан калган жиһазларны да файдалангансыз, алайса? — дип белеште Дмитрий.

— Безнен шәһәрчек өр-яна жиһазлардан, өр-яна ысуллар белән күтәрелде.

— Күченү-кору өчен күпме вакыт сарыф итеlә? — дип белешүен дәвам итте Мәскәү кунагы.

— Бер тәүлек!

Дмитрий моңа ышанмады, чөнки ышанырлык түгел иде, шулай да кайтарып та сорамады.

[54] Түнкәрелү — ваз кичү.
[55] Диван-би — дәүләт шурасы рәисе.

Ниһаять очрашуның рәсми тантанасы билгеләнде. Тагын өч көннән, әбәттән соң, аны Абдуллаһ хан кабул итәчәк. Ярлык мәсьәләсе шунда ачыкланачак. Ул көткәнчә булырга ошап тора. Бәкләрбәгенең тел төбе шундыйрак. Ә монда аның сүзе сүз. Ул ни әйтсә, шул була. Толымбикә ханәкә: «Борчылма, кенәз, теләгеңә ирешерсең», — дип ачыктан-ачык әйтте. Аннан соң, озата килгән дьяк-боярлар инде ничә көн баш күтәрми эшлиләр. Сөйләшүләр килгән көнне үк башланды. Бәкләрбәге хәтта салым мәсьәләсендә дә ташламага барырга әзер икәнен сиздергән. Бу бик кулай булыр иде. Чыгымнар күп булачак. Көтмәгәндә Мәскәүне янгын ялмап алды. Изгеләр чиркәвендә чыккан янгын бер төн эчендә каланың үзәген көлгә әйләндерде. Кремль, Посад, Елга арты корылмаларыннан хәрабәләр генә өелеп калды. Аларны хәзер таштан күтәрергә кирәк, агач биналар вакыты үтеп бара.

Абдуллаһ ханны ул бер күз сирпеп карауда күралмас булды.

Дөрестән дә, тәхетенә капчык сыман ишелеп төшкән бу ит бүкәнедәй симез бәндә күркәмлектән бик ерак иде. Өстәвенә, күсә дә икән әле,үрдәк күкәедәй шома ияк очында гына бер-ике бөртек кара төк шәйләнә.

Дмитрий югалып калды, моннан алдагы күңел күтәренкелеге, ышанычөметләре су белән юып төшергәндәй юкка чыкты. Хәтта Диван-бинең белешмә нотыгы да колак очыннан гына очып узды.

— Хан алдында тезләнеп, үтенеч ярлыгыңны тапшыр, — дип пышылдады эшләр башкаручы дьяк.

Хан тәмәке янчыгын ачып, озак кына иснәп торды да, бүлмәне яңгыратып төчкереп җибәрде.

— Әп-тчи...

Даирә беравыздан хуплавын белдерергә ашыкты.

— Йәркәмдихаллаһ!

Шушы ыгы-зыгыдан файдаланып, Дмитрий хан каршына барып ауды, күзен йомган хәлдә алдан ятлаган сәламләү-гозер мөрәҗәгатен тукый башлады.

— Кояш чыгышыннан кояш баешына кадәр булган җирләрне биләүче бөек Байду хан дәүләтенең бөек мәлиге, һәм дә башка вә башка вә башка хөкүмәтләрнең Хакиме һәм дә мәликәнә боерыкчы, шәүкәтлеләрнең шәүкәтлесе, галиҗәнап Абдуллаһ хан, Сиңа Ходай озын гомер вә дә бәхетле яшәеш насыйп кылсын. Мин ошбу зиннәтле тәхетең каршында, аягыңа егылып, түбәнчелек белән гозеремне житкерергә батырчылык итәм. Миңа, Мәскәү кенәзе Дмитрий Иоанн улына, олуг кенәз дәрәҗәсен шәһадәт ит...

— Нинди бүләк алып килдең? — дип, хан янә тәмәке янчыгына үрелде.

— Әп-тчи...

Хан мине тыңламый да ич, дигән сызланулы уй йөгереп узды Дмитрийның башыннан. Һәм күз алдына капылт кына далада аулаган куян килеп басты. Алар арасында бернинди аерма да юк лабаса. Куянкай да чарасызлыктан җиргә сеңеп беткән иде. Ул да хан олтанын ялап ята. Һәр икесе дә залим хуҗаның мәрхәмәтлелегенә өмет итә. Нинди хурлык!? Русия мондый кимсетелүләргә түзеп ятарга тиеш түгел. Куркак куян булып яшәргә ярамый. Берләшергә, көч-куәт туп...

— Бүләгең кайда? — дип ашыктырды хан. — Тиз, әбәт вакытым житә.

Әлхәмдүлиллаһ кынысы асыл ташлар белән бизәлеп эшләнгән зиннәтле бүләк кылыч аның кулына керде. Ошатты булса кирәк, калын иреннәреннән селәгәе тамып төште.

Диван-би Дмитрийның кулына олуг кенәз шәһадәтнамәсен тоттырды.

Ул Мамай тарафыннан алдан ук әзерләнеп куелган иде инде. Беренче котлаучы да ул иде.

— Сүземнән чыкмасаң, шәһадәтнамәң озын гомерле булыр, — диде. — Иелгән башны кылыч кисми.

— Фатихаң вә дә дустанә мөгамәләң өчен чиксез рәхмәтлемен, — диде Дмитрий. Ә күңелендә бөтенләй башка уйлар иде. Һәм алар бәкләрбәгә тоткан кыйблага бөтенләй капма-каршы иде.

Абдуллаһ белән очрашу аны әнә шулай уятып җибәрде.

Урда өчен исә олуг кенәз дәрәҗәсе белән сату итү урыс җирләрен бүлгәләп тотуның бик тә үтемле ысулы ул. Әлеге дәрәҗә өчен кенәзләр бугазга бугаз ябыша.

Олуг кенәз дәрәҗәсеннән көндәше хакына баш тарткан бер генә кеше бар. Бу — Владимир кенәзе Дмитрий Суздальский. Дөрес, тәүге мәртәбәсен күп көч түгеп алган иде. Нияте дә изге иде, Владимирга элекке абруен кайтару. Чөнки Иоанн Калита урыс дәүләтчелеге лексиконына Мәскәү терминын кертте. Олуг кенәз дәрәҗәсен, инде урнашкан кагыйдә буенча, Владимир шәһәрендә рәсмиләштерсә дә, үзәк итеп Мәскәүне сайлады. Митрополит вазифасын башкаручы изге Пётр атакайны да шунда кодалады, аның хөрмәтенә таштан Успения Богоматерь чиркәвен төзетте.

Билгеле, владимирлылар моны авыр кабул итте. Кенәз Суздальский хәлне төзәтмәк булса да, киселгән ипи кыерчыгын кире ябыштыра алмыйсың шул инде. Заманасы да үзгәрде. Мәскәү чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә державачылык символына әверелде. Калитаның оныгы Дмитрийның исем-атына исә Московский иярченен дә тагып куйдылар.

Мөрид хан Дмитрийның Мамай тирәсендә ышкынып йөрүен ошатмады, үзе лаек кылган олуг кенәзлектән мәхрүм итеп, бу дәрәҗәне янә кенәз Суздальскийга багышлады.

Озак тормыйча Мөрид хан үзе дә тәхетеннән очты, Сарай Мамай мырза кулына төште. Ә Суздальский олуг кенәз дәрәҗәсенә мәскәүләр лаек дип тапты. Тик бер шарт белән: кенәз аның яраткан төпчек кызы Евдокиягә никах балдагы кидерергә тиеш. Бу очракта Владимир, Түбән Новгород, Суздаль белән Мәскәү арасындагы низагка зур нокта куелачак.

Дмитрий ике куллап ризалашты. Чөнки зур зәңгәр күзле, озын толымлы, нечкә билле кәләшне бер күрүдә ошатты.

— Бер атнадан туй! — диде ул даирәсенә.

— Галиҗәнап олуг кенәз, һәр гамәлнең үз тәртибе бар, — дип, кияү егетен туры юлга төшермәк итте баш дьяк, — вакыт җитәр, кавышырсыз.

— Әйттем — бетте!

Туй бер айдан зур купшылык вә зиннәтлелек белән Коломна каласында узды. Дмитрийга ундүрт, Евдокиягә унике яшь иде.

***

Дмитрийның хакимлеге шатлык-кайгылар, җиңү-җинелүләр, уныш-унышсызлыклар белән аралашып башланды. Тәхеткә утыруга анасы бөек княгиня Александра вафат булды, бертуган энесе гүргә керде. Мәскәүдәге янгын күпләрнең гомерен өзде, йорт-җирсез калдырды. Әмма иң фаҗигалесе — үләт афәте иде. Башта ул Түбән Новгород, Коломна, Переяславль калаларында күтәрелде. Аннан Ростов, Тверь, Торжок төбәгенә күчте. Бераздан Мәскәүнең үзен дә аяктан екты. Сырхау кагылган бәндәнең йөрәге пычак кадагандай кисәк кенә сызылып уза. Шул мизгелдә бу кайнар ук калак сөяге астына, кулбашы арасына килеп чәнчелә. Авыздан кан килә башлый, тир бәреп чыга, калтырата...

Халык чебен урынына кырылды. Смоленскида афәт өч дулкын булып дулады. Ахырда исәннәрдән нибары биш кеше калды. Алары да шәһәрнең капкасын бикләп, качып китәргә мәҗбүр булды.

***

Витаутас[56] кунак егетен мәгъшукасын күрсәтергә алып барды. Утарлары шәһәрдән читтә икән. Урыны искиткеч матур. Тирә-як ямь-яшел. Үзе җәймә җәйгәндәй тип-тигез. Әлеге тигез яшел аланны көмеш сулы инеш чорнап алган. Нәкъ уртада, эреле-ваклы манараларын күккә терәп, кирмән балкып утыра. Ерактан караганда ул озын томшыклы күл кошын хәтерләтә иде. Кирмәнгә илтүче киң юл инеш янында өзелә. Алда дугадай бөгелгән аермалы күпер.

Атларның тезгеннәрен тартуга, җир тишегеннән генә чыккандай сакчылар пәйда булды.

— Кемнәр сез, ни йомыш?

— Без княгиня Варвараның кунаклары, — диде Витаутас һәм бер кулы белән генә камзулының кайтармасын ачып күрсәтте.

Анда ниндидер алтын билге ялтырап күренеп китте.

Күпернең идәне шыгырдап үз урынына ятты.

— Рәхим итегез!

Витаутас жиргә тәңкәләр сипте.

Мансур мырза мондый мөгамәләгә күнмәгән, хәлбуки, Литвадан чакырткан мөгаллимнәр андагы яшәү тәртибе турында мәгълүмат бирәләр иде. Сөйләү белән күрү арасында аерма зур шул.

Егетнең кыз алдындагы кыланулары гомумән бер кысага да сыймый. Жә, кем кыз-хатын алдында шулай боргалана инде? Хәер, кенәз үзе дә кыз-хатын сынары ич — кылгандай озын саргылт чәче, озынча йөзе, юка иреннәре, кылыч борыны княгиняныкыннан һич тә калышмый. Ир-егеткә чибәрлек килешми. Ул орыш өчен яратылган. Орышта батырлык зарур. Чибәрме син, ямьсезме — бернинди әһәмияте дә юк.

Витаутас, чыннан да, анасы Биритага охшап, чибәр иде. Атасы воевода Кестутис бу сылукайны Пруссиядә бер жиңүле орыштан соң очратты. Һәм эчәк-бавырлары белән гашыйк та булды. Сылукайның исә хәбәрендә дә юк.

— Мин керәстиән кызы, өлешемә тигән көмешем дә жир кешесе булыр, — диде.

— Бармак белән дә кагылмам, фәрештә кебек бер гөнаһсыз гомер кичерерсең, янымда гына бул, — дип ялварды воевода.

— Минем фәрештә кебек гөнаһсыз буласым килми, — диде кыз, — ирем белән сөешеп, балалар табып яшисем килә.

— Теләгең үтәлер, — диде гашыйк егет, киттек чиркәүгә!

Биританың башына көчләп диярдәй никах яулыгы бөркәндерделәр.

Хәзерендә княгиня Кестутис язмышына бик тә рәхмәтле, яраткан гаиләсендә йомырка сарысыдай бәхет эчендә хозурлана.

Мансур йорт хужасы кенәз Гавриилның хәрби кораллар тупланмасын күргәч, яңа дусларын онытты. Ниндиләре генә юк? Кылычлар гына да ике дистәдән артык. Викинг кылычын беренче тапкыр күрүе иде. Алты батман чукмардан да авыррактыр, валлаһи. Үзе алагаем озын.

— Алып батыр яраглары бер якта торсын, — диде исе китеп.

— Викинглар сезнең Алып батырдан ким булмаган, углан, — диде кенәз, — хәзер генә ул халык вакланды. Яшь чакта мин үзем дә ут уйната идем.

[56] Витаутас — тарих басмаларында — Витовт.

Гавриил Аристахович ерак кунакның тупланмасы белән кызыксынуын ошатты, ахры, элгечтән алды да, көмеш саплы бер кылычын ана суздыы.

— Күрәм, углан, син оста орышчы булсаң кирәк, бу бүләгем сина яна җинүләр алып килсен.

Мансур кылычның йөзенә бармак битен ышкып алды. Бүселеп кан саркыды.

— Каным белән ант эчәм, йөзенә кызыллык китермәм, — дип, үз кылычын бушаган элгечкә элде.

— Монысы, кенәз, минем бүләгем, истәлеккә калсын.

— Коллекциямнен бизәге булырдай бүләк, рәхмәт, углан, — диде кенәз, — Дәмәшкъ кылычлары бөтен дөньяда бәһале санала.

Алар кунак бүлмәсенә кергәндә яшь княгиня ниндидер, кеше биеклеге аяклы уен коралында бармак биетә иде.

Далада да бар уен кораллары. Сыздырып кабал сугалар. Мәҗлесләрдә субра ерау кубызга, чалгыга кушылып җыру җырлый. Янә дә думбак кагалар, быргы сузалар. Тик бу аларга бөртек тә охшамаган.

Кызның кулларына күз иярми. Ун бармагы да кыл өстендә, ничек җитешәдер.

Варварага бер күз сирпеп алу белән, сөяк сарае, дигән мөһер суккан иде инде ул. Чөнки кызның нәфислеге, нәзакәтлелеге, шәмдәй туры буй-сыны, кием-салымнары ул корган матурлык калыбына туры килми иде. Матур кыз ул түп-түгәрәк йөзледер, чем-кара кашлыдыр, кап-кара күзледер, озын кара чәчледер, түгәрәк мыймылтык гәүдәледер. Бармаклары кыска-кыска гына симез бармаклар. Ә моныкы ташка үлчим. Үзе сап-сары. Җитмәсә, ир-ат алдында кычкырып көлә, оялу-кыенсынуның ни икәнен дә белми. Аны исә кыз-хатын кеше арасында бозау шикелле юаш, йомык телле булырга тиеш дип өйрәтteләр.

— Минем төпчегем әнә шулай арфада бик оста уйный, — диде кенәз, — яшьли өйрәнде.

Арфа чыннан да монарчы ул кичермәгән ашкынулы сихри аһәң белән мөлдерәмә тулган иде. Княгиня үзе дә үзгәргән. Тәкәбберлеге — назлылыкка, чарасызлыгы — күндәмлеккә әверелгән дә куйган. Кыз-хатын җил өрсә җиде төрле кыяфәткә керә диюләре хактыр, мөгаен.

— Княгиня Варвара синең кәләшеңме? — дип белеште Мансур дустыннан.

— О-о, княгиняның кавалерлары бихисап, — дип тегесе шома гына котылмак иткән иде дә, Мансур төпченүеннән туктамады.

Ахыры шул ачыкланды, кавалерлар арасында мәгъшукка аяк чалырдае берәү генә икән. Ягелло[57] атлы кенәз, яшьтәше.

— Күренекле паннар нәселеннән, — диде Витатутас, — ике ыру арасында гомер-гомергә тәхет өчен көрәш бара. Әлегә без өстә.

— Княгиня җәһәтеннән ниятегез нинди соң? — дип сорады Мансур.

— Бәхәсне рыцарьларча хәл иттек.

— Ягъни...

— Рыцарьларча көч сынашачакбыз. Җинелгән кеше кавалерлык хокукын югалта.

— Менә бу егетләрчә!

Мамай бәк һәм аның улы Мансур Бөек Литва дәүләтенең башлыгы олуг кенәз Альгирдасның[58] шәрәфле кунаклары. Бу ике кәҗүн зат менә өченче көн инде баш күтәрмичә Русиянең язмышына кагылышлы мөһим мәсьәләләрне хәл итү хәстәре турында гәп коралар. Анда ике яшь әтәч

[57] Ягелло — тарих басмаларында — Ягайло.
[58] Альгирдас — тарих басмаларында — Ольгерд.

кан чәчрәтеп чукыша. Илне һәрбере үз йодрыгына йоммакчы. Дмитрий Мәскәүне өстен чыгармакчы, Михаил Владимирның хакын хаклый.

Владимирның элекке кенәзе Дмитрий Суздальскийның үз ирке белән олуг кенәз дәрәҗәсеннән Мәскәү файдасына баш тартуы да, Дмитрий Московскийның Евдокия белән никахы да бу тарткалашны көн үзегеннән алып ташламады. Соңга таба хәтта Суздальский үзе дә еш кына вәгъдәсен бозыштырды. Зур нокта дигәннәре нәтиҗә бирмәде.

Низаг Тверь кенәзе Симеонның үләт чиренә таруыннан соң янә яңа көч белән кабынып китте. Вафат кенәзнең биләмәсен туганы дәгъваләмәк итсә дә, Симеонның улы Михаил үзен кануни варис дип санавын белдерде. Яшь кенәзнең нәфесе моның белән генә чикләнмәде. Төп мәсләге — Тверьга Владимирны кушып, үзен Русиянең олуг кенәзе итеп таныту иде.

Аркаланыр кешең булганда нигә әле куркып торырга? Җизнәсе Альгирдас Бөек Литваның олуг кенәзе ләбаса!

Мәскәү даирәсендә бу, билгеле, зур ыгы-зыгы тудырды. Дмитрий боярларны җыеп, авызыннан бер сүздән гыйбарәт сорау җөмләсен очырды.

— Нишлибез?

Куллар сакалга ятты.

Тәкъдимнәр күп булды. Ахыр чиктә хәйләгә барырга булдылар: кенәз Михаилны алдап-юлдап Мәскәүгә чакырып китерә дә, ниятеннән баш тартырга мәҗбүр итә. Сылтавы да табыла — имеш, дәгъваченең агасы кенәз Йеремий мирас хакында митрополит Алексейга аның өстеннән шикаять язган.

Православие башлыгының сүзе абруйлы сүз. Михаил аны тыңламыйча булдыра аламы соң? Килде ул Мәскәүгә. Һәм шунда ук зинданга да эләкте.

Әлеге башбаштаклык турындагы хәбәр Мамай бәккә дә килеп ирешә. Ул да ашыгыч рәвештә Мәскәүгә Карача атлы илчесен чыгарып җибәрде — Альгирдасның каенише тоткында ятарга тиеш түгел!

Михаил азат ителүгә, туры җизнәсе кочагына атылды. Ә ул бәхәсне чын һиммәт иярәдәй тугрылык белән хәл итәсе урынга, кенәз дигән шөһрәтле дәрәҗәгә тап төшереп, алдау юлына баскан Дмитрийны, һәм дә вәгъдәсез митрополитны тезләндереп кенә калмас, табаннарын ялаттырыр.

Альгирдасның эче пошып, ямансулап йөргән чагы иде. Орыш кырыннан читтә үткән көннәрен заяга саный ул. Андыйлар турында: «Авыз сөте ат өстендә йөреп кибәр», диләр. Яу кырында гына тулы канлы тормыш белән яши. Кулына кылыч алуга, сулышлары иркенәеп, йөрәге гаярь чабышкыныкы кебек ашкынып тибә башлый. Кырык яшенә житте инде, шөкер, әлегә җинелү ачысын кичергәне юк. Кемнәрнең генә башын идертмәде. Тевтон алманнары аның исемен ишетүгә качу ягын карый. Славяннарга да көн күрсәтми. Һич югы дусты Мамай бәк бакчасына булса да таш атып тынычлык ала. Нәтиҗәдә Литва Русиянең көнбатыштагы җирләре, Киев Русе, Белорусь биләмәләре исәбенә күпкә киңәйде.

Аурупада аны хәзер Бөек урыс-литва дәүләте дип йөртәләр. Чөнки халыкның яртысын славяннар тәшкил итә.

Каһәргә дучар булган урыс түрәләре дә Литвада сыену таба.

Каенишенең зарын тыңлап бетерүгә, ул агасы воевода Кестутисны чакыртып алды.

Әй, кадердән кадераным, безне бәдгөман[59] кылма,
Дошманга таба әйләб, дусларга яман кылма,

[59] Бәдгөман — яман уй

Бу серне жиһан кыл, гайре кешегә гаян[60] кылма,
Атамага кылыб мәгълүм, рисваи жиһан кылма.
Безләргә тәрәхим[61] сал, дошманга тоба кылма.

Яу алдыннан олуг кенәзнең теленә әнә шулай сандугач куна. Бу халәтендә ул кәләшен сагынган гашыйк затны хәтерләтә иде.

— Димәк, сәфәр чыгабыз, — диде воевода.

Альгирдасның күнеле әле һаман шигъри дулкында тибрәлә:

Тәңре биргән Тир-салны
Тир чыкканчы менәрмен.
Тәңре биргән тимер тун
Сүтелгәнче киярмен.

Ай катында бер йолдыз
Зәрәдә балкый торганым,
Таң алдыннан чыккан йолдыздай
Яна-яна торганым.

— Бик хуп, — диде Кестутис, — кул кычытып тора иде, берочтан йон кундырып, ганимәт жыеп кайтырбыз.

— Синең шул инде, алтын-көмеш, мал, әсирләр, — диде Альгирдас иренчәк битарафлык белән, — княгиня Мария сынары, ул да һаман туганы Михаил хәстәрен тукый. Ә мин аның көен көйлим...

— Кеше булган кешенең кеше белән эше бар, кенәз, һични эшли алмыйсың, — диде өлкән кенәз, — поэзияң коры кабык кына, ачуың астында калырга язмасын.

Хак, Альгирдас танымаслык булып үзгәрә. Бу яуда аеруча аяусыз булды. Үчле кулына беренче булып Мәскәүнең шанлы воеводасы Симеон Кропива килеп капты. Гаскәр башлыкларын ул гадәттә әсир итми иде. Жиңүчегә ихтирам йөзеннән тез чүгеп, гафу үтенергә генә кирәк. Кропива исә кенәзнең бу дуамаллыгын хәрби чинын түбәнсетү, югары нәсел-ыруын кимсетү дип кабул итте.

— Мин — воевода, мина мыскылга караганда үлем артыграк, — диде.

— Ихтыярың, — диде Альгирдас, иреннәрен кыйшайтып, — мә, ал!

Бер селтәнүдә Симеонның башы жиргә тәгәрәде.

Шул кызудан олуг кенәз урысларның барлы-юклы өч полкын таптап-изеп үтте дә, Мәскәү капкасын какты.

Дмитрий мондый ташкынлы һөжүм көтмәгән иде, шыр жибәрде. Митрополит Алексей атакай, туганы кенәз Владимир һәм дә кайбер башка якын кешеләре белән Кремльгә кереп бикләнде. Тирә-яктагы биналарны жимерергә боерды — янәсе, Альгирдас хәрабә арасыннан аны эзләп йөрмәс.

Кремльдә салкын иде. Яксаң төтен чыга, иске-москыга төренеп, калтыранып утырдылар. Суыкта йокы да алмый бит ул.

— Бәлкем, Альгирдаска илче жибәрергәдер? — дип мөрәжәгать итте Дмитрий даирәсенә, — сез нинди киңәш бирәсез?

— Мин бу тәкъдимне хуп күрәм, — диде митрополит, — нииндидер чара күрергә омтылу үзе үк күркәм гамәл. Ходайның рәхмәте киң, ярдәменнән аермас.

— Литувяй ультиматум куячак, күп алтын таләп итәчәк, — диде Владимир, — бәлкем, халыкны аякка бастырыргадыр?

[60] Гаян — ачык
[61] Тәрәхим — мәрхәмәт

Бу вакытта хәлиткеч һөҗүмне иртәнгә тәгаенләп, Альгирдас йокларга әзерләнә иде. Урыны җылы, көн матур.

Астрология белән шөгыльләнүче раһиб[62] дәфтәренә түбәндәгеләрне теркәде: «Йолдызлар сирәк күренә, Җидегән йолдыз карасу төскә кергән, көннең бозылуы ихтимал. Иртәгә кырга эшчеләр чыгармау хәерлерәк».

Таң җәяүле буран эчендә атты. Тора-бара җил көчәеп, кар өермәсе җиһанны үз кочагына алды. Юка-җиңел киемле литвалылар өчен бу фаҗига иде.

Альгирдас ашыгыч рәвештә камалышны туктатырга мәҗбүр булды.

Алексей атакайның гөманы рас килде, тәкъдир үзе Дмитрийга йөзен ачты. Вәзгыять бермә-бер үзгәрде. Әйтерсең лә кемдер язмыш баскычын астын-өскә әйләндереп куйды.

Альгирдас каенишеннән читләште. Тегесенең ябышкак кебек ябышып ятуы аны ялыктырган иде инде. Мәскәү белән тынычлык Килешүендә Михаилның хәтта исеме дә телгә алынмады. Аның урынына Альгирдас кызы Елена белән кенәз Владимирның никахына ризалыгын бирде. Шул рәвешле дәгъвачеләр туганлашты.

Михаил янә Урда тупсасына барып егылды. Ләкин бу юлы Мамайның чырае төмсә иде.

***

Көндәшләр иртән иртүк очрашырга сүз куештылар. Билгеләнгән урынга килеп җиткәндә, ашыгып килгән көзнең сүрән кояшы кызгылт-сары яфраклар аша башын гына төртеп килә иде әле.

— Кенәз, намус һәммә нәрсәдән өстен! — дип кылычын болгап сәламләде Витаутас орышташын.

— Турылык һәм гаделлек өчен! — дип җаваплады Ягелло.

Шуннан соң арачылар эшкә тотынды. Иң элек һәр икесенә дә алман тәңкәсе кебек чылтыр-чылтыр китереп, корыч боҗралардан теркәлгән көбәләрне кигерттеләр. Башларына бит япмалы шлем кунаклады. Кылыч белән калканны ияргә утыргач кына тоттырдылар.

— Бәйге каршы як җиңелүен таныганчыга кадәр дәвам итә, — диде арачы, — билгесе — кылычлы кулны баш өстенә кую. Кагыйдә төгәл үтәлмәгән очракта, бәйге туктатыла. Кагыйдәгә ризамы?

— Риза!

— Риза!

Мансур яңа дусларына күз төшереп алды. Йөзләре каплаулы, күреп булмый, әмма гәүдәләре җәя җебедәй тартылып сузылган. Чебен кунса да ычкынып китәр иде, шәт. Үзеннән белә, аннан соң тыелырмын димә. Көч сынашу кайвакыт чын орыштан да хәвефлерәк тәгалләнә. Аның башыннан да үтте андый хәл.

«Дала батыры» өчен барган ярышта ул җан дусты Минтимер углан белән туры килде. Шактый озак матавыкландылар. Көчләр тигез иде. Шулай да Мансур хәйләкәррәк булып чыкты. Абынып киткән атлы булды да, җәт кенә көндәшенең күкрәк астына керде. Калганы осталыкка бәйле иде. Ә осталыкка күршегә керәсе түгел.

Тамашачы гөр купты. Үзенең дә шатлыгы эченә сыймый. Дан сукмагын өч тапкыр гына әйләнмәгәндер.

Бераздан аңына килеп дустын кочмак иткән иде дә, суеп ташланган малныкы сыман җансыз гәүдәсен шәйләүгә, йөрәге тота язды...

— Марш!

[62] Раһиб — монах.

Жайдаклар агач куаклары белән камалып алынган озынча тигез аланның икесе ике башына барып басты.

— Пли!

Атлары шәпле иде. Орыш өчен өйрәтелгән җинел сөякле алашалар. Элдерттеләр генә. Егетләр дә җегәрле, уңганлыклары менә мин дип тора. Витаутас буйга калкурак, алга ятыбрак төшкән. Ягелло кечерәк сынлы, ияренә каккан казыктай береккән.

Һәм менә булат кылычлар кисеште. Тирә-якка яугир йөрәген ашкындыручы дәртле чын таралды. Толпарлар да бер басасыга ике басып, орыш унаена җайлашты: әле читкә тайпылалар, әле чигенәләр, әле башка-баш киләләр.

Мансур Витаутасның җинүен тели. Шуна күрә һәр уңышлы селтәнү-кизәнүләренә куанып, хуплау авазлары белән көч биреп торды. Күр, нинди өлгер, көндәшенә сулыш алырга да ирек куймый бит, һөҗүм арты һөҗүм. Кысрыклады тәки. Янә дә бер ыргым һәм дә бәйге тәмам.

— Афәрин!

Ягелло һич көтмәгәндә хәлне үзгәртте дә куйды. Атын читкә борды да, Витаутасның кул унаен бозып, арка ягына төште. Һәм бер кизәнүдә көндәшенең кылычын җиргә бәреп тә төшерде. Юри генә, бәйгедәшенең уяулыгын какшату өчен генә сүлпән булып кыланган икән, төлке.

— Аһ!

Ягелло җинүе хакына тост тәкъдим итте.

— Туташларыбыз — илебезнең зиннәте. Туташларга мәрхәбә!

— Мәрхәбә!

Мансур эчмәде, касәсен җиргә бәрде дә әйтте:

— Мин дә уенга керәм, хәзер минем чират!

Мансур бәйге алдындагы төнне йокылы-уяулы үткәрде. Уйламаганда-нитмәгәндә княгиня Варвара йөрәк итенә шырпы булып калаллды бит, каһәр. Күзен йомуга күз алдына килә дә баса, килә дә баса. Бер кыска гына арада төшләнеп тә алды.

Анасы Толымбикә белән Түгәрәк күл буенда пар аккошларны күзәтә-күзәтә хозурланып йөриләр, имеш.

— Улым, шушы аккош шикелле синең дә парлы булыр вакытың житте, — диде ханәкә, — ул көнне мин түземсезлек белән көтәм.

— Атаем Феодоро грек кенәзлеге хакименең Александра исемле кызын ярәшәбез, ди. Ә минем аны күргәнем дә юк.

— Син княгиня Варвараны үз итәсең булыр, шулаймы?

— Анам, син моны каян беләсен?

— Аналарның күнел күзенә чикләр юк, улым. Мин үзем дә хуплыйм сайланмышынны. Варвара бик сөйкемле кыз. Чибәр. Ана безнең кебек күкрәгән киеребрәк, билен сыгылдырыбрак, тезен ачыбрак, күзләрен майландырыбрак та йөрергә кирәкми. Ходай барысын да тутырып...

Шушы урында дерт итеп уянып китте. Саташу дисәң дә саташу. Нинди күкрәк, нинди тез? Анае шушы мәгънәсез сүзләрне әйтәме соң?

— Углан, синең уенда катнашуын аллан килештерелмәде, шулай булгач...

Ягелло арадашны бүлеп, үзенекен ялгап китте.

— Мин тәкъдимне кабул итәм, тик бәйге безнең кагыйдәләр нигезендә үтәчәк.

— Шартына күнәм, — диде Мансур.

Ягелло үзенең өстен чыгасына тузан бөртеге кадәр дә шикләнми иде. Ә бәйге беренче ыргымда ук тәгәлләнде. Кылычы бер якка, калканы бер якка очты. Мансур үзен дә җиргә мәталдерә ала иде, кенәзне бу хурлыктан бәйге кагыйдәсе генә саклап калды.

Һәр ике кавалер да җинелүен таныды. Ләкин бу һич тә княгиняны яулап алу дигән сүз түгел иде. Сайлау хокукы Варварада: Ягелло белән Витаутас фәкать Мансурга кыз янына барырга комачау гына тудырмаячак. Үзләре дә моннан ары кенәз Гавриилның йортын урап узачак. Вәгъдә — иман. Рыцарь өчен ант бозу үлемгә тиң гөнаһ.

***

— Мөхтәрәм бәкләрбәге, минем уемча, без урысларның эчке хәлләренә кирәгеннән артыграк игътибар бирәбез бугай, — диде Альгирдас иртәнге табын вакытында, — хәмер сасысы сеңгән ялкау вә булдыксыз халык. Хәер, үз көнен үзе күрә алмаган нәселдән ни көтмәк кирәк? Биләмәләрен Скандинавия викингы кенәз Рюрик төенгә төйнәмәгән булса, кыргый көтү кебек чәчелеп беткән булырлар иде. Рюрик үзләрен Киев град...

Ул шушы урынды тотылып калды. Ник дисәң, Киев Урданың авырткан җире иде. Алтмышынчы еллар башында Сарайда кузгалган тәхет зилзиләсеннән файдаланып, Альгирдас, каны кайнап торган яшь воевода, Зәңгәр Су елгасы тамагында Мамайның Кырымдагы таянычлары исәпләнгән Котлыбога белән Хаҗибәк әмирләрнең төмәннәрен тар-мар итеп ташлаган иде. Нәтиҗәдә Днепрның көнбатышы, Днестр һәм көньяк Буг елгаларының төньягына караган Кара диңгез буе җирләре Литвага күчте. Аңа кадәр яулаган Киев һәм Волынь өлкәләренә дә дәгъва бетте. Дөресрәге, Литва аларга Урданың кулы житәрлек түгел дип саный иде.

Бу уйнап кына башланган хәрби сәфәрнең Урда өчен сизелерлек югалту белән тәмамлануында Мамайның бер катнашы да юк иде. Бу ханнар гаебе. Әмма хәзерендә, Алтын Урданың язмышын үз кулына алган дәүләтмән буларак, ул битараф кала алмый иде. Шуңа күрә мәсьәләне кабыргасы белән куйды.

— Ул җирләр Урданыкы, һәм Урда анда кайтачак!

— Аннан соң ничәмә-ничә ел фасылы гына алышынды, бәк, элекке хәлләргә әйләнеп кайту инде мөмкин түгел, — диде кенәз, — килешүнең башка юлын табу мәслихәт булыр.

— Ягъни мәсәлән...

— Без ясак түләргә риза.

— Керемнең уннан бер өлеше.

— Биштән бер...

Ахыр чиктә жидедән бер өлешкә килешеп, кул суктылар.

Чынлыкта бу Урданың үз көчсезлеген тануы иде.

Әлеге табын вакытында Мамай тирәнгә кереп тормады, «Киев град»ны да ишетмәгәнгә сабышты. Әңгәмәдәшен үзе чеметеп алуны мәгъкуль күрде, бугай.

— Альгирдис «хәмер сасысы сеңгән ялкау вә булдыксыз» урысларның берсенә кызын никахлаган икән дигән сүзләр дә йөри бит, — диде.

Ата кешенең ияге очлаеп, алга бәреп чыкты.

— Гафу, бәк, беренчедән, кенәз Владимир Андреевич олуг кенәз Дмитрий Московскийның якын туганы. Алар Рюриклар токымыннан. Икенчедән, кыз бирү һич тә дәүләт бирү түгел. Дәүләт мәнфәгатьләре барысыннан да өстен. Мәскәүгә элек ничек яу чапкан булсам, моннан ары да ул туктамаячак.

Мамай инде күптәннән учларында уйнаткан бүксәдәй кабарынкы бәллүр касәсен иренәнә дә тигезмичә өстәлгә куйды.

Табынчы җәт кенә аны икенчесе белән алмаштырды. Кунак монысына да кагылмады.Башланган сүз арасына хәмер кертәсе килми иде, ахры.

— Син, кенәз, барыбер сандал белән чүкеч арасында. Бер якта Михаил,

икенче якта — Дмитрий. Бу икебез өчен дә уртак чир. Әйдә, ачыклыйсын хәзер үк ачыклап бетерик.

— Кунак хужанын сандугачы, ди литувяйлар, ризамын, бәк.

— Ә бездә: «Кунак хужанын ишәге», — диләр, литувяйлар мәрхәмәтлерәк икән.

— Кунагына карап инде...

— Рәхмәт.

— Мин яхшы анлыйм, — дип дәвам итте Альгирдас, — безнең һәрберебезнен үз мәнфәгате, үз сере, үз хәйләсе бар. Русия мөнәсәбәтендә уртаклык мөгаен зуррактыр. Турысын гына әйт әле, өстенлекне син кемгә бирәсен, Дмитрийгамы, Михаилгамы?

Мамай, ниһаять, шәрабен эчеп куйды. Озак кына тәмен татып торды да:

— Мина шушындый әчкелтем шәраб ошый, — диде.

— Бу җәһәттән дә зәвыкларыбыз туры килә икән, мин бик шат.

— Русия кенәзләрен бәяләүгә дә кагыла дип беләм әлеге ачышынны — диде Мамай, — мин ул ике кенәзне бер дилбегәдә тотам: бер башында Дмитрий, икенче башында — Михаил. Берара Михаилга якты йөз күрсәтеп алдым. Ике мәртәбә олуг кенәзлеккә ярлык бирдем.

— Бу мәрхәмәтлегеннән файдалана гына белмәде, — дип сүз кыстырды Альгирдас.

— Хак, кенәз, теле шома, гамәле — кәй. Дмитрийда икенче чир — минминлеге бугазына утырган. Үзен Калитадан да өстен саный башлады. Хәтта берара минем сүзгә дә колак салмас итенде.

— Эт симерсә, иясен тешли, ди, бу шул инде.

— Мин ул фырт егетне улым кебек якын күрәм бит, кенәз. Мансурым белән бергә үстеләр. Ханбикәм дә Дмитрий дип үлеп тора. Тик, үзен әйтмешли, дәүләт мәнфәгатьләре барысыннан да өстен.

— Хәзерендә олуг кенәз ярлыгы кемдә сон?

— Монда килер алдыннан гына Дмитрий бусагама аркылы ятты. «Менә мин каршында басып торам, бәк, гомерем сиңа кирәк икән, ал, фәкать ярлыка гына», — ди. Күзендә яшь. Мансур да йоммай түгә.

Дмитрий, әлбәттә, бәкләрбәгенең үзен яратканын белә иде. Шуңа исәп тотып чыгып китте дә инде ул Урдага. Мин сындыра алмасам, Мансур углан, Толымбикә ханәкә булышыр, дип өметләнде.

Мәскәүләр яраткан кенәзләрен курку хисе белән озатып калдылар, һәммәсе пошаманда иде, ышан син басурманнарга. Митрополит Алексей өч көн, өч төн догага талды.

Шомны табигать шаукымы да көчәйтте. Нәкъ шушы көннәрдә кояшта кадакка охшаш кара төрткеләр хасил булды. Шуннан сон җиһан томан эчендә калды. Томан шулкадәр куе иде ки, биш-алты адымнан кешенен йөзен аеру мөмкин түгел иде. Кошлар оча алмас хәлгә килде, хайваннар көтү-көтү булып җиргә елышты.

Ике ай чамасы дәвам иткән әлеге мәхшәрдә болын-кырлар шакырдап кипте, яфраклар коелды, елгалар корыды, мал-туар кырылды. Юллар баскынчылар белән тулды. Ачлык башланды.

Халык бу бәла-казаны олуг кенәзнен бәхетсезлегенә юрады. Димәк, явыз Мамай аны кичермәгән.

Урдада исә барысы да әйбәт иде. Дмитрийның көннәре сый-хөрмәттә, кәеф-сафа эчендә үтте. Жариянен дә колындай яшен, чибәрен, татлысын, уттай кайнарын таптылар. Шуңа күрә кенәз вакыт агышын сизмәде дә, әле кузгалырга да уе юк иде.

— Дмитрий, ярлыгың әзер, илеңдә дә юксыналардыр, — диде Мамай, — ханәкә сүзенә карама, ул сине бөтенләй җибәрмәс иде.

Аңа кадәр ир белән хатын фикер алышканнар иде инде.

— Дмитрий моннан ары Урдага җайсызлык китермәс, — диде Толымбикә, — яшьлеген исәпкә алып, ташламалар ясасаң да урынлы булыр иде.

— Ясакны киметербез, ә менә бөтен урыс кенәзлекләрен Мәскәү башлангычында тупларга омтылуы ошап җитми.

— Ни өчен?

— Урыс кенәзләре дә Алтын Урда ханнары кебек үк монафыйклар, азгыннар, үчлеләр, көнчеләр...

— Минемчә, аларның ызгыш-талашы безгә кулай гына, бәк.

Әңгәмә өзелде, чатырга Дмитрий үзе килеп керде.

— Яхшылыкларыгызга яхшылык белән генә җавап бирергә сүз бирәм, — диде, — дәхи дә бер үтенечем бар: монда дәгъвачем кенәз Михаилның улы Иоанн тоткынлыкта ята дип ишеттем. Бурычы бар, имеш.

— Атасының бурычы, — дип төзәтте Мамай, — акчасын түлә дә алып кит, бер-бер файда чыгармак итәсең булыр. Син шул максаттан кызыксынасың да инде, билгеле. Астыртын вә үчле кеше син, олуг кенәз.

Дмитрий иртәгәсен кайтыр юлга чыкты. Алар башка күзгә-күз очрашмадылар.

***

— Инде аз-маз җилләнеп алу да зыян итмәс, — дип урыныннан торып басты Альгирдас, — сине сюрприз көтә, бәк, кузгалдык. Бер очтан калабызны да күрерсең.

Мамай Вильнюсны ошатты да, ошатмады да. Йортлары ике-өч катлы, таштан өелгән. Бигрәк тә чиркәүләре күркәм, кабырга-увыклары челтәр-челтәр, эче-тышы бизәккә төренгән, зур-кин тимер ишекләр. Матур, бик матур. Шуның белән бергә, сугыш-орыш алдында кала яраксыз. Урамнар тар, кылыч уйнатырга урын юк. Таш җәелгән урамга ат белән керерлек түгел. Тын кысыла, һава җитми.

Альгирдас кунагын хәрби полигонга алып килде. Монда аларны көтәләр иде инде.

Кенәз ике тәгәрмәчле арбага урнаштырылган ниндидер бастырыкка тартым эче куыш тимер нәмәстәкәй янына килеп басты. Шунда гына түгәрәк шарлар өеме, кулларына озын саплы пумала тоткан берничә гаскәри.

— Менә шушы инде сюрприз!

Мамай хуҗага ярарга тырышып булса кирәк, әлеге тимер бастырыкны сыпыргалагандай итенде.

— Ошбу утлы корал туп дип атала, — дип, мәгълүмат бирде кенәз, — алманнар бүләге.

— Хәтерем ялгышмаса, бездә аны утчагыр диләр, хикмәте нидә инде?

— Хәзер хикмәтен күрсәтәбез, — диде Альгирдас, — түбә астыннан күзәтик.

Гаскәри җиһангирларга колакчынлы калын бүрек өләшеп чыкты.

— Колак тонмас өчен, батырыбрак кияргә кирәк.

— Тупны әзерләргә!

Үрә каткан гаскәриләргә җан керде: өйрәнелгән төгәл хәрәкәтләр белән туп авызына түгәрәк шар салдылар, ә берсе учактан пумаласына очкын индерде дә, аны тупның маңгаена тигезеп-тигезеп торды...

Һаваны челлә дуамаллыгы белән күкрәгән күк гөрелтесе икегә ярды. Тирә-якны зәңгәр төтен каплап алды, бүрек астында да колаклар чынлап торды.

Шул ук мизгелдә алдагы корылмада ялкын кабынды.

— Туп якын киләчәк сугышларның патшасы, бүгенге яугирларның ясины, — диде кенәз, куанычын яшермичә.

Мамай сүзсез генә җан сакчысының җәясен тартып алды да, туп атучылар тарафына ике сәрпи ук очырды.

Ике тупчы да киселгән агачтай җиргә ауды.

— Монысы утчагырга ясин, кенәз! Ул хәзер яраксыз тимер өеме.

— Сюрпризым сюрприз булмады, алайса.

— Бу утчагыр коралын мин үзем дә сынап карадым, кенәз. Түмәр дә түмәр, ул да түмәр. Аны каядыр өстерәп алып барганчы, корганчы, артына ут төрткәнче атлы яу орыш кырын өч-дүрт мәртәбә әйләнеп чыга, — диде Мамай, — татарга җинүне житезлек, өлгерлек, тәвәккәллек китергән. Киләчәктә дә шулай булачак!

— Мин барыбер тупны калалар, кирмәннәр өчен булган сугышта алыштыргысыз дип саныйм, — диде Альгирдас, — җайсыз яклары да бар, әлбәттә, син аны исбатлап та күрсәттең инде.

— Мин сиңа, кенәз, тупчыларың бәрабәренә утта янмас, суда батмас бер һиммәтле яугир бүләк итәм, — диде Мамай.

— Кем дип белик инде баһадирны?

— Улым Мансур. Аның Литвада калып, заманча орыш серләренә төшенәсе, ышанычлы ярдәмчең буласы килә. Мин ризалыгымны бирдем. Соңгы сүз — синдә.

— Миңа угланның шәрәфле кавалерлар бәйгесендә өстен чыгуы турында хәбәр җиткергәннәр иде инде. Әгәр дөрес аңласам, кенәз Гавриилга кызы Варвараның кулын сорап, яучы җибәрергә уйлыйсыз, димәк ки.

Мамай килешмәгәнен белдереп башын чайкады.

— Әүвәл орыш кырында егетлеген күрсәтсен әле, шуннан соң кнәгиняны яучылау-яучыламау мәсьәләсен үзең хәл итәрсең. Мин аңа кәләш тапкан идем инде, хәзер баш тарта әнә. Кыскасы, угланның язмышын тулысы белән мин сиңа ышанып тапшырам.

— Бик хуш, бәк, мин риза. Татар яугирларыннан үзенә төмән җыяр. Бу минем хыялым иде.

***

Түрәлек сәнгате мәшһүр дәүләтпәрвәр Чыңгызханнан килә.

> Өченче ләй ни яман? Өздереп чыккан җан яман.
> Түртенче ләй ни яман? Түрәсез көткән ил яман.

Дәүләт тәгәрмәченә таяк тыгучыларга карата ул рәхимсезләрнең дә рәхимсезе булган. Әле япь-яшь чагында ук хан сүзеннән чыккан бер төркем гыйсьянчыны халык алдында житмеш казанга салып кайнаттырган. Күпмедер вакыттан соң тагын нindidер бер кемсә аның күрсәтмәсен шик астына алырга җөрьәт итә. Җәза шулай ук аяусыз. Адәмнең баш сөяген кояшта киптертеп, көмеш кыршауга кигерттерә. Тора-бара ул Темучинның ачуын гәүдәләндерүче скульптурага әйләнә.

Чыңгызхан дәвереннән соң дөнья бик нык үзгәрде. Дөнья белән берррәттән дәүләтнең функцияләрне дә тирән үзгәреш кичерде. Мәсәлән, Чыңгыз мәмләкәтен сугыш тәэмин иткән. Хәзер исә, киресенчә, икътисад сугышны тәэмин итә. Шуңа күрә җиһангирлар да хуҗалык эшләре белән шөгыльләнергә мәҗбүр.

Алтын Урда казнасы нигездә Кырым, Идел буе төбәкләре исәбенә тулылана. Аларда игенчелек, терлекчелек, бакчачылык, һөнәрчелек алга киткән. Бу утрак тормыш өстенлеге. Халык үз көнен үзе күрү белән бергә, базар, алыш-бирешмаксатларында да азык-төлек, кием-салым, төрледән төрле кирәк-яракларны күпләп җитештерә.

Мамай хуҗалык эшенә һәвәс кешеләрен яугирлыктан азат итү кебек кискен адымга барудан да тайчанмады. Урыннардагы вәкаләт ияләренә, мәэмүрләргә[63] ярлык җибәреп, аны «Бик мөһим» дигән мөһер белән рәсми дәүләт язулары кенәгәсенә кертте.

Бәкләрбәгенең салым чүлмәгенә баш тыгуына Абдуллаһ хан үзе сәбәпче булды. Ул берничә аксөяккә Мамай белән килештермичә муаф[64] дәрәҗәсе биргән иде. Ризасызлык белдергәч:

— Ханның шәрәфле боерыгы шәрехләнми, — дип, тешен күрсәтмәк итте.

Мамай сүз көрәштереп тормады, фәкать ханның шәхси казнасын гына үз карамагына алды. Ханның һәр чынаяк чәе дә аерым исәпкә керде.

Муафлар күзгә күренеп кимеде. Баскакларның хокуклары, киресенчә, артты. Алар хәзер турыдан-туры бәкләрбәгенә буйсыналар. Бу идарәгә мөнәсәбәтле чыгымнарның шактый кимүенә китерде.

Шулай да, тулаем казнаның хәле беренче чиратта тышкы сәүдәгә бәйле. Мамайның Литвага сәяхәтендә дә бу мәсьәлә үзәк урынны алып торды. Моның сәбәбе дә җитди иде. Әйтик, соңгы вакытта Италия сәүдә җөмһүриятләре баш бирмәскә маташа. Азактагы Венеция төркеменең кырын эшләре ачылды. Сарай белән элемтәгә кереп, салымга кагылышлы яшерен сөйләшүләр алып бара башлаганнар. Нишлисең, дус булып йөргән консул Корнаро белән хушлашырга туры килде.

Жилгә каршы төкермә, үзеңә тияр, диләр. Икенче көнне үк Венеция илчеләре Мамайга килеп баш орды. Ул да киеренкелекне куертмады, алай гынамы, кайчандыр Җанибәк хан тәгаенләгән салымны бер процентка киметте дә әле.

— Акча таш астында, илче, таш аждаһа башы астында, — диде Мамай эчке бер ишарә белән, — аңладыңмы?

— Аңламаслыкмы соң, аңладым, бик аңладым, бәк, ул аждаһаның тезгене Мамай галиҗәнаплары кулында икәнен дә аңладым.

— Болай булгач, алга таба да эшебез пешәр.

Илчегә һуш керде, хәтта әйтемне шәрехләүгә үк алынды.

— Пешә-пешә таш астындагы акчага ук төшеп җитәр...

Мамайга бу тәвәккәллек ошамады.

— Алай нәфес куа торган булсагыз, азыннан да коры калырсыз.

Илче шым булды.

— Мин сезгә генуялыларга иярмәскә киңәш итәр идем, синьор, — дип әңгәмәгә нокта куйды бәкләрбәге, — үкенергә туры килер.

Алтын Урданың генуялылар белән мөнәсәбәте күпкә алдан башланды. Алар Кырымга килеп тамыр җәя башлауга ук «Ефәк юлы» сәүдәсен үз кулларына алдылар. Алыш-биреш күп, әйләнеш зур, акча керә. Салым кеременең йөздән өч өлешен генә тәшкил итсә дә, Урдага да мулдан чыга иде. Яклар бер-берсеннән риза-бәхил булып, дустанә яшәделәр. Консул Антоний вакытында аралар тагын да якынайды. Ышаныч шундый зур иде ки, Антонийны хәтта Римга илче итеп тә җибәрделәр. Мамай итальяннарда кәеф-сафа корып, күңел ачарга ярата иде. Бу җәһәттән аларга тиңнәр юк. Уен-көлке, сый, жария... Онытылмаслык хатирәләр.

Баксаң, бу чын тормышның күбеге генә булган икән. Хак хәлне белгәч, Мамайның тел күәсе югалды. Чылбырыннан ычкынган усал үгез кебек үкерә-үкерә чатырны пыр туздырды, барча җиһазларны таптап-изеп бетерде.

— Ух-ух-ух...

[63] Мәэмүр — чиновник.
[64] Муаф — салымнан азат зат.

Ухылларсын да, Антоний Каффа[65] белән Солхатны[66] шәхси биләмәсенә әверелдергән, салым түләүне ике мәртәбә киметкән, яшертен исәп-хисапка күчкән, шәһәргә җирле халыкны кертми башлаган. Алай гынамы, Феодоро кенәзе Дмитрийны алдап-юлдап, унсигез авылын үз карамагына алган. Бу инде аерым дәүләт берәмлегенә дәгъва.

— Консулны каршыма китереп бастырыгыз! — дип үзен-үзе белешмичә акырды Мамай.

— Антоний чит мәмләкәт кешесе, дипломатик иммунитетка ия зат, — диде карачы-би.

— Төкерәм мин сезнең дипломатиягезгә!

Толымбикәне дәштеләр. Ул килеп җиткәндә дә Мамай әйбер кыра иде әле. Хатынын күргәч, йөгереп барып кочаклап алды да, үксеп еларга кереште. Ханәкә кул изәп кешеләрне чатырдан чыгарып җибәрде.

— Еларлык тойгыларың бар икән әле, Мамуч, — дип, ирен назлап юатты хатын, — сөендерден.

— Гарьлек бит, Мысык, болай күрәләтә алдаганнары юк иде әле. Ул минем нәсел-ыру биләмәләренә кул сузган лабаса. Кылбөртек әйберсез кала яздык.

— Инде чарасын күр, минемчә, моны Гарәпшаһ угланга тапшыру мәслихәт булыр.

— Мин, бәк, синең кушу буенча Мукшы иленә җыенам, бер-ике атна эчендә хәстәрен күреп бетерермен, — диде Гарәпшаһ, — шуннан да иртәрәк булмас.

Ул бәкләрбәге шушы мәсьәлә буенча чакырткан дип уйлый иде.

— Италиашкалар йөгәннән ычкынган әле монда, — диде Мамай, — башта аларны авызлыкларга кирәк.

— Кирәк икән, кирәк, бәк, минем бурыч нидән гыйбарәт соң?

— Беренче эш итеп Феодоро кенәзлегенең Антоний басып алган авылларын иясенә кире кайтар...

— Солхатны таш коймa белән әйләндереп алырга кирәк, — дип сүзгә кушылды ханәкә.

Мамай җилкәсен җыерып куйды.

— Дала гаскәриләре кирмән төземи димәкче буласың инде, бәк, — диде Толымбикә, — ләкин заманалар үзгәрә, дәүләтнең башкаласы теләсә-нинди көтелмәгән хәлләргә дә әзер булырга тиеш.

— Татарның кирмәне ат, ханәкә, — дип Гарәпшаһ түмәнбашка ярдәмгә ашыкты.

— Углан, вазифаңда бул!

Шунда ук Солхатны таш коймa белән әйләндереп алу турында да фәрман бирелде.

Ханәкәнең икенче тәкъдиме дә бик урынлы иде.

— Без тышкы сәүдәдә Венеция белән Генуя эшмәкәрләренә генә исәп тота алмыйбыз, бәк, урау юлларыбызны булдыру да зарур.

— Мәсәлән?

— Мәсәлән, Литва аша төньяк коры җир сәүдә юлларын үзләштерергә мөмкин булыр иде. Кенәз Альгирдас моны хуплар гына, чөнки сәүдә үзе белән үсеш тә алып килә.

Мамай хатынына яратып күз атып торды. Толымбикә, яшьлек ялтыравыгын җуйса да, әле һаман асыл хатын-кызларга гына хас тылсымлы ымсындыргыч җәлеп итү көчен җуймаган иде. Алтын егач тутый коштай тулыланып торган шома йөзе, сызылып киткән кара кашы, шул кара

[65] Каффа — Феодосия.
[66] Солхат — Иске Кырым.

кашлар астына уелган төймәдәй күзләре үзенә бер сер оясы. Сулыш алганда уйнаклап-уйнаклап торган күкрәк алмалары, юантык гәүдәсе бу килешкилбәткә күркәм ямь өсти иде.

Шушы сөелү өчен генә яратылган мөхтәрәмә затка Ходай акылны да өеп биргән иде.

— Синең урының Алтын Урда тәхетендә, — диде Мамай, — бу иң зур гаделлек булыр.

— Минем янадан туасым килми шул.

***

— Сатып алу бет үтерү, сата белү борча тоту белән бер ул, бәк, җиһангир башың белән нигә шул юк-бар гамәлләргә тыгыласың? — дип гаҗәпләнде Альгирдас, әлеге тәкъдим турында ишеткәч, — бу — тирес кортлары эше.

— Кенәз, мин бит хан түгел, бәкләрбәге, шул тирес кортларының берсе инде, — дип көлде Мамай, — әгәр Львов белән Краков калаларында Алтын Урданың сәүдә үзәкләрен булдыруга фатиха бирсәң, синең өчен бу күңелсез сөйләшүгә хәзер үк нокта куябыз.

— Язуларыңны бир, мөһеремне салам.

Озак еллар буе Үзәк Аурупа белән икътисадый бәйләныш шул калалар аша башкарылды.

***

Абдуллаһ хан йокысыннан уянмады. Кичтән берүзенә бер яшь куй бәрәне белән сыйланып, тулы корсакка яткан иде. Соңгы вакытта туя белми иде ул, алдында ни бар, барысын да сыпырта.

— Бирән сырхавын талымлылык белән генә җиңеп була, — дип табиб туктаусыз тукып торса да, хан нәфесен тыя алмады. Кыяфәте кибәнгә охшап калды. Тыны кысылудан зарлана башлаган иде. Йөрәге озакка тарта алмады мескеннең.

Мамай Литвадан кайтканда җидесен уздырганнар иде инде.

— Бик җайлы хан иде, урыны оҗмахта булсын.

— Яңа хан эзләргә кирәк бит инде хәзер, — диде Толымбикә, — кемне табарсың икән?

Мамайның фикере тәгаенләнгән иде инде, ике дә уйлап тормастан:

— Хан таҗын син киярсең, Толымбикә! — диде ул.

Толымбикәнең төймә күзләре кашларын сындырып маңгаена менде. Керфекләре челт-челт килә, йөзен кисеп, урын-урын дулкыннар сикерешеп алды. Шуннан соң гына керфекләре арасыннан сүзләре сытылып чыкты: «Акылыңдамы син, бәк?»

— Акылымда.

— Мин бит хатын-кыз, танымаячаклар, башыңа бәла алма.

— Бүгеннән синең исемнән акча суга башлыйбыз. Акча йөремсәк ул, танымаган җирдән таныйлар.

Бу чакта башкала Мамай кулында иде. Тиздән Толымбикә ханбикә исеменнән Сарай-әл-Җәдид мөһере сугылган көмеш тәнкәләр алыш-биреш, сәүдә әйләнешенә кереп, бик күп мәмләкәтләргә таралды. Аларны шик астына алучы табылмады. Тәхеткә мөнәсәбәтле каршылыклар булыштырды анысы. Мисал өчен, Бохара әмире бәкләрбәгенә бүләк итеп кыз-хатын киемнәре җибәргән иде. Янәсе, кием-салымлы булдың, инде чәч үстерәсең генә калды.

Мамай боларны Толымбикәгә күрсәтмәде дә, белгертмәде дә. Дәүләт элек ничек яшәгән булса, шул кимәлдә яши бирде. Ихтимал, шулай

дәвам дә иткән булыр иде, Толымбикәнең сырхавы гына әлеге көйләнгән тормышның астын өскә әйләндереп ташлады. Ул үзе теләп тажыннан ваз кичте.

Толымбикәгә эч өянәге ябышты. Мона кадәр дә йомшарып-йомшарып ала иде аның эче. Ләкин озакка бармый иде. «Картыем Тайдула ханбикәгә охшаган мин», — дип көлә иде үзе.

— Тайдуланы урыс рухание килеп дәвалады, чире дә бүтән иде, — диде Сарай табибы, — күреп торасың, синең чиреңә минем көчем житми, башка берәр гыйлем иясен эзләтергә кирәк.

Өянәк ешайганнан-ешая барды. Коса башлады. Хәле күзгә күренеп начарая иде.

— Мине картыем янына жирләрсең, — дип, беркөнне Мамайны һушыннан яздыра язды хатыны.

Һәр Мәжнүннең үз Ләйләсе була. Мамайныкы Толымбикә иде. Шулай, йөрәк ашъяулык түгел ул, аны һәркем алдына жәеп булмый.

— Мысыгым, ышан, мин сине терелтәчәкмен, — диде Мамай ачынып, — үлсәк, бергә үләбез!

— Минем чаң сугылган инде, Мамуч...

— Юк, ялгышасың, ханбикә, сугылмаган әле!

Ишек уемында ябага жиләнен киндерә белән кысып бәйләгән Юзекәй басып тора иде.

Мамай аның аяк астына ауды.

— Алла хакы өчен, мосафир...

Юзекәйнең төсенә төгәнмә кунды, йөзе яктырып китте.

Ул бүген ничектер үзгә иде. Уратмый гына, турыдан ярып сөйләшә.

— Бәрәкалла, бәк, авызыңнан, ниһаять, мөбәһһиж[67] сүз чыкты, мин моны күптәннән көтә идем, — диде, — иншаллаһ, догага да ятарсың.

— Ханбикә үлә анда, мосафир...

— Борчылма, Газраил фәрештә сүземнән чыкмас, тоткарлармын, тик бер шартым бар.

— Сиңа мәгълүм, мин теләсә-нинди шартны кабул итә алмыйм, әмма жәмәгатем хакына шәхси ташламалардан бернәрсә дә тоткарламый.

— Сөбхәналлаһи вә биһәмдихи, алайса, әүвәл пәйгамбәрләр тормышыннан бер хак хикәят тыңла.

**Хикәят.** Аталы-уллы пәйгамбәрләр тау башына житеп тукталдылар. Ибраһим елый-елый улына әйтте:

— Төшемдә сине корбан итеп чалу турында хәбәр алдым, инде шул бурычымны үтәү вакыты житте, — диде.

Исмәгыйль орылып бәрелмәде.

— Аллабыз кушкан икән, мин риза, — дип, васыятьләрен житкерде, туганнары, якыннарына сәламен тапшырды.

Ибраһим, бау белән бәйләп, улын жиргә салды да, бугазын пычак белән ышкып жибәрде:

— Бисмиллаһир-рахман-ир-рәхим!

Ни хикмәт, үткен пычак аны тыңламады. Икенче катында батырыбрак басып ышкыды. Тик бу юлы да пычак суймады.

Өченче тапкырында да шушы ук сәер хәл кабатланды, пычак шуып кына йөри, эчкә үтеп керми.

Ибраһим ачу белән пычагын читкә бәрде.

Шунда пычак телгә килде:

— Син суярга теләрсең ул, әмма бу Аллаһ Тәгаләнең әмеренә туры килми. Мин сиңа түгел, Аллаһуга буйсынуны хак саныйм, — диде.

[67] Мөбәһһиж — кәеф китерүче.

Шул вакытта тирә-якка нур сибеп, җиде кат күк ачылып китте дә Аллаһуның әмере яңгырады:

— И, Ибраһим, төшеңне расладың, минем өчен иң кадерле затны, балаңны корбан итеп китерергә ниятләдең, инде тыңла: Исмәгыйльне исән-сау калдыр, аның урынына куй чал!

Күз ачып йомганчы Җәбраил галәйһиссәлам бер куй сарыгы алып килде. Бу куй, Адәм улы Һабилнең Аллаһуга биргән корбаны булып, җәннәттә Исмәгыйль бәрабәренә ничәмә-ничә еллар буена махсус симертелгән иде.

Ибраһим пәйгамбәр:

— Аллаһудан башка Илаһи зат юк, ул — безнең таянычыбыз! — дип, куйны Исмәгыйльгә тоттырды.

Куйны шунда ук чалдылар.

Әлеге вакыйгадан соң ата белән бала бик тә якынлашты. Мәккә шәһәрендә бергәләшеп Кәгъбән-Шәриф бинасын төзеделәр. Аллаһы Тәгалә аларга рәхмәтле булды.

«Зәмзәм» чишмәсен дә, әле нәни чакта, җиргә тибеп, Исмәгыйль ачкан иде.

— Бу гыйбрәтле хикәятнең мәгънәсе нидән гыйбарәт инде? — дип сорады Мамай.

Юзекәй биштәреннән алып, өстәлгә Коръән китабын куйды.

— Белмәсәң бел, теге вакытта сине үлемнән Исмәгыйль пәйгамбәр рухы коткарды, — диде, — иншаллаһ, җәмәгатеңнең дә саулыгы кайтыр. Мәгънә дигәнебез дә, шарт дигәнебез дә шушы инде, ягъни Исмәгыйль пәйгамбәрнең теләктәшләре мәзһәбенә турылыклы булачагың хакында Коръән тотып ант эчү.

— Җә мәзһәб, җә үлем? Бу бит шантаж!

Юзекәйнең чигенергә исәбе юк иде, аңгәмәдәшен ишетмәмешкә салынып, үз дугасын бөгүен дәвам итте.

— Мәгълүм ки, Алтын Урдада Ислам дине Толымбикә ханәкәнең бабасы утыз ел тәхет тоткан мәшһүр Үзбәк хан вакытында ныклап җәелә башлый, үзе дә намазга баса. Син аның кияве, гурген. Бу үрнәк синең өчен өлге. Монысы — бер. Икенчедән, тәкъвалек карт-коры вазифасы гына дип бик нык ялгышасың. Ислам мескен тәгълимат түгел, кирәк икән, үз мәнфәгатьләрен көч ярдәмендә яклаудан да тартынмый. Җиһад Рәсүлуллаһ заманыннан килә.

— Мин дә намазга басарга тиешме?

— Шәһадә, намаз, ураза, зәкят, хаҗ. Исмәгыйль мөзһәбенә килгәндә исә, ул тугыз баскычтан гыйбарәт. Беренче өч баскычы шигый юнәлешендәге гади дин. Ә син аерым исәптә. Ходай зур язмыш баглый, югыйсә, Исмәгыйль пәйгамбәрне корбаннан азат иткәне кебек, әҗәлеңне кичектермәс иде.

— Мосафир, ханәкәнең хәле авыр бит, — диде Мамай нәүмизләнеп, — көттермисе иде.

И, чалышка каеш, син тимер булсаң, мин — күмер, барыбер сындырачакмын, дип күнеленә беркетеп куйды Юзекәй.

Толымбикә коры чырага калган иде, йөз-бите уңган киндер төсенә кергән, күз төпләре караянулы. Хак, сырхавы ашау-эчүгә бәйле.

— Кешегә — сан, үземә — җан, — диде Толымбикә, — тәкатем тәмам бетте.

— Таң төшкәннән — таң суы, күз тигәнгә — көзән койрыгы, ханәкә, әйт, иң яраткан гөлеңне китерсеннәр әле.

— Яратканым тамчы гөл.

— Бик хуш, — диде мосафир, — гөлгә су сипмәсеннәр, зәгыйфьләнеп, кәүсәсе коры курага калсын.

Кинәшләрен биргән арада Юзекәй биштәреннән таш касә тартып чыгарды. Касә төтен төсендә булып, өслеге сизелер-сизелмәс кенә ниндидер үзгә, тоныкс корычка тартым ялтыравык белән ялтырый иде. Төбеннән югарырак үзеннән чыккан кыршавы да бар. Шактый калын күренә, һич тә көнкүрештә кулланыла торган савытка охшамаган.

— Мин шушы касәгә су салып калдырам, гөл корыган вакытка ул су зөльмәт[68] суына әвереләчәк. Дәвабыз шул булыр.

Ике атна дигәндә гөлнең сабагы корып, ишәк койрыгы рәвешенә керде. Толымбикә дә үзен хәллерәк хис итә башлады, үлән төнәтмәсенен дә файдасы тиде, күрәсең.

Юзекәй үзе, гадәттәгечә, күктән төшкәндәй капылт кына пәйда булды.

— Гөлен кызганычмы, ханәкә?

— Кызганыч булмыйча, суга тилмереп корыды бит, бәгырь.

— Өч көн көтәргә туры килер, ханәкә.

Мосафир касә ише таш кашыктан гөлгә су бөркеде. Ул аны, үзе әйткәнчә, өч көн сугарды. Дүртенче көнне иртән Толымбикә үз күзенә үзе ышанмый торды. Гөл шау чәчәктә иде. Бүрек-бүрек булып шыбырдашып утыралар. Жете кызыл чәчәкләр, әйтерсен лә, шәфәкъ балкышына манып алганнар. Таҗларыннан шып-шып тамчы тама...

— Ходай сина сихри тылсым көче насыйп иткән икән, мосафир, — диде Толымбикә, чын әсәрләнү белән, — нинди зур мөкяфәт[69].

— Гөлен зөльмәт суынын үзенә дә мөштәфа[70] буласын дәлилләде, — диде Юзекәй, ханәкәнен аһ-аһларына игътибар итмичә, — ошбу касәдә жиде кашык су бар, аны тәүлеккә бер мәртәбә жиде төн уртасында эчәргә кирәк. Бу вакытта үчлек, ачу-үпкә, орыш-талаш, ялган, көнчелек ише тискәре гамәлләр тыела. Миһербанлык, ярдәмчеллек, хәер-сәдака файда гына булып беркәчәк.

— Мин бик рәхмәтлемен, мосафир, хәзер табынга рәхим ит, синен хөрмәткә бик затлы ризыклар хәзерләттек. Бүләкләрем дә бар.

Юзекәй сакалын сыпыргалап куйды да әйтте:

— Ханәкә, мин сез туклана торган ризыклардан күптәннән ваз кичкән бәндә. Без дәрвишләр бик аз белән канәгатьләнәбез, жан сакланса, шул житкән. Бөтен көч — суда!

— Минем яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтарасым килә бит, мосафир.

Юзекәй, гадәттәгечә, еракткан суктырды.

— Ябалак кош мактанса, ярдан тычкан тоттым, дир; яман кеше мактанса, яхшынын якасыннан тотып кыстым, дир. Бу хәлгә калудан адәмне Аллаһу гына коткара ала. Кызганыч, кайчак иң хөрмәтле затларыбыз да сукырларча үзләренекен тукыйлар.

— Анладым, — диде Толымбикә, — мин ул затнын күзен ачарга тырышырмын.

*Дәвамы киләсе санда*

---

[68] Зөльмәт — тере су.
[69] Мөкяфәт — бүләк.
[70] Мөштәфа — шифа.



Чыңгыз
Мусин

## ДӨНЬЯ ИРКЕН — ҖАНДА КЫСАНЛЫК

### Имзасыз хат

**Каһәрләгән бер хат алдым бүген,**
**Ләгънәт чәчеп ята өстәлдә.**
**Ләгънәтләргә инде күнеккәнбез**
**Каһәрләнгән илдә үскәнгә.**

**Юкны-барны язып ятасың, дип,**
**Берәү мине каты әрләгән.**
**Әрләнүдән түгел гарьләнүем,**
**Кеше язмышыннан гарьләнәм.**

**Күпме еллар гомер ителгән дә,**
**Күпме юллар иҗат ителгән.**
**Өстәлемдә кара конверт ята,**
**Шуңа бераз күңел кителгән.**

**Усаллыклар эзли берәү миннән,**
**Усал ният булмый иҗатта.**
**Шигъри гамәл — ул бит хис гамәле,**
**Бикләп булмый аны йозакка.**

**Шигъри җанлы, ихлас күңелләрдән**
**Күпләр эзли никтер усаллык.**
**Очар кошлар кебек талпынамын,**
**Дөнья иркен — җанга кысанлык.**

**Өстәлемдә шикле кәгазь ята,**
**Янау сүзе һәрбер җөмләдә.**
**Янаулардан куркып хисләремне**
**Җыенмыйм мин әле җирләргә.**

Чыңгыз МУСИН (1934) – *шагыйрь; «Язмыш узәннәрендә», «Баганалы юллар», «Карт юкәләр яшь чәчәктә» исемле китаплар авторы. Әгерҗе районы Тирсә авылында яши.*

Шигырь язып яткан мизгелем,
Бәйсез минем хисләр тезгенем.
Боек күңелләрне юатырдай
Тылсымлырак сүзләр эзлимен.

Агу чәчеп бирәү хат җибәргән,
Тик куймаган никтер имзасын.
Имансызлар күп шул инде хәзер,
Кем дип атыйм хатның хуҗасын?

## Исте җилләр

Үсте гөлләр, исте җилләр,
Туктамый исте генә.
Исте дә барып бәрелде
Тәмәй тау өслегенә.

Бәрелде дә җиргә төште,
Гөлләрне җилгәрергә.
Тик шулай да нәрсә җитә,
Туган як җилләренә?

Туган яклар аралады,
Җилләрдән, давыллардан.
Зыялы бәндәләр чыкты
Без үскән авыллардан.

Җил-давыллар да кичердем,
Мин сабый чакларымнан.
Сөремле җилләр дә исте
Көнбатыш якларыннан.

Иссен җилләр, тик шулай да,
Булмасын исе генә.
Күңелемдә саф җилләрне
Үз итү хисе генә.

Искән җилләр, иссен, әйдә,
Юлларын бүлмә генә.
Талгын җилләр дәва минем
Тынгысыз йөрәгемә.

## Соңгы күкрәү

Соңгы тапкыр күкрәү узып китте,
Тик бер бөртек тамчы таммады.
Дулап килгән шушы кысыр күкрәү
Җәй айларын көзгә ялгады.

Яр буенда үскән тирәкләрнең
Яфраклары акты елгада.
Өермәле җилләр кузгалды да,
Сары келәм җәйде юлларга.

Күкрәп үскән алтын башакларның
Көлтәләре инде әвендә.

Күпне күргән авыл агаеның
Күңелкәе тыныч хәлендә.

Җәй көненең тынмас шау-шулары
Кабатланмас язга кадәрле.
Кыр казлары кабат алып килер
Язлар җитте дигән хәбәрне.

Их... Күкләрнең соңгы авазлары
Яз китергән назлар түгел сез.
Күкрәүләрне язлар алып килә,
Ә күкрәүсез язлар күңелсез.

Хыялымда мин дә күкрәр идем,
Узды инде гомер еллары.
Йөрәгемдә янган хисләр белән
Шигъриятта күкрәп булмады.

Шигырь язып күкрәп булмыйдыр ул,
Каләм көче җитми аңарга.
Хисләреңне синең кем аңласын
Бу болгавыр кыргый заманда?

Ян син, йөрәк, янып яшәү кирәк,
Кемнәр янар син дә янмагач?
Бушка янулардан ни мәгънә бар
Каләмеңнең көче калмагач?

Их... гомернең гүзәл мизгелләрен
Ядкарь итеп кайда сөйләргә?
Кеше күрке шунда: ана телен,
Гүзәл телен янып сөйгәндә.

Хыялымда сәфәр чыгар идем,
Салкын болытларга сарылып.
Кыр казлары миңа юлдаш булып
Озата барса канат кагынып.

Иж буеның сихри гүзәллеген
Йөрәгемә салып китәрмен.
Кыр казының кауры канатында
Язлар булып кайтып җитәрмен.

Ямьле җәйләр үтте, көзләр җитте,
Юллар тайгак, туфрак катмаган.
Күкрәүләр дә тынды, көннәр дымлы,
Аяз күкне болыт каплаган.

## Үзгәртәсе килә

Хыяллардан күңел, һай, туямы?
Мин юләрдә яшьлек хыялы.
Әкияттәге җәннәт бакчасы күк
Үзгәртәсе килә дөньяны.

Һәр елганың була үз ярлары,
Тормышта бар хакы, ялганы.

Мин дөньяны үзгәртмәкче идем,
Язмыш мине никтер алдады.
Тойгы–хисләремнән аерды да,
Тормыш арбасына ялгады.

Эшләп тапкан ризык тәмлерәк шул,
Үзең корган тормыш ямьлерәк.
Туфрагында гомер сөргәннәрнең
Күңелләре була гамьлерәк.

Әкияттәге җәннәт бакчаларын
Булдырулар кулдан киләме?
Авыл агаеның бар терәге,
Кулларында сәнәк–көрәге.

Бераүгә дә золым теләмәдем,
Изгелектә булды теләгем.
Ходай насыйп иткән гомеркәйнең
Ике килмәүләрен беләмен.

Гомер дигән юллар үтелгән шул,
Без үтәсе күпер сүтелгән.
Еллар мине күпме сынаса да,
Кырыс язмышымнан үкенмәм.

---

## Электрон почта да төпсез түгел


Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнең фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульъязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, жинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянең электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр һ.б.) гына кабул ителә.


Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар жибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.


1991-2010 ЕЛЛАРДА «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫНДА
ДӨНЬЯ КҮРГӘН КАЙБЕР КИТАПЛАР


























БАЛАЧАК ӘДИПЛӘРЕ
БАЛАЧАК ӘДИПЛӘРЕ
БАЛАЧАК ӘДИПЛӘРЕ
БАЛАЧАК ӘДИПЛӘРЕ



ТАТАРСТАН ТАРИХЫ




THE SUN AND THE MOON
LE SOLEIL ET LA LUNE




Татар акылы


Аккош куле -

# ОНЫТЫЛГАН АЛТЫН ЙОЛДЫЗ ИЯЛӘРЕ

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга да 68 ел узып китте. Инде әйтеләсе — әйтелгән, языласы язылган да сыман. Чынбарлыкта, тау-тау китаплар нәшер ителүгә, меңнәрчә мәкаләләр, истәлекләр язылуга карамастан, ачылмаган серләр, ачыкланмаган вакыйгалар һәм дөнья күргән хезмәтләрдә хаталар, төгәлсезлекләр һаман бихисап әле. Татар халкының каһарман улы, легендар разведчик-партизан Даян Мурзинга бәйле материаллар туплаганда андый «ак тап»ларга үзем дә шактый еш юлыктым һәм аларның берничәсен бәян итү кайбер гаделсезлекләрне, төгәлсезлекләрне бетерергә ярдәм итми калмас дип өметләнәм.

Даян ага белән Уфага барып очрашып кайттым кайтуын, әңгәмәбез 90 минутлык кассетага көчкә генә сыеп бетте. Тик менә теманы киңрәк итеп ачу ихтыяҗы туганлыктан, китап кибетләренә һәм китапханәләргә ешрак йөрергә туры килде. Владимир Коневның «Каһәрләнгәннәр һәм онытылганнар» («Прокляты и забыты», М.) дигән хезмәтенә дә китап кибетендә юлыктым. Автор заманында төрле сәбәпләр белән читкә тибелгән, ягъни онытылуга дучар ителгән Советлар Союзы Геройлары турында яза. Суслов идеологиясе хөкем сөргән кырыс совет чорында гына түгел, «демократик» Россия шартларында да «ябык» булып калган теманы күтәрү В.Коневның батырлыгы, әлбәттә.

Билгеле инде, әлеге китапта бәхетсез язмышлары тасвирланган 48 «Алтын Йолдыз» иясе (андыйлар барлыгы 86 кеше) турында Мәскәүдә 1987 һәм 1988 елларда нәшер ителгән ике томлы хезмәттә («Герои Советского Союза». Краткий биографический словарь») берниндй мәгълүмат та таба алмыйсың. Кырыс язмышка дучар булучыларның берсе — милләттәшебез Абдулла Фәйзрахман улы Шаһиев. 1942 елның ноябреннән — 58нче гвардия кавалерия полкында пудемет расчеты командиры (Белоруссия фронты, 7нче гвардия кавалерия корпусы, 16нчы гвардия кавалерия дивизиясе). 1943 елның 3 октябрендә Днепрны кичкәндә күрсәткән батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган кыю старшинага сугыштан исән-имин әйләнеп кайту насыйп була. Тыныч тормышта да үз урынын таба: Төрекмәнстанның Мукмы каласында склад мөдире булып эшли. Тик язмыш сынавымы, әллә сәүдә өлкәсендә, аеруча Урта Азия ягы өчен хас булган мәкергә юлыгуы буламы, 1959 елның 2 гыйнварында социалистик милекне урлауда гаепләнеп хөкем ителә һәм Алтын Йолдызы тартып алына. Ветеран кан түгеп алган дәүләт бүләген кире кайтару өчен нык тырышкан, көрәсең: СССР таралып берничә ай узгач булса да, 1992 елның 3 апрелендә аны Герой исеменнән мәхрүм итү турындагы суд карары юкка чыгарыла. Шунысы мөһим: тарихта башка мондый очрак теркәлмәгән. Якташыбызның ул чакта Төрекмәнстанның Чаршанган районы Тамработ авылында яшәве мәгълүм.

Заманы шундый булгач, А.Шаһиевнең исеме «Безнең якташлар — Советлар Союзы Геройлары» китабының 3нче томында ( «Герои Советского Союза — наши земляки», Казан. 1985.) бирелгән Татарстаннан читтә яшәүче татар геройлары исемлегенә кермәгән. Патриотик темага күп әсәрләр иҗат иткән, саллы мәкаләләр язган Шамил Рәкыйпов та каһарман милләттәшебезне телгә алмый. Әле хәтта Ибраһим Исмәгыйлевнең 2006 елда нәшер ителгән һәм милләт

өчен гаять мөһим булган рус телендәге «Татар халкы Геройлары» («Герои татарского народа», К.) хезмәтендә дә Абдулла Шаһиев атлы Герой юк.

Ни аяныч, Казанда дөнья күргән әлеге ике китапта без Советлар Союзы Герое, генерал-полковник Фатыйх Хәсән улы Чураков исемен дә очратмыйбыз. Әлеге хәрби эшлекле Мәскәүдә чыккан Геройларның кыскача биографик сүзлегенә дә эләкмәгән. Гәрчә «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә (Финляндия. 2003, 758 б.) һәм Нургали Булатовның «Йолдызлы йолдызлар» китабында (Казан. 2000, 188 б.) Фатыйх Чураков күрсәтелә. Гаҗәп тә түгел, чөнки ул 1999 елның 14 маенда ике генерал белән Казанга кайта, Президент Минтимер Шәймиев белән очраша. Аңарчы исеменең серле пәрдә артында саклану сәбәбен фаразларга гына кала. Әнә Стратегик ракета гаскәрләре һәм Космик гаскәрләр институтларында эшләгән, 1974-1984 елларда СССР Кораллы Көчләре Генераль штабының Баш разведка идарәсе (ГРУ) аппаратында җаваплы вазифалар биләгән, профессор, техник фәннәр докторы, генерал-майор Фирьяз Рәхим улы Ханцеверов; Социалистик Хезмәт Герое, Казан «Радиоэлектроника» фәнни-җитештерү үзәге директоры (1962 - 1988) һәм бер үк вакытта генераль конструктор булган (1962 - 1989) Илдус Шәйхелислам улы Мостюков; Мәскәү өлкәсе Истра каласындагы Электромеханика фәнни-тикшеренү институтында генераль директор урынбасары (1965 елдан), «Метеор-2», «Метеор-3» космик аппаратларының баш конструкторы урынбасары (1984 - 1994), «Элкос» космик техника бүлеге директоры, «Метеор-3», «Метеор-3М» космик аппаратлары баш конструкторы Рәшид Салих улы Салихов кебек шәхесләрнең исемнәре дә совет чорында сер итеп сакланды ич.

Шул ук вакытта татар милләтеннән булган Геройлар санын нигезсез рәвештә арттырырга тырышу омтылышларын да кабул итеп булмый. Мисал өчен, «Татар халкы Геройлары» дигән исем белән менә дигән белешмә-хезмәт чыгарган (Казан шартларында бу да кыюлык. Минемчә, әлеге хезмәтнең татар телендәге тулыландырылган басмасы республика хөкүмәте ярдәме белән нәшер ителергә тиеш. Чөнки ихтыяҗ зур. Чаллыда, мәсәлән, бу китапны 560 сумга саттылар) Ибраһим әфәнде Мамадыш районындагы Албай авылында туган Михаил Кириллович Москвинны да үз китабына керткән. Тик авылда керәшен татарларыннан тыш руслар да яши. Москвин — рус милләтеннән. Шундыйрак вәзгыять Минзәлә районының Иске Матвеевка авылында туган (1959 елга кадәр Матвеевка авылы), Бөек Ватан сугышыннан соң атып үтерелгән һәм фәкать Хрущев хакимияткә килгәч кенә акланган Советлар Союзы Герое, генерал-полковник Василий Николаевич Гордов исеме тирәсендә дә куертыла. Бу көндә мөселман татарлар күпчелекне тәшкил итсә дә, Иске Матвеевка рус авылы. Дөрес, әле Пугачев явы чорында да анда гел татарлар яшәгән һәм авылның исеме Кәҗә дип аталган булган. Әмма XVIII гасыр ахырларында бу төбәктәге уңдырышлы туфраклы җирләрне бертуган алпавытлар Матвей һәм Никита Можаровлар сатып ала. Күп авыллардан, шул исәптән, Кәҗәдән дә татарлар куыла һәм алар урынына үзәк губерналардан крепостной крестьяннар күчереп утыртыла. Кәҗәне исә Матвеевка итеп үзгәртәләр.

Аппетит ашаганда килә дигәндәй, И.Исмәгыйлев татар милләтеннән булган Советлар Союзы Геройлары исемлегенә язмыш авырлыкларын күп татыган генерал-майор Петр Георгиевич Новиковны да керткән. Чистай районының татарлар һәм чуашлар яшәүче Югары Кондрата авылында туган милләттәшебез Севастопольне саклаганда зур батырлык үрнәкләре күрсәтә. Әмма авыр яраланып дошман кулына эләгә. Сугыш ансыз гына булмый: 1941-1944 елларда алманнар барлыгы 83 совет генералын әсирлеккә төшерә. Аларның 26сы азат ителеп тикшерү үткәч, армия сафларына кире кайтарыла, 31е дошман белән хезмәттәшлек итүдә гаепләнеп репрессиягә эләгә, ә инде тагын 26сы әсирлектә һәлак була. Милләттәшебез Петр Новиков шул соңгылары арасында. Төрле хата фикерләргә һәм мифларга урын калдырмас өчен, шунысын искәртергә кирәк: әсир төшкән генераллар махсус лагерьларда һәм замокларда аерым тотыла.

Дошман кулында булган 83 генералның язмышы белән Федор Свердловның 1999 елда Мәскәүдә чыккан «Әсирлектәге совет генераллары» («Советские генералы в плену») дигән китабында танышырга мөмкин. Бу кадәр совет генералы әсир төшмәс дип шик белдерүчеләр өчен тагын бер чыганак — «Россиянең хәрби элитасы» («Военная элита России», М., 2010.). Әлеге саллы хезмәтнең редколлегия составында 4 Советлар Союзы Маршалы (В.Г.Куликов, П.И.Петров, С.Л.Соколов, Д.Т.Язов), флот адмиралы И.М.Капитанец, авиация маршалы Ф.Н.Ефимов һәм 8 армия генералы бар. Армия генералларының берсе патриотик рухтагы хезмәтләре өчен тарихчы Марк Солонин һәм хәзер Лондонда яшәүче элекке хәрби разведчик Виктор Суворов (Резун) тарафыннан даими «чукылып» торучы милләттәшебез, Россия Хәрби фәннәр академиясе президенты, хәрби фәннәр докторы, тарих фәннәре докторы Мәхмүт Әхмәт улы Гәрәев. Менә шул хезмәттән бер өзек:

«1941 елның җәй һәм көз айларында 3нче, 13нче, 18нче, 24нче, 28нче, 43нче армияләрнең командующийлары генерал-лейтенант П.С.Пшенинников, генерал-лейтенант П.М. Филатов, генерал-лейтенант А.К.Смирнов, генерал-майор К.И.Ракутин, генерал-лейтенант В.Я.Качалов һәм генерал-лейтенант С.Д.Акимов һәлак булдылар. 5нче, 6нчы, 12нче, 19нчы, 20нче һәм 32'нче армияләрнең командующийлары, генераллар М.И.Потапов, И.Н. Музыченко, П.Г. Понеделин, М.Ф. Лукин, Ф.А.Ершаков, С.В.Вишневский әсирлеккә төштеләр. Сугышның беренче елында барлыгы Кызыл Армиянең 63 генералы әсирлеккә эләкте» (178 б.).

Әлбәттә, Петр Новиковның әсирлектә булуы аның гаебе түгел, фаҗигасе. Ул Власов белән хезмәттәшлек итүдән кискен баш тарта. Сугышта кылган батырлыклары да, һичшиксез, Советлар Союзы Герое исеменә лаек булырлык. Кызганычка каршы, Алтын Йолдыз аңа бирелми. Шуңа күрә андый мәсьәләгә бик сак карарга кирәк. Бу юлны сайлыйсыз икән, татар Геройлары исемлегенә Рейхстагка беренчеләрдән булып байрак элгән өлкән сержант Гази Заһитовны; Чехиядә беренче партизаннар бригадасы оештырып, Гитлерның шәхси дошманына әйләнгән майор Даян Мурзинны; легендар «Катюшалар» командиры, полковник (татарлыгы өчен генерал дәрәҗәсе бирелмәгән) Бари Йосыповны; Гитлерның империя канцеляриясен штурмлаган һәм алган полк командиры, подполковник Идрис Гомәровны (соңыннан полковник), генерал-лейтенант Якуб Чанышевны; әсирлектә җәзалап үтерелгән полковник Хәйретдин Мөҗәйне; һәлак булуы «ачыкланмау» сәбәпле генә «онытылган» генерал-майор Миңлегали Шәйморатовны; кылган гамәлләре белән японнарны американнар белән «чәкәштерү»дә хәлиткеч роль уйнаган һәм Рихард Зорге, Ким Филби, Яков Рейзман, Рудольф Абель шикелле легаль булмаган разведчиклар дәрәҗәсенә ирешкән полковник Исхак Әхмәровны һәм башка бик күпләрне кертергә мөмкин булыр иде. Монда тагын бер нәрсә сагайта. Мөгаен, узган гасырның «шанлы» 90нчы елларында, бүлгәләнгән Коммунистлар партиясенең бер канатын җитәкләүче Сажа Умалатованың «Алтын Йолдыз»лар өләшеп йөргәнен күпләр хәтерлидер әле. Шундый «эшчәнлек» нәтиҗәсе буларак, 1998 елда ике Чаллы вәкиле Умат-Гирей Наурбиев (чечен) – «Социалистик Хезмәт Герое, ә Мирза Габитов (башкорт) «Советлар Союзы Герое» исемнәренә «лаек булдылар». Әлбәттә, ният изгедер. Әмма «Советлар Союзы Герое» исеме СССР Югары Советы Президиумы карары белән генә бирелә, мондый вазифа — дәүләт вәкаләтендә. Аны бозу закон тарафыннан тыела һәм эзәрлекләнә. Җинаять җаваплылыгы турында сүз чыгуга ук, замана «Робин Гуд»лары андый гамәлләрен туктаттылар туктатуын, тик нәтиҗәләре калды. Шул гына. Әлеге ике зат 2007 елда Казанда рус телендә нәшер ителгән «Чаллы каласы энциклопедиясендә Алтын Йолдыз ияләре (237 һәм 66 битләр) дип күрсәтелде.

Төгәлсезлекләр дигәннән, А.Шаһиевнең 16нчы гвардия кавалерия дивизиясендә хезмәт итүенә басым ясауның үз сере бар. 1943 елга кадәр ул 112нче Башкорт кавалерия дивизиясе дип аталып йөри. Ә инде 1943 елның

14 февралендә Югары Башкомандующий И.В.Сталин боерыгы белән «112нче Башкорт кавдивизиясе 16нчы гвардия кавдивизиясе итеп үзгәртелә...» («Слава башкирских конников. «Башкорт атлылары даны», Уфа. 2005 ел, 12 б.). Төгәлсезлек исә шушы дивизиядә 146нчы артиллерия полкы командиры булып хезмәт иткән тагын бер милләттәшебез, Советлар Союзы Герое капитан Шамил Рәхмәтуллин исеме белән бәйле. Аңа бу югары исемне Днепрны кичкәндәге батырлыклары өчен, үлгәннән соң бирәләр. Нindидер сәбәп белән, «Безнең якташлар — Советлар Союзы Геройлары»ның икенче томында (Казан. 1984, 220 б.) герой турында язган автор Л.Ханин Ш.Рәхмәтуллинны 14нче кавалерия дивизиясе полкы командиры дип күрсәтә. Шул хата, беренче чыганактан Мәскәүдә 1988 елда нәшер ителгән «Советлар Союзы Геройлары. Кыскача биографик сүзлек»кә (2 т., 349 б.) « һәм бу гасырда дөнья күргән Ибраһим Исмәгыйлевнең «Татар халкы Геройлары» китабына да ( 80 б.) күчә.

Тагын бер күңелне кырып торган нәрсә — Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган беренче татар кешесе мәсьәләсе. Китаплардан без аның Гыйльфан Батыршин икәнен белеп үстек. Донбасстагы Голубовка руднигында туган (хәзерге Украинаның Луганск өлкәсенә керүче Кировск каласы) отделение командиры, чик сакчысы Батыршин Хәсән күле янында японнарга каршы сугышта күрсәткән батырлыгы өчен 1938 елның 25 октябрендә «Алтын Йолдыз» белән бүләкләнә. Чыгышы белән Саратов өлкәсенең Петров районыннан булган тагын бер татар егете рядовой Кәрим Яһудинга да нәкъ менә Хәсән күле янындагы сугышларда кылган батырлыгы өчен, шул ук көнне бирелә «Советлар Союзы Герое» исеме. Артиллерия дивизионы командиры капитан Яһудин 1944 елда Литва җирендә башын сала, ә майор Батыршин 1947 елда Токиодан кайтканда авиация катастрофасына эләгә. Аларның берсен милләт гел хөрмәт белән искә ала, ә икенчесен белүчеләр – бармак белән генә санарлык. Тарихи гаделлек өчен искәртеп китик: Хәсән күле өчен сугышларда күрсәткән батырлыклары өчен 22 командир һәм 4 кызылармеец 1938 елның 25 октябренда СССР Югары Советы Президиумы карары белән «Советлар Союзы Герое» исеменә (барысы да — беренче йөзлектә) лаек була. Шуларның икесе — татар каһарманнары.

Читкә тибәрелгәннәр димәктән, татар милләтенең кадерле кызы, хәрби очучы, Ватан сугышында иптәшләре арасында Ләйлә исеме белән йөргән Советлар Союзы Герое капитан Ольга Санфированы ничек инде искә алмыйсың ди. Анасы татар булган һәм барлык энциклопедия-белешмәләргә татар булып кертелгән Санфированың якты истәлеге хөрмәтенә ни дә булса эшләндеме республикада? Юк бит! Ярый әле икенче бер татар кызы, Ольга Санфированың ахирәте, Советлар Союзы Герое, өлкән лейтенант Мәгубә Сыртланова исемен Казандагы бер урам йөртә. Әмма бу гына бик аз шул. Әнә, казакълар «Алтын Йолдыз»га лаек булган кызлары Маншук Маметова (исем-фамилиясе Кырым татары дип тора) белән Алия Молдагулованы дан-хөрмәткә күмделәр. Ә без совет чорында да сынаттык, хәзер дә әллә ни мактана алмыйбыз. Уфаны гына күрегез! Шартлатып ике генералга — татар Шәйморатов белән Кусимовка һәйкәл бастырдылар. Бездә исә Маша түти белән Степан агай ачулана күрмәсен дип кан калтырап торалар.

**Рәис ЗАРИПОВ**

## «Китап» дигән товар юл табармы?

*Нурихан Фәттахның архивын барлау, тәртипкә салу белән шөгыльләнгәндә кызык кына бер язма – 1952 елгы рәсми хисап килеп чыкты. «Балтач районында китап сатуның торышы» дип атала. Бу отчетны язган вакытта Нуриханга 24 яшь булган.*

*Отчеттан аңлашылганча, районда ул чактагы китап сату эше канәгатьләнерлек булмаган. Ул заманнардан соң 60 ел вакыт үткән. Кызык, шул ук Балтач районында китап сәүдәсе эше бүгенге көндә ничек тора икән? Отчетта күрсәтелгән кимчелекләр бетерелде микән?*

*Язучы Нурихан Фәттахның хатыны*
**Руфина ФӘТТАХОВА.**

# БАЛТАЧ РАЙОНЫНДА КИТАП СӘҮДӘСЕНЕҢ ТОРЫШЫ

Татарстан ВКП/б/ Край комитеты йөкләмәсе буенча, Татарстанның Балтач районында китап сәүдәсе торышын тикшердем. Командировкада барлыгы биш көн булдым һәм шушы вакыт эчендә Балтач авылындагы Книготорг магазины, аның кешеләре, Потребсоюз, сельпо кибетләре, җитәкче эшчеләр, сатучылар белән таныштым. Миңа бу эштә Балтач ВКП/б/ райкомының агитация, пропаганда бүлеге мөдире ип. Хәсәнов якыннан ярдәм күрсәтте. Балтач районының Бөрбаш авылында булдым, андагы кибет, уку йорты, җидееллык мәктәп белән таныштым. Шулай ук шушы эш буенча сельпо урнашкан Норма авылында булдым, Сасна авылына барып кайттым. Кыскача нәтиҗәләр:

Балтач районының КОГИЗ магазины ике катлы йортның аскы катында урнашкан. Йортның аскы каты таштан. Магазинның эче чиста, җыйнак, төзек. Китапларны тезеп куяр өчен урын җитәрлек, һәрбер төр китап аерым шкафка урнаштырылган. Магазин эче чамача 45-50 кв/м бар. Китап склады шул ук бинада, склад та зур гына, урын күп. Гомумән, китап магазины буенча зарланырлык урын юк.

Книготорг магазины мөдире — Сиражиева Галия. Белеме 4 класслык. Бу эштә 21 ел эшли. Китап сату эшен яратып башкара кебек күренә, ләкин белеменең сай булуы аны бераз чикләнгәнрәк кеше итеп күрсәтә (аның турында алда тагын сүз булыр әле).

Сатучы — Кәримова Сәрвәр, 7 класс белемле, китап сатуда 5нче ел эшли. Бер ягы белән дә күзгә артык чалынмады.

Книготорг магазинының китап сату планының үтәлеше турында отчет.

| | Гомуми товар әйләнеше планы үтәлеше | | Әдәбият сату планының үтәлеше | | Шул исәптән потребкооперация аша сату | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | план | үтәлеш | план | үтәлеш | план | үтәлеш |
| 1951 | 160000 | 180106 | 108000 | 109688 | 35000 | 28898 |
| 1952 елның 4 ае | 41000 | 23741 | 24000 | 9647 | 21000 | 5704 |

Күренгәненчә, 1951 елгы план арттырып үтәлгән. Ләкин 1952 елның беренче квартал планы 50 процент чамасы гына үтәлгән. Моны ип. Сираҗиева, нигездә, берни белән дә аңлата алмады. Ул: «1 апрельдән соң, китап бәяләре төшкәч, әле ныклап эшкә тотынып булмады», диде, әмма бу сүзләр генә план үтәмәүне акларга нигез булып тора алмый.

Магазинда башлыча татарча китаплар. Русча китаплар бик аз. Бу якта бөтенесе дә татар авыллары, русча укучылар күп түгел, булганнары да медицина хезмәткәрләре, рус теле укытучылары. Магазинда политик, авыл хуҗалыгы, Марксизм-Ленинизм классикларының әсәрләре бик күп. Матур әдәбият, балалар әдәбияты буенча яңа китаплар әз. Мәсәлән, мин Татгосиздат 1952 елда чыгарган күп кенә исемдәге балалар китабын күрмәдем, алар әле монда килеп җитмәгән, яки килеп тә сатылып беткән. Матур әдәбият, балалар әдәбияты китапларын халык бик ала. Сатучының, магазин мөдиренең әйтүенә караганда, бу китаплар җитми, Таткниготорг Балтач районына аларны җитәрлек җибәрми. Мәсәлән, К.Нәҗминең «Якты сукмак» китабы унлап экземпляр гына җибәрелгән булган. Бу китапка сорау бик зур. Минемчә, «Якты сукмак»ның 3000 тираж экземплярда гына чыгуы дөрес түгел, бу китапны яңадан бастырырга кирәк. Тагын да магазинда «Намус», «Язгы җилләр», «Алтын йолдыз» китаплары юк. Бу китапларга сорау шулай ук бик зур. Татарча политик сүзлек, татарча Авыл советы председательләре, колхоз председательләре өчен белешмә (справочник) бик кирәк. Татарча комбайннар, тракторлар турындагы китапларга да сорау зур, алар Книготорг магазиннарында юк (тракторлар турындагы китап потребкооперациянең культмаг кибетендә генә бар иде). Магазинда балалар өчен, аерым алганда, мәктәпкәчә яшьлек балалар өчен китаплар бөтенләй диярлек юк. Әйтүләренә караганда, мондый китапларны килү белән үк алып бетерәләр. Магазин эшчеләре, райкомның икенче секретаре ип. Ишмуратов һәм башкалар миңа Ленин биографиясенең (татарча), ВКП/б/ тарихын өйрәнүчеләргә ярдәм альбомнар (татарча) юклыгын әйттеләр һәм бу турыда крайкомга белдерүемне сорадылар. Балтач районында берничә удмурт авылы бар. Удмурт балалары мәктәпләрдә җиде класска кадәр үз туган телләрендә укыйлар. Ләкин районга удмуртча китаплар бөтенләй диярлек килми. Матур әдәбият әсәрләре юк, уку китаплары белән тәэмин итү бик начар. Удмурт кешеләре үз туган телләрендәге китапларны Казан аша берничә мәртәбә соратканнар, ләкин моның нәтиҗәсе әлегә кадәр сизелми. Таткниготорг, күрәсең, аларның соравына бик аз колак сала, әйтергә мөмкин, бөтенләй колагына да элми. Таткниготоргның моңа никадәр җавапсыз караганы бары шушы мисалда гына да ачык күренә: миңа Книготорг магазинында удмурт китаплары дип берничә китап күрсәттеләр. Мин җентекләп карый башладым. Нәрсә? Таткниготорг удмуртча китап дип мордвача, марича китаплар җибәргән! Бит аларның удмуртчамы, түгелме икәнен ул китапларның кайда басылганы буенча да белергә мөмкин иде. Мин Крайком алдына Балтач районына удмурт халкы өчен үз туган телләрендә китап җибәрүне юлга салырга кирәклеген искә төшерергә һәм бу эшнең бик мөһим икәнлеген әйтеп китәргә тиешмен. Әгәр без үз республикабызда яшәүче татар, рус булмаган халыклар өчен аларның үз телләрендә китап кайтармасак һәм әгәр Татарстаннан тыш республика, өлкәләр татарча китап белән ныклап сәүдә итмәсәләр /кызганычка каршы бу шулай да/, моннан нәрсә килеп чыгар иде?

1951 елда мәктәпләрне дәреслекләр белән тәэмин итү дә бик начар булган. Урта мәктәп укучылары күп кенә дәреслекләр булмаган хәлдә укыганнар. Урта мәктәп директоры ип. Закиров һәм Сираҗиева иптәшләр татар әдәбияты (10 кл. өчен), татар класслары өчен дә, рус класслары өчен дә физика (8, 9, 10 кл өчен), рус класслары өчен рус теле китапларының булмавын әйттеләр. Кешенең анатомия һәм физиологиясе, математик таблицалар (логорифма таблицалары) да бөтенләй кайтарылмаган яки бик аз санда гына кайтарылган.

Тагын да, Тукай әсәрләренең 1нче томы, Пушкин әсәрләре (татарча), русча-татарча сүзлек юк, бу китапларга сорау зур.

Книготорг магазины заказлар буенча китап соратып алу эшен алып бара, төрле белгечләрнең сорауларын үти. Кайткан яңа китаплар турында реклама,

белдерү эше бик үк канәгатьләндерерлек түгел, минемчә. Дөрес, магазинның витринасы бар, анда яңа китаплар куела. Ләкин газетага язу, радио аша хәбәр итү — юк. Магазин мөдиренең әйтүенә караганда, алар кайчандыр бу эшне үтәгәннәр дә, хәзер, имеш, радиодан әйтүне тыйганнар. Укучылар конференциясе бөтенләй үткәрелмәгән. Книготорг эшчеләре районда төрле киңәшмә, җыелыш, конференцияләр вакытында китап сату оештырганнар.

Книготоргның бүгенге көндә читтә сата торган киосклары юк. Әйтүләренә караганда, 1 апрельгә, китапларга бәя төшкәнче, андый киосклар булган, ләкин аларны кире җыеп аларга туры килгән, ә хәзергә әле андый киосклар ачып җибәрелмәгән.

## Потребкооперация буенча китап сәүдәсе турында

Балтач райпотребсоюзының председателе — Абдуллин. Китап сату эшенә турыдан-туры сәүдә эше мөдире ип. Садыйков Хан җаваплы. Балтач потребсоюзы буенча дүрт сельпо һәм кырык кибет бар. Кырык кибетнең утыз өче китап белән сату итә. Шул исәптән бер культмаг бар.

Китап сату буенча һәрбер кибеткә план бирелгән, ләкин бу план күп кенә кибетләр буенча үтәлми. Бөтен райпотребсоюз буенча 1951 елны 48 меңлек китап сату планы бары 44301 сумга гына үтәлгән. Бигрәк тә Нурма сельпосы артта бара. Монда 8 меңлек китап сату планы 6500 сумга гына җиткерелгән. 1952 елның беренче кварталы өчен план үтәлеше бигрәк тә түбән. Мәсәлән, Арбаш сельпосы план буенча 2000 сум урынына бары тик 527 сумлык, ә Балтач сельпосы 1500 урынына 600 сумлык кына китап саткан. Тик Янгул сельпосы гына 3000 сумлык планны 2700 сумга үти алган. Райпотребсоюзда аерым рәвештә китап сату мәсьәләсенә багышланган җыелышлар уздырылмаган, китап белән сәүдә итәргә теләмәүче һәм бирелгән планнарын үтәмәүче кешеләргә бернинди чара күрелмәгән.

Сатучылар, сельпо председательләре, райпотребсоюз эшчеләре китап белән сату эшенә бер мәҗбүри йөкләмә итеп кенә карыйлар. Моның шулай икәнен кибетләрдә китапның нинди хәлдә булуы гына да ачык күрсәтә. Кибетләрдә китап өчен аерым шкаф файдаланылмый. Китаплар шкафның берике шүрлегенә генә куелган. Китапларның һәрберсе алучыга күренми, алар кайбер авыл кибетләрендә /мәсәлән, Борбаш, Норма, Балтач авылларында / чүп-чар кебек бер өемгә өелгән. Шунлыктан халыкка кирәк китаплар кеше күзеннән яшеренеп яталар. Мәсәлән, Книготорг магазинында миңа Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» китабы кирәк дип әйттеләр. Книготорг магазины урнашкан шул ук Балтач авылындагы Балтач сельпосы кибетенә кереп, шүрлектәге китаплар белән кызыксына башлагач, бүтән китаплар астыннан ике экземпляр «Язгы җилләр»не «казытып» чыгарырга туры килде.

Кайбер кибетләрдә сатучылар, китап белән сәүдә итү түгел, китапның ни икәнен дә аңламыйлар. Мәсәлән, Борбаш кибетендә сатучы иптәш Габдрахманов Хәбри китапның бәясе кайда язылганны да белми. Книготорг магазинына килгән яңа китаплар сельполар тарафыннан вакытында алынмый. Моның шулай икәнен Книготоргтан китап алу планының үтәлеше генә дә күрсәтеп тора.

Райпотребсоюз системасындагы кибет һәм складлардагы китап саны турында мин бернинди мәгълүмат та бирә алмыйм. Райпотребсоюзның плановик экономисты ип. Касимова, мәгълүматләр бирергә берничә көн ышандырып килсә дә, мин Балтачтан Казанга кайтып китәр көн җиткәч тә, алдан кисәтеп куюыма да карамастан, сәүдә эше буенча мыштым гына Казанга китеп барган. Мин, нигездә үз эшем беткәч, Касимованың Казаннан кайтканын көтеп тора алмадым.

Балтач райкомы подписка буенча Ленин-Сталин әсәрләрен тарату эшендә Книготорг магазинына бик күп ярдәм иткән. Ләкин гомумән районда китап сәүдәсе буенча, әйтергә кирәк, райкомның систематик эшләве күренми. Райком 1951 елда китап айлыгы вакытында сентябрь аенда гына дүрт,

ноябрьдә өч мәртәбә китап сәүдәсе буенча бюро җыйган, киңәшмәләр үткәргән. Ә бүтән айларда һәм 1952 елның беренче кварталында бер генә утырыш та, бер генә җыелыш та уздырылмаган. Бу хәл райкомның районда китап сәүдәсенә һәрвакыт игътибар итәргә, айлыклар вакытында гына шау-шу ясап калмаска тиешлеген күрсәтә.

Китап сәүдәсе буенча райисполком 1951 елда да, 1952 елда да бер генә утырыш та үткәрмәгән. Райисполком председателе ип. Галиев киләчәктә эшне җайларга вәгъдә итүдән башка берни дә әйтә алмады.

## Союзпечать буенча

Союзпечать буенча миндә бернинди тулы мәгълүмат юк. Матбугат таратуга җаваплы кеше өйдә юк, отпускага чыккан иде, ә ул бөтен кәгазьләрен, документларын бикләп киткән булган. Балтач элемтә бүлеге мөдире ип. Ибраһимовның әйтүенә караганда, Союзпечать үзенең планын бөтенләй үтәмәгән, анда эш бик начар тора, киоскалар, штаттан тыш сатучылар юк.

Мин 15 майда райпотребсоюзның сельпо председательләре белән булган киңәшмәсендә катнаштым. Монда, бүтән эшләр белән бергә, китап белән сәүдә мәсьәләсе дә тикшерелде. Шул ук көнне кич райкомда, ип. Хәсәнов һәм райпотребсоюз председателе Абдуллин, дүрт сельпо председателе, Книготорг магазины мөдире Сираҗиева һәм райисполком вәкиле, элемтә бүлеге вәкиле, культура-агарту учреждениеләре мөдире катнашлыгында тагын бер киңәйтелгән утырыш булды. Бу утырышта Балтач районында китап сәүдәсенең торышы, сельполарда китап сатуны яхшырту һәм райпотребсоюз белән Книготорг магазины арасындагы аңлашылмаучылыкларны чишү мәсьәләсе тикшерелде.

Сельпо председательләре һәм ип. Абдуллин потребсоюз буенча китап сатуның начар торышында башлыча Сираҗиеваны гаепләргә тырыштылар. Аларның әйтүенчә, Сираҗиева сельполарга бары тик иске, халык арасында сатылмый торган китапларны гына бирә, ә яңа кайткан китапларны башта үзе сата яки бөтенләй бирми. Сираҗиева шулай ук сельполарга дәреслекләр бирүгә дә каршы булган. Мәсәлән, Янгул сельпо председателе Камалов Книготорг магазиныннан үзе теләгән матур әдәбият китаплары, дәреслекләр алуда Сираҗиева ягыннан зур гына каршылыкларга очраган, райком аша гына үз теләгенә ирешә алган. Ип. Сираҗиева дәреслекләрне бары тик үз магазиныннан гына сатарга теләгән, сельполар исә дәреслекләрне үзләре сатарга телиләр. Монда, бер яктан, Сираҗиеваның үз интереслары өчен совет сәүдә кагыйдәләрен бозуы күренә. Ләкин, икенче яктан, потребсоюз кешеләре барлык китап сәүдәсен бары тик дәреслекләр белән генә сату итүгә кайтарып калдырмакчы булалар. Һәм, шуңа күрә, потребсоюз белән когиз магазины арасында үзеннән-үзе бер-берсенә карата дөрес булмаган мөгаләмә туган. Монда, чынында, дәреслекләр өчен генә тарткалаш килеп чыккан. Уку йортларын китаплар белән тәэмин итү мәсьәләсендә дә шундый ук хәл. Бу эштә сельполар приоритетны үзләренә, ә когиз магазины үзенә алмакчы булган. Нәтиҗәдә, халык арасында чын-чынлап китап белән сату итү урынына мәктәпләрне дәреслекләр, ә уку йортларын матур әдәбият белән тәэмин итү турында гына сүз барган. Сираҗиева сельполарның китап алу планын үтәмәүләренә каршы дөрес чара күрү юлына басмаган. Ул Казан оешмаларына сельполар өстеннән жалобалар җибәргән, ә үзе потребсоюз белән уртак тел табу өчен бармак та селкетмәгән. Сельполарда китап сәүдәсенең торышы мәсьәләсен райисполком яки райком каршына куярга башына килмәгән. Ә потребсоюз председателе Абдуллин шулай ук Сираҗиева белән уртак тел табу турында уйлап та карамаган. Аны китап белән сәүдә итүгә караганда магазинда икмәкнең дөрес сатылуын тикшереп тору ныграк кызыксындырган.

Утырышта сельпо председательләре һәм ип. Абдуллин 1952 елның 2 кварталында китап сату планын тулысынча үтәргә һәм киләчәктә китап белән сәүдә эшенә нык әһәмият итәргә, ә Сираҗиева сельполарга китаплар, дәреслекләр җибәрүне берсүзсез үтәргә сүз бирделәр.

## Татарча китаплар белән сәүдә итү турында минем кайбер фикерләрем:

Татар халкы арасында татарча китаплар белән сәүдә итү, аларны укучыга җиткерү мәсьәләсе мине күптән кызыксындыра. Билгеле булганча, Татарстаннан тыш республика, өлкәләрдә татарлар бик күп яши. Аларда татарча мәктәпләр, институтлар, китепханәләр, уку йортлары бар. Бездә китап сәүдәсе турында сөйләгәндә бары тик Татарстан территориясен генә күз алдында тоталар. Бу караш дөрес түгел. Без үзебезнең китапларның бүтән өлкәләрдәге укучыларына барып җитүе белән а е р у ч а кызыксынырга тиешбез. Татарстаннан тыш авыл, шәһәрләргә татар китаплары бик авыр барып җитә. Хәтта күрше республика, өлкәләрдә сатуда татарча китаплар әз. Китепханә эшчеләре еш кына китап алу өчен Казанга үзләре киләләр яки Татарстан территориясенә чыгып алалар. Бу бер дә нормаль хәл түгел. Бит дәреслекләр Союздагы бик күп мәктәпләргә тарала. Аларның тиражы да зур — 50-100 меңгә җитә. Ә без Татарстанда 3000-5000 тиражлы китаплар да сатып бетерә алмыйбыз. Монда капма-каршылык килеп чыга. Татарстаннан тыш татар укучылары татарча китапка интегәләр, сусыйлар, ә Татарстанда санаулы китаплар да складларда ята! Татарча китаплар белән сәүдәне дөрес оештырганда, безнең җитәкче кешеләребез бу эш белән ныгытып кызыксынганда татарча китапларның тиражы 3000-5000 белән генә калмаячак. 20, хәтта 25 меңле тираж тулысынча сатылып бетеләчәк.

Минемчә, крайком бу эш белән бик нык кызыксынырга тиеш. Бүтән өлкәләрдә татарча китаплар белән сәүдә итүнең торышын тикшерү өчен крайком, Татгосиздат, Язучылар союзы урыннарга кешеләр җибәрсә бик яхшы булыр иде. Чкалов өлкәсеннән килгән бер укытучы иптәш, татарча китапларның килеп җитмәвенә зарланып, Казах язучылары турында сөйләде. Казах язучылары Чкалов өлкәсендәге казахлар арасында казахча китапларның ничек таратылуы белән бик кызыксыналар, казах авылларында еш кына булалар, ди. Ә бит моның өчен безнең дә мөмкинчелекләр бар. Тик теләк кенә кирәк!

*19 май, 1952 ел.*
**Н.ФӘТТАХ**

---

# СЕЗДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ ШУЛАЙ САТАЛАР КИТАПЛАРНЫ

«Балтач районында китап сәүдәсе эше бүгенге көндә ничек тора икән?» дигән сорауга сорау белән: «Ә бу эш Казанда—Татар иле башкаласында ничек тора, аерым алганда, татар китабын күпме чыгаралар да, кайда, нинди шартларда саталар?» — диясе килә килүен, ләкин безнең үзара әйтешүдән генә хәл үзгәрмәячәк. Әмма шулай да Балтач яисә теләсә кайсы башка район хәлләрен сөйләгәндә һәрдаим Казанны да истә тотарга туры килә, чөнки «балыкның башы» нәкъ әнә шунда. Бәлки әле ерактарактыр да.

Моннан нәкъ алты дистә ел элек Нурихан Фәттах Балтачның китап сәүдәсе эшендә байтак кимчелек тапкан. Татарстан җитәкчелегенең бу эш белән якыннан кызыксынуы, яхшыртырга омтылуы шартларында бит әле бу! Нурихан ага, татарның булачак зур әдибе, үзе дә бу мәсьәләне, аның Хисабыннан күренгәнчә, «Татарстан ВКП/б/ Край комитеты йөкләмәсе буенча» өйрәнгән. Ә бүген Татарстан хакимияте дәрәҗәсендә бу эш белән аз гына булса да кызыксынганнарын, халыкны мөмкин кадәр аң-белемле, мәгърифәтле, китаплы һәм матбугатлы итәргә иде, сез моның өчен ниләр эшлисез дип

җирле җитәкчеләрдән сораганнарын ишеткәнегез бармы? Спорт, спорт һәм тагын бер тапкыр спорт кирәк безгә! һәм— Мәскәүгә «төбәкләр арасында беренче» дип әйтерлек күп итеп салым җыеп җибәрергә кирәк. Аз балалы татар мәктәпләрен бетерү исәбенә оптимизация үткәрү дә архимөһим бугай. Соңгы араларда гаилә фермаларын ишәйтү белән дә мавыгып киттеләр, киләчәктә авыл проблемаларын, рәсми хакимияттән алып, тулаем алар җилкәсенә салыргадыр исәпләре. Дөрес, мәгълүм Разил Вәлиев парламент мөнбәреннән китап, матбугат, мәдәният проблемаларын әледән-әле күтәреп тора, нәтиҗәсе дә бар, сукырлар түгелбез, шөкер, күрәбез. Ләкин хөрмәтле Туфан Миңнуллин вафатыннан соң татарның рухи-милли мәнфәгатен кайгыртуда зуп-зур парламентта берданбер диярлек калган депутат «акча» һәм «спорт» дип кенә авызы ачыла торган безнең хакимият армадасына каршы ни кыла ала? Әле аның да депутатлык гомере чиксез түгел. Бу урында депутат Роберт Миңнуллинның да, «Яңа гасыр» телеканалында байтактан махсус тапшыру алып барып, китап пропагандалау буенча зур эш башкаруын әйтергә кирәктер. Тик менә бу тапшыруны «немедленно туктатырга» (?) тәкъдим итүчеләр хәтта танылган каләм ияләре арасында да бар икән (Татарстан язучыларының соңгы корылтаен искә төшерик), рәсми хакимиятнең китап таратуга игътибарсызлыгы хакында сүз алып барырга да уңайсыз әле.

Ярар, «балык башы»ннан үтеп, Балтачка кайтыйк. Әйе, район башкарма комитеты рәисе урынбасары Вакыйф әфәнде Зәкиев белән сөйләшүдән аңлашылганча, китап сәүдәсен киңәйтү, җанландыру кирәклеге хакында беркайда да җитди сүз булмаган. Бәлки, ул белеп тә бетермидер, чөнки бу урында бер генә ел эшли әле. Хәер, күп итеп китап алып кайтып сат дип кемгә күрсәтмә бирсеннәр (безнең хакимиятләр тегеләй итеп, болай итеп карыйк дип киңәшергә түгел, күрсәтмә бирергә генә күнеккән) — ирекле базар заманы лабаса. Ә ул базардагылар ни сатасын үзләре хәл иткәннәр инде, нәрсә күп һәм тиз сатыла—шуны саталар, тыелган әйбер генә булмасын. Димәк, хакимият сүзе үтәрлек берданбер райпо, төгәлрәге, элекке райпоның дәвамчысы—кулланучылар җәмгыятьләре берлеге дигән фәкыйрь генә оешма кала. Ике дистә еллар элек гөрләп барган китап сәүдәсен таратып ташлаучылар да шушылар булганлыктан, хакимият «киңәше» нәкъ алардан башланырга тиеш тә кебек. Тик менә... Берлекнең аз санлы хезмәткәрләрен мин элекке райпо идарәсенең иске зур бинасыннан чак эзләп таптым.

Көннән-көн яңара, бөтәя, үзәк урамдагы ике йортның берсе ят исемле заманча сәүдә үзәгенә әверелә барган Балтачның (мондый яңарыш аңа күптән түгел бистә исеме китерде) иң тузган, иң шыксыз бинасыдыр бу, мөгаен. Бигрәк тә эчке ягы кызганыч хәлдә. Авыллардагы кибетләре дә гел азая икән, мөгаен, шуларны сату, зурракларын арендага бирү исәбенә генә яшәп ятмышларыдыр (идарә бинасының каралмый торуы да аны юк бәягә бер «үзара дус»ка сатып бирү максатын күздә тотмый микән?

Бу уңайдан тагын бер сорау бар: һәркайда кулланучылар җәмгыятьләренең никадәр мал-мөлкәте сатылды, туздырылды, үзләштерелде инде, ә шушы байлыкның төп хуҗалары булган, аны хәләл тиеннәре белән барлыкка китергән пайчыларга кем, кайчан, нинди өлеш чыгарырга исәпли, контроль органнары моңа ничек карый икән?) Кибетләрнең булганнары да товар аз сатыла, шунлыктан хосусый сәүдәгәрләрне кызыксындырмый торган кечкенә авылларда гына калып бара. Иң аз керемле китап сәүдәсен дә ничек тагасың инде боларга? Халык телендә «Путинныкы икән», «Казандагы фәлән түрәнеке икән» дип йөртелә торган супер һәм гипер кибетләр берсе дә китап сатып мәшәкатьләнми әнә. Китап сатучыларга (һәм китапны басып чыгаручыларга да, әлбәттә) «балык башы» тарафыннан салым ташламалары ясалса, бүтән төр түләүләре дә кечерәйтелсә иде менә. Бигрәк тә милли телләрдә, аз санда чыгарыла һәм сатыла торган китаплар хөкүмәтнең аерым бер игътибарына мохтаҗ, ләкин «туган» илебезнең рус булмаган, аз санлы халыкларга Явыз Иваннан ук килә торган «аталарча» (патшаның үз улын тимер таяк белән кыйнап үтергәне бар дөньяга мәгълүм) мөнәсәбәтен әйбәт белә торып, бу хакта сүз башлау урынлы микән?

Өйрәнү-сораштыру шуны күрсәтте, Балтачның кайчандыр гөрләп торган китап сәүдәсе «эзсез» югалган инде. «Гөрләп торган» дигән гомуми сүзне читкә куеп, мин ике дистә еллар элеккене конкрет саннарда күрсәтеп бирергә теләгән идем. Районда айга, елга күпме китап сатылган, ул тулаем товар әйләнешенең йөздән ничә өлешен алып торган... Авыллардагы зуррак кибетләрнең һәркайсында китап сату почмагы эшли, бу өстән шулай кушыла иде бит, димәк, аз сатылмаган булгандыр. Әмма берлек идарәсендә мондый мәгълүматлар сакланмаган булып чыкты. Бөтенесе архивка тапшырылды, диләр. Район архивы мөдире Әлфия Атабаева, бик ипле һәм игътибарлы ханым, райподан килгән аз сандагы кәгазьләрне битен-биткә аерып эзләде: безне кызыксындырган саннар бөтенләй юк анда. Саннарны унбиш еллап районың китап сәүдәсе белән шөгыльләнгән товароведы (товар белгече дип язуыбызны электән өнәми иде ул) Асия Закирова да хәтерләми. Асия ханым хәзер ире Радик Закиров янәшәсендә хосусый сәүдәдә. Радик әфәндене, районның мәдәни чараларына бик теләп матди ярдәм күрсәтә дип, газеталарга язып торалар, Әле быел Карадуган урта мәктәбен заманча төзекләндерүдән дә читтә калмады. Тик «Радик» кибетләр челтәренең бер ноктасында да китап сатылмый. Кызык бит бу (әллә кызык түгел диярсгәме?). Нилектән шулай, дигән сорауга Асия ханым гади һәм көткәнебезчә җавап бирде: «Сатып алучыда китапка ихтыяҗ юк». Шулай инде, кайсы ирекле сәүдәгәрнең үз кибетен үтмәс товар белән тутырасы килсен ди.

Әйе-әйе, әнә шул «ихтыяҗ юк»лык теге елларда китап сәүдәсен тәмам томалады да инде. Җәмгыять көтелмәгән үзгәрешләрдән ыгы-зыгы килә башлагач, аптыраган халыкта китап сатып алу кайгысы калмады, җитмәсә, аны басып чыгару азайганлыктан, кибетләргә яңа басмалар кайтмады, чыгарылганнары да кулга алмаслык начар кәгазьдә яки акча түләп кенә нәшир ителгән «макулатура» иде. Болай итеп «искене җимерү» Балтач кебек район сәүдәгәрләреннән дә, җирле җитәкчеләрдән дә башланмады, киресенчә, аларның байтагы элекке җай белән, конкурентларсыз эшләп торуга бүген дә шатланып гына иде. Шулай булгач, китап сәүдәсенең җимерелү сәбәпләрен нигә дип әле без бу хәлгә иң аз гаепле булган урыннан эзлибез? Әнә «китаптан киткән» Асия Закирова да яшьләрнең-балаларның аз укуына һич куанмый. Китаптан укымаган, «күрү хәтере» булмаган балалар дөрес яза белмиләр, шуңа күрә хатага батабыз инде, ди ул. Хак әйтә, карагыз инде бүгенге матбугатны. Кайвакыт дөрес язганны да «төзәтеп» чыгаралар, мәкаләңне укырга куркып торасың.

Элекке Балтач универмагының китап сату бүлегендә егерме ел Разия Гыйльмуллина мөдирлек итте. Ул башка кибеткә күчкәндә китап сәүдәсе таралмаган иде әле. Бүтән җирдә эшли башлавын ул «Татарстан яшьләре» газетасында чыккан бер мәкаләсендә болай дип аңлатты: «Тамагың туяр дип райпо рәисе Васыйл Вәлиев мине азык-төлек кибетенә күчерде». Ләкин төп сәбәп тамак тую-туймауда гына булмаган. «Ул чакта дефицит басмаларның кибеттән тыш кына сатылуы бик туйдырган иде», — ди хәзер Разия ханым.

Әйе, дефицит товар, һәр кибеттәге кебек, китап сәүдәсендә дә «хәрәкәтләндерүче көч» иде шул. Сирәк китапларга кибеттә озак ятканнарын өстәп, матур тасмалар белән бәйләп бүләк җыелмалары ясау, күмәк хуҗалыкларга посылкалар җибәрү—сатучылар план үтәү өчен ниләр генә кыландырмый иде.

Шундый тәҗрибәләр хакында бер мәзәк хәтердә калган. Кайдадыр бер китап кибете сату планын һич үти алмый икән. Партия райкомыннан киләләр дә шелтәлиләр боларны, кешене китап сатып алуга кызыктыру өчен яңа әмәлләр табыгыз, диләр. Сатучылар таба, билгеле, партия кушкач, нишләсеннәр. Күп җыелган китапларның башта берсе, аннары икенчесе, өченчесе сатылып бетә, Эш көйләнде генә дигәндә, тагын да хәтәррәк җирдән яңа тикшерү килеп төшмәсенме! «Рус илендә кем рәхәт яши?» дигән китапка кадерле Леонид Ильич Брежнев гаиләсенең фотосын кушып саттыгыз — дәшми калдык, «Али баба һәм кырык карак» китабына Политбюро рәсемен өстәдегез—монысына да түздек, инде «Нахаленок» китабын хөрмәтле Леонид Ильич рәсеме белән сатасыз, беләсезме кая барганыгызны?» дип әй тиргәгәннәр ди сатучыларны.

Дефицит димәктән, булган бит заманнар, әйеме! Сатучылар сатып алучыларга китап җиткерә алмаганнар! Ә бит кытлык нииндидер чит ил басмаларына яки русча китапларга гына түгел иде, еш кына үзебезнекеләр дә җитмәде. Язучы Мәгъсум Хуҗинның үтенече белән мин дә бервакыт Утыз Имәни китабын эзләп йөрдем. Китап кибете Балтачтан тыш Чепья авылында да бар иде, ләкин Утыз Имәни анда да сатылып беткән булып чыкты. Балтачтагы складта да калмаган иде. Склад димәктән, аның иң соңгы мөдире булып Гөлчирә апа Касыймова эшләде. Нурихан Фәттах Хисабында телгә алынган, аңа китап сәүдәсе хакында мәгълүмат бирүдән качып йөргән Касыймова әнә шул инде. Тагын да җаваплырак вазифалар башкарып пенсиягә чыккач кына китап складында эшләп алган иде ул, хәзер мәрхүмә инде. Бик яңарган да, һич үзгәрмәгән дә кебек бу дөнья.

Шагыйрь Нәҗип Мәдияров та, Балтачта чагында, Казандагы каләмдәшләренә әледән-әле төргәк-төргәк китаплар илтте (хатыны шунда эшләгәнлектән, ул китап кибетендә үз кеше иде), ләкин сораганнарын барыбер илтеп бетерә алмады. Әгәр бүген дә китап үтемле товарга әйләнсә, акча китерсә, аны сатарга теләүчеләр, һичшиксез, күбәячәк, билгеле, һәм... күбәя дә бугай инде.

Шәхси эшмәкәр, Карадуган кызы (авылыбызның чагыштырмача мәгърифәтлерәк булуын, анда төзелгән беренче күмәк хуҗалыкның да «Мәгариф» исеме йөртүен язган идем инде) Гөлнур Гыйззәтуллинаның хосусый китап сәүдәсе ябык базарга әверелгән элекке ике катлы универмаг бинасының подвалына урнашкан (әйтәм ич, бөтенебез Казаннан үрнәк ала). Сөбханалла, сәүдәсе киңәя дә бара икән, соңгы елда янәшә ларекны да үзенекенә кушып эшли башлаган. Базарга ул бүтәннәрдән шактый соң килеп кушылды, югары белемле авылдаш аңа кадәр Балтач гимназиясендә укыта иде. Ул чакта аңа сату өчен китаптан башка товар калмаган да булгандыр, бәлки. Айга, елга күпме сатканын гына белеп булмады. Без беркемгә бернинди мәгълүмат бирергә тиеш түгел, дип кырт кисте авылдаш (кыланчыклык та ят түгел безгә!). Әйтүенчә, романнар һәм балалар китаплары әйбәтрәк сатыла икән. Романнарны күбрәк язсыннар, сатылып беткәч нәшрият кабат бастырып чыгарсын иде, ди Гөлнур ханым. Нәбирә Гыйматдинова, Мәдинә Маликова китапларын күп-күп алып кайтып сатып бетергән. Халык сорап йөдәткән Зифа Кадыйрова китабы сатуда да бар әле. Татарча балалар китабының ничек сатылуы турындагы соравыма җавап итеп, Гөлнур ханым каршыдагы өстәлгә өр-яңа басмалар китереп куйды. Зур өемдә — төрле нәшрият чыгарган русча китаплар, кечкенәсендә — татарчалары. Карагыз әле боларның рәсемнәрен, җир белән күк аермасы бит, кайбер татарча балалар китапларының рәсемнәре кеше карарлык түгел, ди эшмәкәр. Аннары, сүзен раслау өчендер, кулына Гөлнур Корбанова китабын алып, битләрен ачкаларга керешә. «Монысының рәсемнәре ярыйсы икән әле, дөрес, төрлесе була инде» — ди азактан. Талия Шакирова китапларын да алып кайтып сатып бетергән. «Кайбер китапларны Буа кебек зур районнар утыз данә алса, мин йөзәрләп алып кайтам», — ди авылдаш (юньле сүз әйткәндә аның авылдашлыгы гел истә тора).

Сатуда күпчелекне әдәби китаплар түгел, мәктәп өчен төрле-төрле ярдәмлекләр алып тора кебек күренде миңа (төгәл мәгълүмат алып булмагач, чамаларга гына кала инде).

«Безнең укытучыларга һәйкәл куярлык, үзләренә кирәкле китапның чыкканын тиз арада белеп әйтәләр дә, мин эзләп алып кайтам. Кайберләрен әле Казаннар да белмәгән була», — ди Гөлнур ханым. Монда рус теле укытучысы Алия Шакированың да сәүдә ноктасы икән. Анысы шушы бинаның беренче катында эшли һәм тулысынча мәктәп ярдәмлекләре генә сата.

Басма әдәбият сәүдәсе юкка чыгып торган елларда да районда китап хәрәкәте туктамады һәм моны җирле хакимиятнең уңай эше дип карарга кирәк (шулай булмый ни, ул чактагы хакимият башлыгы Марат Зарипов — Карадуганның мәгарифле күмәк хуҗалыгында рәислек иткән ир, район башкарма комитеты рәисе Рамил Шакиров — әнисе Карадуганныкы булганлыктан, яртылаш шушы авыл кешесе ләбаса). Беренчедән, китапханәләр челтәренә район бюджетыннан аз-азлап булса да яңа әсәрләр алгалап

тордылар. Икенчедән, нәкъ шушы елларда җирле авторлар активлашты: район һәм авыллар тарихы турында Бакый Зыятдиновның— уннан артык, Мәгъсүм Мөхәммәтҗановның—биш, танылган шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшинның, җирле каләм ияләреннән Фәридә Шакированың, Мәгъмүрә Хөрмәтуллинаның, Чулпан Габделганиеваның, Энҗе Закированың, Фаварис Галиевнең берничәшәр китабы басылып чыкты (иң күп китаплылардан өчесе — йә гомере буе, йә берара Карадуганда эшләгән кешеләр). «Идел-пресс»та яки «Сүз» нәшриятында заманча чыгарылган китаплар турында сүз бара монда. Хакимият исә әлеге басмаларның һәрберсен китапханәгә күпләп сатып алу өчен акча бүлде, байтагының нәшрият чыгымнарын да күтәреште.

Китап сәүдәсе сүрелеп торган чорда да китапханәләр челтәренең укучылары әйтерлек кимемәде, инде хәзер, тормышлар бер көйгә салынып килгәндә (Аллага шөкер!), арта да икән. Укучыларны җәлеп итү өчен ниләр генә эшләнми монда. Бер төре — язучылар белән очрашулар. Мин белеп хәтерләгәннәре генә дә — өч очрашу: Гөлчәчәк Галиева белән, Мәдинә Маликова белән, Айдар Хәлим һәм режиссер Нурания Җамали белән. Узган декабрь аенда «Яңа гасыр»ның «Җырлыйк әле» тапшыруында Арча педагогия көллияте студентлары җырлады. Шунда катнашкан директор ханым кайчандыр шушы уку йортын тәмамлаган күренекле кешеләрне санап үтте. Язучы һәм шагыйрьләр, матбугат, телевидение хезмәткәрләре... «Тулгак», «Газзәбану» кебек әсәрләре белән татарча укучылар дөньясын гөр китергән, Татарстан Язучылар берлеге һәм «Татнефть»нең Саҗидә Сөләйманова исемендәге премиясенә лаек булган Гөлчәчәк Галиева исеме генә никтер ишетелмәде. Белмиләр микәнни? Ә Балтачта беләләр һәм бик хөрмәт итәләр аны. Айдар Хәлимнең Балтачка килеп чыгуы да очраклы түгел, чөнки аның соңыннан кинофильмга әверелгән «Өч аяклы ат»ын — «әллә кайчан чыгып, бернинди игътибарга ия була алмыйча тузанга күмелгән заман әсәре»н (Айдар Хәлим сүзләре) матбугатта иң элек бәяләүче — шушы район (Карадуган!) кешесе.

Китапханә җирле авторлар белән очрашуларны, китап тәкъдир итү, иҗат кичәләрен гел уздырып тора. «Иң күп китап укучы» конкурсларын да ел саен үткәрәләр. Җиңүчеләрне балалар, яшьләр, өлкәннәр арасында аерым билгелиләр һәм Тукай көннәрендә, күп халык каршында игълан итеп, бүләклиләр. Тукай темасына рәсем, инша конкурслары, төрле темага китап күргәзмәләре көндәлек, гадәти эшкә санала монда. Бүген исә китапханә директоры Резидә Зарипованы (ул күрше Арбашта туып-үсеп, Карадуган урта мәктәбендә укыган кыз) иң нык куандырганы—ниһаять, республика һәм федераль казнадан яңа китаплар сатып алу өчен байтак акча бүленү. Ул яктан Татарстан Мәдәният министрлыгы нык булыша, газета-журналларга да күп язылабыз, ди Резидә сеңел. Соңгы ике елда гына да 10 мең данәдән артык татарча китап алынган. Удмурт авылларындагы китапханәләр дә онытылмый: алар өчен Резидә ханым күптән түгел Ижауга үзе барып, 36 мең сумлык китап алып кайткан (беләсе иде, Удмуртиянең татар укучыларына Казаннан күпме татар китабы сатып алып кителәр икән?).

Язма башында китерелгән сорауга минем җавап менә шушы булыр.

**Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ**

**Редакциядән**. *Руфина Фәттахова куйган сорау бер Балтач районына гына карамыйдыр. Сездә хәлләр ничек?*

# ШИГЪРИ РУХ ТАНТАНАСЫ

## XX ГАСЫР АХЫРЫ ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ МӘЙДАНЫНДА К.СИБГАТУЛЛИН ҺӘМ Н.АКМАЛ ИЖАТЫ

XX гасыр ахыры татар әдәбиятында шигърият үзенчәлекле урын алып тора. Әлеге кызыклы һәм әһәмиятле күренешнең аерым сыйфат-билгеләре Т.Галиуллин, Ф.Галимуллин, Д.Заһидуллина, Р.Рахман, Р.Рахмани, М.Вәлиев-Баржылы, Ф.Хәсәнова кебек галим һәм тәнкыйтьчеләрнең мәкаләләрендә, китапларында чагылыш тапты. Әлеге хезмәтләргә нигезләнеп, хәзерге татар поэзиясе үсешен анализлаганда өч агымны аерып чыгарырга мөмкин. Беренчесен «шартлы шигъри идеологик агым» дип билгелибез. Бу агымның асылы сәяси фикерләрне шигъри хис фәлсәфәсе җирлегендә чагылдыруга корылган. Аның төп вәкилләре, әлбәттә, Р.Харис һәм Р.Фәйзуллин булдылар. Шигъриятькә яңа көчле агым сыйфатында 60нчы елларда килеп, 70 нче елларда таныла барып, алар XX йөз ахырында да төп шигъри идеологик фәлсәфәнең әйдәп баручыларыннан иделәр. Зур елгаларга инешләр ничек килеп кушылса, шуның кебек аларга иярүче шагыйрьләр дә аз булмады. Әгәр дә 80 нче елларда татар шигъриятен эпигонлык томаны каплаган икән, асылда аның барлыкка килүе «шартлы шигъри идеологик агым» уңышларының халык рухы киңлекләренә күтәрелүенә бәйле иде. Шагыйрьләрнең зур күпчелеге гүяки үзләренең йөрәк хисләренә ачылыр өчен юл һәм мөмкинлекне шушы шигъри агымга иярүдән күрделәр. Ул чор өчен яңа буын буларак төсмерләнгән Г.Морат, Р.Зәйдулла, Л.Лерон, Л.Зөлкарнәй, аларга кадәр Э.Касыйм, Х.Гайнетдин һ.б. шагыйрьләр мәйданга чыкты һәм фикер-хис-фәлсәфәдә шушы агымга кушылган мул сулы елгалар төсен ала барды.

Икенче әдәби юнәлешне «шартлы шигъри сурәт агымы» дип атарга мөмкин булыр иде. Алар тормышны, табигатьне, кеше күңелен, тарихны, барлыкны-юклыкны шигъри сурәт эчендә, шигъри сурәтләнмеш аша күрделәр, ягъни әсәрләренең төп тукымасын сурәт хасил итте. Ул сурәтнең җирлегендә ни-нәрсә күзалланса, алар аны хакыйкать дип атадылар һәм ихластан халыкка төшендереп бирергә ашыктылар. Шуңа да шигырьләрендә романтик рух өстенлек итте. Аларның чишмә башы шулай ук еракта, әдәбиятыбыз тарихыннан ук килеп, И.Юзиев һәм Ш.Галиев лирикасында үз көчләрен күрсәтә башлап, асылда бар тулылыгы һәм күркәмлеге белән Зөлфәт һәм М.Әгъләмов иҗатларында ачылды. Бу агымга кушылган шагыйрь һәм шагыйрәләр шактый иделәр. Мәсәлән Г.Саләне бер дә читкә куеп булмый, Р.Гаташка килгәндә, ул хәтта робагыйлары белән дә беренче агымның вәкиле буларак ачылды.

Татар шигъриятенең өченче юнәлешен «шартлы шигъри фикер агымы» дип атарга мәҗбүрбез. Бу төр әдипләр дөньяны фикер бәяләмәсе аша күрә-күрсәтә иделәр. Аларда фикер бирелеше метафорик куәт алып, бәяләүче, ачыклаучы көчкә әверелә барды. Шуның белән затлы бер шигъри агым тудырылып, күңелләрне заманча хис белән баетуга да иреште. Бу агым татар әдәбиятының шулай ук тарихи катламнарыннан ук килеп, асылда XX йөзнең 70 нче елларында үзенең барлыгын белдерде, алга таба да куәтләнә барды. Әмма метафорик фикер аша дөньяны күрә һәм бәяли белү татар акылы өчен катлаулы мәсьәлә булып чыкты, шунлыктан аңа кушылучыларның сирәк күренеш икәнлеген искәрми мөмкин түгел. Өченче

агымның башында Кадыйр Сибгатуллин торды, аңа Нияз Акмал килеп кушылган иде. Никадәр тирән һәм көчле юнәлешне тәшкил итмәсен, әмма ул агым артык җәелеп китә алмады. Шуның белән аның әдәбиятыбыз тарихы өчен кадере дә зур дип әйтә алабыз. Шул рәвешле, татар шигъриятендәге әлеге өч агым, олы елгалар кебек, тормыш мәйданында агып барышларында, сәяси-көнкүреш ландшафтларына бәйле рәвештә, әле үзара якынайдылар, әле ерагайдылар. Шунлыктан аларның берберсеннән шигъри-әдәби дым алган очраклары да булмады түгел.

Китап укучыны шушы агымнарга кергән шагыйрьләрнең шәхси мөнәсәбәтләре кызыксындырмый иде. Сәяси даирәләргә әгәр дә «шартлы шигъри идеологик агым» әһәмиятлерәк тоелса, халыкны «шартлы шигъри сурәт агымы» кызыксындырды. Алар арасында иң сөеклеләре әле И.Юзиев, әле Ф.Яруллин, әле Зөлфәт яисә М.Әгъләмов булдылар. Әмма беренче агымда беренчелек һәрвакыт Р.Харис һәм Р.Фәйзуллин каләмнәренә бирелде. Аларның шигъри сүзләре өлгергән һәм житди саналды, шулай дип кабул ителде. Өченче агымга игътибар җитмәде. Моны К.Сибгатуллин да, Н.Акмалов та бик авыр кичерде. Әмма алар да татар әдәбиятының үксез баласы түгелләр иде. Ничек кенә булмасын, нинди генә формаларга һәм төрләргә кермәсен, «шартлы шигъри идеологик агым» юнәлеше татар шигъриятендә озын юллар үтәргә җыена, шушы ягы белән ул урта гасырлар суфичылык дәвере татар шигъриятен дә хәтерләтергә мөмкин.

«Шартлы шигъри идеологик агым» татар әдәбиятында яшь М.Җәлилнең 1919 елда «Кызыл йолдыз» газетасында басылып чыккан «Бәхет» шигыреннән үк баш алып киткән иде. Менә аның кайбер строфалары: «Кулыма мин кызыл кылычны алсам,/ Шулай шуннан кызыл фронтка барсам,/ Олуг бер дәрт белән сафка атылсам.../ Үлем кулы килеп басса — егылсам,/ Җаным күккә-гарешкә очса-китсә — / Менә шунда бәхетле мин, бәхет — шул». Байракларның, тарихи фонның төсе үзгәрүгә карамастан, «шартлы шигъри идеологик агым» нәкъ шушы мотивларда үсте, шушы уртаклыкта чәчәк атты һәм туклыклы канәгатьлек җимешләрен бирде.

Шигырь автор әйтергә җыенган төп фикерләрдән һәм шулар арасына куелган эчтәлек тукымасыннан гыйбарәт. Боларның чагыштырма үзенчәлекләре, әлбәттә, шигъри-поэтик модусны барлыкка китерә. Модус ул, атрибуттан, ягъни предметның төп үзенчәлегеннән аермалы буларак, предметның билгеле бер очракларына-халәтенә генә хас үзенчәлек. Димәк, жанр күренеше түгел, бәлки шул жанрның теге яки бу әсәрдә, яисә әдип иҗатында файдаланылган мөмкинлегенә бәйле үзенчәлеге. Әгәр дә, мәсәлән, рифма, ритм, строфика төшенчәләрен без шигырь атрибутлары буларак белсәк, хис, мотив, фон, борылыш һәм башкаларны, алар арасындагы үзара бәйләнеш үзенчәлекләрен, күләм мөнәсәбәтен, эчке бүленешне шигъри модуска бәйле дип карарга тиеш булабыз. Әдәби фон һәм әдәби борылышлар белән шушы ук хәл, алар да поэтик модус төшенчәсенә-эчтәлегенә туры килә. Шунысы кызыклы, поэтик атрибутлардан аермалы буларак, шигъри модуслар һәр очрак өчен үзенчәлекле һәм иҗади осталыкка бәйле күренеш юнәлешен ала.

Шигъри модус белән эш итү осталыгын Х.Туфанның «Иртәләр житте исә» шигыре ачык аңларга ярдәм итә. Шагыйрь бу әсәрендә һәр строфаны аерым эчтәлектә билгели һәм алга таба шул строфаларның урыннарын алыштырып бара. Атрибутлар саклана. Әмма һәр шигъри строфа, анда шул ук сүзләр кабатланса да, яңа хис мөнәсәбәте һәм кабатланмас эчтәлек алып килү тойгысын уята. Әмма «шартлы шигъри фикер агымы» шагыйрьләре Х.Туфанның Шәрык әдәбияты даһиы Фөзүлидән үк килгән шигъри алымын файдаланмадылар. Моның төп сәбәбен аларның әдәби агымнары аерылып торудан күрергә була. Һәрхәлдә «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре Х.Туфанны башка агым вәкилләре кебек соклану объекты итсәләр дә, аның иҗатына мөкиббән китсәләр дә, әсәрләрендә аны данга төрсәләр дә, үз агымнарында кала бирделәр. Бу факт та аларның чын әдип булуларын ачык раслый ала билгеле.

XIX йөзнең соңгы чирегендә М.Акмулла шигъри сентенцияне (әхлак өйрәтүне) шигъри фикер бирү белән алыштырып, «шагыйрьләрдән сүз чыгар хикмәт белән» дигән шигарь-лозунг астында иҗат итеп, хикмәтне монда суфи шагыйрьләр яратып кулланган әхлакый һәм танып белү характерындагы әсәр жанры буларак

түгел, канатлы метафорик фикер бирү сыйфатында куәтләп язды. Татар әдәбияты бервакытта да фикерсез булмады. Фикер куәте белән иҗат итү, яна фикерләр бирү ягыннан һәр шигъри агым да көчле иде. Әмма әһәмиятлесе шунда, башка агымнар өчен шигъри фикер бирү турыдан-туры әдәби әсәрнең идеясенә хезмәт итсә, «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләрендә ул шигырьне барлыкка китерүче поэтик модус рәвешен алды, шуның белән схоластик формуладан котылу, фикер киңлегенә юл ачкычы ролен үтәп, метафорик мәгънә нигезенә әвереләдерелде. Әгәр дә символистлар фикер бирүдәге схоластик формулаларны символик һәм мистик-метафорик форма бирәмлекләре белән алыштырсалар, «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре шигъри метафорика белән эш итүне өстен чыгарды. Менә К.Сибгатуллин болай яза:

*Авыр димим сине,*
*җиңел димим,*
*үлчәп булмый сине, Замана.*
*Утыз яшькә җиткән егетләрнең*
*икенче кат чәче агара.*

(«Без синеке инде», 1973.)

Формаль мантыйкка буйсындыра калсак, чәч ике тапкыр агара алмый. Әгәр дә шигъри логика нигезендә карасак, монда метафорик фикер тасвирлануы аңлашыла. Сүз тормыш авырлыкларыннан чәчнең агаруы хакында бара, билгеле. «Икенче кат чәч агару»ны да яшәеш шартларының бер дә җиңеләймәвен, тагын да кыенлаша баруын белдерә дип алырга була. Лирик герой заманны үлчәп булмавын, ягъни үлчәүгә салу мөмкин түгеллеген дә искә ала. Бу да метафорик фикер, әлбәттә. Лирик геройның зарланырга да, сөенергә дә җыенмавы әйтелә. Шигырь шул ук: «Авыр димим сине,/ җиңел димим,/ үлчәп булмый сине, Замана», – фикерләмәсе белән башланып китә. Әдәби борылышның К.Сибгатуллинда метафорик фикер бирү өчен файдаланылуын күрәбез. Әдәби фон ролен шигырьнең эчке тукымасында тасвирланган эчтәлек били.

К.Сибгатуллин шигъриятенең хикмәте шунда – ул фикерләр галереясе белән шигъри фон барлыкка китерү остасы булып тора. Шул фикерләр сурәтне дә, идея-идеология катламын да алыштыруга юнәлдерелгән. Аның лирик герое кылыч айкап көрәшкә дә ташланмый, үз хаклыгын да раслап сөйләми, халыкның нинди бәлаләр астында калуын фикер төрткеләре ярдәмендә бирә. Аның иҗатында сурәтне метафорик фикер һәм фикерләмәләр агышы алыштыра: «Бишекләрдән үзебез төшеп җиктек/ туарылып калган атларны». Тормыш авырлыгы сурәтен дә шундый ук метафорик фикер аша бирә ул: «...Камыт агачлары шартлап сынды,/ атлар пеште юлда... ачудан».

Әсәрдән аңлашылганча, лирик герой – сугыш еллары баласы, алар буынына әүвәле әтиләре калдырып киткән эшләрне башкарырга, аннары гына үзләренекен күтәрергә туры килә. Шигырьдә К.Сибгатуллин моны буынның «ике чылбыры» турында фикер әйтеп узганда да искәртә:

*Мәңгелеккә үтеп бара торган*
*кешелекнең шушы буыны*
*алып тора*
*халык тарихында –*
*бер чылбырда ике урынны.*

Шигъри фон, шулай итеп, үзе дә тыгызланган фикерләр тезмәсеннән тора. Әмма алар аерым-аерым түгел, бәлки шигъри фикер мантыйгының аерым синтагмалары рольләрен башкаралар һәм, һичшиксез, башка бер, зур һәм төп фикергә күңелнең омтылышын тудыралар. Әсәрдә ике вакыйга фикерләр тезмәсе рәвешендә ачыла. Беренчесе – аталарның дошман угына каршы килүе, икенчесе – бишектән төшеп, балаларның аларны алыштыруы, ягъни кешелек тарихының чылбырындагы ике буыны бу.

Лирик герой заманага мөрәҗәгать итеп болай ди: «Без синеке инде,/ син – безнеке,/ Тоеп тора сине җилкәләр...» Монда да автор шигъри метафорик фикерне бирә. Укучы күнелендә сорау туа: «Әгәр дә лирик герой замана авырлыгын тоя икән, ни өчен соң ул вакытта аны «үлчәп булмый сине» дип белдерә?» Монын хикмәте бары бер төрле генә анлатыла ала: әдәби-композицион борылышны барлыкка китерүче шигъри юлларга эчтәлекне бирүче әдәби фон метафорик каршылыкка куела, ягъни лирик миннең уйланулары «аларны ук әйтәсем килмәгән дә иде» дигән тойгы тудыра. Бу исә шигъри фикер йомгагын тагын да тәэсирлерәк дәрәҗәгә җиткерү өчен хезмәт итә. Утыз яшькә җиткән егетләрнең, әгәр дә фон эчтәлегендә генә фикер калдырылса, фикер әтиләре өчен дә балаларының чәчләре агарган дигән булып анлашылыр иде, ә хәзер ул, беренче эчтәлеген җуеп, яңа мәгънә тирәнлеген ала һәм тормыш хакыйкате дәрәҗәсендә кабул ителә.

Шул ук әдәби агымдагы Н.Акмал, шигъри метафорик фикер коллизияләре белән эш итүче булуына карамастан, әдәби фонны лирик сурәт төсмерендә бирергә омтылышы белән К.Сибгатуллиннан берникадәр аерылып та тора кебек. Бу факт аларның үз иҗатлары белән бер-берсеннән аерымлануларын да күрсәтә. К.Сибгатуллинның катгыйлыгы, фикердә корылыгы Н.Акмалнын лирик тоемны читкә какмавы – болар поэтик модус закончалыкларын барлауда кызыклы күзәтүләргә этәрә. «Шартлы шигъри фикер агымы»ндагы әдипләрне лирикага бирелү ритмик сөйләм юлына кертеп җибәрә. Бу яктан Н.Акмал шигърияте шулай ук кызыклы:

*Иң борынгы бөек философлар*
*Яшәү асылын ачар урынга,*
*Калын-калын трактатлар язган*
*Дәүләт төзелеше турында.*
(«Философлар», 1980)

Н.Акмал шигъри метафорик фикерне К.Сибгатуллин кебек үк алга чыгара, аннары аны раслаучы эчтәлек фонын бирә. Дәүләтләрнең тарих барышында үз вакытлары белән җимерелә баруларын искәртеп, фәлсәфәләрнең бүтән төс ала баруларына да, фән үсешенә дә аерым игътибар күзе салып үтә. Н.Акмал эчтәлек борылышларын шигъри метафорик тезмәгә әверелдергән сыман, әдәби фон эчендә үстереп тә бара. Һәм шунда: «Галимнәрдән ләкин сер кача,– дип белдерә дә, – Бөтен илгә урта белем керттек,/ Акыл ягы калды уртача»,– дигән раслау сүзләре белән фикерен ассызыклый. Әмма бу метафорик фикере дә бары тик шигъри эчтәлекне ныгытучы фон ролен үти. Һәр фикер сиггагмасы аерым берәмлеккә әверелеп китсә, әлбәттә, шигырь таркалыр иде. Н.Акмал әсәрләрендә дә К.Сибгатуллин иҗатына хас булганча, темага ике тапкыр йомгак ясалгандай тойгы калдырыла, ягъни шигырь инде тәмамланып, ана соңгы строфа өстәп кенә куелгандай анлашылып кала. Әмма монын шул ук әдәби-поэтик ысул икәнлеге шигырьнең соңгы строфасында эчтәлекне хасил итүче әдәби фонны шагыйрьнең тулысы белән шигъри метафорик кысаларга кертүеннән күренә. Мондый шигъри фикерләү алымы әсәрнең эчтәлеген тагын да тирәнәйтә. Шигырьләре кыска булсын, озын итеп төзелсен, барыбер дә шушы алым «шартлы шигъри фикер агымы»ндагы шагыйрьнең иҗатында өстенлек ала. Мисал өчен Н.Акмалның «Философлар» шигыре ахырында ул болай бирелгән:

*Айны, күкне, йолдызларны сөеп,*
*Яшәү асылын ачар урында,*
*Философлар һаман нидер яза*
*Дәүләт төзелеше турында...*

Шушы рәвешле шигырьдәге калку итеп чыгарылган фикер фәнгә әдәбиятнысәнгатьне каршы куя, әмма бу хакта бөтенләй бер сүз дә әйтелмидер кебек тойгы да калдырыла. Яшәеш белән дәүләт системасы да метафорик фикер планында үзара каршы куелалар.

К.Сибгатуллин һәм Н.Акмалның шигырь барлыкка китерүче модуслары менә шушы рәвештә: әүвәле метафорик фикер китерелә, аннары ул эчтәлек эчендә «әдәби фон» кысаларында башка фикер синтагмаларына бәйле ачыла, фикергә йомгак ясала, ахырда кабат өстәмә строфа китерелеп (ә ул асылда шигырьнең беренче строфасын кабатлый), янача нәтиҗә чыгарыла, ягъни идеяне формалаштыруда төп рольне үтәүче шигъри метафорик фикер итеп бирелә. Укучы, Н.Акмалның «Философлар» шигырен укыганнан соң, кешелек өчен дәүләт төзелеше мәсьәләсе түгел, сөенеп яши белү зур әһәмияткә ия икән дигән фикергә килә. Әмма әсәрнең идеясен шигырьне барлыкка китерүче модусны ачыклауда гына таба алабыз.

Эчтәлек тукымасында фон буларак мондый фикер китерелә: «Фән агачы үскән./ Ә кешенең/ Тамырлары җиргә бәйләнгән». Аңа кадәрге строфаларда борынгы фәлсәфәләрнең хәзер башка төстә аңлашыла барулары, дәүләтләрнең җимерелүләре сөйләнелә, аннары килә торган тезмәләрдә белем белән аң үзара каршы куела. Шулай итеп, Н.Акмал фәннең дәүләт хезмәтендә икәнлеген, ә кешеләрнең җиргә берегеп яшәүләрен раслый бара. Ә бу фикерләр суммасы әсәрнең идеясен аңлауга китерә, аның нигезен тәшкил итә бара, эчтәлек тирәнлеге фикерләр кушылмасында кала. Бу шигырь кешенең бәхете сөенеп яшәүдә дигән идеяне бирүгә корылган, югыйсә. Әмма фикерләрнең күплеге эчтәлек киңлегенә китерми.

Әгәр дә шушы әсәрне формаль логикага буйсындырсак, борынгы фәлсәфәчеләрнең дәүләт төзелеше турында гына язмаган булуларын, бәлки чынбарлыкны танып белү һәм аңлату, хакыйкатьне ачыклауга бар зиһеннәрен, акылларын юнәлтүләрен искә төшерсәк, шагыйрьнең хаталануына чынлыкта хәйран итәргә мәҗбүр булыр идек. Әмма «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләренә андый нигезләмәләргә таянып эш итү ул шигырьне үтерүгә тиң. Әдәби әсәрләрнең хикмәте шунда ки, аларда хакыйкать – образлы фикер, метафора ярдәмендә ачыкланыла. К.Сибгатуллин да, Н.Акмал да үз күзәтүләрен әдәби фикер кысаларында укучыга җиткерәләр. Аларның метафорик шигъри фикере аңлаешлы тышкы билге буларак укучыга тәкъдим ителә. Ул тышкы билге эчтәлек белән баетыла, фикерне үзенә ияртә һәм фикри нәтиҗәгә киленә. Әмма фикри нәтиҗә идеянең үзе түгел, була да алмый. Идеяне барлыкка китерү өчен бу тип шагыйрьләр, әдәби фикерләү катламына күтәрелеп, метафорик фикер белән әсәрне йомгаклыйлар. Шигырьнең көче бермә-бер арта, тәэсир куәте үсә. Укучыда хис-тойгылар өермәсе туа.

Шулай итеп, «шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре әһәмияткә лаеклы әдәби үсешне укучының күңел дөньясында тәэмин иттеләр. Мондый күренеш шигърият өчен ят түгел, аның бөек таләпләренә җавап бирә иде. Бу агымга XXI йөз башында шагыйрь М.Мирза килеп кушылды, әмма аның формаль логика кысаларына шигъри фикерне кертергә омтылышы шигырен канатланудан берникадәр чикләп тота башлады.

Шигырьнең асылы шунда – ул рухка ирек бирә, шигырь канатларында рух үз дәртендә җырлый, үз моңында көйли, үз теленда сөйли. Менә шуны тудыра алучыны бүгенге көндә чын шагыйрь дип әйтәбез. Рух үзе сүзләрне рифмалаштыра, ритмга сала, фәлсәфәсен, строфикасын, башкасын таба, ягъни чын шигырьне яза. Аңлашылып тора, мәсәлән «икенче кат чәче агара» дигәндә К.Сибгатуллин формаль логиканы, тормыш дөреслеген боза, монда берниндн хакыйкать юк сыман, бу – әдәби уйдырма. Әмма чынлыкта аның эчтәлеге формаль логик эчтәлектән бермә-бер киңрәк һәм тирәнрәк. Әдәби әсәрләрдә тасвир кылынган фикерләр тезмәсе, һичшиксез, укучыны идеягә якынайта. Идея – әсәрнең җаны. Укучы әдәби әсәрнең эчтәлеге белән танышуның буеннан-буена үз фикерләрендә хәрәкәт тудыра, бу исә хакыйкатьне аңлауга юл ача. Аңлау мөмкинлеген бирү фикер үсеше юлында төп әһәмияткә ия. Бер фикер икенчесен тудыра. Ризалашу яки ризалашмаудан башланган фикерләү аерым-аерым модуслар хасил итәләр, без моны хис үзгәреше белән дә бәйлибез. Әгәр дә Н.Акмал шигырендә, мәсәлән, «Урманнарда бүре сирәгәйсә,/ Урамнарда этләр күбәя» дип белдергән икән, монда бүренең табигать санитары булуын, шул ук вакытта сүзнең җәмгыятьне чиста тотучылар хакында баруын да, ә этләрнең әшәке кешеләр икәнлеген дә аңламый мөмкин түгел. Формаль логика һич югы сарыкларның күбәюе белән бәйле фикер алып барыр иде. Әмма

әдәби метафорик фикер күчерелмә мәгънәләр белән эш итү аша хакыйкатьне күрү-күрсәтүгә, бәянләүгә, тасвирлауга ирешә. Шигъри фикер бирү бер нәрсә, аны шигырьгә әверелдерү – икенче. Шушы формадагы әдәби борылышларны әдәби фон аша дәлилләү, белдерү, аңлату һәм сурәтләү вакытында ул бөтенләй башка төрле эчтәлек алырга мөмкин. Бу очраклылыкның шигырь тукымасында гаҗәеп зур әһәмияте бар. Менә шушы очраклылык шигырь тудыручы модус булып тора да инде. Әгәр дә Фөзулидән алып Х.Туфанга кадәр әдәби үсешкә бәйле вакыт аралыгында шигырь тудыручы модус төшенчәсе ачыкланылып, теоретик яктан билгеләнеп житкән булса, «шартлы шигъри фикер агымы» бүгенге көндә бездә берникадәр сәерсенү тойгысын уятмас та иде.

«Шартлы шигъри идеология агымы» һәм «шартлы шигъри сурәт агымы» вәкилләре дә фикер бирү ысулларыннан йөз чөермәделәр. Киресенчә, анарда фәлсәфәлек күреп, иҗат офыкларын киңәйтү мөмкинлекләренә юл ачу юнәлешендә файдаланып эш иттеләр. Әмма бу факт аларның үз агымнарыннан читләшүләре дигән сүз түгел иде. Алар, тоткан юлларында калып, үз карашлары мөмкинлек биргән кадәрле фикер сөйләүне шулай ук еш файдаландылар. Шигъри фикер күп әйтелде һәм әйтелә торды. «Шартлы шигъри идеологик агым» аны үз кысаларыннан чыкмыйча сөйләде, «шартлы шигъри сурәт агымы» шигъри фикерне сурәт хисе мөмкинлек биргәнчә байрак итәргә омтылды. Әмма аларга карап берсенең дә асыл үзгәреше күзәтелмәде. Бу факт исә шигъри агымнарның мөстәкыйльлеген тагын да бер кат раслады.

Фикер әйтүнең, билгеле бер фикер тирәсендә шигырьне оештыруның үз дәверечоры татар әдәбиятында XX йөзнең буеннан-буена диярлек яшәде. Аның шулай булуында хикмәт тә бар иде. Укучылар тарафыннан фикер җиңел табыла һәм үзләштерелә торган эчтәлек төсен алды. Хәтта теориядә дә әдәби әсәрнең идеясе эчтәлектә күтәрелгән төп фикер белән тәңгәл куелды. Шушы рәвешле идеяне фикер алыштырды. Төп фикер билгеләнелсә, әдәби әсәр анализланган дип саналды. Әмма һаман да «шартлы идеологик агым» өчен фикер сәяси һәм әдәби идеологияләргә буйсындырылды һәм шуның өчен дә алардагы төп фикерләр иҗтимагый күренешне бәяләп, алга омтылыш, халык өчен тырышу юнәлешләрендә корылдылар. Алар өчен халык һәм җәмгыять, җәмгыять һәм ил, ил һәм хөкүмәт, хөкүмәт һәм сәясәт, сәясәт һәм идеология, халык һәм дәүләт төшенчәләре бердәй тигез яссылыкта күз алдына китерелде. Бу рәвешле монолит фикерле белү аларга уңышлар китерде һәм дәүләт идеологлары бу төр шагыйрьләргә һәрвакыт югары бәя бирде. Шул рәвешле «шартлы шигъри идеологик агым» вәкилләре «сарай җырчылары» хезмәтен башкардылар. Әмма бу хәл «шартлы шигъри сурәт агымы» шагыйрьләрен канәгатьләндерә алмый иде.

Аларда да фикер чыгару, фикергә таяну, сурәтне фикергә китереп ялгау, яисә фикерне сурәткә җәелдерү-таркату шигъри модусның төрләрен барлыкка китерде. Фикерчелек стихиясе һәммә төрле вариантларда һәм вариацияләрдә яшәде. Фикерне сурәткә әверелдерү яки сурәтне фикергә әйләндерү әлбәттә кеше зиһене башкара ала торган күренеш. Әмма бу вакытта фикер генә түгел, күңелгә хис белән бергә идея дә үтеп керә. Ә аның фикер белән тәңгәл килмәгән очраклары ешрак була бара. Шигъри сурәтнең хикмәте дә шунда, ул күңелләрдә хисләрне кузгата, зиһенне-аңны уйната, хисләр әгәр дә мотив белән ачыкланылган булса, укучы күңелендә моң калдыра. «Шартлы шигъри идеологик агым» вәкилләрен әгәр дә укучы «корылыкта» гаепләсә, «таш белән эш итүче төзүчегә» охшатса, «шартлы шигъри сурәт агымы» вәкилләрендә хис ташкынын күрде, аларның шигъриятендә рухның яшәвенә сокланды. Һәммә төрле фикерләр әйтелеп беткән һәм алар, мең дә беренче тапкыр кабатланалар сыман тойгы калдырып, фикерчелек дәвере замана мәйданыннан тарихка үтеп китәргә, әдәбияттан кичәргә тиеш иде. Әмма еллар янарып килә торалар, житмәсә үз хикмәтләре белән алар туа баралар.

«Шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләреннән К.Сибгатуллин үз юнәлешенең сафлыгын, чисталыгын тәэмин иткән иң куәтле шагыйрь булды, әлбәттә. Н.Акмалның аңа кушылуы бу агымга зур көч бирде. «Шартлы шигъри идеологик агым» һәм «шартлы шигъри сурәт агымы» шагыйрьләренең дә фикер әйтергә омтылышы һәм моны үз агымнары ярларында калган хәлләрендә оста итеп башкара алулары шулай ук «шартлы шигъри фикер агымы» мәртәбәсе өчен хезмәт итә иде.

«Шартлы шигъри фикер агымы» рәсми идеология белән санлашмады. Ул аны хәтта танымады да, аны тануда хәтта мескенлек, фикри житешсезлек күрде. Дөньяга караштa тәнкыйдилек, ризасызлык, әмма килешүчәнлек аларның төп маягы булды. К.Сибгатуллинның да, Н.Акмалның да лирик герое шушындый юнәлешләр эчендә хәрәкәт итте. Хәер, аның заманасы да, кешеләре дә ул чорларда нәкъ шундый иделәр. Сокландырганы да лирик геройларының шушындый була алулары аркасында!

Бу өч агым татар әдәбиятының XX йөзе соңгы чирегендә, ягъни 1970 елларыннан куәтле үсеш кичереп яшәп, татар шигъриятен монарчы күрелмәгән биеклегенә күтәрде, аны башка халыкларның әдәбиятларына иярмәүче, үз потенциаль көче белән, үз стихиясендә яшәүче итеп күрсәтә алды. Г.Тукай чорында башланып китеп, 1914 елларга чын мәгънәсендә милли юнәлешкә кереп китә алган шигъриятебез, аннары килеп, 1920–1950 еллар арасында башка әдәбиятларга ияреп алды, аларны мөмкинлеге барча кабатлады, хәтта берничә оригиналь әдипне дә биреп алды әле. Ә менә шигъриятебезнең XX йөзнең соңгы чирегендә үсеше бөтенләй башка әдәби картинаны күз алдына китереп бастырды. Татар шигърияте ашкынган атлар чабышын хәтерләткән сабантуй мәйданына әверелде. Шагыйрьләребез берсеннән-берсе көчле иде. Хәтта телләрдә сирәк янгыраган әдипнең әсәрләрен генә алып укып карасак та, аның иҗатына хәйран ителми мөмкин түгел иде. «Шартлы шигъри сурәт агымы» вәкиле Н.Гамбәр, мәсәлән, татар укучысы өчен шундыйларның берсе булды. Р.Мингалим исә, хәтта сөйләмле шигъриятне якын күрсә дә, беренчел дәрәҗәгә күтәрелеп куелды. Татар шигъриятенең һәр вәкиле диярлек сокланырлык әдип була алу зур мәртәбә иде.

Инде гомумиләштерүгә килсәк, «шартлы шигъри идеологик агым»ның реалистик пафос белән коралланган икәнлеген ассызыклап үтәргә тиешбез. Без, укучылар, аларны реалистлар буларак кабул иттек. Дөрес, «шартлы шигъри сурәт агымы» вәкилләре дә рәсми реализм кысаларында кала килделәр, әмма алар романтик пафос белән коралланган иделәр. Бу яктан бәяләгәндә, Роберт Әхмәтҗан чын мәгънәсендә романтиклыкның иң гүзәл үрнәкләрен күрсәтте. «Шартлы шигъри идеологик агым»дагы Р.Гаташны да реалист итеп күз алдына китерүе авыр иде. «Шартлы шигъри фикер агымы» вәкилләре рационализм юлыннан хәрәкәт иттеләр. Әмма бу өч агым гомуми юнәлештә барыбер дә реализм өчен тырышлык куйдылар һәм хаклы рәвештә шулай дип бәяләнеп тә килделәр. Тәнкыйть исә алар язган әсәрләрнең эчтәлеген сөйләү юлында эш итте. Шунысы да бар, ул әдипләр берсе дә чын мәгънәсендәге саф реалист түгел. Әсәрләре гүяки зиһен, акыл һәм күңел саташуыннан гыйбарәт иде. Аларның кайсы шигырен генә алсак та, һичшиксез, шушы хәл белән очрашабыз. Әдәби анализ белән эш итә белгән укучы моның шулай икәнлеген күреп, аңлап, белеп торды. Постмодернизм термины безнең фәндә юктан гына килеп чыкмады.

Соңгы вакытларда хәзерге татар әдәбиятын «сонарган модернизм» юнәлешендә хәрәкәт иттерергә теләүчеләр ул төр дөньяны танып белү һәм әдәби чагылдыру методының асылында мистицизм ятканлыгын онытып җибәрделәр булса кирәк. Бәлки акыл, зиһен, күңел саташуларына корылган шигъриятне чыннан да модернистик әдәбият дип билгеләргә кирәктер? Әмма моның белән килешүе авыр.

Алга таба безнең татар шигърияте ничек һәм нинди юллардан үсәр? Бу сорауга, шушы аналитик мәкалә чикләреннән чыкмыйча гына, бары тик бер төрле җавап бирергә мөмкин, ул – ирекле рух тантанасы юнәлешен алачак!

Шигырь гомумән дә ирекле рух тантанасына корылырга тиеш. Шундый шигърият кенә дөньякүләм масштабка чыга ала. Сиксәненче еллар башында аның орлыклары әдәбият бакчасына чәчелеп, инде ул күптән шаулап үсә дә башлагандыр? Хәер, һәр яна чор, яна дәвер шагыйрьләре ирекле рух тантанасында мәйданга чыгып, үз юнәлешләрен табалар. Монда да нәкъ шулай була бара төсле. Көндәлек җырларның эчтәлеген хасил иткән лубок шигърияте барлыкка килгән һәм үсеш алган кебек, классик юнәлешләр дә формалашып җитәрләр. Мәйдан бар, вакыт бара тора.

**Фәрит ЯХИН,**
*Казан федераль университеты профессоры*

# ТАРИХ МӘЙДАНЫНДА СӘЛҖҮК ТӨРКИЛӘРЕ

ФӘННИ-ПОПУЛЯР ОЧЕРК[1]

## Бәйсезлек өчен көрәш

X гасыр башларында Сыр-Дәрьяның урта агымындагы, Каратау (Көньяк Казакъстан) алдындагы далаларда төрки-угыз кабиләләре гомер иткән, күчмә һәм ярым утрак тормыш алып барган. Аларның саны кыпчак һәм башка төрки кабиләләр исәбенә һәрдаим тулыланып торган. X-XI йөзләрдә угызлар байтак кына кабиләләргә һәм бик күп ыруг төркемнәренә бүленә. Соңрак кабилә-ыруглар бергә кушылып эре-эре берләшмәләр хасил була. Алар «ил» дип аталган. Ил башында «йабгу»[2] титулын йөрткән юлбашчы торган. X гасырның икенче яртысында аеруча зур берләшмәне (илне) угызларның кынык кабиләсеннән чыккан Сәлҗүк ибне Тукак җитәкли. Ул тарихка үз исемендәге династиягә нигез салучы күренекле зат булып кереп калган, ә бу династия варисларын сәлҗүкләр дип атап йөрткәннәр.

X гасыр азакларында байгу Сәлҗүк үз кавеме белән Мәвараэннәһергә (Әму-Дәрья белән Сыр-Дәрья елгалары арасындагы җирләр), аерым алганда, Сыр-Дәрьяның түбән агымындагы далаларга үтеп керә, Җәнд (Дженд)[3] каласын кулга төшерә. Мәвараэннәһер җирләре Габбасыйлар халифәлегенә кергәнгә күрә, IX гасыр урталарына анда гарәб халкы ишәя. Гарәбләрнең Урта Азия аша Кытайга сәүдә юллары җанлана. Болар барысы да Әму-Дәрья буендагы калаларда, халык күп тупланган башка урыннарда мәчетләр төзүгә зур этәргеч бирә. Шулай итеп, төрки-угыз кабиләләренең Ислам дөньясына килеп керүе мөселманлыкны кабул итүне тизләткән булырга тиеш. Һәрхәлдә, 920-960 елларда алар барысы да диярлек ислам динен кабул итә.

X гасыр ахырында Мәвараэннәһергә Көнчыгыштан төрки-караханидлар гаскәре бәреп керә. Бохараны яулап ала. Багдад тарафыннан куелган Нух ибне Мансурның (саманидлар династиясеннән) мәркәзне кире кайтарырлык көче булмаганлыктан, ул ярдәм сорап сәлҗүкләргә мөрәҗәгать итә. Сәлҗүк бәй угылы Исраил җитәкчелегендә саманидларга ярдәмгә атлы гаскәр җибәрә. Бергәләп хәрәкәт итеп, алар Бохараны азат итәләр. Әмма 999 елда караханидлар ханы Наср I мәркәзне янә тартып ала. Алга таба, соңгы саманид Әбу Ибраһим Монтасир сәлҗүкләр белән берлектә караханидларны берничә мәртәбә кыйнап ташласалар да, бу барыбер тулы җиңүгә китерми. 1005 елны Әму-Дәрья буендагы чираттагы бәрелештә саманидларның зәгыйфьләнгән гаскәре тар-мар ителә, ә Монтасир үзе яу кырында һәлак була. Нәтиҗәдә саманидлар дәүләте таркала, аның Әму-Дәрьядан төньякта һәм төньяк-көнчыгышта яткан элеккеге биләмәләре (Мәвараэннәһер һ.б.) караханидлар кулына эләгә, ә Әму-Дәрьядан көньякта һәм көньяк-көнбатыштагы өлкәләре (Хорасан, хәзерге Әфганистан һ.б.) Мәхмүд Газнәви (988-1030) тарафыннан тартып алына.

[1] Мәкаләдә Р.Т.Телботның «Селджуки. Кочевники – завеватели Малой Азии» (М., 2004), Р.Н.Бәзертдиновның «Татары, тюрки – потрясатели вселенной» (К., 2005), Т.Ю.Ирмиеваның «История мусульманского мира. От Халифата до Блистательной Порты» (Челябинск, 1996), Всемирная история. Т.III. (М., 1957) хезмәтләре файдаланылды.

[2] «Йабгу» («байгу», «җабгу») титулы ау кошлары «лачын» яки «карчыга» дигәнне аңлата.

[3] Бүгенге көндә каланың хәрабәләрен Сыр-Дәрьяның уң як ярында, хәзерге Кызыл Урда шәһәреннән ерак булмаган урында күрергә мөмкин.

Багдад хәлифәсе әл-Кадыйр (991-1031) бу җирләр белән идарә итүне газнәвиләр династиясе хакиме Мәхмүд Газнәвигә тапшыра. Караханидлар тарафыннан яулап алынган Әму-Дәрья белән Сыр-Дәрья елгалары арасындагы далаларга Көнчыгыш Төркестаннан, Җидесу һәм Кашгар өлкәләреннән күпләп карлык, ягма, чыгыл төркиләре агыла башлый. (Сүз уңаенда, караханидлар династиясе башында нәкъ менә чыгыл төркиләре торуын әйтеп үтик). Көчеп килүчеләр ин шәп көтүлекләргә ия була, ә бу исә сәлҗүкләрне авыр хәлгә куя. Күп тә үтми алар караханидлар кул астында кала.

***

Сәлҗүк бәй үз кавеменең караханидларга бәйле калуын күрмәгәндер, мөгаен. Ул бик картаеп 107 яшендә Җәнд каласында дөнья куя. Аның Исраил, Микаил, Юныс һәм Муса дигән дүрт угылы кала. Борынгыдан килгән гадәт буенча «йабгу» титулына олы улы Исраил ия була. 1025 елда караханидлар белән газнәвиләр арасында сугыш башланып китә. Сәлҗүкләр караханидларга бәйле булганлыктан, бу сугышта алар ягында торып катнашырга мәҗбүр булалар. Бер бәрелеш сәлҗүкләр өчен бик күңелсез тәмамлана – бу көнне йабгу Исраил бине Сәлҗүк газнәвиләргә әсирлеккә эләгә. Мәхмүд Газнәви аның белән назланып тормый: богау кидереп ерак Һиндстандагы Каланҗар кальгасына ябып куя. Ыругдашлары аны коткарырга бик тырышып карасалар да, булдыра алмыйлар. Уңышсызлыкны белгәч, Исраил ирекә мондый эчтәлектәге хат җибәрә: «Миңа бүтән өмет итмәгез. Энеләремә сәламемне һәм үч алуларын теләвемне җиткерегез...» Исраил зинданда җиде ел үткәрә, бик күп җәфа чигеп, 1032 елда чит-ят җирдә ятып кала.

Мәхмүд Газнәви сәлҗүкләрне эзәрлекләп, аларның көтүлекләренә басып керә, биниһая мал-мөлкәт, тоткыннар алып китә. Караханидларга да зур зыян салына. Мәхмүд Газнәви яу йөргәндә күп санлы сәлҗүк-угыз кабиләләренә тап була һәм киләчәктә аларның үч алу ихтималын күздә тотып, таратып зәгыйфьләндерергә карар кыла. Шул максатта үзенә хәрби хезмәт итү һәм яңа көтүлекләр өчен салым түләү шарты белән дүрт мең гаиләне Әму-Дәрья аша чыгарып, Хорасан өлкәсенең көнчыгыш чикләрендәге Данданакан тирәләренә күчереп утырта.

Исраил үлгәннән соң кабиләләр белән җитәкчелек итү аның бер туганы Микаилга күчә. 1029 елда аңа ике угылы – Тогрул бәк, Дауд бәк (соңрак ул үзенә Чагры исемен ала) һәм аналары ягыннан бертуган Ибраһим ибне Йинал белән газнәвиләрдән үч алырга бик саллы сәбәп килеп чыга. Эш шунда ки, газнәвиләр гаскәрендә килешү нигезендә ялланып хезмәт иткән сәлҗүкләрнең хәрби төркемнәре баш күтәрә: алар тиешле акчаны түләмәү аркасында гаскәр башлыклары боерыкларын үтәүдән баш тарта. Моңа җавап итеп, газнәвиләр сәлҗүкләрнең барлык хәрби төркем башлыкларын, шул исәптән Сәлҗүк бәй оныгы Йосыфны җәзалап үтерәләр.

Газнәвиләргә каршы яу сәфәренә чыгар алдыннан Микаил Багдад хәлифәсе әл-Кадыйрга Хәлифәлекнең мондагы биләмәләрендә хөкем сөргән башбаштаклыкны бәян итеп, вакыйгаларга үз карашын да белдереп, хат юлларга җөрьәт итә. Хәтта ул шулай ук хәлифәгә тугры булуына ышандыра һәм гаделлекне торгызу максатында газнәвиләргә каршы изге көрәштә аның фатихасын сорый. Сугыш алмашынучан уңыш белән шактый еллар дәвам итә. Башлангыч чорда Микаил үзен корбан иткән булса кирәк, чөнки 1030 елда гаскәрләр белән Чагры бәк һәм Ибраһим җитәкчелек итүе теркәлеп калган. Ә Микаилның олы улы Тогрул бәк хәрби хәрәкәтләр башлануга ук, ягъни шул ук 1029 елда әсир төшә, 5-6 ел гомерен зинданда үткәрә. Тик абзасы Исраилдән аермалы буларак, ерак Һиндстанда түгел, ә газнәвиләр мәркәзе Газни каласында.

1035 еллар башында сәлҗүкләр берләшмәсенә хәзерге Үзәк һәм Көнбатыш Казакъстаннан чыккан угызлар, кыпчаклар һ.б. төрки кабиләләренең яңа төркемнәре килеп кушыла. Шактый тулыланган көчләр башында Муса, әсирлектән котылган Тогрул бәк һәм Чагры бәк тора. «Байгу» титулын баштарак Муса йөртсә дә, соңыннан бу титулга гайрәте, алдан күрүчәнлеге белән аерылып торган Тогрул бәк ия була. Шул ук елның июлендә сәлҗүкләрнең 10 меңләп җайдагы

Әму-Дәрья аша чыгып, Хорасандагы Мерв (хәзерге Мары) һәм Ниса калалары тарафына кузгала. Мәхмүд Газнәви вафат булу сәбәпле, хәрби хәрәкәтләр белән житәкчелек итүче улы Масуд аларга каршы үзенең иң тәҗрибәле һәм кыю әмире Бәктуды житәкчелегендә чама белән 20 меңлек гаскәр җибәрә. Бәрелеш Ниса тирәләрендә килеп чыга. Газнәвиләр сәлҗүкләр лагеренә һөҗүм итүгә, тегеләре бернинди каршылык күрсәтмичә диярлек, чатырларын, олауларын ташлап, ком чүленә чигенеп күздән югала. Газнәвиләр исә, дөньяларын онытып ыстандагы мал-мөлкәткә ябырыла һәм талау белән шундый мавыгып китә ки, сәлҗүкләрнең яшеренгән урыннан ничек килеп җитүен сизми дә калалар. Сәлҗүк жайдакларына югалып калган, зур табышка өметләнгән әмир атлыларын тураклап ташлау әллә ни кыенлык тудырмагандыр, мөгаен.

Җиңүчеләр кулына ганимәт малы (трофей) сыйфатында Масудның ун мең динарлык казнасы, олаулары белән бихисап сугыш кирәк-яраклары, күбә киемнәр, сугыш атлары эләгә. Сан ягыннан сәлҗүкләрдән ике тапкыр диярлек өстенрәк булган, баштанаяк коралланган Масуд гаскәренең хурлыклы җиңелүе, шул хәтле матди байлык югалтуы Газнидә шаккатыргыч тәэсир калдырып, чын мәгънәдә аяз көнне яшен суккандай кабул ителә. Килешү шартлары да Масуд мин-минлегенә бик каты китереп суга, чөнки Хорасанның төньяк өлкәләре сәлҗүкләргә күчә.

Аталары Микаил үрнәгендә Тогрул белән Дауд (Чагры) бәкләр дә үзләрен Габбасый хәлифәләре яклы булуын игълан итәләр. Моңа җавап рәвешендә икенче елны яңа хәлифә әл-Каим (1031-1075) сәлҗүкләр кул астына күчкән биләмәләрне рәсмиләштереп, аларны шундагы Дихистан, Ниса, Фәрава калалары хакимнәре итеп билгели. Икесе дә хакимлек билгесе булган ике очлы башлык, зиннәтле җилән белән байрак ала. Шуның өстенә төрки егетләренең иң зур хыялы булган иярләнгән гарәб чабышкылары, алтын белән бизәлгән бил каешлары, шулай ук утызар кисәк кыйммәтле кытай ефәге белән бүләкләнәләр.(Ул заманнарда кытай ефәге валюта урынына йөргән – Г.Г.). Шуны да әйтергә кирәктер, сәлҗүкләрнең эшләре уңышлы барган саен, шуна бәрабәр көчләре дә арта бара. Әлеге җиңүдән соң да Төркестан һәм Мәвараэннәһердән Хорасанга андагы кабиләләрнең яңа төркемнәре күчеп килә. Шуңа бәйле рәвештә вакыйгалар тагын да куерып китә. Эш шунда ки, 1036 елның ноябрендә сәлҗүк башлыклары Мерв, Серахс, Абиверд тирәләрендә, ягъни үз биләмәләреннән көньяктарак яткан җирләрдә газнәвиләр гаскәрендә хезмәт итү шарты белән өстәмә көтүлекләр бирүне сорап Масудка мөрәҗәгать итәләр. Алар үзләренең үтенечен, Хорасанга яңадан-яңа кабиләләр өстәлә барганга күрә, көтүлекләрнең житешмәве белән аңлаталар.

Сәлҗүк башлыкларының яңа дәгъваларыннан тәмам ачуы кабарган Масуд үтенечкә колак салу түгел, аларга яңа сугыш игълан итә. Хәрби хәрәкәтләр башлана. Газнәвиләрнең гаскәр сафларында сугыш филләре дә булганга күрә, акрын кыймылдаучы зур һәм килбәтсез армиягә каршы сәлҗүкләрнең бер урыннан икенче урынга тиз күчеп йөри торган жайдак төркемнәре хәрәкәт итә. 1037 елның язында Моргаб үзәнлегендә ике арада каты бәрелеш була. Нәтиҗәдә Мерв каласы сәлҗүкләр кулына күчә. Газнәвиләр бу югалту белән килешә алмыйлар, әлбәттә. Һиндстанда яу йөргән Масуд үзенең әмиренә Мервны кире кайтару бурычы куя. 1038 елның 30 маенда әмир гаскәре Нишапур юлы белән Серахс тарафына кузгала. Гаскәрләр 10 июньдә очраша. Серахс капкасы төбендә көн буена сузылган орышта газнәвиләр янә җиңелә. Яубашы 20 жайдагы (тән сакчылары) белән Герат ныгытмасына кереп бикләнә. Әлеге бәрелештән соң ике атна вакыт үткәч, Нишапур капкасы янына 200ләп жайдак озатуында Тогрул бәкнең бертуганы Ибраһим ибне Йинал килеп туктый. Ул каланың хакиме Әбү әл-Сәидкә төп көчләрнең менә-менә килеп җитәргә тиешлеген хәбәр итеп, бирелергә тәкъдим итә. Мәчетләрдә хөтбәне Масудка түгел, ә Тогрул бәк исеменә укырга куша. Озак та үтми олы капка ачылып китә һәм Тогрул бәкнең алдынгы төркеме шәһәргә килеп керә. Моннан соң җомга намазларында, дини бәйрәмнәрдә хөтбә бары тик Тогрул бәк исеменә генә укыла башлый.

## Сәлҗүкләрнең мөстәкыйль дәүләте барлыкка килү

Әлеге вакыйгалардан соң ике арада үзгәрүчән уңыш белән тагын берничә бәрелеш булып ала. Әмма Масудны һәлакәткә китергән вакыйга дип, һичшиксез, Данданакан[4] тирәсендәге хәлиткеч орышны атарга кирәктер. Өч көн дәвам иткән канкойгыч бәрелештә газнәвиләрнең 100 меңлек гаскәре тар-мар ителә, ә барлык хәрби милке җиңүчеләр кулына эләгә. Масуд үзенең йөзләп җайдагы белән яу кырыннан качып китеп, көчкә үлемнән котылып кала. Газнигә кайтып егылгач, тәхет варисы итеп улы Мәүдүдне билгели, ә үзе кайгыдан тәмам көчтән язып, хәмер эчүгә бирелә. Җинелү хурлыгын күтәрә алмаган Мәүдүд исә гаскәр туплап инде ничәнче тапкыр үч алу теләге белән сәлҗүкләргә каршы кузгала. Әмма газнәвиләрнең эше бу юлы да уңмый. 1043 елда Бәлх тирәләрендә Тогрул белән Чагры бәкләр тарафыннан алар тагын җиңеләләр. Аннан чират Хорезмга җитә. Нәтиҗәдә, Үргәнечтә чолганышта калган хорезмшаһ Исмәгыйль Хандан ибне Алтынташ та бирелергә мәҗбүр була. Шулай итеп, Төньяк-Көнчыгыш Иран (Хорасанны да кертеп), Хорезм өлкәләренә ия булу сәлҗүкләргә мөстәкыйль дәүләт төзергә мөмкинлек бирә.

Газнәвиләр байтак биләмәләрен югалта. Аларның кул астында бары тик төп биләмәләре: Газни, Кабул, Кандагар өлкәләре (хәзерге Әфганстанда) һәм Төньяк Һиндстанда Пәнҗаб өлкәсе генә кала. Яңа җирләрдә кабилә башлыклары Тогрул бәккә үзләренең тугрылыгын белдереп ант итәләр. Сугыш барышында сәлҗүкләргә теләктәшлек белдергән кабиләләр өч елга салым түләүдән азат ителә. Ә Мәхмүд Газнәви тарафыннан кайчандыр Әму-Дәрьяның аръягына күчереп утыртылган гаиләләр кире туган якларына әйләнеп кайта. Тогрул бәк соңгы вакыйгаларны тасвирлап, газнәвиләр династиясен бәреп төшерү сәбәпләрен аңлатып, хәлифә әл-Каимга хат юллый. Җиңү хәбәрен Мәвараэннәһердәге караханидлар ханына да җибәрәләр.

1040 еллар башында Хорасаннан газнәвиләрнең соңгы хәрби төркеме китеп баргач, яңа барлыкка килгән дәүләтнең мәркәзе итеп Мерв каласы сайлана (1043), ә Чагры бәкне Тогрул бәк Хорасанның хакиме итеп билгели. Соңыннан хәлифә әл-Каим Чагры бәккә Малик әл-Мөлек («хакимнар хакиме») титулын бирә һәм ул шушы дәрәҗәле исем астында газнәвиләр белән сугыш хәрәкәтләрен уңышлы гына дәвам итеп, кул астына кергән яңа җирләр белән үзе үлгәнче (1059) хакимлек итә.

***

Тогрул-Чагры бәкләрнең Данданакан тирәсендәге тарихи җиңүенең әһәмияте сәлҗүкләрнең яңа мөстәкыйль дәүләте барлыкка килүе белән чикләнми. Бу вакыйга Аттиладан, төрки каганатлардан соң тарих мәйданына янә күтәрелеп чыккан сугышчан (Гумилев әйтүенчә, «арысланга охшаш сыйфатлы») төрки кабиләләренә яңа җирләр яулап алу өчен көнбатышка юл ачылу белән дә мөһим. Әгәр Чагры бәк яулары нигездә көньякка, хәзерге Әфганстанда газнәвиләргә каршы юнәлтелсә, Тогрул бәк үзенең походларын Иранны тулысынча яулап алу максатында җәелдерә. 1040 еллар уртасында ул Буидлар династиясенең[5] Көнбатыш Ирандагы биләмәләренә үтеп керә, Гурган, Мазандаран якларында уңышлы хәрәкәтләр алып барып, Рәй каласын[6] кулга төшерә. Соңыннан ул каланы төзекләндерергә әмер бирә һәм аны Мерв урынына дәүләтнең башкаласы дип игълан итә. Аннары бу шәһәр Иракка һәм Кавказ арты илләренә бәреп керер өчен терәк пункт буларак та файдаланыла.

1045 елда Тогрул бәк Рәйдән көнбатыштарак урнашкан Хамадан шәһәренә ия була, ә 1050 елда аның алдында үзенең капкаларын Иранның иң бай һәм эре шәһәрләреннән берсе — Исфахан ача. Шул ук елны Тогрул бәк башкаланы тагын күчерә, бу юлы әлеге Исфахан шәһәренә. 1053 елда сәлҗүкләр карамагына Иранның көньягында Шираз каласы күчә. Ә бу инде Иранның тулысынча Сәлҗүкләр кул

[4] Данданакан – ныгытылган шәһәрчек. Бүгенге көндә аның таралып яткан хәрабәләрен Мары шәһәреннән (Төрекмәнстан) 33 чакрымда күрергә була.
[5] Буидлар династиясе Иран территориясендә 932-1062 елларда хакимлек итә.
[6] Рәй – борынгы Иранның иң эре шәһәрләреннән берсе. Хәрабәләре хәзерге Тәһраннан 8 чакрымда.

астына керүен аңлата. Шулай итеп, Иракка — андагы дөнья мөселманнары мәркәзе Багдадка — туры юл ачыла.

Бу чакта Буидлар династиясенең соңгы хакиме әл-Мәлик Иранның фарсы өлкәсендә тупланган була, ә Багдад белән аның кешесе — хәлифә янында вәзир булып торган, бер үк вакытта әмирләр әмире (иң югары хәрби дәрәҗә) сыйфатында гарнизон башлыгы вазифаларын да үтәгән — әл-Бәсәсири идарә иткән. 1055 елда Багдад диварлары каршында Тогрул бәкнең атлы гаскәре пәйда булгач, гарнизон башлыгы әл-Бәсәсири бәрелешкә керүнен мәгънәсезлеген күреп һәм бирелү таләбенә буйсынып, шәһәр капкаларын ачарга куша. Бер төркем җайдаклары алдында менә дигән гарәб атында Тогрул бәк тантаналы төстә күп санлы гавамның көчле хуплау авазлары астында Багдадка килеп керә.

Тогрул бәк әл-Каимга үзенең элеккечә Габбасыйлар династиясе хәлифәләренә тугры калуын, аларга һәрвакыт ярдәм күрсәтергә әзер булуын белдерә. Әл-Каим үз чиратында Тогрул бәккә хәлифәлек җирләре белән идарә итү хокукы биргән рәсми кәгазь тапшыра, бер җомга намазында хөтбәне аның исеменә укыгач, зиннәтле тәхеткә утыртып «Көнчыгыш һәм Көнбатыш илләре солтаны» дип игълан итә, иңбашына кыйммәтле җөббә сала. Шулай итеп, бу югары дәрәҗәгә төрки-угызлардан иң беренче булып Тогрул бәк ия була. Әл-Каим сүзләренә колак салмыйча, Буидлар тарафыннан иң мөһим урыннарга билгеләнгән түрәләр куып таратыла. Бушаган урыннарга, хәлифә белән килештереп, Тогрул бәк кешеләре билгеләнә. Бүтән яңалыклар да кертелә. Хәлифәлектәге үзгәрешләр әл-Бәсисиринең җен ачуларын чыгара. Гәрчә бу үзгәрешләрдә хәлифәнең Тогрул бәк ягында булуын белсә дә, ул үзенең гарнизондагы тарафдарларына таянып, яңа солтанга каршы баш күтәрә. Көндәшен Тогрул бәкнең энесе Ибраһим Йинал кулы белән бәреп төшерергә ниятли. Шул максатта яңа солтан Ибраһимнан арынырга тели дигән имеш-мимеш тарата. Тегесе бу хәбәрне ишетүгә, аны-моны уйламастан, фетнәчеләр гаскәрен җитәкләп, абыйсы өстенә китә. Тогрул бәк аңа каршы чыга һәм Рәйгә килеп җиткәч, Хорасаннан бертуганы Чагры бәкнең улы Алып Арысланны чакырып ала. Берләшкән көчләр белән алар шактый тиз арада фетнәчеләрне тар-мар итә. (Ибраһим Йиналның әлеге бәрелештән соңгы язмышы билгеле түгел - Г.Г.). Бу җиңүдән соң күп тә үтми, әл-Бәсисири гаскәрендә хезмәт иткән бәдәвиләр (күчмә гарәпләр) Тогрул бәк ягына чыга. Гаскәреннән дә мәхрүм калган әл-Бәсисири Мисырга качып китә. Анда ул Фатыймиләр династиясе хакиме әл-Мостансир тарафыннан теләктәшлек табып, яллы гаскәр туплауга ирешә һәм югалткан хакимлеген кире кайтару максатында Багдад тарафына кузгала. Әмма мәркәзгә килеп житмәстән, Куфа шәһәрчеге тирәсендәге бәрелештә һәлак була. 1058 елда әл-Каим белән Тогрул бәк арасындагы җылы мөнәсәбәтләр тагын якыная: хәлифә солтанның энесе Чагры бәкнең кызы Хәдичәгә, ягъни Алып Арысланның сеңлесенә өйләнә. Тогрул бәккә әҗәл бик вакытсыз килеп җитә. Ул 1063 елның 4 сентябрендә хәлифә кызы белән никахлашу алдыннан баш миенә кан йөгерүдән кинәттән дөнья куя. Аңа бу чакта нәкъ 70 яшь тулган була. Шул рәвешле, күренекле дәүләт эшлеклесе, оста гаскәрбаш Тогрул бәк үзеннән соң чикләре Әму-Дәрьядан алып Евфрат елгасына кадәр җәелгән гаять киң мәйданны биләгән дәүләт төзеп калдыра.

## Дәүләт чикләренең киңәюе

Тогрул бәкнең ир балалары булмаганлыктан ул үзенең дәвамчысы итеп Чагры бәк уларыннан берсен — яшь Сөләйманны билгели. Әгәр дә Алып Арысланның абзасы Тогрул бәккә тугры хезмәт итүен искә төшерсәк (мәсәлән, Багдад фетнәчеләрен бастырганда), бу аңа карата гаделсезлек булган. Шуңа да карамастан, бәлки ул энесенә дә тугры хезмәт иткән булыр иде, тик көтелмәгән хәл килеп туа: тәхеткә Исраил улы Котылмыш дәгъва белдерә һәм хакимиятне тартып алу нияте белән гаскәр башында Сөләйманга каршы чыга. Алып Арыслан дәгъвачыга каршы чыга. Гаскәрләр Дамган дигән җирдә очраша. Бәрелеш Котылмыш өчен зур фаҗига белән тәмамлана. Үзара тураклашу ин кызган бер мәлдә ул ат өстеннән егылып төшә һәм башы ярылып шунда ук җан тәслим кыла. Бу вакыйгадан соң Казвин шәһәрендә

уздырылган корылтайда Алып Арыслан тантаналы төстә солтан дип игълан ителә, ә Багдад хәлифәсе бу сайлауны танып, аңа Әдуд әд-дәүләт («дәүләт яклаучысы») дигән мактаулы титул тапшыра. Алып Арысланның исеме җисеменә шул хәтле тәңгәл килүе тарихта бик сирәк хөкемдарга насыйп булгандыр. Ходай биргән озын буе, биек баш киемнәренә өстенлек бирү сәбәпле, аның кыяфәтен тагын да мәһабәтрәк күрсәткән. Тагын бер үзенчәлеге: ул шундый озын мыек җибәргән була ки, кыргый җәнлекләргә, киек кошларга ауга йөргәндә җәядән атканда комачауламасын өчен мыек очларын баш артына бәйләп куярга мәҗбүр булган. Гомумән, бу пәһлеван килеш-килбәте белән дә, яу кырында күрсәткән кыюлыгы-тәвәккәллеге аркасында да замандашлары арасында көчле тәэсир калдырган.

Алып Арыслан 1064 елда Рәй каласыннан (Тогрул бәк әле 40-50 нче елларда туздырып йөргән, мәгәр кулга төшерергә өлгермәгән) Византия империясенең көнчыгыш чикләренә яу чаба. Гаскәр Әзәрбайҗанны үтеп, Ислам дөньясының көнбатышта иң соңгы форпосты Нахичевань кирмәненә килеп җитә. Монда Карс елгасын кичеп чыккач, чирү икегә бүленә: солтан үзе Кавказдагы Албания аша Грузиягә юнәлә, ә улы Мәлик шаһ Византиянең Әрмәнстандагы ныгытмаларын яуларга керешә. Соныннан ул атасы гаскәренә килеп кушыла. Византиянең союздашы Грузия озак каршылык күрсәтә алмый. Төп ныгытмасы Шәфид шәһәре бирелергә мәҗбүр булгач, грузиннар патшасы Баграт IV җиңелүен танып, Тогрул бәктән соң туктатылган салымны янә түләү шарты белән килешүгә кул куя. Аннары солтан көньяк тарафка хәрәкәт итеп, Византиянең эчке биләмәләренә юлны бикләп торган Ани кальгасына килеп җитә. Өч яктан Арпачай елгасы уратып аккан биек кыя өстендәге ныгытма алып булмастай күренә. Византиялеләрнең күп санлы гарнизоны торган әлеге ныгытма алдында мөселман гаскәре шактый озак тоткарлана. Ярсулы һөҗүмнәр зур югалтулар белән кире кайтарылып тора. Баскычлардан үрмәләп менүчеләргә дивар өстеннән кайнап торган су һәм сумала коя, колгалар белән этәреп баскычларны аудару аркасында бик күп яугир сафтан чыга, корбан була. Бары тик авыр тараннар белән бертуктаусыз бәреп диварның бер өлешен җимереп төшергәч кенә вазгыять үзгәрә. Камаучылар, дәррәү алга ыргылып, кальгага бәреп керә. Урам сугышларында византиялеләрнең каршылык күрсәтүе сындырыла. Җиңүчеләр кулына меңәрләгән тоткыннар, ганимәт малы эләгә. Юл өстендә яткан Карс шәһәре каршылык күрсәтмичә бирелә. Гаскәр Карстан көньякта Византия йогынтысында булган Антиохия белән Эдесса калаларына килеп җитә. Аларны да бөлгенлеккә төшергәч, Алып Арыслан кайту ягына борыла. Солтан 1065 елда янә Кече Азиягә (Анадолу) бәреп керә. 1067 елда Левитания, Севастия тирәләрендә аңа каршы чыккан византиялеләр армиясен пыр туздыргач, ул Кесариягә (Кайсери) һөҗүм итә. Уңышлардан рухы күтәрелгән солтан 1069 елда Византиянең төп биләмәләренә үтеп керә. Андагы Иконий (Конья) каласын кулга төшерә, ә тагын бер елдан чирүен корабларга утыртып, Эгей дингезендәге Хонас портына десант төшерә.

***

Бу чакта Византиядә император Роман IV Диоген (1067-1071) идарә итә. Төркиләрнең өзлексез дәвам итеп килгән һөҗүмнәреннән тәмам гаҗиз булган император бу бәладән котылу максатында Әрмәнстанны чик буе зонасына әйләндереп, аны үтеп булмаслык киртә ясау карарына килә. Ә моның өчен иң әүвәл андагы мөселман гарнизоннарыннан арынырга кирәк була. Шуның өчен ул төп армиясе җитәрлек булмаганлыктан, империянең төрле кавем-кабилә вәкилләреннән, зур хәрби табыш вәгъдә итеп, яллы гаскәр тупларга мәҗбүр була. Нәтиҗәдә, скандинавия норманнары (варяглар), франклар, славяннар, чиркәсләр, грузиннар, болгарлар, куманнар, угызлар һәм башка бәхет эзләүче авантюристлардан торган 200 мең кешедән дә ким булмаган искиткеч чуар гаскәр җыела. Роман IV армиянең сугышка сәләтлеге чамалы булуын истә тотып, гаскәр белән җитәкчелек итүне үз өстенә ала. Император Алып Арысланның бу вакытта Мисырда яу сәфәрендә йөрүеннән файдаланып һәм Әрмәнстанга көтмәгәндә бәреп керер өчен походка кузгала. Императорның Әрмәнстан чикләренә якынаю хәбәрен ишетүгә, Алып

Арыслан Мисырдагы барлык эшләрен ярдәмчесе Атсыз ибне Авак карамагына тапшырып һәм аңа шулай ук 1071 елда Байтелмөкатдәсне (Иерусалим) алу бурычын куеп, гаскәр арасыннан сайлап алынган иң кыю 15 мең җайдакны җитәкләп, ашыгыч рәвештә Мисырдан төньякка чыгып китә. Төркиләрнең ерак яу сәфәрендә йөрү гадәте буенча, һәр яугир берәр запас ат иярткән була. Евфратны ат койрыгына тотынып йөзеп чыккач, гаскәр Ирак территориясе аша Манцикерт (Маназкерт) ныгытмасына килеп җитә. (Әрмәнстанда Ван күленнән төньяктарак). Манцикерт тирәсендә исәпсез-хисапсыз чатырларны, арбаларны, утлап йөргән күп санлы ат һәм дөяләрне, гаскәр төркемнәрен күргәч, Алып Арыслан башта низагны тыныч юл белән хәл итү омтылышы ясап карый. Шул максатта ул император станына килешү тәкъдим итеп, үзенең ышанычлы кешесен җибәрә. Мәгәр, Диоген масаеп, килешү Рәй каласында гына төзелергә мөмкин дип, тәкъдимне кире кага.

Көчләрнең чагыштыргысыз дәрәҗәдә тигез булмавына карамастан, солтан бәрелештән баш тартырга уйламый. Шул турыда солтанбикә белән баш вәзире Низам әл-Мөлеккә (бу исем вәзирнең титулы: « дәүләт эшләрен җайга салучы» дигәнне аңлата) хат җибәрә: «Мин булган кадәр гаскәрем белән дошман өстенә барам. Әгәр исән калсам мин моны Ходай игелеге, ә инде Ислам дине өчен шәһит китсәм, анысын да Аллаһы Тәгалә рәхимлеге дип кабул итәрмен. Варисым итеп улым Мәлик шаһны билгелим», – диелә бу хатта. Ул бер үк вакытта Багдадка, хәлифә әл-Мәлик I гә дә вазгыятьне аңлатып һәм аның фатихасын сорап хат юллый. Хәлифә хатны алуга мөселман гаскәренең җиңүен теләп, мөнбәрдән дога укый һәм аның текстын барлык мәчетләрнең имам-хатыйпларына таратып чыгарга боерык бирә.

1071 елның 19 августында иртәнге намаздан соң Алып Арыслан хәлиткеч һөҗүмгә күчә. Бәрелеш башлангач, солтан төркиләрнең сыналган хәрби алымын куллана: дошман армиясенең төп көчләрен чигенгән булып атлы гаскәргә алышырга кулайрак булсын өчен Манцикерттан ерак булмаган үзәнлеккә алдап кертә. Ә караңгы төшкәч император өчен күңелсез хәл башлана: акчага ялланган угызлар, болгарлар, куманнар һәм башка төркиләр (ә аларның байтагы сәлҗүкләр белән кардәш-ыру мөнәсәбәтләрендә торган) туганнарына каршы бармас өчен, лагерьны ташлап китәләр. Икенче көнне иртән иртүк орыш янә башлана. Беренче мизгелләрдән үк мөселман гаскәренең өстенлеге күзгә ташлана. Ярсулы һөҗүмнән каушап калган византия гаскәренең сафлары бозыла һәм дошман вак төркемнәргә бүленеп, төрлесе төрле якка таралып качып китә. Килеп туган ыгы-зыгыда алар императорны саклау бурычын да оныталар. Хәтта үзенең тән сакчылары тарафыннан да ташлап калдырылган хәсрәт император әсир алына. Византиялеләр коточкыч җиңелүгә дучар ителә. (Шуннан соң бу сугыш турында сүз чыкканда, аны бары тик «теге һәлакәтле көн» дип кенә искә төшерә торган булганнар). Җиңүчеләр кулына император казнасы, аның барлык кыйммәтле әйберләре, олаулар, исәпсез-сансыз тоткыннар, көтүләре белән ат һәм дөяләр, сугыш кирәк-яраклары, ныгытмаларны камау җиһазлары һ.б. бихисап хәрби табыш эләгә. Солых шартлары бик кискен куела. Император үзен тоткынлыктан азат итү өчен бер миллион динар йолым түләргә мәҗбүр була. (Ул аны азат ителгәч, Константинопольдан җибәрә). Моннан тыш 50 елга килешү, әсирлектә газап чиккән мөселман яугирләрен азат итү, беренче зарурлык килеп чыгуга солтан армиясенә билгеләнгән санда гаскәр бирү, ел саен 360 мең динар күләмендә салым түләү һәм Анадолуның зур өлешен җиңүчеләргә калдыру турындагы шартнамәгә имза салына. Шуның өстенә, Манцикерттан тыш сәлҗүкләргә элегрәк император кул астында калган Анадолуда Эдесса, Сүриядә Мәнбиҗ һәм Антиохия кальгалары күчә.

Роман IV Диоген Константинопольга әйләнеп кайткач, күп тә үтмәстән тәхеттән бәреп төшерелә, ә аның урынына алмашка килгән Михаил дигән дәгъвачы шартнамәне үтәүдән баш тарта. Моңа җавап итеп мөселман гаскәре Византиянең әле Анадолуда сакланып калган биләмәләренә яу чаба, аларны да бөлгенлеккә төшерә. Бу хәрби сәфәрне инде Алып Арыслан түгел, ә Тогрул бәкнең туганы, өстәрәк телгә алынган Котылмыш улы Сөләйман җитәкли, чөнки солтан бу чакта Урта Азиядә чираттагы яу сәфәрендә була. Гомумән алганда, сәлҗүк төркиләрнең уңышлы хәрби хәрәкәтләре нигезендә Кече Азия тулысынча диярлек Византия

императорлары кулыннан ычкына. Азат ителгән территорияләрдә Сөләйман ибне Котылмыш тарафыннан башта Сәлҗүкләр дәүләтенең бер өлешен тәшкил иткән Рум солтанатына нигез салына. Сөләйман үзенә солтан титулын ала. Яңа дәүләтнең мәркәзе дип Мәрмәр диңгезе буенда урнашкан Никея каласы игълан ителә (1078). Ә 1086 елда Сөләйман солтанатны бәйсез дәүләт дип белдерә.

Манцикерт янындагы сугыштан соң, икенче елны Алып Арыслан Мәвараэннәһер тарафына, андагы Сәмәрканд белән Бохараның баш күтәргән хакиме Шәмси әл-Мөлеккә «сабак бирү» максаты белән яуга чыгып китә. Аллдагы вакыйгалар күрсәткәнчә, бу солтанның соңгы хәрби сәфәре була. Әму-Дәрьяны кичеп чыккач, мөселман гаскәре шактый озак чолганышта тотканнан соң, караханидларның Барзан дигән ныгытмасына бәреп керә. Гарнизон башлыгы Йосыф әл-Хәрәзми бирелер алдыннан хатыны белән балаларын һәлак итеп һәм киеме астында хәнҗәр яшереп җиңүчеләр алдына чыгып баса. Аны кулларын бәйләгән килеш Алып Арыслан хозурына китереп бастыралар. Йосыф үлем җәзасына хөкем ителүен ишеткәч (җәзаны солтан үзе игълан итә), төрле ямьсез сүзләр белән солтанны мыскыл итәргә тотына. Халык алдында әйтелгән мәсхәрәләү сүзләренә аеруча нык ачуы кабарган Алып Арыслан Сакчыларга тоткынның кулларын чишәргә, ә үзләренә читкәрәк китәргә кушып, җәядән Йосыфка атып җибәрә. Әмма, ни хикмәт, заманында иң төз атучы буларак дан казанган хөкемдар бу юлы укны төбәгән җиренә тидерә алмый. Аның янындагылар бер мизгелгә каушап-югалып кала. Шуннан файдаланып, Йосыф Алып Арысланга ташлана һәм бер-ике мәртәбә хәнҗәр белән кадый. Барысы да аһ итә. Йөгереп килеп җиткән тән сакчылары әл-Хәрәзмине шунда ук тураклап ташлыйлар. Солтан тагын өч көн яши һәм 1072 елның 8 декабрендә 40 яшендә дөнья куя. Аны Мерв каласында атасы Чогрул бәк һәм абзасы Тогрул янәшәсендә җирлиләр. Шул рәвешле, солтанның соңгы яу сәфәре фаҗига белән тәмамлана, ә гаскәр максатка ирешә алмыйча, Мервка әйләнеп кайта.

Алып Арысланның хакимлеге ун ел дәвам итә. Солтан үлем алдыннан баш вәзир Низам әл-Мөлеккә үзенең варисы итеп калдырган олы улы Мәлик шаһка тугры хезмәт итүен васыять итеп калдыра. (Алып Арысланның тагын Тәкши, Аяз, Тотыш, Бүре Барс һәм Арыслан Аргун исемле ир балалары кала). Солтан Малик шаһ атасы Алып Арысланның яулап алу сәясәтен дәвам иттереп, 1072 елда әмир Атсыз ибне Уак Хәрәзми җитәкчелегендә Якын Көнчыгышка хәрби сәфәр оештыра. Әмир Палестинага үтеп керә, Рамла шәһәрен ала, Байтелмөкатдәсне чолганышта тота, ә 1076 елда Сүриянең башкаласы Димәшкъкә басып керә. Соңыннан әлеге уңышлы яулар нәтиҗәсендә Сүриядә сәлҗүк төркиләренең бәйсез биләмәләре барлыкка килә. Гомумиләштереп әйткәндә, XI гасыр ахырына Бөек мәмләкәткә әверелгән Сәлҗүкләр дәүләте үзенең сәяси йогынтысын Фатыймилар династиясе хакимлек иткән Мисырга хәтле җәелдерә. (Фатыймилар Багдадтагы Габбасыйлар һәм аларның яклаучысы сәлҗүк солтаннары белән бик каты дошманлашып торганнар. Бу чакта хәлифә әл-Каим бакыйлыкка күчкән, ә үзе урынына оныгы әл-Моктадины (1075-1094) калдырган була).

Солтан Мәлик шаһ, Мәвараэннәһер караханидлары белән күптәнге низагны хәл итү максатында, 1074 елда Урта Азиягә яу сәфәре оештыра. Мәлик шаһ шул ук елны Термез каласын ала, аннары Сәмәрқандны бирелергә мәҗбүр итә, ә каһан Шәмси әл-Мөлек әсир төшә (1075). Югары дәрәҗәле тоткынны Исфаһанга алып китәләр, әмма күп тә үтмәстән солтан аны азат итеп, кире Сәмәркандка кайтарып җибәрә. Ул 1080 елда вафат була һәм аның урынына тәхеткә энесе Хәсән Ай тәгин утыра. Хәлбуки, ул караханидларның җинелүен танырга теләми һәм солых шартларын үтәүдән (салым түләүдән) баш тарта. Шуңа күрә, 1089 елда Мәлик шаһ Исфаһаннан янә Мәвараэннәһергә яу белән китә. Солтан гаскәре Бохара, Сәмәрканд калаларын ала, караханидлар ханын әсир итә. Гәрчә күпмедер вакыттан соң Мәлик шаһ ханны азат итсә дә, ул озак яшәми, фетнәчеләр тарафыннан үтерелә. Мәлик шаһ һөҗүмне җәелдереп, Узгенд каласын кулга төшерә. Шул рәвешле, караханидлар дәүләтен шактый зәгыйфьләндереп һәм тагын да күбрәк ясак түләп торырга мәҗбүр итеп, ул бихисап мал төялгән олаулар белән Хорасанга кайтып китә. Кайчандыр сәлҗүк

төркиләрен буйсындырып торган караханид ханнары белән исәп-хисап шулай ясала.

Солтан Мәлик шаһны (титулы: «Җәләл әд-дин вә дәүләт» — «Дин вә дәүләт таянычы») әҗәл сәфәрдә, Исфаханнан Багдадка хәлифә әл-Моктади хозурына барганда куып җитә. Көтмәгәндә ул авырып китә һәм 1092 елның 19 ноябрендә дөнья куя. Мәлик шаһ үз кул астында шундый зур территорияләрне тоткан ки, бу солтанның хакимлеге азагында солтанлыкның чикләре көнбатышта Урта һәм Мәрмәр диңгезләре, көнчыгышта Сыр-Дәрья елгасы, төньякта Арал диңгезе, көньякта Персия култыгы белән Сүрия чүллегенә кадәр җиткән була. Әлеге хикмәтнең серен хәзерге тикшеренүчеләр генә түгел, шул заман, ягъни XI-XII гасырлар галимнәре дә аңлата алмаган. Дөрестән дә, ничек инде нибары ике буын эчендә ярым утрак һәм күчмә төрки кабиләләре үзләреннән һәрьяктан өстен кебек күренгән иран, византия, әрмән, грузин, көрд һәм башка кавемнәрнең регуляр армияләрен тар-мар итеп, Бөек сәлҗүкләр империясе төзи алган? Бу могҗиза бүгенгәчә сер булып кала бирә.

## Сәлҗүк төркиләрнең яшәү рәвеше

1. *Дәүләт төзелеше, җәмгыятьтәге тәртипләр.* Солтанлык дип аталган дәүләт башында чиксез хакимияткә ия булган солтан торган. Солтан вазифасына, аерым алганда, казна һәм тәхет милкен бүлү, хәрби яки дәүләт хезмәте бәрабәренә икта дип аталган җир биләү системасына ярашлы рәвештә вакытлыча яки мирас милке сыйфатында җир участоклары бүлеп бирү, дәүләт аппараты эшчәнлеген күзәтү, урыннардагы түрәләргә һәм вазифаи затларга зарланып язган шикаятьләрне тикшерү һ.б. дәүләт күләмендәге эшләр кергән. Гражданлык мәсьәләләре белән беррәттән солтан хәрби эшләр белән дә шөгыльләнгән. Әйтик, сугыш игълан итү, солых төзү, гаскәрбашларны билгеләү һәм аларны хезмәттән чыгару шулай ук солтан карамагында булган. Солтан вафатыннан соң тәхет, кагыйдә буларак, аның олы улына күчкән. Кайчакта мәрхүм гаиләсендә ризасызлык туып һәм төркиләрнең иске гадәтен искә төшереп, тәхетне солтанның абзасы яки бүтән олы туганы дәгъвалый башласа, бәхәс корал кулланып хәл ителгән. Мондый очракта тәхет җинүчегә эләккән.

Солтаннан соң хакимият баскычында икенче урында вәзир торган. (Урта гасырларда вәзир хәзерге премьер - министр вазифасына тиңләшкән). Вәзир үзәк хакимиятнең диван дип аталган югары органын җитәкләгән. Бер үк вакытта ул илдәге эчке эшләр өчен җаваплы булган, ә солтан юк чакта диван утырышлары белән җитәкчелек иткән. (Вәзир үзенең билбавында вәкаләтләр билгесе булган кара савыты тагып йөргән). Вәзирдән соң әһәмиятлелеге буенча башкомандующий саналган. Өченче урынны баш казый биләгән. (Казый — гарәпчә судья, мөселманнарның гражданлык һәм җинаять эшләрен шәригать һәм гадәт нигезендә тикшереп хөкем итүче). Баш казыйны, гадәттә, Багдадтан хәлифә билгели торган булган. Хакимият баскычының тагын да түбәнрәк басмасында эре хәрби берәмлекләрне җитәкләгән кабилә башлыклары, әмирләр урын алган. Бу рәсми затлар диванның киңәшчеләр советын тәшкил иткән. Диван утырышларында аларга аксөякләрнең (эре җирбиләүчеләрнең) йогынтылы вәкилләре дә кушылган. Эш кәгазьләре кайчакта гарәпчә язылса да, нигездә фарсы теле файдаланылган. Язуда тыныш билгеләре куелмаган. Рәсми кәгазь солтан мөһере белән расланган. XIII гасырда сәлҗүкләр монголлар кул астында калгач, дәүләт кәгазьләре төрки телдә башкарыла башлый, ә аннары күп тә үтми, ул рәсми тел буларак та кабул ителә. Гәрчә сәлҗүкләр хәлифәне дөньяви хакимияттән читләштерсәләр дә, алар элеккечә аның рухи хакимиятен хөрмәт итәләр. Үзләрен хәлифәнең тарафдарлары һәм яклаучылары дип белдереп, аңа һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер булып торалар. Рухи һәм дөньяви өлкәләр белән җитәкчелек итү билгеле бер кагыйдәгә нигезләнеп башкарылган. Әйтик, әгәр Ислам дөньясы белән идарә итү хәлифәгә һәм урыннарда ул билгеләгән дин әһелләренә тапшырылса, дәүләт идарәсенә укымышлы фарсылар, ә җирле хакимияткә, гадәттә, күпчелекне тәшкил иткән милләт вәкилләре җәлеп ителгән.

Яна хужалар буйсындырылган халыкның күнегелгән тормыш тәртибен бозарга теләмиләр, киресенчә, урыннардагы кануннарны, гореф-гадәтләрне саклап калырга тырышалар. Шуна күрә күчмә тормыш шартларындагы байтак йолаларын саклап килсәләр дә, тора-бара аларның яшәү рәвеше мөселман кавеме тәэсирендә шактый үзгәрә, тулыландырыла.

Чираттагы каланы яулап алганнан соң, җиңүчеләр иң әүвәл аның таранлардан җимерелгән саклану диварларын элекке хәленә кайтару, мәчетләре булмаганнарында Аллаһ йортлары һәм башка дини корылмалар төзү белән шөгыльләнә. Нәтиҗәдә, кала алынып күп тә үтми, аның манзарасы танымаслык булып үзгәрә. Элеккеге төссез биналар урынына биек манаралары әллә кайдан күренеп торган мәчетләр, атаклы кешеләрнең җәсәден куяр өчен төзелгән конус төбәле мәһабәт төрбәләр үсеп чыга. Шул ук вакытта тормыш шартлары да унай якка үзгәрә. Иҗтимагый-көнкүреш мәсьәләләренә зур игътибар бирелә: шифаханәләр, хастаханәләр ачыла; картларны, ятимнәрне, ярлыларны, акылы зәгыйфьләнгән авыруларны тәрбиягә алучы биналар, дини һәм дөньяви уку йортлары эшли башлый. Анда хезмәт күрсәтү бушлай, дәүләт исәбенә башкарыла.

Мисал өчен, сәлҗүкләр салып калдырган кайбер хастаханәләр Төркиядә XIX гасыр урталарына һәм хәтта Беренче бөтендөнья сугышына хәтле гамәлдә булган. Әлбәттә, биналарны янартып торганнар. Мәгълүм булганча, Анадолу минераль су чишмәләренә бик бай, ә солтан хөкүмәте бу суларның шифалыгын белгәнгә, алардан бик дөрес файдаланган: чишмәләр янында күп сыйдырышлы мунчалар (шифаханәләр) салынган, ә эчәргә махсус фонтаннар ясалган. Мондый мунча һәм фонтаннарның күбесе Төркиядә бүгенгәчә файдаланыла.

Дәүләт чыгымнары, шул исәптән телгә алынган иҗтимагый-көнкүреш ихтыяҗларын да кертеп, салым җыю, хәрби бәрелешләрдә кулга төшкән ганимәт малы һәм сәүдә итүдән тупланган керем исәбенә капланып килгән. Салым авыл һәм шәһәр халкыннан, икта яки бүтән имана җирләрен биләүчеләрдән, вакыф милкеннән, өйләнмәгән ир-атлардан җыелган. Авыл хуҗалыгындагыларга салым кош-кортка, терлек-туарга, иген уңышына салынган. Әмма дини оешмалар, диннәренә карамастан, салымнан азат ителгән. Моның өчен алар үзләренең гыйбадәтханәләрендә (мәчет, чиркәү, синагога һ.б.) солтанга һәм аның гаиләсенә исәнлек-иминлек теләп дога кылырга тиеш булганнар.

2. *Гаскәр әзерләү*. Солтанлык асылда хәрби дәүләт булганлыктан, гаскәрне даими сугыш әзерлегендә тоту изге бурыч булып саналган. Дәүләтнең һәр өлкәсе белән вәзир билгеләп куйган хәрби җитәкче идарә иткән. Хәрби җитәкчеләргә ел саен билгеле бер санда никрутлар җыеп, аларны корал белән тәэмин итү бурычы куелган була. Һәр елны яз килү белән бәрелешләрдә чыныккан яугирләр һәм яңа гына хәрби хезмәткә алынган егетләр солтан исеменнән әзерләнгән указда әйтелгән җыелу урынына килгән. Ә анда аларны хәрби җитәкче каршы алып торган. Хәрбиләр махсус мәктәпләрдә авыр һәм катлаулы хәрби әзерлек үтәргә тиеш була. Төп максат алардан менә дигән җайдак һәм җәядән атучы (укчы) ясау булганга, җәядән ату һәм тоткарлыкларны ерып чыгу күнегүләренә зур әһәмият бирелә. Хәзерлекнең икенче өлешендә хәрбиләрне ике төркемгә бүләләр һәм, иң шәпләрен сайлап алып, атлы гаскәргә билгелиләр, ә калганнарын сөнге һәм кылыч белән эш итәргә өйрәтә башлыйлар. (Болары инде җәяүле гаскәргә тәгаенләнгән булгандыр). Кыяфәтләренә килгәндә, барысында да калкан, күбесендә көбә кием, башларында очлаштырылган тимер башлык ялтырап торган. Яуга чыгар алдыннан укчылар очлыклары тешләнгән һәм кыздырып чыныктырган уклар белән тәэмин ителгән. Укларны үзләре белән йөрткән агулы матдәгә манчып атканнар. Сәлҗүкләрнең хәрби уңышларына, төрки кавемнең табигый кыюлыгыннан, гаскәрләрнең сугыш осталыгыннан тыш, коралларның камил булуы зур роль уйнаган. Бик күп хәрби җитәкчеләр ике ягы да үткен кылыч тагып йөргән, укчылар исә чит гаскәрләрдә күренмәгән аерым сыйфатларга ия җәяләр белән коралланган булган. Мондый җәяләрдән аткан ук 700 метрга кадәр зыян китерерлек була, ә 450 метрдан инде теләсә нинди көбәне тишеп чыккан. Гомумән алганда, уклар очышы һәм нәтиҗәсе буенча төрки кавемнәр

Европа рыцарьларыннан һәм тәре йөртүчеләрдән ике мәртәбә диярлек өстенрәк торган.

3. *Төзелеш эшләре һәм сугару системалары.* Гомуми ихтыяҗларны күздә тотып, солтанлыкта гаять зур күләмдә төзү эшләре алып барыла. Солтан Мәлик шаһ заманында сугару каналлары казу, күперләр салу, шәһәрләр тирәли саклану дивары торгызу, чик буе ныгытмалары һәм йөк ташучы сәүдәгәрләр өчен кәрван-сарайлар төзүгә гаять зур акчалар тотыла. Олы юлларны, аеруча мөселманнар хаҗга йөрү юлларын төзекләндерүгә һәм саклауга зур игътибар бирелә. Мәлик шаһ Багдадта үз акчасына солтан сарае, базар, кибетләр төзеп калдыра, Җәмигъ мәчетенә нигез сала (тик вафат булуы сәбәпле, төзеп бетерә алмый). Солтан хөкүмәте мәчетләр салу белән генә чикләнмичә, эре шәһәрләрдә гыйлем үзәкләре булган мәдрәсәләр төзү белән дә ныклап шөгыльләнә. Шундый мәдрәсәләр – мөселман югары уку йортлары – Багдад, Мосул, Басра, Димәшкъ, Нишапур, Бәлх, Мерв, Герат һ.б. калаларда ачыла.

1070 - 1090 елларда солтанлыкның төрле өлкәләрендә коры җирләрне сугару корылмаларының искергәннәрен рәткә кертү, яңаларын төзү буенча зур эшләр алып барыла. Мисал итеп Мургаб елгасында төзелгән плотинаны китерергә мөмкин. Элек-электән бу елга Мерв тирә-ягындагы җирләрне туендырып килгән: җирле халык аны берничә урында чыбык-чабыктан ясалган вакытлы буалар белән бүлеп, суын арыклар буйлап басуларга җибәргән. Әмма соңгы су басу аркасында зур бәла-каза килеп чыга: көчле ташкын буаларны алып китә. Нәтиҗәдә чәчүлекләр, җимеш бакчалары болганчык су астында калып харап ителә. Сәлҗүкләр килгәнче табигый афәтнең зыянын төзәтүче табылмаган. Бары Мәлик шаһ чорында, Мургабны халык файдасына хезмәт иттерер өчен, елга аша плотина төзү эшенә керешәләр. Искиткеч күп көч кую нәтиҗәсендә, нибары алты ай эчендә мәһабәт плотина әзер була.

4. *Кәрван юллары, кәрвансарайлар.* Сәлҗүкләр чит илләргә ат һәм терлек чыгарган, ә аларга грек һәм әрмән сәүдәгәрләре кыйммәтле келәм-паласлар китергән. Соңга таба товар төрләре дә үзгәрә, сәүдә географиясе дә киңәя. Әлеге үзгәрешләр Кара дингездәге Синоп портын күзәтчелеккә алгач аеруча күзгә ташлана. Шуның нәтиҗәсендә аларга Кырымдагы Судак порты аша көньяк дала кыпчаклары, татар сәүдәгәрләре белән җанлы сәүдә алып бару мөмкинлеге ачыла. Уңышлы сәүдә итү өчен юлларның төзек һәм куркынычсыз булуы зарур. Сәлҗүкләр ия булган һәм әле антик заманнардан калган рим, византия яу һәм сәүдә юллары бик искергән, ә байтак урыннарда бөтенләй сафтан чыккан була. Шуңа күрә, солтан хөкүмәте беренче чиратта урыннардагы хакимиятләргә әлеге юлларны төзәтү хакында күрсәтмә бирә. Һәм кызу эш башлана: юллар сипләнә, елгалардагы иске кечү урыннары тәртипкә китерелә, менә дигән яна таш күперләр салына. (Аларның кайберләре, мәсәлән, Төркиядәге Диярбәкер дигән урында 1063 елда Мәлик шаһ һәм аның улы Мәхмүт нигез салган таш күпер бүгенгәчә халыкка хезмәт итә). Юлларны рәткә кертү белән беррәттән бу борынгы юлларның озын-озак тарихында беренче тапкыр буларак сәяхәтчеләр туктап ял итәр өчен махсус биналар – кәрвансарайлар ачыла. Кәрвансарайлар юлбасарлар һөҗүменнән саклану урыны буларак та файдаланылган, шуңа күрә архитектурасы да бик үзенчәлекле булган: әлеге биналарның калын диварлар белән әйләндереп алынуы, диварлар өстендәге саклану манаралары, ихтимал булган һөҗүмне кире кайтару кулайрак булсын өчен бер генә капка калдырылуы, тәрәзәләрнең бойница сыман тар итеп югарырак менгереп уелуы – болар барысы чын мәгънәдә хәрби ныгытманы хәтерләткән. Кәрвансарайларның аралары дөянең бер көн эчендә (9 сәгать) күпме юл үтә алуына бәйле рәвештә 30 чакрым чамасы тәшкил иткән. Шул рәвешчә, иртән иртүк юлга чыккан кәрван караңгы төшкәнче чираттагы кунакчыл кәрвансарайга килеп җитәргә өлгергән. Калалардагы кунакханәләр түләүле булса да, юл өстендәге кәрвансарайларга керү-чыгулар бушлай булган. Ишек алдына килеп керү белән, юлчының күз карашы иң әүвәл йорт уртасында тәһарәт алу өчен фонтаны эшләп торган мәчеткә юнәлгән. Монда юлчылар исән-имин килеп җитеп, сыену урыны биргән өчен Аллаһка рәхмәтләрен җиткереп дога кылган, авыр йөкләрен бушатып, аларны махсус билгеләнгән биналарга кертеп урнаштыргач, арыган хайваннарын

(дөяләр, атлар, ишәкләр) абзарга – ризыгы тулып торган таш улак янына илтеп куйганнар.

Сәяхәтчеләр, мөмкинлекләренә карап, аерым бүлмәдә, яки гомуми залда кунып чыккан. Аларга төрле хезмәт күрсәтү эшләре оештырылган. Юлчылар өчен кәһвәханә, ашханә, мунча, төрле ремонт ясау мастерскойлары эшләп торган. Ә кайбер эре кәрвансарайларда, аерым алганда, Конья – Аксарай, Кайсери (Кәүсәр) – Малатья юллары өстендә яткан кунакханәләрдә юлчыларның күнелен ачу өчен хуҗаларның хәтта уен коралларында уйнаучы музыкантларны җәлеп итүе билгеле.

Шәһәрләрдәге кунакханәләрдә сәяхәтчеләр буш вакытларында, гадәттә, зуррак бер бүлмәгә җыела торган була. Монда алар тәҗрибәле, дөнья күргән сәүдәгәрләр, зур белемле галимнәр, тәкъва хаҗиләрнең сүзләрен-вәгазьләрен тыңлап, алар белән аралашып, күп нәрсәгә төшенгәннәр булса кирәк. Шуңа күрә, мондый кунакханәләр бер үк вакытта мәгърифәт учаклары ролен дә үтәгән дисәк зур хата булмас. Иң хәвефле дип саналган юллардагы кәрвансарайларда хәрби гарнизоннар урнаштырыла. Куркыныч урыннардан узучы сәүдәгәрләр һәр хайван башыннан билгеле бер күләмдә салым түләргә тиеш булган, ә җыелган акчага юл сакчыларын тотканнар.

5. *Сәлҗүк архитектура үрнәкләре.* Сәлҗүк архитектурасы стилендәге корылмаларны бүгенге көндә Татарстанда Болгар шәһәрлегендә һәм Казанда күрергә мөмкин. Алар барысы да Алтын Урда дәвере болгарларының сәлҗүк архитектурасына охшатып салынган төрбәләр, мәчет-манаралар. Төрбә – нигезе сигез почмаклы, кайбер очракта квадрат формасында эшләнгән, түбәсе кыеклап (конус) яисә гөмбәзләп ябылган зиярат кылу урыны. Болгарда Төньяк төрбә, Көнчыгыш төрбә һәм Хан төрбәсе бар. Казанда хан төрбәсе булуы мәгълүм. Мәчетләрдән 1260 елларда (Бәркә хан (1258-1266) заманына охшаган) корылган Болгар Җәмигъ мәчетен атарга мөмкин. Цилиндр формасындагы таш манара бинага ассиметрик рәвештә өстәлеп төзелгән. Җәмигъ мәчете манарасы Олы манара дип атала. Бераз читтәрәк Олы манарага охшатып салынган Кече манара да бар.

## Дәүләтнең таркалуы

Мәлик шаһның үлеме (1092) династия әгъзалары арасында хакимият өчен үзара низаг китереп чыгара. Нәтиҗәдә солтанбикә Таркан хатын хакимиятне тулысы белән үз кулына алуга ирешә һәм аны яклаган әмирләр ярдәмендә дүрт яшьлек улы Мәхмүдне солтан дип игълан итә. Шуннан соң Таркан хатын мәрхүм солтанның бүтән хатыныннан туган беренче улы – унике яшьлек Бәркәаруктан арыну максатында, яу белән Исфаханга юнәлә. Солтанбикә мәркәзгә килеп кергәч, Бәркәарук ана тугры калган әмирләр һәм башка тарафдарлары озатуында Рәй каласына качып китә. Аның тирәсенә бик бай булмаган гавам туплана. Шушы күп санлы яклаучылар тарафыннан Бәркәарук Рәй каласында солтан дип игълан ителә. Билгесезлек озак дәвам итә алмый, солтан тәхете өчен дәгъвачылар арасында кискен көрәш башланып китә. 1094 елда булган хәлиткеч бәрелештә Бәркәарук җиңеп чыга һәм дошманнары кереп бикләнгән Исфаханны камап ала. Озак та үтми, Таркан хатын дөнья куя, ә аннары чәчәк авыруыннан аның сабый малае Мәхмүд тә үлеп китә. Әле 1092 елда ук Төньяк Хорасанда актив хәрәкәткә Алып Арысланның улы Арыслан Аргун кучкән була. Атасы исән вакытта ул Хорезмның әмире итеп билгеләнә. Арыслан Аргун бертуганнарының уллары, башка туганнары арасындагы низагтан файдаланып, Хорасанны яуларга керешә. Моңа сылтау итеп ул бабасы Чагры бәкнең кайчандыр Хорасан өлкәсенә ия булуын, димәк, аның бу җирләрне мирас итеп алырга тулы хокукы барлыгын белдерә. Уңышлы хәрәкәт итеп, ул җиңел генә 1095 елда Хорасан өлкәсенең Мерв, Серахс, Балх, Термез калаларын кулга төшерә. Әмма яңа тәхет дәгъвачысы тулы максатка ирешә алмый: үзенең явызлыгы аркасында үч алу корбанына әверелә. Мерв үзәгендәге ныгытмада аны бер голәм хәнҗәр белән кадап үтерә. (Голәм – хәрби хезмәткә ялланган төрки яугире. Мисырда аларны мәмлүкләр дип атап йөрткәннәр – Г.Г.).

1096 елда солтан Бәркәарук үги энесе Мәлик Сәнҗәрне Хорасанга Арыслан

Аргун өстенә яуга җибәрә. (Сәнҗәрнең әнисе солтан Мәлик шаһның кәнизәге була). Арыслан Аргун һәлакәтеннән соң Сәнҗәр җиңел генә бөтен Хорасанны диярлек кире Бәркәарук кул астына кайтара. Шуннан соң Сәнҗәр Хорасанның хакиме итеп билгеләнә. 1105 елда Бәркәарук вафат була. Аның урынына үги энесе Мөхәммәд Тапар (1105-1118) игълан ителә. (Аларның икесенең дә аталары солтан Мәлик шаһ). Моңа кадәр Мөхәммәд Тапар кул астына төп биләмәсе Әзербайҗаннан тыш, Иранның чиктәш төньяк-көнбатыш өлкәләре, Евфрат елгасы буйлары, Мосул һәм Сүрия җирләре кергән була. Ә инде солтан тәхетенә утыргач, ул әлеге биләмәләргә Мәлик шаһтан соң килеп чыккан гомуми тотрыксызлыктан файдаланып, Иранның байтак өлешен, Хузистан өлкәсен һәм Гыйракны да куша. Нәтиҗәдә, әлеге җирләрне берләштергән «Гыйрак солтанлыгы» дип аталган мөстәкыйль дәүләт барлыкка килә.

Сәнҗәр исә Иранның, Урта Азиянен, хәзерге Әфганстанның кайбер өлкәләрен яулап ала. Ә 1117 елда ул үз йогынтысын заманында сәлҗүк төркиләрен буйсындырып торган Газнәвиләр мәмләкәтенә дә җәелдереп, аларны салым түләргә мәҗбүр итә.

1118 елда солтан Мөхәммәд Тапар үлеп китә. Тәхеткә аның улы Мөгис әд-дин Мөхәммәд утыра. Тәхеткә бераз ияләшкәч, Гыйрак солтанлыгының яңа хакиме беренчелеккә дәгъва кыла башлый: ул Сәнҗәрдән үз казнасына ел саен шактый күләмдә салым түләүне һәм әле генә яулап алынган Мазандаранга бәйсезлек бирүне таләп итә. (Мазандаран – Иранның Каспий диңгезе көньягында урнашкан өлкәсе). Вәзирләр коткысына бирелгән яшь туганының таләпләренә җавап итеп, Сәнҗәр гаскәр башында яу белән Рәй өстенә китә. 1118 елның августында Сава дигән җирдә гаскәрләр арасында каты бәрелеш була. Сәнҗәр җиңеп чыга, аннары тынычлык килешүенә кул куела. Килешү нигезендә Сәнҗәр кул астына Төньяк Хорасан, Мазандаран, Рәй, төньяк - көнбатыш Иран, Бәлх (Төньяк Әфганстанда) өлкәләре һәм башка кайбер җирләр керә. Тиздән Сәнҗәр әлеге җирләрне берләштергән Көнчыгыш Сәлҗүкләр дәүләте (Хорасан солтанлыгы) оешуы турында белдерү ясый. Дәүләтнең башкаласы дип Мерв (хәзерге Мары) шәһәре игълан ителә. Багдад хәлифәсе әл-Мостаршид (1118-1135) 1120 елда әлеге килешүне раслап, Сәнҗәрне солтан дип таный. Мәхмүд исә Гыйрак солтанлыгы тәхетен саклап калган хәлдә, Сәнҗәргә буйсынырга мәҗбүр була. Хорезм, Газнәвиләр, Мәвараэннәһер, Систан, Көнбатыш Иран яңа дәүләткә бәйле булып калалар. Әлеге вакыйгалар белән бер үк вакытта диярлек Якын Көнчыгышта Сүрия, Урта көнчыгышта (Төньяк Һиндстанда) Кирмән солтанлыклары да бәйсезлек игълан итәләр. Ә элгрәк телгә алынган Анадолудагы Рум солтанлыгы, билгеле булганча, әле 1086 елда ук мөстәкыйльлек игълан иткән иде.

***

XII гасырның 30 нчы еллар ахырында хәзерге Казакъстан белән Урта Азиягә Үзәк Азиядән ташкын сыман кидан төркиләре бәреп керә. Алтай тауларының көньяк тармакларына килеп җиткәч, аларның җитәкчесе Елюй Та-ши шул якларда гомер иткән күп санлы шәһәр һәм кабилә вәкилләре ( уйгыр, татар, тангут, кыпчак һ.б.) катнашында корылтай уздыра. Корылтайда Елюй Та-шины гурхан (хәрби җитәкче) дип игълан итәләр һәм сайлап алынган гаскәр белән яу сәфәренә чыгарга фатиха бирәләр. Унышлы хәрәкәт итеп, Елюй Та-ши XII гасырның 30 еллары башында Җидесу өлкәсен яулап ала, ә 1137 елда Мәвараэннәһер чикләренә килеп җитә. Караханидлар хакиме Арыслан хан аңа каршы чыга. Ходжент каласыннан ерак түгел бер урында каты бәрелеш була. Караханидлар гаскәре тар-мар ителә, исән калганнары Сәмәркадка качып китә. Әлеге җиңелүдән соң Арыслан хан ярдәм сорап Сәнҗәргә мөрәҗәгать итә.

Сәмәркәнд өлкәсендә гомер сөрүче карлык кабиләләрендә терлек саны арту сәбәпле көтүлекләргә кытлык башлана. Карлыклар көтүлекләрне киңәйтү бәрабәренә солтан гаскәрендә хезмәт итәргә, ел саен салым түләп торырга ризалыкларын белдерсәләр дә, Сәнҗәр якын даирәсе басымы астында әлеге

тәкъдимнәргә колак салмый. Киресенчә, көтүлекләргә һөҗүмнәр башлана. Ахырда төрле кыерсытуларга түзә алмыйча, карлыклар дәррәү кузгалып, гурхан янына чыгып китәләр.

Мәвараэннәһернең эчке эшләренә тыкшынырга җай гына көтеп торган Елюй Та-ши бу вакыйгадан бик оста файдалана. Ул солтан биләмәләрен ташлап киткән өчен карлыкларны гафу итүне сорап Сәнҗәргә хат юллый. Ә инде тупас төстә язылган тискәре җавап алгач, карлыкларның хокукларын торгызу сылтавы белән Мәвараэннәһергә бәреп керә. Гаскәрләр Сәмәркандтан төньяк-көнчыгышта Катаван даласында очраша. Елюй Та-ши гаскәренең төп өлеше Тәңрегә ышанган татар, уйгыр, кыпчак һ.б. кабилә вәкилләре тәшкил иткән. Боларга шулай ук кыю һәм җәядән бик оста атучы 50 меңләп карлык төркиләре дә килеп кушылган. Сәнҗәр җитәкчелегендә исә хорасан, систан, мазандаран хәрбиләреннән торган регуляр армия һәм караханид гаскәрләре булган. 1141 елның 9 сентябрьда Катаван даласындагы каты бәрелеш сәлҗукләр армиясенең коточкыч җиңелүе белән тәмамлана. Солтанның гаять зур гаскәре туздырылып качып китә. Сәнҗәр үзе зур булмаган төркем белән камалышка эләксә дә, дошман рәтләре аша үтеп, качып котыла. Җиңүчеләр кулына исәпсез-хисапсыз ганимәт малы (трофей) һәм бик күп әсир эләгә. Кулга төшкәннәр арасында солтанбикә Таркан хатын да була. Соңрак Сәнҗәр аны зур йолым түләп азат итә. Һәлак булучылар саны 30 меңнән артып китә. Аларны мөселман кануннары нигезендә шаһитлар дип игълан итәләр һәм Сәмәркандтан көнчыгышта далада җирлиләр.

Катаван сугышы тарихи әһәмияткә ия була. Шуның нәтиҗәсендә Елюй Та-ши яулап алган җирләрдә яңа дәүләт – кидан төркиләре ханлыгы оештыруы турында хәбәр итә. (Башкаласы – Баласагун шәһәре, хәзерге Кыргызстандагы Токмак каласыннан ерак түгел). Алга таба Елюй Та-ши яңа дәүләткә Бохараны куша, гаскәрбашы Әрбүзне яу белән Хорезм өстенә җибәрә. Хорезмшаһ Атсыз үзенең буйсынуын белдергәч, гурхан аның ел саен салым түләп торырга тиешлеге белән чикләнә.

Мәвараэннәһернең зур өлешен кулга төшергәч, җиңүчеләр монда гомер сөргән угыз кабиләләрен Әму-Дәрьяның аръягына – Бәлх өлкәсенә кысрыклап чыгаралар. Күп санлы угыз кабиләләрен андагы хаким дошманнарча каршылый. Милләте буенча фарсы Комач, аның кул астында калган угызларның авыр хәленнән файдаланып, аларга салымны арттырырга чамалый. Мәгәр угызлар өстәмә түләүгә каршы чыгалар, ә бу исә Комач тарафыннан баш күтәрү дип кабул ителә. Кабилә башлыклары ташламаларга барып, килешергә тырышып карасалар да, хакимнең таләпләре чиктән тыш зур булганга, сөйләшүләр бернәрсәгә дә китерми. Мондый килешмәүчәнлек тиздән ике арада канлы бәрелешкә сәбәп була. Нәтиҗәдә Комач җиңелә, ә аның улы яу кырында һәлак була. Моннан соң Комач яңа көчләр туплап, угызларга һөҗүм итә һәм янәдән тар-мар ителеп, Мервка солтан Сәнҗәр янына барып сыенырга мәҗбүр була. Бу урында шуны әйтү зарур. Фарсы түрәләренә һәм гарәп дин әһелләренә таянган Сәлҗук солтаннары сәясәте күчмә угыз кабиләләре белән элеккеге туганнарча бәйләнешләрнең өзелүенә китерә. Шуннан файдаланып, Комач Сәнҗәрне баш бирмәс угызларга «сабак бирү» кирәклеге белән котыртып, солтанны аларга каршы хәрби поход оештырырга күндерә.

1153 елның яз башында солтанның гаять зур армиясе Бәлхтәге угызлар өстенә яуга кузгала. Кабилә башлыклары яуны туктаткан очракта Сәнҗәргә 50 мең баш ат һәм дөя, 200 мең сарык бирергә, хәтта Комач малаен үтерүчене тотып тапшырырга вәгъдә итсәләр дә, солтан угызларның бөтен тәкъдимнәрен кире кага. Әлбәттә инде, моннан соң угызларга сугышка әзерләнүдән башка чара калмый. Алар таулар арасында бер сукмактан гына керә алырлык тигезлектә ныгып урнаша. Тар сукмакка килеп кергән сәлҗук атлылары угызлар лагерена ук яңгыры яудыра башласалар да, уклар тирмәләргә, хайваннарга, арбалардагы вак-төяк нәрсәләргә тигәнгә күрә, саклаучыларга әллә ни зыян китерми. Аның каравы угызларның һәр угы корбанын табып «чүпләп» кенә бара. Шул вакытта тән сакчылары, яраннары белән бәрелешне ерактанрак күзәтеп торган Сәнҗәр гаҗәеп күренешнең шаһитына

әверелә. Һич көтмәгәндә угызлар солтан атлыларын шактый гына сирәгәйткәч, тирмәләр арасыннан дәртле тавышлар чыгарып ярсулы һөҗүмгә күчә. Сәнҗәр үзенең яраннары белән әсир төшә. Яу кырыннан угызлар Мервка юнәлә. Алар җинел генә Мервны ала. Шәһәр, җинүчеләр тарафыннан талана. Башкаланы алудан рухлары күтәрелгән угыз житәкчеләре, хәрби хәрәкәтләрне көньяк тарафка җәелдереп, 1154 елның ноябрендә Туса каласына, ә декабрьда Нишапурга бәреп керәләр. Нишапурдан соң бөтен Хорасан диярлек угыз әмирләре кул астында кала. Әлеге уңышлардан соң, солтан хакимиятенә каршы гомуми баш күтәрүләр башлана: угызларга канәгатьсез халык ополчениесе төркемнәре, гарнизоннардагы хәрби хезмәткәрләр килеп кушыла. Бер ук вакытта үзәк хакимияткә каршы булган кара көчләрнең корткычлык эшчәнлеге активлаша. Аеруча Мисырдагы фатыймиләр династиясе тарафдарлары, үзләрен чын мөселман дип атаучы исмәгыйлиләр яшерен мәзһәбе әгъзалары зур зыян китерә. Алар күренекле шәхесләрне, эре түрәләрне үтереп кешеләр арасында коткы салган, юк ителгәннәр урынына үз вәкилләрен куеп, дәүләтне эчтән таркату эше алып барган. Гомуми чуалыш-тәртипсезлекләрдән куркуга төшкән Урта Азиянең һәм Иранның идарәче даирәләре, баш күтәрүчеләрнең терәге булган угызлар хәрәкәтенә чик кую максатында, хәрби берләшмә төзү фикеренә киләләр. Бу эштә башлап Хорезмшаһ Атсыз йөри. Ул үзенең улы Ил Арыслан белән гаскәр туплап Хорасанны угызлардан азат итү омтылышы да ясап карый, тик уңышка ирешә алмый. Ә бу чакта уңай вазгыять тә килеп туа: 1156 елда угыз әмирләренең үзара низаглары Сәнҗәргә тоткынлыктан качарга ярдәм итә. Солтан Термез шәһәрендә ныгып урнаша. Ул аннан тарафдарларын үзенә кушылырга чакырып атчабарлар җибәрә. Нәтиҗәдә күрше өлкәләрдән җыелган, хорезмшаһ биргән хәрби көчләр белән угызларга каршы зур һөҗүм планы әзерләнә. Бер ук вакытта Атсыз ярдәмендә кайбер угыз кабиләләре башлыклары белән сөйләшүләр башлана. Тик бу планны тормышка ашырырга насыйп булмый: 1156 елның июль азагында, тәхетне Ил Арысланга калдырып, хорезмшаһ Атсыз дөнья куя. Шул унайдан Термезда хәрби житәкчеләр җыела. Тик Сәнҗәр планын гамәлгә ашыру урынына бу хәсрәт җитәкчеләр башта талаша башлап, соңыннан бер-берсен кырып бетерәләр. Асылда инде таркалган дәүләтне торгызу мөмкинлеге калмый: казна буш, ә гаскәр җитәкчеләре инде картайган солтанны тыңларга теләми. Тирән борчылудан Сәнҗәр авырып китә һәм 1157 елның 29 апрелендә җан тәслим кыла. Аның хакимлеге (1118 елдан башлап) барлыгы 39 ел дәвам итә.

Сәнҗәр үлеменнән соң Көнчыгыш сәлҗүкләр дәүләте (Хорасан солтанлыгы) Хорезм хакимнәре кул астына кергән берничә вак биләмәләргә таркала. Төп дәүләтнең таркалуыннан файдаланып, 1187 елда угызлар Кирмән солтанлыгын буйсындыралар һәм монда XIII гасырга кадәр яшәп килгән бәйсез дәүләт булдыралар. Аннан соң таркалу чираты сәлҗүкләрнең ваграк дәүләтләренә дә житә. Көнбатыш (Гыйрак) солтанлыгы Тогрул III ибне Арыслан хорезмшаһ Текеш белән сугышны оттыргач, 1194 елда дошманнары кулыннан корбан китә, солтанлык та яшәүдән туктый. Сүрия солтанлыгын мәмлүкләр үз канат астына ала, ә Рум солтанлыгы бәйсезлеген 1308 елда югалта. Шул рәвешле, сәлҗүк дәүләтләренең төп тарихи роле шунда — алар гарәпләр саклап кала алмаган Багдад хәлифәлегенең яшәү гомерен монголлар явына кадәр озайта алганнар.

**Гамир ГАРИФУЛЛИН,**
*Яшел Үзән*

# Фирдәвес Гарипова

## АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

### Мөслим

Чистай районының иң зур авылларыннан берсе — Мөслим. Ул җирле үзидарә үзәге, районнан 22 чакрым ераклыкта урнашкан.

Мөслим авылы А.Артёмьев җыентыгында (1866) телгә алына. Мөслим суы буена утырган бу авылдагы 221 хуҗалыкта 790 ир-ат һәм 739 хатын-кыз яшәгән, авылда мәчет эшләгән.

1867 елда Мөслим авылы тарихи җыентыкта телгә алына. В.П.Семенов редакцияләгән хезмәттә авылда ике меңгә якын кеше яшәве, анда волость идарәсе һәм ике мәчет булуы әйтелә.

Чыннан да, XIX йөз ахырларында Мөслим авылында ике мәчет эшләгән. 1891 елда ике мәчет тә яна. 1893 елда алар янадан төзелә. XX йөз башында беренче мәхәлләдә ир-атлар саны — 710, икенчесендә 630 булган.

Икенче мәхәлләдә имам-хатыйб булып ярты гасыр буена, 1863 елның 23 апреленнән 1910 елның 7 ноябренә, ягъни вафатына кадәр, Нурулла Яһудин хезмәт итә. Әле үзе исән вакытта ук, 1901 елның 25 июлендә, икенче мулла итеп аның улы Мөхәммәтхәсән Нуруллин билгеләнә.

Авыл аксакаллары сөйләвенә караганда, Мөслим авылын Мөслим баба нигезләгән. Аның үзен монда Чирүле Шонталасыннан килеп утырган дип әйтәләр. Мөслим авылы халкы чукындырылган, ләкин алар янадан исламга кайткан. Керәшен зираты аерым булган.

Мөслим авылы янында Ташбилге дип аталган борынгы зират та бар. Монда изгеләр күмелгән дип сөйлиләр.

Мөслим тигезлектә урнашкан. Бик борынгы вакытта авылның бер ягы урманга тоташкан булган. Хәзер ул урман юк инде, аның урынына Татар Талкышы дигән авыл үсеп чыккан.

Авылның икенче ягында чишмәләр күп булган. Камышлы (яки Мөслим) елгасы авыл күрке булып торган, ләкин хәзер саеккан, тарайган. Бу Камышлы (башланган урынында камышлар үскәнгә шулай атаганнар) елгасына шактый күп башка сулар килеп кушылган. Бахты елгасы, Өч каен (елга янында өч каен үскән), Пәжи елгасы, Мар елгасы, Мар елгасыннан соң Наратлы елгасы Аэропорт суына кушыла. Бу елгага Яуширмә елгасы кушылып, Байтирәк авылын узгач, Камага килеп тоташа.

Авылда чишмә-кизләүләр дә шактый.

Авыл тимер юлдан шактый ерак. Мөслим авылы янынннан асфальт түшәлгән олы юл уза. Элек Себергә юл шуннан үткән.

Элек авыл крестьяннары җирсезлектән интеккән. Җирнең 70 проценты һәм урман-сулар авыл байлары кулында булган. Крестьяннар җирләрен агач сука һәм тырма белән эшкәрткән. Революциягә кадәр 386 хуҗалыкның дүртесендә генә атлы ургыч һәм Әхмәтвәли исемле алпавытта атлы сугу машинасы белән чәчкеч булган. Калган хуҗалыклар кул белән чәчкән, урак белән урганнар, чабагач белән сукканнар. Бер дисәтинәдән (1,5 гектар) алынган уңыш 40 поттан артмаган.

*Дәвамы. Башы 2006 елның бнчы санында.*

Элек авылда хастаханә булмаган. Халык суфый һәм муллаларның өшкерүеннән шифа күргән. Авылда мәктәп тә эшләмәгән. Балалар мәчет каршында оештырылган мәхәллә мәдрәсәләренә сабак укырга йөргән.

1918 елда Мөслимдә ярлылар комитеты (комбед) төзелә. Шул ук елның ахырында беренче авыл советы барлыкка килә. Авыл советы җирсез, атсыз һәм сыерсыз ярлы крестьяннар өчен зур таяныч булган.

Шул ук 1918 елда авылда башлангыч мәктәп ачылган, аның дүрт классы булган. 1931 елда Мөслим авылында җидееллык белем бирүгә күчәләр, ә 1933 елда тагын бер мәктәп бинасы салына.

1930 елда авылда колхоз төзелә. Аны «Ударник» дип атыйлар.

Авыл янышнан Мөслим суы яисә Инеш ага. Ярлары биек, тирән, ә суы бик аз. Инешкә Корка чишмәсе коя. Корка – кушаматтан барлыкка килгән атама. Ташчишмә суы да Инешкә төшә. Суы ташлар арасыннан акканга чишмә шулай дип аталган. Кара чишмәнең суы каралып тора һәм ул кышның салкын көннәрендә дә тунмый.

Авыл уртасында зур бакча үсә, аның уртасына таш мәчет салынган. Авылның нәкъ уртасында ике катлы зур урта мәктәп бар. Мөслим урта мәктәбе Чистай районы күләмендә, ә соңгы елларда бөтен республикада да үрнәк мәктәпләрдән санала. Аның алма бакчасы һәм теплицасы бар. Мәктәп Советлар Союзы Герое Касыйм Ситдиков исемен йөртә.

## Мөэмин–Каратай

Мөэмин-Каратай авылы Лениногорск районында, район үзәге Лениногорск шәһәреннән – 40, җирле үзидарә советы үзәге Иске Иштирәк авылыннан 5 чакрым ераклыкта урнашкан.

Авыл атамасы күп кенә тарихи чыганакларда һәм халык иҗаты әсәрләрендә очрый.

1859 ел мәгълүматларын эченә алган тарихи белешмәгә караганда, авылдагы 54 йортта 158 ир-ат һәм 194 хатын-кыз яши, мәчет эшли.

Мөэмин-Каратай авылы кешесе Фазыл Мөхәммәт улы язмаларыннан Ш.Максудова күчереп алган «Иштирәк» легендасы игътибарга лаек. Анда авыл тарихына кагылышлы мәгълүматлар табарга мөмкин.

«Халык белән гаскәр арасында низаг чыгуга нинди сәбәп булгандыр, моны һичкем дә белүче юк. Шулай булса да, бу вакыйга кечкенә сәбәпләр аркасында гына булганга охшамый. Чөнки халык өстенә бик куркыныч төстә коралль атлы гаскәр килү сәясәте билгеле булганнан соң, авылдагы барлык ирләр һәм хатын-кызлар коралларын алып, каршыдагы тау өстенә менеп, дошманны көтеп торган. Халыкның күзәтчеләре гаскәрнең су буйлап – Каратай (Зәй елгасының сул кушылдыгы) тамагы буйлап килгәннәрен белдергәннән соң, авыл халкы Чирле елганың кояш чыгышы ягында, тау битенә яшеренеп көтеп торганда, дошманнарның гаскәре чынлап та су буеннан килеп чыккан. Ләкин гаскәрнең аннан килүе үзләре өчен уңышсыз булган. Чөнки алар бер дә искә-санга алмый гамьсез генә килгәндә, Шушма суының тау итәгенә терәлеп ага торган җиргә җиткәч, тау башындагы халык гаскәрнең алгы һәм арткы ягын бүлеп алып, өсләренә зур-зур хисапсыз күп ташлар тәгәрәтеп төшергәннәр. Күп кенә атлар һәм кешеләр җәрәхәт алган, үлүләр дә булган. Авыл халкына гаскәр берниндн зарар китерә алмыйча, чигенергә мәҗбүр булган. Тәртипсез рәвештә качып күздән югалгач, авыл халкы тынычланып, һаман да гаскәрне аскы юл белән килер дип уйлаган. Ләкин гаскәр күпне күргән шул инде ул. Алар чигенсәләр дә, бик ерак китмичә, Кара бия елгасы чокыры, Кирмәт буйларына тупланып, бу көндә дә «Яу юлы» дип йөртелгән урыннан текә тауны казып, тау кырыннан өскә менгәннәр. Канлы сугышларда күп кенә җаннар кырылган. Авыл халкы җиңелгән, бөтен халыкны куып, ерганак буена китереп кысрыклаганнар да, Шушма суына турап салганнар. Ирләрдән байтагы гына атларына атланып, Шушма суы аркылы чыгып, әрәмәгә кереп югалган. Шушы дәһшәтле вакыйгадан качып котыла алган кешеләр

Иске Иштирәк, Бәкер авылы һәм Яна Иштирәккә килеп урнашканнар. Үзләренең иске авылларына урнашу мөмкинлеге калмаган, чөнки ул яндырылган, көлгә әйләндереп бетерелгән.

Шулай итеп, бу иске авылдан өч яңа авыл барлыкка килгән».

Шушы җәһәттән тарихчы галим Җәмит Рәхимов язмаларына мөрәҗәгать итик.

«Мөэмин-Каратай дип сүз башлауга, монда яшәүче халыкның күбесе Иске авылдан күчеп утыруын тарих итеп сөйли. Риваятьләргә һәм кайбер билгеләргә (утырып калган ялгыз каен) караганда, ул Шушма елгасының уң як ярында, элеккеге Трактор авылы янында булган. Аксакаллар хәтерләве буенча, Иштирәк дип аталган бу иске авыл – ул хәзерге Иске Иштирәкнең дә, Мөэмин-Каратайның да бабасы. Безнең яклардагы беренче татар авыллары XVIII гасырның 30нчы елларында гына нигезләнүләрен тарихи документлар буенча билгеләнгәнчә, без әлеге Иске авылны 1730 еллар тирәсендә барлыкка килгән, дип әйтә алабыз.

Әлеге Иске авыл тарихында телгә алып сөйләрлек нәрсә – аның аша хәзерге Татарстан җирендә хәрәкәт иткән пугачевчыларның бер алае (гаскәре) узу. Тугыз йөз болачыдан һәм биш туптан торган бу алай белән шушы борынгы Иштирәк кешесе, корпус старшинасы Аит Уразмәтов (1718-74) җитәкчелек итә. Шунысын да әйтик, Пугачев үзенең йөзләрчә полковниклары, атаманнары һәм старшиналары арасыннан бу олуг исемне нибары ике кешегә – Иван Черняев белән Аит Уразмәтовка гына бирә. Уразмәтов яугирләренә биредә меңьяшәр агачларны кисеп юл сабарга, баткак-сазлыкларга түшәүлекләр тезәргә, хәтта тауларны кисеп (әйтик, Мөэмин-Каратайның яу юлы тавы) юллар салырга туры килә. Иске авыл янында алар Шушманы кичә. Елга аша тупларны алып чыгу өчен, алар төптәге комга, туплар батмасын дип, тирән су төбенә таш түшиләр. Бу эшләрнең барысына да яугирләр генә түгел, Иске авыл кешеләре дә катнаша. Алай ул чакта мул сулы елганы исән-имин кичеп, юлын дәвам итә.

Әнә шул вакыйгалар сәбәпче булса кирәк, Иске авылны куып тараталар. Ясаклы татарларның күбесе хәзерге Иске Иштирәккә, беразы Мөэмин-Каратайга күчеп китә.

Яңа урынга, ягъни Шушма елгасына коя торган Каратай (борынгы төрки исем) суы буена әүвәл Мөэмин бабай гаиләсе күчеп утыра. Аннан инде Ялан авылыннан (хәзерге Алешкино, анда башлап татарлар утырган була) тагын бер гаилә килеп төпләнә. Яланлыларның башкалары да күченеп, бүгенге көндә Чүтене нигезлиләр. Вакытлар үтү белән Каратай суы буена төрле җирләрдән (нигездә, Иске авылдан) изелгән, тапталган татар гаиләләренең өченчесе, дүртенчесе... казык кага. Шулай итеп, хәзерге район җирендә өр-яңа авыл барлыкка килә. Аны күп еллар буе, хәтта әле Ватандашлар сугышы елларында да Иштирәк Каратае дип йөртәләр. Бер үк вакытта авылны нигезләүче Мөэминнең дә исеме онытылмый. Совет хакимияте елларында ул авыл Мөэмин-Каратаена әйләнеп кала».

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Хисаметдин
Исмәгыйлев

# КЫРЫМ ТАТАРЛАРЫ ФАҖИГАСЕ

Соңгы вакытларда нинди генә көннәр, нинди генә бәйрәмнәр уйлап табылмый. Телевизор белән радионы иртән кабызу белән шул турыда сөйли башлыйлар. Имеш, шул көнне шул изге зат туган, бу көнне — бу бәйрәм. Бүген мәхәббәт көне. Көн саен яратышып-үбешеп йөрергә кирәк дип халык башына безгә бөтенләй ят булган гореф-гадәтләрне көчләп тагарга чамалыйлар. Хәтта озак үбешү һәм күпләп үбешү бәйрәме белән ярышлар да үткәрәләр. Дураклар көне дә, көлке көне дә, сыра яратучылар көне дә бар.

Озакламый май ае житә, анда инде кирәкле-кирәксез бәйрәмнәрнен чуты юк. Тик менә үткән гасырда шушы язның иң матур, ин жылы аенда татар халкы өчен бик тә кайгылы коточкыч вакыйга була. Менә шушы вакыйга турындагы бер бик яшерен хөкүмәт документы кулыма килеп керде. Һәм менә шул, 1944 елның май аенда Сталин кул куйган үтә дә яшерен документны сезнең хөкемгә тәкъдим итәм.

## Совершенно секретно.

*ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 5859 от 11мая 1944 года, г. Москва. Кремль.*
*О крымских татарах.*

*В период Отечественной войны многие крымские татары изменили Родине, дезертировали из частей Красной Армии, обороняющих Крым, и переходили на сторону противника, вступали в сформированные немцами добровольческие татарские воинские части, боровшиеся против Красной Армии; в период оккупации Крыма немецко-фашистскими войсками, участвуя в немецких карательных отрядах, крымские татары особенно отличались своими зверскими расправами по отношению к советским партизанам, а также помогали немецким оккупантам в деле организации насильственного угона советских граждан в германское рабство и массового истребления советских людей.*

*Крымские татары активно сотрудничали с немецкими оккупационными властями, участвуя в организованных немецкой разведкой так называемых «татарских национальных комитетах» и широко использовались немцами для заброски в тыл Красной Армии шпионов и диверсантов. «Татарские национальные комитеты», в которых главную роль играли белогвардейско-татарские эмигранты, при поддержке крымских татар направляли свою деятельность на преследование и притеснение нетатарского населения Крыма и вели работу по подготовке насильственного отделения Крыма от Советского Союза при помощи германских вооруженных сил. Учитывая вышеизложенное, Государственный Комитет Обороны постановляет:*

*1.Всех татар выселить с территории Крыма и поселить их на постоянное жительство в качестве спецпереселенцев в районы Узбекской ССР. Выселение возложить на НКВД СССР (т. Берия), выселение крымских татар закончить к 1 июня 1944г.*

*2. Установить следующий порядок и условия выселения:*

*а) разрешить спецпереселенцам взять с собой личные вещи, одежду, бытовой инвентарь, посуду и продовольствие в количестве до 500 кг на семью. Оставшиеся на месте имущество, здания, надворные постройки, мебель и приусадебные земли принимаются местными органами власти; Весь продуктивный и домашний скот, а также домашняя птица принимается Наркоммясомолпромом, вся сельхозпродукция – Наркомзагом СССР, лошади и другой рабочий скот – Наркомземом СССР, племенной скот – Наркомсовхозом СССР.*

*б) Наркомздраву СССР (т.Митереву) выделить на каждый эшелон со спецпереселенцами, в сроки по согласованию НКВД СССР, одного врача и двух медсестер с соответствующим запасом медикаментов и обеспечить медицинское и санитарное обслуживание спецпереселенцев в пути.*

*3. Наркомторгу СССР (т. Любимову) обеспечить все эшелоны со спецпереселенцами ежедневно горячим питанием и кипятком. Для организации питания спецпереселенцев в пути выделить Наркомторгу продукты в количестве, согласно приложению №1.*

*4. Обязать секретаря ЦК КП(б) Узбекистана т. Юсупова, председателя СНК УзССР т. Абдурахманова и Народного Комиссара внутренних дел УзССР т.Кобулова до июня с.г. провести следующие мероприятия по приему и расселению спецпереселенцев:*

*а) принять и расселить в пределах УзССР 140-160 тысяч человек спецпереселенцев-татар, направляемых НКВД СССР из Крымской АССР. Расселение переселенцев произвести в совхозных поселках, существующих колхозах, подсобных сельских хозяйствах, предприятиях и заводских поселках для использования в сельском хозяйстве и промышленности...*

*5) Обязать Сельхозбанк (т. Кравцова) выдавать спецпереселенцам, направляемым в УзССР, в местах их расселения ссуду на строительство домов и на хозяйственное обзаведение до 5000 рублей на семью с рассрочкой до 7лет.*

*6) Наркомфину СССР (т. Звереву) отпустить НКВД СССР в мае с.г. из резервного фонда СНК СССР на проведение специальных мероприятий 30 млн. рублей.*

*Председатель Государственного Комитета Обороны И.В.Сталин*

Укып чыктым мин бу документны һәм уйга калдым. Озак уйланып утырдым шушы «халыкларның атасы» булган Сталин имзасы куелган кәгазьгә карап. Кырымныкы булмасам да, мин үзем дә татар бит.

Һәм... Кырымда яшәп, Сталин репрессиясенә дучар булган милләттәшләребез белән якыннан танышырга уйладым. Жае да чыкты бит. Мин Кара дингез буендагы бер Ял йортында сәламәтлегемне ныгытып ятам. Әзрәк хәл алып, дәвалангач, җомга көнендә милләттәшләремне эзләп Анапа шәһәренең урамыннан барам. Үзем тегендә-монда сөйләшкән кешеләрнең сүзенә колак салам. Татар сүзе колагыма чалынмасмы? Юк, ишетелми. Шуннан үзәк базарга киттем дә, шундагы күнелемә хуш килгән берәүдән урысча:

— Исәнмесез, хөрмәтле кеше! Бу шәһәрдә мәчет кай тирәдәрәк икән? — дип сорадым. Ул исә үзе миңа сорау бирде:

— Ә нәрсәгә сон ул сезгә мәчет? Берәрсен эзлисез мәллә?

— Юк, эзләмим. Мин дини кешемен. Шуңа да мәчеткә кереп әзрәк дога укып, мәчеткә хәер-садака калдырып китәргә иде, — дигән булам. Башта исә бөтенләй башка төрле уй: татарлар мәчете булмый калмас. Теге кеше миңа:

— Безнен шәһәрдә мәчет юк, әмма Анапски дигән шәһәр кырындагы бистәдә мулланы таба аласыз, — диде. Ул мулланы ничек эзләп табарга икәнен дә өйрәтеп җибәрде.

Менә мин мулла яшәгән йортның бусагасында басып торам. Сак кына ишек шакыйм. Эчтән урысча:

— Керегез, кер. Ишек ачык, — дигән тавыш ишетелде. Шулай да ишекне ачып

эчкә үтәргә базмый торам. Шунда ишек ачылып китте дә, бик мөлаем генә йөзле олы яшьләрдәге бер апа елмаеп мине эчкә үтәргә чакыра. Сәлам биреп өйгә керәм:

— Әссәламе галәйкем!

— Вәгаләйкүм әссәлам! — ди апам, йөзләре яктырып китеп.

— Миңа мулла кирәк иде, — дим, саф татарча сөйләшүгә күчеп. Һәм паспортымны күрсәтәм. Апам:

— Юк, юк туганым, мин сезгә ышанам, — дисә дә, паспортны алып караштырып чыкты. Апаның исеме Рәмзия икән. Ул Сәрвәр абзыйның озакламый кайтып житәчәген әйтеп, чәй табыны әзерләргә аш-су бүлмәсенә кереп китте. Мин инде, олы кешене борчымаска тырышып, Рәмзия апага:

— Апа, юкка мәшәкатьләнмәгез, мин яңа гына табын яныннан тордым, — дим. Апам газ плитәсенә чәйнекне куеп кире минем янга чыкты да:

— Сәрвәр муллага ни йомышыгыз? Әллә оныгыгызга исем куштырыргамы? — диде.

— Юк, Рәмзия апа, мин бөтенләй башка сәбәп белән килдем. Мин үзем Башкортстаннан, шунда-шунда ял итеп ятам. Татар милләтеннәнмен һәм шушында яшәгән татарлар белән якыннан танышасым килә, — дим аңа. Һәм чамалыйм, апам минем кайбер сүзләремне аңлап бетерми. Минем дә аны аңлавым чамалы. Хәер, бераздан аңламаган сүзләрне урысчага әйләндереп бик мөлаем генә сөйләшеп алып киттек. Апам ачык кеше икән. Менә чәй дә кайнап, өстәлгә килеп утырды. Чәй чәй инде, үзара аңлашу-танышу тагын да җанланып китте. Мин җайлап-җайлап сүземне Рәмзия апаның бала чакларына алып килеп житкердем. Апа немец самолетларының ничек аларның авылын бомбага тотканнарын, ничек немецларның авылга килеп керүләрен яхшы хәтерли икән. Күбрәк куркыныч хәлләр һәм туйганчы ашаган вакытлары хәтерендә сакланган. Авылларын Совет гаскәрләре азат иткән чакларны да белә булып чыкты. Шуннан мин:

— Сез татарларны... — дип сүз башлаган идем дә, үземне үзем төзәтеп, — без татарларны ничек яшәгән җирләреннән куып алып киткәннәрен сөйләгез әле, — дидем. Рәмзия апаның йөзе үзгәрде.

— Нәрсәсен сөйлисең инде аның? Булган да беткән инде. Ул хәлләрне юньләп хәтерләмим дә инде, — диеп тынып калды ул. Мөгаен, безнең ихлас сөйләшеп утыруыбыз шуның белән тәгәлләнгән дә булыр иде, ярый әле Сәрвәр абзый кайтып керде. Урынымнан торып, аның белән ике куллап күрешәм. Аннан абзыем урындыкка утырды да, «Фатиха» сүрәсен укый башлады. Икебез дә битебезне сыпырдык. Мин янадан абзыйга кайдан килүемне, кайда туктап урнашуымны, һәм монда яшәгән татарлар белән якыннан танышып, алар турында берәр мәкалә язарга теләвемне әйттем. Хәзрәт:

— Бик хуп, бик яхшы, — диде дә, кул юарга чыгып китте. Апа аның артыннан ияреп чыкты да иренә әкрен генә нәрсәдер сөйли башлады. Сәрвәр абзый исә:

— Син инде, карчык, гомер бакый шул хәлләрдән куркып яшәдең. Картаеп әби булгансың, ә куркуың һаман калган, — дип, көлә-көлә чәй табынына килеп утырды. Өчәүләп сөйләшә-сөйләшә чәй эчәргә тотындык. Сәрвәр абзый сүзгә һәвәс кеше булып, мин аның белән бик тиз уртак тел таптым. Абзыйның һәм апаның фамилиясе Әхтәмовлар икән. Апаның кыз чактагы фамилиясе исә Исмаилова булып чыкты. Мин, апа фамилиясе белән үземнең фамилиям бер икәнен әйтеп, абзыйга да паспортымны күрсәттем. Абзый бик канәгать кенә:

— Шулай шул, — диде дә, паспортны Рәмзия апага сузды. — Менә, кара.

— Карадым, карадым. Тик шул чаклар искә төшсә, дер калтырап куям, — диде дә, монсу гына елмайды апа. Беразга табында авыр тынлык урнашты. Мин инде, өзелгән әңгәмәне ялгарга тырышып, гаиләм турында сөйлим, авылда татарларның ничек яшәгәннәрен бәян итәм. Аз-азлап әңгәмә яңадан мин теләгән якка юнәлеш алды. Янында Сәрвәр абзый булгач, апаның да шик-шөбһәләре таралды. Һәм ул сөйләп алып китте.

— Мина ул чакны биш яшь кенә иде. Шуңа күрә бик үк хәтерләп тә бетермим. Исемдә калганнары шул инде. Авылны төнлә гаскәр уратып алды. Һәр йортка солдатлар кереп, безгә тиз арада юлга җыенырга куштылар. «Сезгә ярты сәгать вакыт

бирелә», — диделәр. Документлар белән өч күнлек азык-төлек, кирәк-ярак һәм табак-савыт, кием-салым алырга куштылар. Тик ул ярты сәгать эчендә нәрсә генә җыеп аласың да, нәрсә генә төреп өлгерәсең? Әни кулына нәрсә эләгә, шуны юлга җыя башлады. Ике яшь бала бар бит әле. Минем кулыма да әйберләр тоттырдылар. Безне авылның читенә җыйдылар. Хәтердә шунысы калган, кулымдагы төенчек авыр, бер кулым белән әниемнең итәгенә тотынганмын, икенче кулым белән теге авыр төенчекне өстерим. Әни елый, ана кушылып мин елыйм. Шуннан безне машиналарга төяп алып киттеләр. Урыс авылларыннан үткәндә безгә таш аталар: «Сез сатлык җаннар!», — дип кычкыралар. Тагы әллә нинди алама сүзләр әйтәләр. Шуннан безне вагоннарга төяп, тагын кайдадыр озаталар. Шунысын әйтергә онытып торам. Безне авылдан куарга өч көн кала әтиебезнең энесе Абялил абый сугыштан уң кулын терсәктән өстән өздереп кайтып керде. И без шатланабыз. Әйтерсең лә үз әтиебез кайтты. Ул әле өйләнмәгән, яшь иде. Яшь булса да сугышта өч ел булып, майор дәрәҗәсенә күтәрелергә өлгергән. Ничек кенә булмасын, безне яклаучы, саклаучы, безгә ярдәмче кайтты. Безне вагоннарга шыплап тутырганда ул барча авылдашларны бер вагонга утыртырга ярдәм итте. Без инде ана әүлиягә караган кебек карый идек. Беребез дә урысча юньләп белмибез. Абялил абыйны ин почетлы урынга, тәрәзә кырына утыртабыз. Имеш, менә күрегез, безнең вагонда нинди хөрмәтле совет гаскәре майоры бара. Ул исә барыбыз өчен дә солдатлар белән сөйләшә. Тик сугышта өч ел булып майор дәрәҗәсенә хәтле күтәрелгән һәм сугышта кулын өздергән кешенең үзенә дә әлләни хөрмәт юк. «Сталинга язам, Бериянын үзенә язам. Менә минем орден-медальләр» дип тавыш күтәргәч кенә әзрәк аның сүзенә колак сала башладылар.

Күрәсең, бик куркыныч һәм кыен булгандыр инде, шуңа да минем исемдә нык калган. Безне Үзбәкстанның тугызынчы номерлы совхозына китереп бушаттылар. Шунда землянкалар казып яши башладык. Халык көн дә совхозга эшкә йөри. Соңыннан әнине, язу-сызу һәм исәп-хисапны белгәнгә, бухгалтериягә эшкә алдылар. Яшәү дә бераз җиңеләйде. Ә теге кулсыз Сәлимов Абялил абыйны депортировать ителгән авылдашлар өстеннән комендант итеп тәгаенләделәр. Менә шулай итеп янадан яши башладык. Пешергән ашларны ашарга кашыклар да юк иде ул чакта.

Юлда халык нык кырылды. Ин тәүдә яшь балалар белән картлар үлде. Үлгәннәрне күмәргә рөхсәт итмиләр. Аларны туктальшларда юл буена йә өеп, йә булмаса бөтенләй ташлап китәләр. Күпләрнең ашарларына да юк. Стансыларда туктаган чакны кем ничек булдыра, шулай ашарга әтмәлләргә тотыналар. Тик состав кузгалыр алдыннан сызгыртса, солдатлар пешкән ашларны да алдырмый вагоннарга куып менгерәләр. Берчакны безнең вагонда солдатны тыңламыйча казаны белән пешкән ашын алырга йөгергән бер абзыйны атып үтерделәр. Солдат аны качып китәргә тели дип уйлаган, ахры. Кая качсын инде ул биш онытын ташлап.

Әти сугыштан кайтып, безне килеп тапканда кырык алтынчы елның җәе иде. Әтиле тормыш күпкә җиңел. Их, ничек кенә яхшы итеп сөйләсән дә, яшәү шартлары бик авыр иде, — дип, апа туктап калды. Аннары, «Туганым, искә төшерәсем дә килми инде. Ана агагыз сөйләсен, — диде.

Мин сораулы карашымны Сәрвәр абзыйга күчерәм, ул, тирән генә тын алып, ерактан ук башлап китте:

— Бабаның ике аты бар иде («эти»не Кырым татарлары баба диләр) һәм файтоны. Шул файтоны белән ял иткән бай-НЭПманнарны, советның яна түрәләрен тегендә-монда йөртә, аларны табигать кочагына да алып чыккалый. Шәһәр эчендә, хәзергечә әйтсәк, такси ролен үтәп, кеше ташый иде. Колхозлар оеша башлагач, әтине кулак дип гаепләп ябып куйдылар. Каядыр озатырга чамалыйлар. Ә бит гаиләдә без тугыз бала, тагын әле олы әти белән олы анам һәм бабамның анасы, карт анамыз. Шулай итеп, уникe кеше без. Әниебез атларны һәм файтонны, башка эш коралларын колхозга тапшырды. Күршеләр дә җыелышып яклап яздылар. Шуның аркасында гына баба (әти) торып калды. Менә шулай итеп колхозга кереп киттек. Колхоз колхоз инде. Ни башы, ни арты дигәндәй. Түрәләр күп, тәртип кенә юк. Әтиебез үзебезнең атлар белән колхозда эшли башлады. Аннан әтине сугышка алдылар.

Ә инде кырык дүрттә безне башкалар кебек үк алып киттеләр. Апан

сөйләгәннәрдән бер аермасы да юк. Минем дә ул чакларны искә төшерәсем килми. Бик алама чаклар иде. Бу турыда төрле һәм күп китапларда, журналларда язылды. Сезгә Кырымга барырга кирәк. Анда татар Милли мәҗлесе эшли. Әйдәгез, мин сезне Ришат әфәнде белән таныштырам. Ул безнең халыкның, гомумән, монда яшәгән мөселманнарның тормышы-көнкүреше һәм бүгенге хәлләре белән якыннан таныш. Һәм дә үзе тирә-ягына барча мөселманнарны туплап, корбан бәйрәмнәре, сабантуйлар оештыра.

Менә без Сәрвәр абзый белән Ришат әфәнденең йорты кырына килеп җиттек. Яна гына төзелгән өч катлы йортның тирә-яктагы йортлардан зурлыгы һәм матурлыгы белән әллә каян аерылып торганына игътибар итсәң, бу йортта бик булдыклы һәм эшчән кеше яшәгәнен чамаларга була. Һәм йорттан бик тәмле булып яна гына мичтән чыккан икмәк һәм тәм-томнар исе борынны кытыклый. Сәрвәр абзый миңа кыскача гына Ришат әфәнде турында сөйләп, аның яна йорты белән таныштыра. Абзый бу йортта бик еш була, күрәсең. Менә өйнең подвал өлешендәге гараж эченнән «Газель» машинасы килеп чыкты. Абзыем әйтүенчә, Ришат әфәнде шушы зур йортының ярым подвалында сату өчен әпәй пешерә икән. Беренче катында азык-төлек кибете. Без кибеткә килеп керергә өлгермәдек, кырдагы бер ишектән хуҗа үзе килеп чыкты. Сәрвәр абзый белән бик җылы гына куллар биреп күреште дә, миңа дә елмаеп кул сузды. Мин аны-моны әйтергә өлгергәнче Сәрвәр абзыем минем белән таныштырды. Ришат әфәнденең аның саен йөзе яктырганнан яктыра. Без өчәүләп тап-таза итеп чынлатып татарча сөйләшәбез. Миңа хәтта үзебезнең якта, берәр күрше районда йөргән сыман булып китте.

Ришат әфәнде (монда шулай әфәнде диебрәк сөйләшәләр һәм бу миңа бик тә ошый) безне үзенең бүлмәсенә, өйнең икенче катына дәшә. Сәрвәр абзый гафу үтенеп үзенең каядыр Коръән ашына чакырылганлыгын әйтә һәм бездән шуңа рөхсәт сорый. Мондый изге эшкә кем каршы булсын инде. Без риза. Абзыйга күп рәхмәтләр укып, аның белән бик тә җылы итеп һәм туры килсә тагы очрашырга сүз куешып аерылышабыз.



Менә шулай итеп без Ришат әфәнденең эш бүлмәсендә икәү генә торып калдык. Һәм якыннан таныша башладык. Хуҗа хуҗа инде. Телефон трубкасын гына күтәреп кемгәдер чәй табыны әзерләргә кушты. Әфәндемнең йөзе кояштай балкый. Әйтерсең лә озак күрми торган якын туганын очраткан. «Бу мине үзенең эшмәкәрлеге турында язарга килгән берәр хәбәрче-фәлән дип уйлый инде дим эчтән генә. Ләкин хикмәт бүтәндә икән. Ришат әфәнде минем якташым булып чыкты. Ташкент якларында туып, Ишембай шәһәрендә яшәгән икән ул.

Ул арада чәй табыны әзер дип хәбәр иттеләр. Һәм без, ике якташ, чын үзебезчә чәйләп утырабыз менә. Сүзем Кырым татарлары турында булса да, әнисе Авыргазы районы Әпсәләм авылыннан, әтисе исә Миякә районыннан булган якташым турында әйтеп китми кала алмыйм. Абзалетдинов Ришат Максут улы Ишембай каласында, аннары, Эстәрлетамакта һәм Уфада төрле җитәкче урыннарда эшләгән. Теге «перестройка» дигән болганышлар башлангач, Анапа шәһәренә килеп урнашкан. Кыскасы, үзебезнең кеше. Шушы шәһәрдәге көллиятләрдә укытучы да, директор да булырга өлгергән. Хәзерге көндә шәхси көллият ачу белән мәшгуль. Һәм шул ук вакытта эшкуарлык белән дә шөгыльләнә. Әйткәнемчә, Анапски бистәсенең күп кенә кибетләрен яңа пешкән ипи һәм булки-калачлар белән тәэмин итеп тора. Әйтүенчә, тирә-як кибетләргә әпәй-калачларны пешереп өлгертә алмый, ихтыяҗ бик зур икән. Шулай итеп, ул эшләре гөрләп барган эшкуар икән. Алай гына да түгел, берничә ел Мәскәүдә дин гыйлеме алып, әлеге көнне имам дәрәҗәсендәге кеше дә. Һәм ул миңа үзенең эш бүлмәсе кырында гына булган зур-зур ике залны күрсәтте.

— Менә монда һәр җомга саен бистәдәге мөселман кешеләре намазга йөриләр. Бу залда ирләр, бабайлар укыса, монсына бәйрәм көннәрендә хатын-кызлар җыелып киләләр, — ди.

Чынлап та, бу ике залның идәннәренә зур-зур келәм-паласлар җәелгән. Ирләр ягындагы залда вәгазь сөйли торган мөнбәргә кадәр ясап куелган. Бик күп дини китаплар мөнбәр кырындагы шкафта урын алган.

— Дини бәйрәмнәрдә, бигрәк тә корбан бәйрәмендә халык күп җыела. Менә быелгы корбан бәйрәмендә унбер сарык корбан чалынды. Аш әзерләдек. Ятимярлылар өчен табын оештырдык. Андыйларның исемлеген дә төзедек. Бер мөселман да читтә калмасын дип тырыштык, — дип сөйли хәзрәт.

Мин үземне борчыган сорауны бирмичә булдыра алмадым.

— Монда татарлар шулай күпмени?

— Безнең як татарлары ул кадәр юк. Бармак белән генә санарлык. Булганнарының да хатыннары күбесе башка дин кешеләре. Ә менә Кырым татарлары җитәрлек. Мине шунысы борчый: яшьләр дингә сирәк тартыла. Депортация галәмәтенең Кырым татарларына кире йогынтысы бик көчле. Халык куркуыннан айнып бетә алмый. Икенчедән, монда кире кайткан Кырым татарларын алар урынына килгән халыклар(башка диндәгеләр) колач җәеп каршы ала дип уйлыйсызмы? Әлбәттә, юк. Шуна да мәрһүм булган туганнарыбызны христиан зиратына күмәбез. Алай гына да түгел, безгә мәчет төзергә урын бирмиләр. Кырым татарлары бергә җыелмасын өчен, кайткан татарларга Краснодар өлкәсенең төрле җиреннән урын бирергә мөмкиннәр. Тик бу тирәгә, тарихи яшәгән урыннарына гына түгел. Депортациядән кайткан поляклар, алманнар (немецлар) төрле мажаралар белән чак-чак үзләренең католик чиркәүләрен төзи алдылар әнә. Анда да әле Германия белән Польша илчелекләре Россиягә рәсми хат белән мөрәҗәгать иткәч кенә урын бирделәр. Ә җирле православный динлеләр үзләренең зур-зур тәреләрен һәр юл аермасына утыртып куйдылар. Монда кем хуҗа икәнен белеп торыгыз дигән кебек. Утыртсыннар, табынсыннар, гыйбадәт кылсыннар. Алла барыбыз өчен дә бер. Тик мөселман булган халыклар өчен дә бераз иркенлек кирәктер бит, үзләренең дини йолаларын үтәргә. Менә минем шушы шәхси көллият ачуым да, ислам динен тотуым һәм исем-фамилиям дә хакимияттә торганнарга бер дә ошамый. Әмма без бирешмибез. Алга куйган ниятләрне җайлап кына тормышка ашыра барабыз. Менә былтыр җәй Салават шәһәреннән артистлар килде. Оренбургтан да килеп хәл белеп, тамашалар күрсәтеп китәләр. Унае чыкканда тагы шуны да әйтәсем килә. Укучы балаларны диңгез күрсәтергә, әзрәк ял итеп, диңгездә су коенып алырга, гомумән, экскурсиягә бер-ике атнага алып килергә мөмкинсез. Бик кыйммәт булмаган торыр урын оештырырга була. Югыйсә кунакханәләр, пансионатлар бик кыйммәт монда. Бигрәк тә җәй айларында.

Менә шулай күңелле генә гәпләшеп, чәйләп утырабыз һәм сүзебез җайлап кына тагы туган илләреннән куылган Кырым татарларына килеп терәлә. Депортация шушы тирәдә яшәгән күп халыкларга кагылган. Татарлар белән бергә әрмәннәр, греклар, болгарлар һәм башка кавемнәр дә куылган. Депортация ике өлештән торган. Беренчесе — кырык икенче елдан соң ук. Немецлар басып алган җирләрне азат иткәннән соң. Ә инде иң һәлакәтлесе, иң фаҗигалесе кырык дүртенче елның унҗиденче һәм унсигезенче майларында була.

Яңадан бу темага кайтып, мина:

— Сезгә Осман, Диләвир һәм Куртимер әфәнделәрне күрергә кирәк, — диде Ришат әфәнде. — Куртимернең әнисе дә исән. Апа күп нәрсәләр белергә тиеш. Шушы көннәрдә мин сезне очраштырырмын. Ә хәзер, әйдәгез, — дип, минем айваема карамый үзләренә алып китте. Аның Анапада да фатиры бар икән. Менә мин Ришат Әхмәтҗанов әфәнделәрдә кунактамын. Хатыны Казан татары, өч ул һәм бер кыз үстереп аякка бастырырга әзерләнәләр. Олы улының хатыны да Казанның үзеннән булып, аерым торалар икән. Өченче уллары, компьютер белгече, әтиләре белән бергә яши. Кызлары Мәскәүдә экономистка укый. Әйе, безнең халык монда да кунакчыллыгын җуймаган. Һәм мин Ришат әфәнделәрдә кунак булып, яхшы гына сыйланып алдым.

Безнең якларда сыйлану сүзен кайберәүләр аракы эчү белән бутыйлар. Бу якларда аракы эчүчеләр мөселманнар арасында юк дәрәҗәсендә. Без чәйләр эчеп, башка сый-нигъмәтләр белән сыйландык. Кич соң гына, хатыны Әлфия ханым белән, мине

Ял йортына чаклы озатып куйдылар. Юлда алар шәһәр белән таныштырып, тарихи урыннарны күрсәтеп килделәр. Кырым татарлары белән таныша башлавымның беренче көне әнә шулай үтте. Үземчә бик уңышлы булды дип уйлыйм.

***

Түземсезлек белән тагы бер-ике көн үтеп китте. Һәм менә мине шатландырып бүлмәдәге телефон аша Ришат әфәнде алдан вәгъдәләшкән Кырым татары белән очрашырга мөмкинлек бар икәнен әйтте.

Османның йорты әллә кайдан ук күз явын алып, тирә-якка балкып тора. Безне капка төбенә үк чыгып каршы алдылар. Өйнең тышы гына түгел, эче дә күз явын алырлык итеп эшләнгән. Һәм бик зәвык белән бай итеп җиһазланган. Йорты иркен, һәм йортның икенче яртысында, шулай ук таш йортта улы үз гаиләсе белән тора. Осман абзый хәләл җефете Зәйтүнә ханым белән шулай матур итеп яшәп ята.

Зәйтүнә апа үзе Казакъстанда туа. Әнисе Кырым татары кызы. Гаиләләре белән 42нче елны ук Керч каласыннан халык дошманнары дип Чиләбегә сөрәләр. Әтиләре бу вакытта фронтта була. Чиләбе өлкәсендәге ниндидер бер колхозга барып урнашалар. Ачтан үлмәс өчен нәрсәләр генә эшләргә туры килми аларга. Курсаитов Юсуф исемле энеләре эштән кайтканда итеге эченнән ике уч бодай табалар. Юсуф, ул ике уч бодайны апасының балалары ачтан үлмәсен дип алган була. Хөкем итәләр. Дүрт балалы хатынны колхоз рәисе хөкем иттерми. Җәлләп алып кала. Әмма тиз арада бу тирәдән качып китәргә киңәш бирә. Чөнки урындагы КГБ хезмәткәре аларның ачтан үлүләрен көтеп йөргән икән. Колхоз рәисенә дә һичнинди азык бирмәскә дип әйтеп куйган була. Болар ачтан үлмәгәч, шешенмәгәч, Юсуфны тентиләр. Рәис аларга кая китәргә кирәклеген дә әйтә. Шулай итеп, ике хатынга җиде бала белән Казакъстанга, Күкчәтауга таба качып китәләр. Юлда ачтан шешенер хәлгә житкән балаларны күреп, бер чегән хатыны Зәйтүнә апаның картәнисен фасоль борчагы белән күрәзәлек кылырга өйрәтә. Шуның белән тамак туйдыра-туйдыра барып житәләр. Әмма шунда барысы да тиф белән авырып китәләр. Бары Зәйтүнә ханымның әнисе генә авырмыйча кала. Һәм ул барысын да карап дәвалый. Тормыш әкренләп җайга салына башлый. Ни дисәң дә, Күкчәтау шахтерлар шәһәре. Шахтерларны азык-төлек белән тәэмин итү дә күпкә яхшырак. Ләкин качып килүчеләргә язмыш һаман үзенең сынауларын җибәреп тора. Шунысы кызыклы, Зәйтүнә ханымның булачак әтисе, чыгышы белән Башкортстанның Дәүләкән районыннан, бу Кырымнан куылган ябык кына качкын татар кызына (Зәйтүнә ханымның әнисенә) үлеп гашыйк була. Фин, Бөек Ватан һәм Япон сугышларында катнашып кайткан егет була. Гомумән, утны-суны кичеп кайткан бу Абзалетдин атлы шахтер егетне кыз (Зәйтүнә ханымның әнисе) нигәдер өнәп бетерми. Кызның әнисе, ягъни Зәйтүнә ханымның картәнисе, бу хәлне белеп алгач, кызын Абзалетдингә кияүгә чыгарга үгетли. Кыз, ничек кенә каршы торса да, әнисен тыңламыйча булдыра алмый. Туганнары ачлыктан шешенә башлыйлар әнә. Һәм шушы егеткә кияүгә чыккач кына аларнын тамаклары ризыкка туя башлый. Ни дисәң дә, шахтерларның эш хаклары әйбәт һәм гаиләләрендәге эшләмәгәннәргә дә беркадәр микъдарда паек бирелә. Кызның әнисе үлгәнче киявенә рәхмәт укый. «Син бит безне ач үлемнән коткарып калдың, кияү, үзенә дә, сине тапкан ата-анаңа да рәхмәт», ди. Шуннан инде, бер ел үткәч, Зәйтүнә ханым туа.

Ә Осман абзыйның әтисе Ослан1906 елгы булып, аны да 1939 елны фин сугышына алалар. Шуннан инде Бөек Ватан сугышы башланып китә. Ул илебезне саклап кан коя, ә өендә гаиләсен Кырымнан Үзбәкстанга сөрәләр. Сөрелгәннәрне дүрт иске пароходка дыңгычлап төйиләр. Дингезне кичеп чыкканда шуларның өчесе бата. Ниндидер самолетлар пароходларны бомбага тота. Конвой төялгән пароход кына исән кала. (Бик тә сәер бу.) Шушы конвойлар күпләп утырган пароходтагы Кырым татарлары гына котылып кала. Әниләре Жаппарова Сабе апа да балалары белән шул пароходта булып, дингезне исән-сау кичеп чыга. Тик юлда кызлары үлә, аның гәүдәсен бер станциядә калдырып китәргә мәҗбүр булалар, җирләргә ирек бирмиләр. Уллары Осман белән Рөстәм генә исән кала. Ослан абзый гаиләсен кырык бишенче елның көзендә генә эзләп таба. Куылган халыкның бер өлеше Сырдәрья

өлкәсендә Гөлестан районы Крупская исемендәге колхозда мамык үстергән. 200-250 грамм бодайга эшләдек, дип сөйли Осман абзый.

— Шуннан шул бодайны әни төнен кул тегермәнендә тарттырып, боламык пешереп ашатты. Тәүдә аена бер тапкыр НКВД бүлегенә барып билдәләнсәк, азактан ун көн саен барып билдәләнергә кушылды. Үзбәк халкынын да төрлесе бар иде. Аларны да куркытып куйганнар. Ярдәм итсәгез, үзегезне дә Себергә сөрәбез диеп. Ә без ач-ялангач идек. Бер абыебызны бакчага кереп бер карбыз ашаган өчен кәтмән белән сугып үтерделәр. Тикшереп тә тормадылар. Безне бер җирдә дә колач җәеп көтмәделәр. Тиф белән авырып халык күп кырылды. Әтине тире иләп чүәкләр теккән өчен чак төрмәгә утыртмадылар. Зур штраф түләп кенә котылып калдык. Ай куркыныч, алама чаклар бар иде. Ә без эшчән, укымышлы һәм чиста халык. Шунын аркасында гына күпләребез исән калды. Татарлар белән бергә яшәгән үзбәкләр алардан күреп матур, чиста яши башлый. Хәтта өйләрен дә татарларга охшатып салалар, алар кебек агартып, буйыйлар. Элек өйләрдә урам якларында тәрәзә булмаган. Соңыннан гына бездән күреп урам якка тәрәзә уя башлыйлар.

Мин абзыйны бүлдереп, сорау бирмичә булдыра алмадым.

— Бик житеш яшисез, Осман ага, сере нәрсәдә?

— Бик гади. Таннан торып эшкә җигелдем. Кара таннан торып, помидор үсентеләре утыртам. Аннан вакыты җитүгә хөкүмәт эшенә йөгерәм. Эштән кайтуга тагы бакчада эшлим. Балаларымны да шуна өйрәттем. Һичкайчан исерткеч эчемлек белән, тәмәке белән мавыкмадым.

Осман ага гаиләсе белән үткән гасырнын сиксәненче елына чаклы Үзбәкстанда яшәгән. Күп кыенлыклар аша Новороссийскига кайтып урнашалар. Аннан соң гына шушы Анапа шәһәренә күчеп киләләр. Абзыйнын йортында да бик тәртип. Бәләкәй генә теплицалары да бар. Төрле-төрле җимеш агачлары, уралып-уралып өй кыегына, ихатага үрмәләгән йөзем куаклары да байтак күренә. Өй хуҗасынын әйтүенчә, алар Урта Азиядә дә начар тормаганнар. Үзбәкстанда да шушынардан ким булмаган йорт-җирне бушка калдырып, туган якларына кайтып киткәннәр.

Шулай танышып сөйләшүләр һәм Кырым туганнарымнын милли ашларыннан, Краснодар ягында үскән тәмле чәйләреннән авыз итә-итә көннен үткәне сизелми дә калган. Осман аганың гаиләсе белән саубуллашып, кайтырга чыгам. Алар мине тагы да кунакка килергә чакырып, саубуллашып, якын туганнары кебек озатып калалар.

***

Менә татар туганнарым арасында тагы бер көнем үтеп китте. Шушы көндә ишеткәнем ничәмә кешенен гомер юлын үзенә сыйдырган. Барысын да яза башласаң, әллә ничә китап томы булыр иде. Шуна да бик кыска гына итеп язарга тырышам.

Ришат әфәнде икенче көнне дә үзе шылтыратты. Ул мина тагын бер кызыклы гына шәхес — Газиев Диләвир атлы Кырым татары белән очрашу мөмкинлеге бар дигәч, ике дә уйламый Ришатның эшләгән урынына киттем. Хәзер инде минем анда тиз генә барып җиту тәҗрибәм дә бар. Ярты сәгать тә үтмәде, мин инде Ришат белән Диләвир абзыйлар гаиләсендә кунакта утырам.

Диләвир абзыйларның өйләре дә шәп итеп эшләнгән. Шулай ук зур гына йорт биләмәсендә ике өй бетергәннәр. Йортларның берсендә үзе, икенче йортта кече улы гаиләсе белән яши икән.

Диләвир абзыйның хатыны Лидия Алиевна сөйләп алып китте: «Безне Балаклав шәһәреннән депортировать иттеләр. Мин үзем 39нчы елгымын. Әмма безне ничек дошман самолетлары бомбить иткәнне әзрәк хәтерлим. Бик куркыныч булгандыр, шуна да ике яшьлек баланын хәтерендә калгандыр инде. Ә бүтән хатирәләр бик үк исемдә юк. Олылар сөйләгәннәрдән генә беләм. Әтиебез олы яшьтә булу аркасында сугышка алынмаган. Оккупация вакытында подпольщик булган. Оккупантларга каршы көрәшкән. Чөнки партия әгъзасы иде. Ул — укытучы. Депортация алдыннан берничә көн алдарак районга чакырып, кисәтеп куйганнар. «Ниндидер бер коточкыч, алама хәлләр булырга тора, әзер тор», диеп.

Андижан өлкәсе Ленин районындагы бер урыс авылына эләктек. Бу авылдагы

урысларны да Екатерина патша вакытында шушында сөргән булганнар икән. Шуңа да алар бер дә гаҗәпләнмәделәр, безне аңлап, төрлечә ярдәм итеп, безгә яхшы мөгамәләдә булдылар. Урыс мәктәбендә урысча укыдым. Шуңа да урысча бик яхшы сөйләшәм. Һич аерып алырлык түгел. Менә шул урысча белүем туган якка, Кара диңгез буена кайтып төпләнергә ярдәм итте. Без бу якка житмеш алтынчы елны ук кайттык. Качып дигәндәй кайттык. Чөнки тегеннән безне жибәрмиләр. Ә бит 1976 ел. Беркайда да пропискага алмыйлар. Дүрт бала белән кайтып төштек. Ирем тагын үзенең эшенә чыгып китте. Ул нефть-газ разведкасында эшли иде. Аптырагач, шәһәр хакимиятенә киттем. Прописка эшләрен тикшерергә өлкәдән жибәрелгән бер ханымга кердем. Хәлне сөйләп биреп, гозеремне әйттем.

— Мине, — дим, беркайда да пропискага алмыйлар. Сез менә махсус жибәрелгән кеше, ярдәм итегез, рәхим итеп, — дим.

— Ничек? Кем сезне пропискага алмый? Хәзер үк чарасын күрербез, — ди бу хатын, бик тә кемгәдер ачуланып. Һәм кеше хәленә керә белмәгән совет бюрократларын һәм милициядә бу өлкәдә җаваплы кешеләрне әрләргә керешә. Минем алда алар өчен үзенә бик оят булганын әйтеп:

— Бирегез әле паспортыгызны. Исем фамилиягезне язып алыйм. Иртәгә үк кайсы касабадан, кайсы шәһәрдән өй алырга телисез, шунда сезне теркәрләр.

Мине бик яхшы кабул иткән һәм миңа кичекмәстән ярдәм итәргә әзер булган ханымга паспортымны сузам. Паспортымны алды да, исем шәрифләремне укыгач, чак атып бәрмәде. Әйтерсең лә кайнар пәрәмәч тоттырдылар. Юк, юк, кайнар пәрәмәч кенә түгел, ә кулына кара елан уралдымыни. Һичшиксез атып бәрер иде, кискен хәрәкәттән еланның чагып куюы бар. Атып та бәрә алмый, тотып торырга да куркыныч бу паспорт! Нәрсә эшләргә дә белми. Әле генә күкләр күкрәтеп, яшен яшьнәтеп утлар чәчкән хатын тынып калды. Зиһене буталды, кулындагы минем паспортны кая куярга да белми. Паспорт калтыранган кулыннан идәнгә үк төшеп китте. Ирексездән Владимир Маяковскийның шигыре исемә төшә:

*Берет*
*как бомбу,*
*Берет*
*как ежа.*
*Как бритву*
*Обоюдоострую*
*Берет*
*как гремучую*
*20 жал*
*Змею двухметроворостую.*

Тик бу шигырьдә капиталист таможнигының егерменче елларда совет паспортын кулына алганы сурәтләнә. Ә бит шул ук кызыл тышлы паспортны Совет чиновнигы әле генә куркуыннан идәнгә төшереп жибәрде. Менә шулай, туганым. СССР да, аның калдыгы Россия дә — парадокслар иле. Без Үзбәкстанда төрле милләт кешеләре бертуган булып яшәдек. Ә менә хәзер үземнең төп Ватанымда, әти-әниләр, бабай-картәтиләрнең кендек каннары тамган жирдә мин— чит. Үз илем дип йөргән илдә мин — килмешәк, үги бала хәлендәмен. Кайсы гына «өлкән агайлар» күпләп яшәгән өлкәгә барма, без анда килмешәк хәлендәбез. Безнең белән балаларны куркыталар. Алар үзләренең нинди гөнаһ, нинди коточкыч аламалыклар эшләгәннәрен беләләр. Шунардан куркалар. Без Кырым татарларыннан түгел, ә үзләренең безгә карата нинди геноцид эшләгәннәрен исләренә төшерүдән куркып, тагын да аламарак гөнаһлар кылалар.

*Ахыры киләсе санда*

# П

**ПЕРЦОВ** Эраст Петрович (29.11.1804, Воронеж ш. – 11.7.1873, С-Петербург ш.), шагыйрь, драматург, публицист. «Ришвәт алу сәнгате. Мәрхүм титуляр советник Тяжалкин кәгазьләре арасында табылган кульязма» («Искусство брать взятки. Рукопись, найденная в бумагах Тяжалкина, умершего титулярного советника», 1830) сатирасы, «Андрей Бичев, яисә яхуд Мин кешеләрдән көләм» («Андрей Бичев, или Смешны мне люди», 1833) комедиясе, «Механиканың гомумхалык курсы» («Общенародный курс механики», 1847) белешмәлеге, крепостной хокукны тәнкыйтьләүче шигырьләр, сәяси вазгыять, министрлыкларның эшчәнлеге, крестьяннар чуалышларына багышланган очерклар цикллары авторы. 1811 дән П. гаиләсе б-н Казанда яши, 1824 тән – С.-Петербургта. 1830 елларда П. озаклап Казанда яшәп ала. Е.А.Боратынский б-н таныш була. 1833 тә Казанга килгәндә П. янына А.С.Пушкин сугыла, анда берничә тапкыр М.С.Щепкин туктала. Шагыйрьнең биографы Н.Я.Агафонов сүзләренә караганда, Казанда П. җәмгыятьнең үзәгендә торып, «җәмгыять тормышын җанландыручы» булып санала, А.А.Фуксның әдәби түгәрәгенә йөри. 1861 дә С.-Петербургта «Колокол» ж-лы б-н хезмәттәшлек иткән өчен кулга алына. Тентү вакытында П.ка юлланган хат пакеты б-н Казан губ. Бездна а. булган крестьян чуалышын тасвирлаган материаллар алына. П. Түбән Новгородка сөрелә (сәламәтлеге начар булу сәбәпле азат ителә). Үзенә үзе кул сала.

Әд.: Бобров Е.А. А.А.Фукс и казанские литераторы 30-40-х гг. // Русская старина. 1904. Т.119, №7.

*М.М.Сидорова.*

**ПЕТРОВ** Константин Константинович (1.4.1924, Буа кантоны Чуваш Биморзасы а. – 2.11.2007, Чабаксар ш.), язучы, журналист, филол. фән. канд-ты (1968). 1941 дә Ульян чуваш пед. уч-щесын, 1958 дә – КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбен (Мәскәү) тәмамлый. 1946-63 елларда «Хёрле ялав» г-тасында (Казан), в 1963-68 «Коммунист Татарии» ж-лында эшли, бер үк вакытта 1963-84 елларда Казан ун-тында укыта. 1984-90, 1995-99 елларда Чуваш ун-тында укыта. «Яратсан» («Юратсан», Чабаксар, 1969) хикәяләр җыентыгы, «Мәхәббәт һәм агу» («Юратупа наркамаш», Чабаксар, 1972), «Тайар» (Чабаксар, 1976), космонавт А.Николаев турындагы «Зәңгәр йолдыз» («Сенкер салтар», Чабаксар, 1991; рус телендә - 1999), «Гаепләләр» («Айаплисем», 1995), шагыйрь М.Сеспель турындагы «Яшәү һәм үлем» («Пурнасма вилем», 1999) романнар; «Тылсымлы сүз» («Асамла самах», Чабаксар, 1990) исемле балалар өчен әкиятләр җыентыгы; чуваш журналистика тарихы буенча хезмәтләр авторы.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

**ПЕХТЕЛЕВ** Иван Георгиевич (21.4.1906, Саратов губ. Камышин ш. – 30.8.1969, Казан ш.), әдәбият галиме, филол. фән. д-ры (1956), проф. (1957). Саратов ун-тын тәмамлый (1931). 1933-38 елларда Әстерхан пед. ин-тында каф. мөдире. 1939 дан Казан пед. ин-тында (1946 га кадәр әдәбият каф. мөдире), 1962 дән Казан ун-тында (1962-67 елларда журналистика каф. мөдире). Хезмәтләре 20 йөз башы рус-татар әдәбиятлары бәйләнешләренә, рус рев.-демокр. тәнкыйть тарихына, В.Г.Белинский, А.И.Герцен, Н.А.Добролюбов, Д.И.Писарев һ.б. иҗади мирасына карый. Г.Тукай, С.Хәким, Ә.Ерикәй, Г.Кутуй, Г.Бәширов һ.б. иҗатларына багышланган мәкаләләр авторы. «Почёт Билгесе» ордены, медальләр б-н бүләкләнә.

Хезм.: Габдулла Тукай: Жизнь и творчество. К., 1946; Белинский как историк русской литературы. К., 1957; Тукай и русская литература. К., 1966; Герцен – литературный критик. М., 1967.

Әд.: Гиниятуллина А. Писатели Советского Татарстана: Биобиблиогр. справ. К., 1970.

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

**ПИРГУЛИ** (Pirguli) Мөхәммәд (1538-1573), төрек шагыйре, татарлар арасында киң таралган «Пиргули васыйәте» дини-дидактик әсәре авторы. Анда популяр формада шәригать кануннары, мөселман дини йолаларын үтү тәртипләре турында язылган. Китап татар теленә тәрҗемә ителгән (авторы билгесез). 1802 дә Казанда басыла, татар мәктәп-мәдрәсәләрендә уку әсбабы рәвешендә кулланыла.

**ПОВАРИСОВ** Суфиян Шәмсетдин улы (29.8.1924, Бөре кантоны Тыпый а.), тел галиме, язучы, филол. фән. д-ры (1992), проф. (1992), Башкортстан, Татарстан Респ-калары атказ. фән эшлеклесе (1992, 2005). РФның югары белем мәктәбе мактаулы хезмәткәре (1997). Татар һәм башкорт телләрендә яза. Казан ун-тын тәмамлаганнан соң (1955) Актаныш р-ны Бурсык урта мәктәбенең директоры булып эшли. 1958-60 елларда «Кызыл таң» г-тасында әдәби хезмәткәр. 1960 тан Башкорт ун-тында. Хезмәтләре татар теленең стилистика, лексика, морфологиясенә, әдәби сүз сәнгатенә карый. Урта мәктәп һәм вузлар өчен уку әсбаплары авторы. «Яратам сине, тормыш» (Уфа, 1963), «Сөмбел» (Уфа, 1973), «Ышанам һинә» (Уфа, 1984), «Йәшлек йылдары» (Уфа, 1992) һ.б. повестьларында әхлакый мәсьәләләр күтәрә, «Биш партизан» (Уфа, 1987), «Үлемһеззәр юлы» (Уфа, 1996) повестьларында, «Язмыш корбандары» (Уфа, 1996) һәм «Ут эсендәге мөхәббәт» (Уфа, 2005) автобиографик романнары Гражданнар һәм Бөек Ватан сугыш вакыйгаларына багышлана. Татар әдәбияты классигы Г.Ибраһимовның фаҗигале язмышы «Пәйгамбәр таңы» (1999), «Күкнең җиденче катында» (1999), «Оҗмахка бер адым» (2000) китапларыннан торган трилогиядә чагылыш таба. П. - «Һөйзергән дә тел, биззергән дә тел» (Уфа, 1969), «Кәрлә йондоз» (Уфа, 1974), «Ауылымдын алһыу таңдары» (Уфа, 1986) һ.б. пьесалар авторы. Бөек Ватан сугышында катнаша. 2 нче дәрәҗәле Ватан сугышы, 3 нче дәрәҗәле Дан орденнары, медальләр б-н бүләкләнә.

Әс.: Язык и стиль прозы. Уфа, 1979; Легенды о счастье. Уфа, 1985; Тел — күңелнең көзгесе. К., 1982; Татар телендә чагыштырулар. Уфа, 1996; Сүз һәм сәнгатьле сөйләм. Уфа, 1997; Сайланма әсәрләр: 3 томда. К., 1999-2000.

Әд.: Суфиян Шамсутдинович Поварисов: Биобиблиогр. указ. Уфа, 2005.

*С.Г.Сафуанов.*

**ПРИХОЖАН** Пётр Борисович (11.2.1940, Крым АССРның Евпатория ш.), шагыйрь. Харьков инж.-төзелеш ин-тын тәмамлый (1964). Братск ш. урман сәнәгате комплексын, КамАЗ, «Атоммаш» (Ростов өлкәсенең Волгодонск ш.) з-дын төзүдә катнаша. 1971 дән Чаллыда яши. Беренче шигырьләре матбугатта 1962 елда чыга башлый. Иҗатында мәхәббәт һәм гражданлык лирикасы өстенлек итә. «Гулливерлар» («Гулливеры», 1970), «Танышу» («Знакомство», 1986), «Багу өчен түләү» («Плата за гадание», 1990) шигъри җыентыклар авторы. «Шәһри Китеж турында уйлану» («Дума о граде Китеже», 1970), «Төзелеш» («Стройка», 1989), «Алексей һәм Ефросинья» («Алексей и Ефросинья», 2000) поэмаларында Россиянең үткән тарихи вакыйгалары автор фикерләвендә бирелә. «Критерийлар» («Критерии», 1998) поэмасы поэзиянең кеше шәхесе үсеше тәэсиренә багышланган. Рус теленә Г.Тукай, Г.Кашапов, И.Юзеев, Н.Мадьяров, Р.Миңнуллин шигырьләрен тәрҗемә итә.

Әдәб.: Хуснуллин Х. Идущий за четвёртым ветром // Светлый путь. 1992. 24 окт.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ПСЕВДОНИМ** (тәхәллүс), (грек. pseudoc — уйдырма, ялган һәм onyma - исем), чын исем-фамилияне алыштыра алган шартлы исем. П.ның барлыкка килү сәбәпләре: чын фамилиянең начар яңгырашы, бер үк фамилияле берничә кеше булу, цензурага бәйле сәбәпләр, иҗадта үз көченә ышанмау, исемне белдерергә теләмәү һ.б. Барлык әдәбиятларда да очрый, бигрәк тә Шәрекъ әдәбиятында. Татарларда исем (яки кыскартылган исем) һәм кыскартылган фамилиядән барлыкка килгән П. киң таралган: Габдулла Тукай (Габдулла Тукаев), Фатих Әмирхан (Фатих Әмирханов), Галиәсгар Камал (Галиәсгар Камалетдинов), Кави Нәҗми (Габделкави Нәҗметдинов), Гадел Кутуй (Гаделша Кутуев), Муса Җәлил (Муса Җәлилев) һ.б. Кайбер П.лар киң таралмый калган очракта, кеше кире үз фамилиясенә кайта (Разин — Г.Бәширов, Бичура — А.Тагиров); кайвакыт П. фамилияне кысрыклап чыгарып әдәби исем булып кала (Кандалый — Габделҗаббар Габделмәҗит угылы, Акмулла — Мифтахетдин Камалетдин угылы, Дәрдемәнд — Мөхәммәдзакир Рәмиев, Г.Минский — Г.Аллаһбирдиев, Х.Туфан — Х.Кусинов, Н.Исәнбәт — Н.Закиров, С.Урайский — М.Мәүлетов). Кайбер очракларда исем П. булып китә (Сирин - Сирин Батыршин, Г.Газиз — Газиз Гобәй-

дуллин), аерым очракларда язучы исемен (Демьян Фәтхи — Касыйм Фәтхетдинов) яки фамилиясен үзгәртә (Г.Карам — Г.Рәхмәтуллин). П. кешенең туган урынын (Сәйф Сараи, Габдеррәфыйк Минзәләви, Мәхмүд Кашгари, Габденнасыйр Ибраһим улы Курсави, Нәжип Думави), этник группага (Мишәр, Кәбәй — Ф.Бурнашев), иҗади жанрга мөнәсәбәтле булуын (Татарин театраль — Г.Коләхмәтов), социаль чыгышын (Дамелла — Ф.Әмирхан), характер үзенчәлеген чагылдырырга мөмкин (Утмалай — Г.Кутуй, Әүлия — Г.Камал). Кайбер вакыт автор кыскартылган фамилиясенә сүз өсти (Ф.Сәйфи-Казанлы). Аерым язучыларның берничә дистәгә якын П.нары җыела (мәс., Г.Тукайныкы 60 тан артык). Бу күренеш бигрәк тә 20 йөз башына хас, чөнки күпсанлы газета-журналларда барлык диярлек язучылар язышa. Аерым очракларда бер санда язучының берничә мәкаләсе басылганда, автор төрле П. кулланырга мәҗбүр була. Кайвакыт автор мәкаләнең эчтәлегеннән чыгып төрле типтагы П. куллана. Мәс., сатирик әсәрләрен Ф.Әмирхан Ташмөхәммәд (яки кыскартып Т-д), әдәби-тәнкыйди мәкаләләрен Дамелла, ә 1917 елдан соң язылганнарын Марксист П. б-н бастыра. Г.Тукай җитди әсәрләрен тулы исеме б-н, ә сатирик әсәрләрен Шүрәле, Тиктормас, Бик усал, Мин язмадым, Кырмыска һ.б. П. б-н бастыра. Кара ш.у. Атрибуция.

Әдәб.: Һади М. Псевдонимнар хакында берничә сүз // Казан утлары. 1969. №1; Мәһдиев М. XX йөз башы татар әдәбиятында псевдонимнар // Казан утлары. 1973. №1; Рәмиев З. Тукай һәм замандаш әдипләр. К., 2004.

*Р.Р.Мусабәкова.*

**ПУШКИН** Александр Сергеевич (26.5.1799, Мәскәү — 29.1.1837, С.-Петербург, Святогорск монастырендә җирләнә, бүген Псков өлкәсенең Пушкинские Горы п.), шагыйрь, яңа рус әдәбиятына нигез салучы, рус әдәби телен булдыручы. «Руслан һәм Людмила» («Руслан и Людмила», 1820), «Кавказ тоткыны» («Кавказский пленник», 1822), «Бакчасарай фонтаны» («Бахчисарайский фонтан», 1824), «Чегәннәр» («Цыгане», 1827), «Полтава» (1829), «Бакыр җайдак» («Медный всадник», 1837) шигъри поэмалар, «Евгений Онегин» (1833) шигъри роман, «Капитан кызы» («Капитанская дочка», 1936), «Белкин повестьлары» («Повести Белкина», 1837), «Дубровский» (1841) романнары, драма әсәрләре, әкиятләр, публицистик мәкаләләр авторы.

Е.И.Пугачёв җитәкчелегендә 1773-75 елларда барган Крестьяннар кузгалышы турында тарихи-документаль роман язу нияте б-н 1833 нең сентябрендә П. Казанда булып китә. Шәһәргә ул 5 сентябрьдән 6на каршы төндә килә. Икенче көнне Сукно бистәсендә сукночы В.П.Бабин б-н очраша. Ул (әтисе-әнисе сүзеннән) шагыйрьгә 1774 елның июль вакыйгалары турында сөйли. 7 сентябрьдә К.Ф.Фукс б-н таныша. Аның турында «Пугачёв тарихы» («История Пугачева», 1834) романының искәрмәләрендә болай дип яза: «Мин аңа биредә тасвирланган чор һәм шушы як турында күп кенә кызыклы мәгълүматлар алган өчен бик рәхмәтлемен». Арча кырындагы Троицкая Нокса а. (бүген шәһәргә керә) әүвәле Пугачёв ставкасы урнашкан җиргә, Кремльгә бара, яшьли Пугачёв гаскәриләре тарафыннан кулга алынган сәүдәгәр Л.Ф.Крупенников б-н очраша. 8 сентябрьдә П. Казаннан китеп бара, юлда үзенең көндәлегендә: «Биредә мин картлар, минем геройның замандашлары б-н кайнаштым, шәһәрнең читләрен урап уздым, сугыш барган урыннарны карап чыктым, сораштым, язып алдым һәм бу җирләргә килеп чыгуым б-н бик канәгать калдым», - дип яза.

Шагыйрьнең тууына 100 ел тулу уңаеннан 1899 елда Казан ун-ты каршында А.С.Пушкин исталегенә багышлап «Рус телен сөючеләр җәмгыяте» оештырыла. 1956 елда М.Җәлил исем. Опера һәм балет т-ры янында П.га һәйкәл куела (скульптор Н.К.Вентцель).

Әсәр.: Собр. соч.: 10 томда. М., 1974-78.

Әдәб.: Архангельский А.С. А.С.Пушкин в Казани (5-8 сентября 1833 года); Несколько заметок о пребывании А.С.Пушкина в Казани с присоединением относящихся к этому литературных материалов. К., 1899; Бобров Е.А. А.С.Пушкин в Казани // Пушкин и его современники: Материалы исследования. СПб., 1905. Вып. 3.

*М.М.Сидорова.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

# «ЙОЗАК» АЧКЫЧЫ

Чаллы каласы әкрен генә, үз көенә генә яшәп ята. Эшчеләр шәһәре буларак төзелсә дә, уку йортларында белем алучы студентлар, аларның укытучылары, барыннан да бигрәк талантлы әдипләре белән үзенә хас интеллектуаль дөньясын, аның бер өлешен тәшкил иткән әдәби мөхитен формалаштырды. Чулман буендагы яшь каланың тарихка сәяхәт итүче Вахит Имамов, искиткеч эшчәнлеккә ия, ярсу йөрәкле Айдар Хәлим, милли җанлы, тарих аркылы татарның җирдә үз хокукы барлыгын исбатлауга Фәүзия Бәйрәмова, шагыйрә һәм галимә Рәзинә Мөхияр, бала җанлы Рәшит Бәшәр, татарның күренекле шәхесләре турында язып, кирәкле эш башкарган Ягъсуф Шәфыйков, талантлы һәм күзәтүчән, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясарга сәләтле Айгөл Әхмәтгалиева кебек әдипләре үзенчәлекле иҗатлары белән танылып, киң катлам татар укучысына хезмәт итеп киләләр.




Санап үткәннәрне Рахман Шәфигуллин исеме белән тулыландырмасаң, хакыйкатькә хыянәт итү булыр иде. Талантлы кеше бар өлкәдә дә талантлы шул инде, киң җәмәгатьчелеккә тележурналист, оста оештыручы буларак танылган Рахман Галим улы соңгы вакытларда «Шәһри Чаллы», «Мәйдан», «Казан утлары» газета-журналларында басылган хикәя-повестьлары белән шәһәребезнең генә түгел, республика укучыларының да игътибарын җәлеп итте. Ә инде аның 2012 елның ахырында дөнья күргән «Йозак» дигән китабы, мәхәббәт хисләре һәм татарны мескен итеп, кызганыч итеп сурәтләү белән сугарылган әдәбиятыбызда, гомумән, яңа аваз булды.

Әдипләр тарафыннан укучыда кызгану хисе уятыр өчен кыйналган, армиягә китсә йә гарипләтеп, йә үтерелеп кайтарылган, русларның «поганый татарин» дип мыскыллауларына җавап итеп үзенә бикләнгән, әнисенә язган хатларына эчендәге сагышларын, туган якны сагынуларын рәхәтләндереп түккән җебек геройлар янында Р.Шәфигуллинның унбиш яшьтән читкә чыгып киткән, кешедән ким булмас өчен көн-төн эшләгән, үзен кимсеттермәс өчен көрәш белән шөгыльләнә башлаган чая егетләре нык, бик нык аерылып торалар. Алар еламый, алар көрәшә, каршылык күрсәтә. «Барына да түзәргә була. Ә мин милли тойгыларга кагылуны күтәрә алмадым. Шул ук «Горняк» ресторанында метр ярымлы берәү: «Узкоглазый, дай закурить», — диде. «Пошел ты...» — дигәч, мина кизәнеп җибәрмәсенме. Әле аны гына түгел, тагын дусларын да акылга утырткан идем».

Бу өзек — «Йозак» китабына кертелгән «Зимагурлар иленда» повестеннан. Мин бу повестьны Оренбург, Башкортостан, Түбән Новгород һәм башка төбәкләрдә яшәгән татар балалары өчен әзерләнгән әдәбият хрестоматияләренә кертер идем. Безгә бүген иманлы, татарлыгы белән горурлана торган, шул горурлыгына кагылсалар ачудан көеп, бүре кебек эндәшми-тынмый рәнҗетүчегә, гафу иттерә белүләре җитми. Елаклар һәм ләң-ләң өрүче этләр белән дөнья тулган.

Рахман Шәфигуллин. Йозак. Татар. кит. нәшр. 2012 ел.

Татар әдәбияты яшьләре олыгайгач прозаик булып киткәннәрне белә. Мәсәлән, Тәлгат Галиуллин, Мөхәммәт Мәһдиев әнә шундыйлардан. Рахман Шәфигуллин әсәрләрендә дә акыл утырткан, төпле фикер йөртүче, тормышның ачысын да, төчесен дә күп татыган ир каләме сизелеп тора. Алай гына да түгел, күп хикәяләрендәге вакыйгаларның автор тормышында урын алганлыгын, геройларның прототибы үзе икәнлеген сизәргә мөмкин.

Язучының һәр күренешкә үз карашы, һәрнәрсәгә үз фикере — тормыш тәҗрибәсе белән ныгытылган фикере бар. Әдәби әсәр булуына карамастан, әйтик, «Яңгырлы август» повестенда, әдип публицистика чигендә торып иҗтимагый тормыш турында фикер йөртә: «Янгыр сибәләсә дә, Казан урамнары аллы-гөлле ситсыларга төренгән. Аның һәрберсендә Мәскәүнең олы кунагына мәдхия җырлана. «Татарстан отправит Родине 100 миллионов тонн нефти!», «Продадим государству 2 миллиона тонн зерна», тагын әллә никадәр ит, сөт, бал, йон, йомырка... Бу — 15 яшьлек авыл малаеның Казанга ипи алырга килгәч, шәһәрнең Н.Хрущевны каршы алырга чыгу күренешен күзәтүе. Гаҗәеп хәл: үзе иген игүче авыл кешесе, башкалага ипи алырга килә! Яшь булса да, хикәя герое Хәбиргә дә бу сәер тоела, ул урамга элгән лозунглар белән реаль тормыш арасындагы упкынны күрә. Милиционерларның төрле кешегә төрлечә мөнәсәбәте бу упкынны тагын да тирәнәйтә. «Сказал ведь тебе, сука, не появляться на моем участке», — дип хәерчене аяусыз типкәләгән сержант шунда ук мондый кансызлыгына аңлатма да биреп куя: «Иртәгә бит Казанга Хрущев үзе килә. Һәр җирдә тәртип булырга тиеш». Бәрәч, бу шулай ук тыштан ялтырау гына икән бит. Дәүләт хәерчелекне бетерү өчен көрәшми, ә ул күзгә ташланмасын өчен генә тырыша икән!

Иген игүче үз җиренә дә, үзе житештергән мөлкәткә дә хуҗа түгел. Хәбир авылга кайта, күңелсез хәбәр — әтисе камыл чабарга баргач, арбасында бер учма арыш кайткан. Партия контроле председателе Комиссаров шуны зур җинаять итеп, эш күрсәтмәкче була, сугыш инвалидына төрмә белән яный. Ходабәндә! Кеше ничек яшәргә тиеш соң? Татар әдәбияты мондый очракларга бай, чөнки халык шундый язмышка дучар ителгән. Менә М.Мәһдиев, «Бәхилләшү» китабыннан: «Әлбәттә, тагын бер халне хәтерлим, дөнья юньлесе, эшлекле, әдәпле, числыклы (бу сүз Казан артында чисталыкны яраткан кешегә карата кулланыла) Шәргыя җиңги бар иде. Кырык өченче ел җәенең эссе, тынсыз, ач бер көнендә, урактан кайтканда ат абзарлары янында председатель, районнан килгән вәкил, прокурор хатын һәм сәламәтлеге буенча армиягә алынмаган, ләкин дә колхоз амбары тирәсендә бик әйбәт көн итеп яткан Фәсхетдин, уракчыларны тентеп, Шәргыя җиңгинең ... фәлән-фәлән урыннарыннан арыш бөртеге табып алдылар. Амбарга алып кереп үлчәделәр, ике йөз грамм килде. Шәргыя җиңги, бичара, шул көнне юк булды. Малае фронтта иде. Малай кайтты — әнисе шул юктан юк булды» (478 б.).

Фронтовик язучы В.Быков «Фронтта һәлак булган иптәшләрем. Без син исән калып, монда күргәннәрне язсын өчен үлдек, дип әйтәләр кебек», ди. Өлкән буын әдипләр дә, үз иптәшләренең михнәт-газаплары юкка булмаган икәнлеген бүгенге ваемсыз буынга җиткерер өчен үткәннәргә мөрәҗәгать итәләр, ахрысы. Ләкин... бу Россия. Рүзәл Мөхәммәтшин «Менә ул яктан әлеге дә баягы урыс халкы бәхетләрәк. Алар беркайчан да рәхәт яшәмәгән...» дип язуы белән мең кат хаклы бугай *(Юану// Идел, 2013, №2)*. Р.Шәфигуллин өчен дә үткән белән бүгенгене чагыштыру күңел юатырлык тынычлык бирми. Менә автор яшьлек эзләре буйлап Воркутага килә: «Кызганычка каршы, монда элекке хозурлыкның эзе дә калмаган. Суворов урамындагы ике катлы матур йортларның штукатуркасы коелган, буяулары уңган. Ташландык йортлар бик күп. Халыкның кигән киемнәре дә әллә ни түгел».

Әдипнең «Йозак» повесте исә, гомумән, татар әдәбиятында аерым урын алып тора. Җинаятьчел дөньяны сурәтләү аша ул, кеше теләсә нинди шартларда да, әгәр аның үзәге нык икән, кеше булып кала алуын кабатлый. Монда шуны әйтергә кирәк: татар әдәбияты классигы Ш.Камалның «Уяну» дигән хикәясе бар. Ш.Камал тормыш төбенә төшкәннәрне сурәтли, хикәя герое Муса хатыны белән эшчеләр бистәсенең иң караңгы почмагында яши, аларның балалары юк, хәлләрен, гомерләрен көн-төн завод суыра. Чарасызлыктан, өметсезлектән Муса көн

саен эчә һәм эчеп акылы томаланган бер мәлдә хатынын кыйнап, аның үлеменә сәбәпче була. Айныгач, Муса моны шул хәтле авыр кичерә ки, хәтта акылыннан шаша. Моның белән язучы иң түбән тәгәрәгән кешенең дә күңел почмагында бер матур очкын, әхлак калуын күрсәтә. Экстремаль шартларда, сонарып булса да, әлеге иман нуры килеп чыга.

Р.Шәфигуллин герое Гайсә дә, олы яшьтәге кешегә ярдәм итү теләге белән остазын яклап, җинаятьчел дөньяга килеп эләгә. Ләкин ул югалмый — дөресрәге, әнисе өчен югалса да, кешелеген югалтмый: «Гайсә тоткынлыкта булса да, тәмәке тарту, хәмер эчү, кеше кимсетү кебек хәрәм сыйфатлардан сакланды. Күпләп китап уку, дингә тартылу аны үз кыйбласыннан аермады. Рухы белән, эчке дөньясы белән чиста-саф калды». Тормыш төбендә дә югалмаска, алай гына да түгел, китап уку, иманга килү аша үз-үзен камилләштерергә, минем уемча, Гайсәгә яшьлегендә алган тәрбиясе, табигый зирәклеге һәм сәләте ярдәм итә. Ә бит татарда күп андый булдыклылар. Шундый милләттәшең белән, нинди генә шартларда да егет булып калган татарлар белән горурланырга була.

Хәтерем ялгышмаса, Г.Ибраһимовның «Карак мулла»сыннан башка татар әдәбиятында җинаятьчел дөньяга мөрәҗәгать иткән бүтән әсәр юк, ахрысы. «Кабахәтлек болай да җитәрлек» диючеләр табылыр. Ләкин, беренчедән, «Йозак»та автор, Ш.Камал кебек, ямьсезлек фонында матурлыкның тагын да күркәмрәк булуын, аның яна һәм гади чагылышын күрсәтә, башка төсмерләрен ача. Икенчедән, җинаятьчел дөнья, телисеңме, теләмисеңме, ул безнең тормышның бер өлеше һәм аны күрмәскә тырышудан гына ул бар булудан туктамаячак. Һәр җирдәге кебек, монда да кыюлык югары бәяләнә һәм бу дөнья кешеләре сентиментальлектән ерак торулары, бары үз көчләренә генә таянулары белән аерылып торалар. Автор боларның барысын да күрсәтә алган. «Йозак»ны укыганда вакыйгаларга ияреп геройларына теләктәшлек белдереп, сурәтләнгән авантюраларның төптән уйланган булуына, шуларның уртасында кайнаган Гайсәнең акча, җиңел тормышка ияреп китүдән тыелуына сокланып утырасың. Мин аны «йодрыклы», ягъни үзен рәнҗеттерми торган, бүгенге дөньяда бик кирәкле, каршылык күрсәтергә сәләтле игелекнең гәүдәләнеше, дияр идем.

Ләкин гел уңай сыйфатлардан гына торган кеше була алмаган кебек, Р.Шәфигуллин китабына кертелгән хикәя-повестьлар да җитешсезлекләрдән бөтенләй үк азат түгел. Әйтик, «Яңгырлы август»та ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрне бераз шәрәләндереп бирү. Әле берничә урында. Дөрес, алар тормышчан бирелгән, уйлавымча, хакыйкатькә хилафлык юктыр, ләкин бит сүз остасы яшәешне ничек бар, шулай бирүче түгел. Ул иң әһәмиятле, укучыга житкерергә теләгән фикерләрен берничә тарих белән калкытып куярга, үзе мөһим санаган детальләр аша алгы планга чыгарырга тиеш.

Аннан соң, автор ашыга, вакыйгаларны сюжет сызыгына артык тыгызлап тезә. Чаллы педагогика институтында миңа «Җирле матбугат теле» дигән курс буенча лекцияләр укырга туры килде. Шунда «Йозак» повестена анализ ясаганда бер студент кыз «Бу бит роман булырлык» дип әйтеп куйды. Әйе, ул өлешчә хаклы, мондагы материал, чыннан да, романга җитәрлек. Әмма вакыйгаларның бер-бер артлы бик тыгыз бирелүе, язучыга образларның эчке дөньясын, психологик халәтләрен ачарга урын да, вакыт та калдырмый. Образлар дөньясын кичерешләр, фәлсәфи һәм лирик чигенешләр, чагыштырулар белән баетканда отышлырак булыр сыман. Мондый кимчелекләр, мөгаен, Рахман аганың озак еллар тележурналист булып эшләве белән аңлатыладыр.

Ничек кенә булмасын, әсәрләренең бер ягын инкарь итеп булмый — алар укыла. Фәнни калыпларга сыешып бетмәгән яклары да бардыр. Ләкин укучы мәхәббәте калыпларны танымый ул, укучы алай үлчәү-мазарларга салып тормый — ул йә укый, йә укымый. Менә бу ноктадан карaганда, Чаллы төбәге әдәби күгендә тагын бер каләм әһеле — һәм җитди каләм әһеле барлыкка килүенә сөенәсе генә кала.

**Гомәр ДАУТОВ**

# БӘХЕТСЕЗ ПОЧМАКНЫҢ ИЯСЕ

Гап-гадәти авылда туып-үскән гап-гадәти кеше ни сәбәпле каләм кыштырдата башлый, әдәбият мәйданына омтыла? Әлеге сергә беркем дә төшенә алмас, мөгаен. Мәдәният учакларыннан еракта, әмма ул чын халык тормышында кайный, халык җырлары туугa ук колагында янгырый, ана сөте белән күнеләнә тел аһәңе сенә.

Әдәби әсәр язган берәр яңа кеше турында ишетсә, Мөхәммәт Мәһди: «Дөньяда тагын бер бәхетсез адәм арткан,» — дия иде. Чыннан да, югалту сагышы татар шагыйренең йөрәген шигырь уты булып беренче адымыннан ук кысып ала. Һәм соңгы сулышкача җибәрми. Нәкъ Тукай әйткәнчә: «Бәхетсез милләтнең бәхетсез угылы, бәхетсез почмакның әсир былбылы...»

Нигә гадәтләнгән, табигый юлдан китми аерым кемсәләр? Көйләнгән тормыш үзе чакырып тора югыйсә. Әти-әнисе шуңа өнди, туган-тумача, таныш-белеш. Кузгал, кеше йөргән эздән бар, кеше төсле бул!

Әллә соң нәселдән килгән кан шулай вакыт-вакыт саташкалап аламы? Шигырь язуымны ишеткәч, Ерак әби (Шыгырданда яшәгәнгә шулай атый идем) миңа бик кызганып караган иде:

— Зариф агайдан инде бу, шунардан...

Зариф Бәшири 1962 елда — нәкъ мин туган ел! — Уфада вафат булган. Аның турында мин сабый чактан ук ишетеп үстем. Бәширинең бертуган сеңлесе Хәлимә әби дә Шыгырданда яши иде. Әбием Мәрьям (аның атасы Габдрахман Бәшири Чүти мулласы була) Зариф агасын еш искә ала иде, атаклы Шәкүр әбзәсен дә аклап сүз кыстырырга онытмый иде. Әбинең сеңлесе Әсма апа Тукай авылы мәтәбендә озак еллар мәктәп директоры булып эшләде. Зариф Бәшири төрмә-сөргеннәрдән котылып, бераз хәл алгач, туган ягына кайтып, мондагы төрле авылларга таралган туган-тумачасы белән күрешеп, хушлашып киткән. Ул бүләк итеп калдырган ак шәлне Хәлимә әби үлгәнче кер кундырмыйча саклады.

Зариф Бәшири туган Чүти авылын белмәгән татар булмагандыр элегрәк . Атаклы ат карагы Шәкүр Рәхимов авылы бит ул! Бәшири язганча, «авылда мәчет салу, мәктәп ачу, мулла-мәзин кую, староста сайлау, җир бүлү, йорт урыннарын билгеләү кебек җәмәгать эшләренең һәммәсе дә» Шәкүр карак ихтыярында була.

«Минем әтинең атасы Тажи бабай белән Шәкүр каракның анасы бертуган булганлыктан, искә алынган мәсьәләләргә алар бергәләп план төзиләр, — дип дәвам итә язучы. — Әнә шул план буенча, озакламый, минем агам Габдрахман әти янына мулла булырга һәм, әти үлгәч, бөтенләй хуҗа булып калырга тиеш. Шәкүрнең миннән бер яшькә кече кызы бар. Ул үсеп, мин пишкадәмчелек дәрәҗәсенә ирешкәч, авылга өченче мәчет салынып, мин шуңа мулла һәм Шәкүргә кияү булачакмын икән.»

Йә, ни кирәк тагын ул заманда татар кешесенә?! Төшемле урын әзер. Нәкъ хәзерге нуворишлар яңа туган балаларына җылы урын әзерләп куйган кебек. Ә юк, ләүхелмәхфүзенә бүтәнчә язылган, Зарифны да мәчет миһрабы түгел, тузанлы редакция коридорлары үзенә суырып ала. Тәкъдирнең үз вәзене бар. Күп тә үтми, яңа татар матбугатында Зариф әл-Бәшири исеме күренә башлый. Татар әдәбияты мәйданында Бәшири үзенә урын даулый.

Бүгенге татар укучысы беләме соң Зариф Бәширине?

Бу кеше, шактый гына озын гомер яшәсә дә, әдәбиятта, халык хәтерендә үзенә лаек урынны алмыйча дөньядан үткән. Озак еллар типкедә, чит якларда җан асраган бу фаҗигале язмыш иясенең ( бәхетсез почмакка куып кертелгән татар әдибенең) иҗаты да, тормыш юлы да тиешенчә өйрәнелмәгән, бәһаләнмәгән әле.

Булачак әдип 1888 елда Чүти авылында (хәзерге Кайбыч районы) Шәрәфетдин мулла гаиләсендә дөньяга килә. Башта әтисендә, аннары Буа, Акъегет мәдрәсәләрендә, аннары Казанның атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укый. Яшьтән үк шигырь җене йоккан шәкерт мондагы әдәби даирәгә тиз кереп китә, шигырьләре бер-бер артлы көндәлек матбугатта басыла башлый. Әлбәттә, аларның күбесе өйрәнчек, зәгыйфь нәрсәләр була, шуңа яшь шагыйрьне шул чорның кискен тәнкыйте күз уныннан ычкындырмый.

Бу тәнкыйть Зариф Бәшири Оренбургка күчеп, «Чүкеч» журналында эшли башлагач та туктамый. Аңа Тукайның зәһәр сатира уклары да тия («Бәшири мыраулый», «кыска аяклы маймыл» һ.б.) Әлбәттә, гарьчел Бәшири дә Тукайга дорфа һөҗүләр юллый. Ул заман матбугатын күзәтсәң, хәйран калмый мөмкин түгел. Тәнкыйть еш кына анда шәхескә тукынуга кайтып кала. Шул ук вакытта матбугатта әле генә бер-берсен дөмбәсләгән кешеләр тормышта еш кына шәхсән дустанә мөнәсәбәттә дә калалар. Тукай да, мәсәлән, Сәгыйть Сүнчәләйгә язган хатында үзе төзегән дәреслеккә Бәширинең бер шигырен кертүен хәбәр итә, аңа унай бәя бирә.

Әмма матбугаттагы мондый пырдымсызлык, минемчә, бөтенләй эзсез югалмый. Егерменче-утызынчы елларда бу шаукым — әдәбият әһелләренең бер-берсенә ташлануы — зур фаҗигагә әверелде.

Оренбургтан киткәч, З.Бәшири Пенза, Тамбов якларында, Җидесу өлкәсенең Капал шәһәрендә мөгаллимлек итә.

Яшьтән үк әдип чуашларның тарихы, көнкүреше белән кызыксына. Бу гаҗәп тә түгел, Чүти бит чуаш авыллары белән янәшә генә утыра. Оренбургта вакытта ул «Шура» журналында «Чуашлар» дигән әтрафлы зур мәкаләсен бастыра. Бераздан шушы мәүзугъ[1] аның әдәби иҗатына да килеп керә. »Чуаш кызы Әнисә» бәянын киң даирә укучылар яратып кабул итә. Чыннан да бу әсәр матур тел белән язылган, аңардан бертөрле лирик җылылык бөркелә.

Гомумән, чәчмә әсәрләрдә аның иҗади мөмкинлекләре киңрәк ачыла. Балалар өчен язылган «Ефәк корты», «Шаян Фәһим» әсәрләре дә шуңа дәлилдер дип уйлыйм. Шигырьләренә исә нәфислек җитми, күп очракта алар коры кычкыруга, тамак ертуга кайтып кала. Юкка гына Ш.Бабич үзенең мәшһүр «Китабеннас» әсәрендә З.Бәширигә мондый эпиграмма багышламый:

*Әй, Зариф, чык ялтырап, тик бар да китсен аптырап,*
*Дошманыңны калтырат, борчакларыңны шалтырат.*

Аның Октябрь фетнәсенә кадәрге шигырьләренең күбесе — милләт язмышын кайгырткан декларатив язмалар. Беренче җыентыгы да «Милләт кайгысы» дип атала. Хәзерге «милли» шагырьләр язучыларга аңардан шактый өйрәнергә мөмкин.

Әлбәттә, З.Бәшири милләт алгарышын җаны-тәне белән теләгән зат. Баласына нинди исем бирүгә карап кешенең кем икәнен әйтеп була. Улларына шагыйрь Ясүкәй, Чагатай, Җүчи дигән исемнәр куша.

Ул күп язган. Арада, билгеле, бүген дә рәхәтләнеп укырлык шигырьләр бар. Үз заманында исә Тукай, Дәрдемәнд, Рәмиләрне санаганнан соң Гафурилар, Укмасыйлар, Думавилар, Бәшириләр, Сүнчәләйләр исемлеге башланган. Бүген дә бу исемлекнең тәртибе үзгәрмәде. Бу үзе үк «бүген мине аңламыйлар, киләчәктә аңларлар» дигән өметнең буш икәнлеген раслый булса кирәк.

Сәяси юнәлешләрдән һәрвакыт читтә торган З.Бәшири дә патша төшерү мәрәкәсен сөенеп каршы ала, юксыллар хакын даулап үзенә хас шигырьләр дә яза, әмма, күрәсең, бу буталышның асылын тиз аңлап ала: татарның кызыл авызлары белән тулган Казан, Уфалардан читтәрәк яшәргә ниятли, Төркестанда уйгыр, татар газеталарында эшли, Урта Азия дәүләт университетында үзбәк, уйгыр телләрен һәм әдәбиятын укыта.Шушы елларда ул «Үзбәк әдәбияты», «Уйгыр әдәбияты» исемле хезмәтләрен дөньяга чыгара. Әсәрләрен үзбәк телендә дә яза (мәсәлән, »Ефәк күлмәк»), шулай ук ул беренче уйгыр газетасы «Садаи Таранчы»ның беренче мөхәррире буларак та билгеле.

[1] Мәүзугъ — тема.

Билгеле, «заман карабыннан» иске әдәбиятны себереп түгәргә җыенган яшь пролетар шагыйрьләр өчен ул комган кебек үк чит була. З.Бәшири моны аңласа да, ярашып карый, әдәби мохитта казганырга омтыла, «кызыл» шигырьләр дә язып азаплана. Ләкин алар зәгыйфь һәм шактый ук көлке чыга. Утызынчы елларда ул Донбаска килә, берара андагы «Пролетар» газетасында эшләп ала. Күрәсең, заман белән тигез атлап, эшчеләр тормышын өйрәнеп, советча әсәр язарга да теләгәндер. Тик, шул чакта Донбаста сөргенлектә булган Шәйхи Маннур үзенең истәлекләрендә язганча, яшьләр ана сәерсенеп һәм көлеп карыйлар. Карт шагыйрьнең (юкса ана әле илле дә тулмаган була!) «эшче темасына» язган «Поезд китте хутлап-хутлап, стансада торды туктап-туктап» дигән юллары телләргә күчеп, З.Бәширине «шәһрәткә» кумә.

Ничек кенә «кызыл» һәм уяу булырга тырышмасын (икенче хатыныннан туган улларына Фрит, Сизгер дигән исемнәр куша) иске милли әдәбият вәкиле, мулла малае булган әдип большевистик репрессиядән котыла алмый. Төрмә-лагерьларда ана «яна тормышның» бөтен ләззәтен кичерергә туры килә.

Иреккә чыккач, ул кабат Уфага кайтып төпләнә. Монда аны, әлбәттә, беркем дә кочак җәеп каршы алмый. «Тукай дошманы», — дигән кара тамга аны үлгәнче эзәрлекли. (Камил Мотыйгый язмышын искә төшерик, ул Тукайның яна «дусларыннан» котылыр өчен үз-үзенә кул салырга мәҗбүр була). Югыйсә ул заманда татар дөньясында Тукайның сатирасына кем генә эләкмәде икән? Эчтән авыр кичерсә дә, мондый гайбәтләрдән З.Бәшири өстен кала белгән. Холык шундый. Ул үзенең замандашлары турында истәлекләр язарга утыра. Гасыр башында татар әдәби мохитының эчендә кайнаган, гаҗәеп кызыклы тормыш юлы үткән кешенең бу истәлекләре безнең әдәбият өчен гаять әһәмиятле. З.Бәшири истәлек, хатирә язу өчен зарур булган искиткеч хәтергә ия була. Аның бу вакыттагы тормышын күзаллау өчен Миркасыйм Госмановның «Ябылган китап» (Казан, 1996) дигән әсәреннән бер өзек китерү урынлы: «Әниебез Гөлҗиһан (1905 елда туган) ике-өч ел Капалда мөгаллимлек итүче Зариф Бәширидән укый...<...> Әниебезнең сүзләренә караганда, Зариф Бәшири ихлас күңелле тәрбияче, тырыш мөгаллим, зур шагыйрь, әмма шәхси тормышында бик бәхетсез кеше булган. Шулар хәтергә нык сеңеп калганмы, мин бер елны Зариф Бәширине махсус эзләп киттем. 1960 елның гыйнвар ахырларында, кышкы каникул вакытында булды бу хәл.

Салават шәһәренә барышлый, Уфада 5-6 сәгатькә махсус тукталдым да, белешмәләр бюросыннан аның адресын алып, бер сәгать чамасы теркелдәгән трамвайда Черняховскийга юнәлдем. Ишекне ачкач, маржа әбие, кемгә килүемне белгәч, эчтәге ишекләрнең берсенә төртеп күрсәтте. Аннан бер күзе йомык чандыр бабай кисәге килеп чыкты. Аягында киез итек, өстендә гадәти сырмак. Үзен эзләп килүемне белгәч, рәхим итүемне үтенде.

Бүлмәдә бер иске тимер карават, ялангач өстәл, ике-өч урындык кына — кычкырып торган ярлылык... Борчып йөрүемнең сәбәбе әниебез икәнлеген әйттем. Карт сагайган төсле ялгыз күзен миңа таба борды.

— Сез Капалда торган чакта әниебез сездән укыган икән...
— Әниегез кем кызы була? — дип бүлдерде Зариф ага.
— Локман Мөлекев кызы...
— Фәрвазмы, Гөлҗиһанмы?!

Шаклар каттым: кем әйтмешли, 40 елдан артык вакыт узуга, аның да егерме елы төрмәләрдә, сөргеннәрдә узуга карамастан, кайчандыр үзеннән ике-өч кыш дәрес тыңлаган чәчби кызларның исемнәрен шулай керфек какканчы искә төшерер өчен нинди хәтергә ия булмак кирәк?!»

Менә шундый кеше хатирәләр язарга утыра. «Замандашлар белән очрашулар» дип исемләнгән бу әсәр 700 биттән артып китә. Тик З. Бәширигә бу хезмәтнең дөньяга чыгуын күрергә насыйп булмый. Ул 1968 елда гына, өчтән ике өлеше кыскартылып, Татарстан китап нәшриятында дөньяга чыга. Ләкин шул да бик авырлык белән басмаханәгә барып житә. Уфаның кайбер язучылары (хосусән Сәйфи Кудаш) бу истәлекләрнең басылуына ни өчендер каттый каршы булалар, Казанга бер-бер артлы хатлар юллыйлар. Истәлекләрнең редакторы итеп билгеләнгән Гали Халит яза: «Китап инде тәмам тиражга әзерләнгән көннәрдә ана каршы Казаннан читтә яшәгән әдипләрнең берсеннән зур гына

хат-рецензия килеп төшә. Бу хат-рецензия авторы З.Бәшири истәлекләрен бөтенләй әһәмиятсез сафсата дип юкка чыгарып, аларны бастыру зур хата булачагын исбат итәргә тырыша. Аның белән генә дә калмый. Казан әдипләренең олы буыннарыннан кайберләрен шушы гаугага кушылырга, булышырга чакыра. Аның шаукымы күпмедер дәрәҗәдә Хәсән ага Туфанга да кагыла. Ә менә ул шул вакытта минем белән сөйләшеп анлашуны кирәк дип саный. Һәм без аның белән очраштык.

— Халит туган, — диде миңа Хәсән ага, — З.Бәшири истәлекләрен чыгару бер дә кирәкмәгән четерек нәрсәгә әверелеп, сезгә уңайсызлык тудырмасмы? Мин шунардан шикләнәм... Аннары бу әдип үз вакытында бөек Тукаебыз белән дә ызгыш-талашларда булгалаган бит. Тукайның шактый зәһәр ләгънәт-каргышларын да татыган... Шулай булгач, аның истәлекләрен халыкка тәкъдим итү ни дәрәҗәдә урынлы булыр икән?

— Хөрмәтле Хәсән ага, — дидем мин, — Бәширинең татар әдәбияты тарихында кечкенә булса да үз урыны бар. Ул революциягә кадәрге әдәбиятыбызның Тукай житәкләгән демократик канатына бик якын торды. Аның истәлекләрендә дөреслек аз түгел. Ул үз чорының байтак әһәмиятле фактларын җанлы итеп күрсәтә алган. Әмма без, Тукай белән мөнәсәбәте яхшы булмаган дип, кайбер язучыларыбызны әдәбият тарихыбыздан төшереп калдырырга ашыкмыйк әле. Ә менә кайбер хөрмәтле иптәшләрнең Бәширигә карата үз шәхси үпкәләрен, үчләрен, антипатияләрен алгарак куеп, сезне бу кирәксез гаугага тартып кертүләрен искә алып бетермәгәнсез, ахры...

Минем сүзләргә каршы Хәсән ага бертөрле дә кире мөнәсәбәтен сиздермәде.»

Махсус редактор Гали Халит, нәшрият редакторы Рәис Даутов төрле каршылыкларны җиңеп чыгалар, укучылар кулына әлеге истәлекләр, бик нык кыскартылып булса да, барып ирешә. Чыккан кадәре дә гаҗәпләнү уята: биредә Риза казый, Дәрдемәнд, Бабич хакында хатирәләр бар, автор аларның эшчәнлеген уңай бәяли, аларга сокланып яза. Бу ул заман өчен гайре табигый хәл. Әлеге шәхесләрне әле сиксәненче еллар уртасына кадәр төрлечә каһәрлиләр иде.

Зариф Бәшири гасыр башындагы мәдәни тормышны безнең күз алдында яңадан терелтә. Бу истәлекләрне бүген тулысынча дөньяга чыгару бик игелекле эш булыр иде. Әмма асыл кулъязма исән микән? Заманында нәшрият чүплегендә Лирон Хәмидуллин «З.Бәшири» дип язылган папкага тап булган иде. Әмма ул истәлекләрнең нәшрият өчен әзерләнгән, инде кыскартылган варианты булып чыкты. Анда китапка кермәгән бер-ике генә бүлек бар иде. Рәис ага Даутов ул бүлекләрне бик тиз искә төшерде (аңарда Бәшири хәтере иде, валлаһи!):

— Аларны главлит(коммунистик цензура) кыскартырга мәҗбүр иткән иде, — диде ул.

Бу төшеп калган бүлекләр, шул көннәрнең сулышын безгә житкерү белән бергә, актуаль дә яңгырый. Бер бүлек Фәтхелислам Агиевның маржа кызына гашыйк булып йөреп тә ни өчен өйләнми калуы турында язылган. Тагын бер бүлектә исә М.Гафуриның химаячы алпавыт утарыннан, хезмәтчеләрнең авыр тормышларын күргәч, кымыз, казылыкларны ташлап кайтып китүе хәзер күпләрдә елмаю гына уятадыр. Кемдер эчтән генә шагыйрьне «хаерче тәкәббер» дип сүгеп алырга да мөмкин. Без бит үзебез яңа байларга барып йөз суын түгәбез, химая өмет итеп аларны мактап газета-журналларда язабыз. Юксыл халык гаме бөтенләй хәтердән чыга.

Әлбәттә, «залимнәрне, өстеннәрне яклый алмаган» шагыйрьләрнең язмышы авыр була. Гомере буе халыкка хезмәт итеп тә, ялгызлыкта, бөлгенлектә үлгән Зариф Бәшири — шуның бер мисалы. Инде без, соңарып булса да, аңа лаеклы бәяне бирик. Аның иҗатын җентекләбрәк өйрәнергә вакыттыр, мөгаен. Ул чакта татар әдәбиятының тарихы да яңа яклары белән ачылып китәр иде. Бу юнәлештә кайбер эшләр башкарыла да инде. Зариф Бәширинең татар әдәбиятында гына түгел, бөтен төрки дөньяда үзенә лаек урыны бар.

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

# ОЛУГ ГАЛИМНЕ ИСКӘ АЛЫП...

Татар әдәбият белеменең чишмә башы Г.Тукай, Ф.Әмирхан, Г.Исхакый, Г.Гобәйдуллин, Ж.Вәлиди, Г.Сәгъди исемнәре белән бәйле. Совет чорында бу өлкәдә Г.Нигъмәти, Х.Вәли, Г.Толымбай, М.Гайнуллин, Г.Халит, Х.Госман, Н.Юзиев, И.Нуруллин һ.б. нәтиҗәле эшләде. Алда атап үтелгән шәхесләрнең эшчәнлеге матбугат битләрендә шактый гына чагылыш тапкан булса, шул чор галиме Абдулла Сайганов исеме читтәрәк калып килә, гәрчә аның хезмәтләре игътибарга һичшиксез лаек.

Абдулла Җамалетдин улы Сайганов 1913 елның 18 маенда Әстерхан шәһәрендә йөк ташучы гаиләсендә туа. 1931 елда тугызьеллык мәктәпне, 1933 елда мәктәпләр өчен укытучылар әзерләү курсларын тәмамлый. 1933-36 елларда Әстерхан өлкәсе Нариман районы мәктәпләрендә укыта. 1936-40 елларда Әстерхан педагогия институтында рус теле һәм әдәбияты факультетында белем ала, тәмамлаганнан соң рус теле кафедрасында ассистент итеп калдырыла. 1941-42 елларда Бөек Ватан сугышында катнаша, яралана, контузия ала. Дәваланганнан соң, үзе укыган институтка эшкә керә. 1942 елның сентябрендә институт белән бергә Тубыл шәһәренә эвакуацияләнә. 1943 елда Сайганов Казанга килә, Татарстан халык мәгариф комиссариатына инспектор итеп билгеләнә. 1943-46 елларда Казан дәүләт педагогия институтында аспирантурада укый. Фәнни эзләнүләре нәтиҗәсе буларак 1950 елда «Шәриф Камал хикәяләре» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый. 1952 елдан башлап гомеренең соңгы көненә кадәр А.Сайганов эшчәнлеге педагогия институты белән бәйле була. Башта татар әдәбияты кафедрасы доценты, 1953-74 еллар арасында шул кафедрага җитәкчелек итә. 1948-51 елларда татар теле һәм әдәбияты факультеты деканы, ә 1951-54 елларда тарих-филология факультеты деканы булып эшли. 1946 елдан башлап студентларга татар совет әдәбияты һәм әдәбият теориясе буенча лекцияләр укый. 1972 елда Баку шәһәрендә «Фатих Әмирхан һәм XIX гасыр азагы — XX гасыр башы татар реализм әдәбиятында эстетик карашлар» дигән темага докторлык диссертациясен яклый.

А.Сайганов фәнни мирасының төп өлешен түбәндәгеләр алып тора: «Шәриф Камал» исемле методик кулланма (1966), «Татар реализм әдәбиятында типиклык проблемасы» (рус телендә, 1972) дигән фәнни кулланма, «Фатих Әмирхан. Язучының иҗаты буенча библиографик күрсәткеч» (1972), «Реализм эстетикасының барлыкка килүе (Фатих Әмирхан эстетикасы һәм аның татар реализм әдәбияты үсешендәге урыны)» (рус телендә, 1982) исемле монографиясе. Болардан тыш галимнең татар мәгърифәтчеләренә, Г.Тукай, Г.Кутуй, Һ.Такташ, М.Шолохов һ.б. иҗатларына багышланган фәнни-теоретик мәкаләләре Казан педагогия институтының фәнни җыентыкларында басылып чыга. Шигърият теле һәм шигырь төзелешенә багышланган хезмәтләре дә игътибарга лаек. Ул шулай ук татар совет әдәбияты буенча урта мәктәпләр өчен дәреслекләр һәм хрестоматияләр төзүдә катнаша.

А.Сайгановның татар әдәбият белеменә алып килгән яңалыгы реализм эстетикасын, татар реалистик әдәбиятында типиклык проблемасын, татар һәм рус әдәбиятлары арасында бәйләнешләрне өйрәнү белән бәйле. Шулар арасында

иң әһәмиятлесе Фатих Әмирхан әдәби мирасын өйрәнүгә карый. Ул Ф.Әмирхан иҗатын XIX йөз ахыры — XX йөз башы татар милли әдәбиятында барган сыйфат үзгәрешләре белән тыгыз бәйләнештә өйрәнә. Әлеге тикшеренү революцион-демократик хәрәкәткә нисбәтле татар сүз сәнгатендә реализм эстетикасының формалашуын, үсеш-үзгәреш закончалыкларын һәм эволюциясен күз алдына бастыра. Ф.Әмирханның әдәби әсәрләре белән бергә публицистикасын, әдәби-тәнкыйть мәкаләләрен дә җентекләп өйрәнү А.Сайгановка классик язучының иҗат концепциясен бербөтен итеп бәяләү мөмкинлеге бирә. Галим фикеренчә, реализмның асылын Ф.Әмирхан сәнгатьнең объективлыгында, вакыйга-күренешләр үзәгендәге шәхеснең төрле яктан ачылуында күрә. Ә инде тәнкыйди һәм эстетик карашларын сәнгать үзенчәлекләре аша аңлату, әдипнең иҗади индивидуальлеген тулырак һәм киңрәк ачарга ярдәм итә. Язучы иҗатында типиклык проблемасын өйрәнгәндә, А.Сайганов татар фәнендә беренчеләрдән булып шуңа игътибар итә: язучы әсәрләрендә тип бер үк вакытта конкрет, тормышчан һәм реаль шәхес булып кала, ә инде образ-типның субъективлыгы күрсәткече язучының дөньяга карашына, әдәби идеалларына бәйле булу билгеләнә. Язучының сәнгать үзенчәлеген никадәр тулы күзаллавы, билгеле бер дәрәҗәдә татар эстетик фикере үсеше күрсәткече, дип яза галим. Ф.Әмирханның тормышны сәнгати чагылдыруында үз чорына хас булган өч типны аерып чыгаруын да искәртә: кадимчеләр, татар буржуазиясе һәм яшь буын вәкилләре. Классик әдип иҗатындагы психоанализ, милли үзенчәлекләр чагылышы һәм аларның халыкчанлык идеяләре белән үрелеп баруы да А.Сайганов игътибарыннан читтә калмый.

Абдулла Сайганов 1974 елның 19 апрелендә Казанда вафат була.

Олуг галим арабыздан киткәнгә инде кырык елга якын гомер узган. Бу вакыт эчендә гаять зур үзгәрешләр булып, алар әдәбият белемнә дә зур йогынты ясады. Билгеле, без бүген Ф.Әмирханны революционер-демократ дип бәяләмибез, әдип гаять кискен тәнкыйтьләгән кадимчелеккә дә бер яклы гына якын килмибез, «пантөркизм», «милләтчелек» кебек күренешләр турында да А.Сайгановтан үзгә фикер йөртәбез. Әйе, тормышның кара һәм ак төсләрдән генә тормаганлыгы яхшы аңлашыла. Үткән чорларда яшәп иҗат иткән галимнәребезнең фәнни эзләнүләрендә өстән тагылган догмалар һәм теорияләр булу турында иркен фикер йөртү мөмкинлеге туды. Шуңа да узган гасырның 1990 елларына кадәр язылган фәнни-теоретик хезмәтләргә гаять сак һәм игътибарлы якын килү сорала. Аларның үз вакытында фәнни һәм әдәби фикер үсешенә уңай йогынты ясауларын, яңа тикшеренүләргә юл салуларын һәрдаим истә тотарга тиешбез. Утыз елдан артык гомерен фәнни-гамәли эшчәнлеккә багышлаган, меңләгән педагогик кадрлар тәрбияләгән, бөтен көчен, белемен әлеге эшчәнлеккә багышлаган олы галим Абдулла Сайгановның хезмәтләре бүген дә актуаль һәм кыйммәтле мирас булып тора.

**Рәйсә МУСАБӘКОВА**

## Нәҗип Думавиның тууына 130 ел

Нәҗип Думави (Нәҗип Сибгатулла улы Тахтамышев) 1883 елның 19 маенда хәзерге Татарстан Республикасының Аксубай районы Яңа Дума авылында туа. 1894 елда әтисе аны Казанның Печән базарында яңа ачылган Габдулла Апанаев мәдрәсәсенә илтеп тапшыра.

1902 елда мәдрәсәне тәмамлагач, унтугыз яшьлек Думави Казандагы Укытучылар мәктәбенә кереп уку турында хыяллана. Ләкин матди хәле авыр булу сәбәпле, бу уен тормышка ашыра алмыйча, хезмәткә ялланырга мәҗбүр була. Ул бераз вакыт Әстерхан һәм Гурьев балык промыселларында эшли, аннары ике елга якын казакъ далаларында балалар укыта. Нәкъ шул елларда (1902-1904) ул әдәби иҗат эше белән кызыксына башлый. Казакъ халкының бай җыр-гыйләннәре белән танышу, акыннарның әйтешләрен тыңлау анарда иҗат дәртен кузгатып җибәрә. Аның беренче шигырьләрендә мәгърифәтче шагыйрь Акмулла шигърияте аһәңнәре дә чагыла.

Беренче бөтендөнья сугышы вакытында Нәҗип Думави солдат хезмәтенә алынып (1916), Австрия юнәлешендәге фронтка җибәрелә. 1917 елгы Февраль һәм Октябрь вакыйгаларын ул инде Чистай шәһәрендә каршылый. 1917-1921 елларда шул ук Чистай шәһәре мәктәпләрендә, мөгаллимнәр әзерләү курсларында укыта, өяз мәгариф бүлегендә инспектор булып эшли.

1921 елда ул туган авылына кайта һәм 1925 елга кадәр шунда указлы мулла булып тора. Бер үк вакытта 1923 елда Диния нәзарәте аңа Чистай төбәгендәге житмешләп авыл мәхәлләсе имамнарының мөхтәсибе вазифаларын да тапшыра.

Нәҗип Думави — шактый бай һәм төрле жанрларга караган әдәби мирас калдырган язучы. Ул — шагыйрь дә, прозаик, публицист, әдәбиятчы-тәнкыйтьче, тәрҗемәче, уку-укыту эшенә, педагогикага кагылышлы хезмәтләр, дәреслекләр авторы да. Шагыйрь буларак ул 1905 елгы инкыйлаби вакыйгалар тәэсирендә мәйданга чыга һәм башта мәгърифәтчелек, соңга таба романтика катыш тәнкыйди реализм рухында язылган социаль эчтәлекле шигырьләре белән үз чорының популяр шагыйрьләреннән берсе булып таныла.

Н.Думави 1905-1921 еллар арасында матбугатта проза әсәрләре — хикәяләр, повестьлар, публицистик һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән дә актив катнашкан язучы. Аның «Болгар кызы Тойгы туташ» (1911), «Юкка үлде» (1912), «Мулла булам, мулла!»(1912), «Алла тигезли» (1912), «Кем гаепле?» (1912), «Янадан тугъдырыныз!» (1914), «Карт мөгаллимнәр» (1914), «Сугыш каһарманы, яки Агач аяк» (1916), «Головка» (1917) кебек хикәя-повестьлары үз вакытында аерым китаплар яки җыентыклар булып басылып чыгалар. Әдипнең махсус балаларга атап язган аерым шигырьләре («Авыл балаларының янгыр теләве», «Янгыр соңында», «Беренче кар» һ.б.) һәм «Зәки» (1910), «Габдулла» (1911), «Мортый белән Мукай» (1911), «Бер баланың көнлек дәфтәре» (1912) исемле хикәяләре инкыйлабкача һәм егерменче елларда мәктәп дәреслекләренә һәм хрестоматияләренә урнаштырыла.

Сәяси бәйләнүләр көчәеп киткәч, 1925 елда әдип авыл мулласы һәм мөхтәсиблектән рәсми рәвештә баш тарта. Тиздән ул туган авылын бөтенләй ташлап китә, әүвәл Дагыстанда берникадәр вакыт педагогия техникумында укытучы булып эшли, аннары бөтен гаиләсен алып Урта Азиягә юл тота. 1927-1933 елларда ул Сәмәрканд төбәгендәге төрле уку һәм мәдәни-агарту йортларында эшли, Сәмәрканд педагогия институтында лекцияләр укый, тәрҗемә эшләре белән дә шөгыльләнә. Яшьтән үк үпкә авыруыннан һәм ревматизмнан җәфа чиккән Нәҗип Думави 1933 елның 5 маенда Сәмәрканд янәшәсендәге Булунгур шифаханәсендә илле яше тулар-тулмас вафат була.

## Гариф Галиевнең тууына 110 ел

Язучы-прозаик, драматург Гариф Закир улы Галиев 1903 елның 10 маенда хәзерге Татарстанның Азнакай районы Урманай авылында дөньяга килә. 1910 елның җәендә жиде яшьлек Гарифны Бәйрәкә авылы мәдрәсәсенә укырга бирәләр.

1917 елгы инкыйлаб вакыйгалары Бәйрәкә мәдрәсәсе шәкертләрен дә канатландырып җибәрә. Алар, мәдрәсә каршында драма түгәрәге оештырып, тирә-як авылларда спектакльләр куеп йөри башлыйлар.

1925 елның көзендә егетне гаскәри хезмәткә алалар. Аннан кайткач, ул Азнакай урта мәктәбендә укыта. 1927 елны аның «Кызыл Армия хикәяләре» исемле мөстәкыйль җыентыгы чыга. Бу елларда Г.Галиевнең әдәби иҗат эшчәнлеге аеруча активлаша. 1931-1941 еллар дәвамында аның янә тугыз китабы дөнья күрә. Алар арасында «Фамилиясез кеше» (1932), «Бибкәй аланы» (1939) кебек заманында популярлык казанган повестьлар, хикәя китаплары һәм очерк җыентыклары бар.

Сугыштан соңгы елларда ул балалар өчен җитди вә шаян хикәяләр, табигать, җәнлекләр дөньясы турында әкиятләр яза. Аның бу төр хикәяләре һәм әкиятләре «Җәй көне» (1958), «Курайлы елга» (1961), «Чәчәкле малайлары» (1965), «Кунелле хикәяләр» (1968), «Без авылныкылар» (1982) кебек җыентыкларында урын алган. Әдип бер пәрдәле пьесалар авторы буларак та билгеле. Аларның күбесе үз вакытында кат-кат сәхнәдә уйнала. Арадан берсе - «Хаттан башланды» исемлесе, аеруча уңыш казанып, өч мәртәбә рус телендә (1950, 1953, 1954) һәм немец телендә (1956, Дрезден) басылып чыга.

Гариф Галиев 1985 елның 22 мартында Казанда вафат була.

---

## Мөхәммәт Садриның тууына 100 ел

Шагыйрь Мөхәммәт Садри (Мөхәммәт Хәбибулла улы Садретдинов) 1913 елның 31 маенда Казанның Яңа бистәсендә туа.

Аның беренче җитди шигырьләре утызынчы елларда «Атака» (хәзерге «Казан утлары») журналы битләрендә басыла.

1932 елда аны А.Луначарский исемендәге Мәскәү театр институтының театр белгечләре һәм драматургия бүлегенә укырга җибәрәләр. 1935 елда институтны тәмамлагач, М.Садри бер ел Татарстан Язучылар берлегендә әдәби консультант булып эшли башлый. Бу елларда әдипнең иҗат эшчәнлеге дә активлаша, бер-бер артлы «Җыр дәвам итә» (1936), «Совет ватаны өчен» (1939), «Коммунарлар турында җыр» (1940), «Волга турында җыр» (1941) исемле лирик, патриотик-публицистик шигырьләре, җырлары тупланган шигъри җыентыклары дөнья күрә.

1941 елның июлендә шагыйрь сугышка китә. Беренче Украина фронтында татар телендә чыга торган «Ватан намусы өчен» газетасында оештыручы-хәбәрче була.

1946 елда гаскәри хезмәттән кайткач, ул Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең җаваплы секретаре булып эшли. 1956 елдан ул профессионал язучы сыйфатында фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә.

М.Садри — кырыклап китап авторы, шуларның җидесе рус теленә тәрҗемәдә чыга. Аның иҗат мирасында «Бәхет турында җыр» (1947), «Александр Матросов» (1951), «Көзге күкрәү» (1956), «Кышкы бакча» (1961), «Россия турында җыр» (1962), «Кайту» (1965), «Җыр дәвам итә» (1965), «Туганлык» (1972) кебек дистәләгән күләмле әсәрләр-поэмалар, йөзләрчә лирик һәм публицистик шигырьләр, җырлар, ике йөздән артык очерк, әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләр бар. Аның татар композиторлары тарафыннан көйгә салынган шигырьләре дә байтак. Шагыйрь әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшли. П.Ершовның ул тәрҗемә иткән «Канатлы ат» («Конек-Горбунок») поэма-әкияте берничә басмада дөнья күрә һәм татар балалары арасында киң популярлык казана.

Шагыйрь 1999 елның 27 мартында Казанда вафат була.

# Булат Сөләйманов

*Булат Сөләйманов (1938-1991) – әдәбият мәйданына алтмышынчы еллар башында күтәрелеп чыккан шагыйрьләрдән. Ул – тумышы белән дә, иҗатының җирлеге белән дә чын Себер татары. Шигырьләрендә Себер җиренең, Себер кешеләренең үзенчәлекле сыйфатларын, табигатен шигъри образларда чагылдыра.*

***

**Кояшым, җаем идең син,**
**Киттеңме әллә юри?**
**Кырга ак кәфен теккән дә,**
**Җил үксеп елап йөри.**

**Төн каплаган тәрәзәмне,**
**Җилләргә табына урам.**
**Кайтыр идем, җәйләр ерак**
**Юлларда уйный буран.**

**Агачларда беткән яфрак,**
**Урманнан киткән кошлар.**
**Канаты кайрылган йөрәк**
**Ялгызы ничек кышлар?**

**Синең киткән юлларыңнан**
**Күңелем карлар көри.**
**Кырга ак кәфен теккән дә,**
**Җил үксеп елап йөри...**

## Хатлар

**Бу җилләр хәтернең түреннән,—**
**Үзләре шәп—шәрә, бик арык —**
**Үткәннең сандыгы төбеннән**
**Хатларны чыгарды актарып.**
**Саргайган ул хатлар хәтердә —**
**Күбәләк шикелле дерелди.**
**Син бит ул, нигә соң дәшмисең?**
**Ул көннәр яңадан терелде.**
**Караңгы төндәге яшен күк**
**Ялтырый, югала хәтердә.**
**Һәр юлы — яшьлекнең тарихы:**
**«Булырбыз, булырбыз без бергә!..»**
**Хәтернең өрәге булма син.**
**Кил бире, алыйм мин бер кочып.**

«Сөямен»,— дип язган сүзләрең
Хатлардан киткәннәр шул очып.
И хәтер! Син җәллад түгелсең,
Тоз сипмә ярама син берүк.
Кайтса да яшьлектән ул хатлар,
Безгә бит яшьлеккә кайту юк.

***

Күренәме Себер Казаннан?
Анда карлар, җилләр уйныйдыр.
Ә тайгада болан баласы
Адашкан да ялгыз, елыйдыр.

Хет җилләре хәбәр бирсәче:
Ничәнче көн эзли анасын?
Аерылу авыр кемгә дә,
Тайга киң шул, каян табасың!

Эзләреннән бүре киләдер,
Борылыр да иде кирегә,
Юк, ярамый, алга ыргылды,
Бала чагын калдырып бүрегә.

Шулайдыр ул хәлләр минем дә,
Эзләремне карлар көридер.
Адашкан да, тайга эчендә
Бала чагым елап йөридер.

***

Бер ел үткән киткәнемә,
Әйләнеп кайттым бүген —
Сагынып иркә гөлемне,
Сагынып Себер күген.
Бер ел бит ул кеше өчен
Аз гына гомер түгел.
Ярсып-ярсып тибә йөрәк,
Талпына никтер күңел.
Урман эченнән үтешли
Бормалы юллар буйлап,
Хисләремне уртаклашып,
Наратлар калды шаулап.
Җилләре дә йөгереп килеп
Битемнән үпкән була;
Юлың йомшак булсын дипме,
Ак карлар сипкән була.
Юл читендә куакларым
Ак шәлләр кемгә чиккән?
Каршыма йөгерә авылым,
(Ул да сагынган икән!)

### ГАЯЗ ИСХАКЫЙ ТАВЫШЫ

Казан федераль университеты Тарих институтының татар халкы тарихы кафедрасы мөдире Искәндәр Гыйләҗев Германиянең Һумбольдт университеты каршындагы Тавыш архивыннан Гаяз Исхакыйның дүрт минутлык чыгышын эзләп тапкан. Данлы милләттәшебезнең тавышы яздырылган тасмалар башка бер генә чыганакта да сакланмаган. Гаяз Исхакыйның «Идел-Урал» төбәге турындагы чыгышы тарих сәхифәләрендә тирән эз калдырырлык вакыйга булды.

### ТАТАРСТАН МӨФТИЕ САЙЛАНДЫ

VI чираттан тыш корылтайда ТР мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе вазыйфасына өч кандидат — Камил Сәмигуллин, Харис Салихҗанов һәм Фәрид Сәлман тәкъдим ителде. Президент Рөстәм Миңнеханов катнашында узган җыенда 250дән артык делегат ачык тавыш белән үз җитәкчеләре дип 4 елга Камил Сәмигуллинны сайлады. Ул 1985 елда Мари Иленең Красногорск бистәсендә туган. Дини белемне Махачкалада, Төркиядә алган. Быел РИУ тәмамлый. Илдус Фәизов эшеннән киткәч, ул вакытлыча мөфти вазыйфасын башкарды. Гарәп һәм төрек телләрен белә. Өйләнгән, өч бала әтисе.

### РӘШИТ СӨНӘЕВКӘ ТАТАРСТАН БҮЛӘГЕ

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Россия Фәннәр академиясе академигы һәм Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле академигы Рәшит Сөнәевкә «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары өчен» орденын тапшырды.

Академик Р.Сөнәевкә шушы көннәрдә 70 яшь тулды. Бүгенге теоретик астрофизика һәм космология өлкәләрендәге кайбер зур ачышлар нәкъ менә аның исеме белән бәйле.

«Татар халкының күренекле улын, атаклы галимне кабул итү — Казан һәм Татарстан өчен гаять зур дәрәҗә», — диде Рөстәм Миңнеханов, академикка мөрәҗәгать итеп.

### ТӨРЕК КАРДӘШЛӘР КАЗАНДА

Төркия Республикасының Бөек Милләт Мәҗлесе вице-спикеры Мерал Акшенер җитәкчелегендәге парламент делегациясе эш сәфәре белән Казанда булып китте.

Делегацияне Казан Кремлендә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов кабул итте.

### БЕРЕНЧЕ ИЛЧЕ ЭШКӘ КЕРЕШТЕ

ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев Казакъстан Республикасының Казандагы генераль консулы Әсхәт Нускабай белән очрашты.

Татарстан башкаласында Казакъстанның генераль консуллыгын ачу турында карар узган елда кабул ителгән иде. Аның башлыгы итеп Әсхәт Нускабай билгеләнде. Шушы көннәрдә ул үзенең бурычларын үтәүгә кереште. М.Шәймиев Казакъстан дипломатын яңа вазифага керешүе уңаеннан котлады һәм: «Беренче булу — авыр һәм җаваплы», — дип, аңа уңышлар теләде. Әңгәмә барышында Минтимер Шәймиев һәм генераль консул татар, казакъ телләрен саклау, мәдәният, мәгариф, туризм өлкәләрендә багланышларны киңәйтү буенча фикер алышты.

### БЕЛЬГИЯ МАТБУГАТЫ ТУКАЙ ТУРЫНДА

Бельгиянең Гент шәһәрендә төрек һәм фламанд телләрендә нәшер ителә торган «Яшь фикер» («Genз fikir») газетасында Габдулла Тукайга багышланган мәкалә дөнья күрде. Язманың авторы — төрек теле һәм мәдәнияте укытучысы Морат Узун.

«Г.Тукай — татар дөньясының, кыска вакыт эчендә дөрләп янып, үзеннән соң якты эз калдырган йолдызы. Ул — үз халкының гасырлар буе кичергән моң-зарын, рухи сулышын шигъри юлга салып аңлаткан, аның үткәненә һәм бүгенгесенә тәнкыйть аша караган, милли хисләрен уяткан халык шагыйре, — дип яза автор. — Кыска гына гомере эчендә Г.Тукай халкына бай мирас калдыра. Мәгърифәтнең зур көчкә ия икәнлеген аңлаган шагыйрь халкына да аның әһәмиятен күрсәтергә тырыша. Милләт гаме белән яшәгән Тукай балалар өчен дә шактый әсәрләр иҗат итеп калдыра».

Моннан тыш, мәкаләдә шагыйрьнең тәрҗемәи хәленә дә урын бирелә.

## БАТУЛЛАНЫҢ ГОМЕР БӘЙРӘМЕ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Рабит Батулланың 75 яшьлек юбилее уңаеннан әдәби-музыкаль кичә булды. 1 апрельгә туры килгәнгәме, ул, бәйрәмдарның үз холык-фигыленә дә ярашлы рәвештә, шаян да, җитди дә рухта узды.

Юбилярны Татарстанның халык шагыйре, Дәүләт Советының мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев тәбрикләде. Ул аңа Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин исеменнән парламентның бүләген тапшырды һәм каләмдәшенә багышланган шигырен укыды. Татарстан мәдәният министры урынбасары Ирада Әюпова исә Р.Батулланы «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләү турында Татарстан Президенты Указын укып ирештерде.

Бәйрәмдарны шулай ук каләмдәшләре — Татарстан Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан, Марсель Галиев, Ркаил Зәйдулла, Газинур Морат, Фатих Кутлу, Ләбиб Лерон, галимнәр Фоат Галимуллин, Васил Гарифуллин, актерлар Ринат Таҗетдинов, Наил Дунаев, Равил Шәрәфи, Гөлсем Исәнгулова һ.б. котлады. Әдипнең гомер бәйрәме сәнгать осталары башкаруында җырлар белән үрелеп барды.

Кичәне Батулланың уллары Нурбәк белән Байбулат һәм Айсылу Лерон алып барды.

## БЕР АЙГА ӨЧ КИТАП

Быел Төркиянең Анкара шәһәрендәге «Бәнгү» нәшриятында Фатих бәй Кутлу тәрҗемәсендә татар язучыларының әсәрләре тупланган өч китап дөнья күрергә өлгерде. Алар — Аяз Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» повесте, Рабит Батулланың «Алып батыр маҗаралары» кыйссасы һәм «Сәссыз курай» («Тавышсыз курай») дигән мәҗмуга. Соңгысына хәзерге татар әдәбиятыннан кайбер үрнәкләр, аерым алганда, Рабит Батулланың «Тавышсыз курай», «Хәерче габәш» әкиятләре, Әсгат Сәлахның «Соңгы вальс» повесте, Аяз Гыйләҗевнең «Күлмәк», Марсель Галиевнең «Балачак әсирлегендә», Ркаил Зәйдулланың «Ак эт», Зөлфәт Хәкимнең «Чын ярату», Галимҗан Гыйльмановның «Күнел күзең күрәме», Асия Юнысованың «Бәби мунчасы», Дания Гайнетдинованың «Бәхет яшьләре», Рәмзия Габделхакованың «Китүчеләр», Айгөл Әхмәтгалиеваның «Җиде ят» хикәяләре урын алган.

## САМАРА КУНАК ҖЫЙДЫ

Шушы көннәрдә Самара шәһәренең Спорт сараенда беренче тапкыр «Боз озату» бәйрәме булып үтте. Идел буенда яшәгән татарларның әүвәлге заманнарда кыш бетүе, елгада боз кузгалуы, табигать уянуына бәйле рәвештә уздырылып килгән бәйрәм быел кабат яңартылды. Аны өлкә Хөкүмәте, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты булышлыгы белән Самараның «Дуслык» төбәк иҗади иҗтимагый оешмасы оештырды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Россия парламентчылыгын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм актив төстә законнар иҗат итү эшчәнлеге өчен Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутаты **Сибагатуллин Фатыйх Сәүбән улы** Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлары өчен» IV дәрәҗә ордены белән бүләкләнде.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казандагы Җиңү паркы.

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Әлмәт төбәге язучыларыннан бер төркем.

## Яңа китаплар




**Камиль Аблязов.** Историческая судьба татар. (Татарларның тарихи язмышы) – Саратов: «Научная книга» нәшр., 2012. Тиражы – 3000 данә.

Китапта татар халкының борынгы заманнардан башлап Екатерина IIгә каләрге тарихы тикшерелә. Татарларның Рәсәй дәүләте белән мөнәсәбәтләре аеруча җентекләп тасвирлана. Автор – күренекле җәмәгать эшлеклесе, тарих фәннәре кандидаты.

Китапның беренче томы «Национальная история: этнос, нация и цивилизация», «Татарский народ и его предки», «Средневековые татары», «Татары на пороге нового времени» дигән бүлекләрдән тора.

Икенче томда «Век реформ: становление татарской нации», «Возрождение государственности», «Татары в Советском Союзе: советский тип модернизации», «Суверенный Татарстан и возрождение нации» дигән бүлекләр бирелгән.



**КАЗАН УТЛАРЫ**
**QAZAN UTLARI**
**ОГНИ КАЗАНИ**

**Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал (на татарском языке)**